# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Үз хәлеңне җитә чамалау... *Шигырьләр.* ....3
Марат ӘМИРХАНОВ. Ататуш. *Бәян.* ....8
Рафис КОРБАН. Казан. *Поэма.* ....35
Рәфкать ШАҺИЕВ. Гайшә-Фатыйма. *Повесть.* ....48
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Сугыш кырларыннан мин кайтсам?.. *Шигырьләр.* ....101
Вәрис ГАЛИ. Соңгы сәфәр. *Бәян.* ....105
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Үз балаңа мирас итеп калдыр телең... *Шигырьләр.* ....132
Гөлнара САБИРОВА. Мин аклык эзлимен җиһаннан... *Шигырьләр.* ....142

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Зәбир ГЫЙМАЕВ. Көрәшче. *Хикәя.* ....136

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Николай ЛУГИНОВ. Һуннар бәяны *(Фирүзә Җамалетдинова тәрҗемәсендә).* ....145

ХӘТЕР

Рүзәл ЮСУПОВ. Бакчачы, галим һәм язучы *(Фарсель Зыятдиновның тууына 85 ел).* ....167

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар тарихыннан энҗе эзләүче галимә. ....173

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Казан ханлыгында ислам дине. ....180

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Могҗиза тудырган әдип *(Бари Рәхмәтнең тууына – 125 ел).* ....188
Рухы белән ул көрәшче иде *(Әмир Мәхмүдовның тууына – 75 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

*Фотоархив:* Юбилей мизгелләре. ....178
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 6 (1196) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.05.2022, график буенча 27.05.2022, басылып чыгу вакыты 01.06.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1552. Тираж 7796.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Фәнил
Гыйләҗев

# ҮЗ ХӘЛЕҢНЕ ҖИТӘ ЧАМАЛАУ...

## Янсын

*«Казан утлары» журналының
олуг юбилеен котлап*

Нинди генә җәүһәр булсалар да,
Булсалар да кырлы эре алмаз,
Чордан-чорга күчеп, утлар кичкән
Сүзләр телсезләргә ирешалмас.

Милләтемнең үксезлегеннән дә
Яманрак сукбайлыгы телнең.
Татар белән татар үз телендә
Аңлашмаса – аңлашыр соң кемем?

Утлар, сулар кичкән кодрәтле сүз
Исән әле, безнең белән телдә.
Сүз коела каләм очларыннан
Ак кәгазьгә, булып җөмлә-җөмлә.

Җөмләләрдән туа фикер, сурәт,
Җырлар туа – әдәбият туа.
Үткәннәре шанлы, зарлы, гарьле...
Киләчәге – шомлы, әрним шуңа.

Сөрем аша, куе томан аша
Абайламак булам өметемне.
Казанымда хисси утлар балкый,
Шигъри утлар! Димәк, өмет тере!

Янсын ла ул балкып, юл күрсәтеп,
Яктыртсын ла юлын милләтемнең.
«Казан утлары»ның якты нуры –
Илһам тулы саф әдәби телем!

---

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ (1987) *– шагыйрь; «Ризасызлык», «Кирмән нигезе» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Иң әүвәле

Милләт өчен көрәшергә була
Мөнбәрләрдән, трибуналардан.
Тик ни файда милли тәрбияңне
Бирәлмәгәч кыз һәм улларга.
«Милләт» диеп күпләр лаф оралар,
Төкерек чәчеп, ертып бугазны.
Үз өендә ләкин милләтчеме
Ким дигәндә берсе шуларның?!
Сөйләшәбез уллар-кызлар белән
Һәм оныклар белән кай телдә?
Мәйдан тоткан байтак шәхесләрнең
Гамәлләре ил-көн күзендә...
Милләт исеменнән сөйләү җиңел,
Авыз чайкап була милләт дип.
Баласына үз телеңдә дәшеп
Аңлашучылар соң сирәк ник?
Дәүләт гаепләме бу гамәлгә?
Әллә үзебезме? Белмәссең...
Милләттәшен үгетләүчеләрнең
Үз дәвамы, йәгез, кемнәр соң?
Милләттәшне үзең үрнәк булсаң –
Нәсыйхәтләү җиңел, хактан да!
Милләтчеме соң мин дигән сорау
Җанны талкый әле һаман да...
Үз милләтең юкса, үз дәүләтең –
Үзең корган гаиләң нәүбәттә!
Милләтебез саумы? Сәламәтме?
Милләтебез нинди халәттә?
Шул сорауга җавап бирим дисәң –
Үз хәлеңне җитә чамалау.
Иң әүвәле, үз хәлеңнән чыгып,
Күрү мөһим житди чаралар!

## Яз көтү

Бездә яз. Кырларда ямь-яшел
Уҗымнар, чирәмнәр шәйләнә.
Озаклап көттермәс, бик тиздән
Керербез чәчәкле җәйгә дә.

Яшәеш тукталмас – сау булсак,
Сау булса саннар да, җаннар да.
Үч, нәфрәт, дошманлык урынына
Сөю һәм мәрхәмәт каннарда.

Кайнаса аңыңны сугарып, –
Һай, рәхәт дөньяда яшәве.
Тик читен хурланып, ут йотып,
Теш кысып, берни дә дәшмәвең.

Кыйланып, кыйналып яшәвең
Яшәүме? Яшьнәүме? Хөрлекме?
Әпипә көенә биюләр
Миллилек, ирекме, ирлекме?

Яшәве соранып, теләнеп,
Намусың, гамеңне үтереп,
Вөҗдансыз, гамьсезгә әйләнеп,
Хак биргән хокукың үтенеп?

Яз килә бернигә карамый,
Берни дә сорамый, алмый да...
Ямь-яшел бөреләр ачыла,
Кышларның үтүен аңлый да...

Бар җиһан яшәрә, уйламый
Боз явар йә кырау төшәр дип.
Кояш гел елмаймас, бер заман
Җәй узар, кышлар да җитәр дип.

Минем дә өметем бөресе
Яз көтә, килер ул – кыш чыкса.
...Һай, озын, йончыткыч икән кыш,
Ватаның хөрлеккә ачыкса.

## Сары халык

Ахыр заман якынайгач, имеш,
Дөнья йөзен сары халык басар.
Ахыр заман килеп җитте, ахры,
Сарыдан да сары хәзер татар...

Сары сагышлардан саргаябыз,
Сарылыктан кан вә сару кайный.
Күпләребез заман сөременнән
Агуланган, һаман айный алмый.

Төтәләбез һаман, ысланабыз,
Җанга сеңә төтен булып ялган.
Саргаябыз шулай, сары халык
Ул үзебез бугай – шунысы яман.

Сары сагыш алган якабыздан –
Ахыр заман шушы түгелме соң?
Җанда әле һаман хөр вә садә,
Керләнмәгән ихлас күңелме соң?

Сур быргысын өрер чагы әле
Әюп пәйгамбәрнең җитмәгәнме?
Биш йөз елдан артык саргаюдан
Дөнья безне сары итмәгәнме?

«Кыямәт көн җиткәч, Дәҗҗал туар,
Җирне Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ басар», диләр...
Сары сагыш Адәм балаларын
Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ итә, аһ, белмиләр!

Лампа-шешәләрдән чыгасы җен
Иректә ич бүген – шешә ачык.
«Нәрсә булыр бу дөньясы белән?» –
Дип торабыз тешсез авыз ачып.

Башны кашып, нидер уйланабыз,
Акыл җитми ләкин уй очына.
Күңел бәргәләнә, ярсый, даулый,
Сүрелә һәм кабат бер очына.

Күңел ярашалмый мантыйк белән,
Бәхәсләшә һаман, эзли хаклык.
Биш йөз елда ниләр җуйдык – мәгълүм,
Ни сакладык – мөһим! Ниләр таптык?!

Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ ул – үзебез, ахры,
Дәҗҗалы да – без сайлаган язмыш.
Үз Мәһдиен көтә милләтебез,
Заман азагына кереп барыш!

Аһ, бер үлеп, туа алсак иде,
Җитсә иде хөрлек тулы заман,
Төзәтелеп, ата хаталары!*
Мәгърифәтле, яңа аналардан

Тумый торып яңа саф гакыллы,
Коллык йөгәненнән азат затлар –
Үз бәхетен мәңге таба алмас
Саргаюдан тәм табучы татар!

## Хакыйкать бер

Мең каһәрле, мең газаплы – сугыш.
Сугыш – үлем, сугыш – кеше суеш.
Ничек диеп кенә аталмасын,
Үзгәртмәс ул мәгънә атамасын.
Акны – ак дип, хакны – хак дип әйтү
Тыелса да, кара – ак булалмас.
Җинаятьне – изге гамәл диеп
Атап кына, ялган – хак булалмас.
Без – капчыкта ятмас, хакыйкатьне
Күпме яшерергә тырышсаң да.
Хакыйкать – бер: җан калдырыр тәнне, –
Бер азакка дучар – кол да, хан да.

* С.Рәмиевнең «Таң вакыты» шигыренә ишарә.

Гамәленә карап кол да, хан да
Үз әҗерен йә җәзасын алыр.
Үзен Алла диеп уйлаучылар
Ахыр чиктә хаксызлыгын таныр.

Тик тәүбәгә генә соңга калыр...

## Аяныч

Шартлаган боралак, очкычлар;
Чәрдәкле, төтәлгән язмышлар...
Җан кыеп, кан коеп йөргәннең
Башына төшәсе каргыш бар!..

Җаннары өзелгән җәсәдләр
Ауныйлар котсызлап җир өстен...
Шулармы шәһидләр? Шулармы
Каһарман, батырлар? Кем белсен...

Өзелгән аягы, куллары,
Чәчәктәй гомере өзелгән…
Берәүнең газизе булган ул –
Нур качкан дәһшәтле йөзеннән...

Шартлаган боралак, очкычлар,
Танклар көлендә – мәетләр...
Кемнеңдер бердәнбер газизен
Кемнәрдер каһәрләр, гаепләр...

Җәсәден таныйрлык чара да
Калмаган – шыр сөяк, юк ите.
Әҗәлен тапкан ул... (аяныч!) –
Дан-шөһрәт артыннан юл китеп;

Күкләрдә кайгы күк кабарган
Болытлар агыза күз яшен –
Җеназа госеле изрәтә
Тетелгән, гөнаһлы гаурәтен...

Кемнеңдер өмете иде ул,
Бәхете иде ул, сөйгәне!
...Ә бүген аңарга кәфенлек
Кидерә чит туфрак тилгәне.

## Икар сыңары

Милләт намусына пакьлек юрап,
Шигъри канатларда югары
Очыйм дисәң – милләттәшең дәшә:
«Җүләрләнмә, Икар сыңары!»

Җүләрләнмә, диеп, чабуыңнан
Җибәрмичә, тартып торырлар,
Кирәк булса, якадан ук алып,
Муеныңны тотып борырлар.

Әллә шигъри канат көймәсенгә,
Әллә инде сәбәп башкада.
«Җүләр» шигырь йә басылмый ята,
Яки аннан күз йә каш кала.

Ертык колак, җимрек борын кала,
Ул, әйтерсең, сугыш корбаны.
Яз син, диләр, ыбыр-чыбырыңны,
Тел-теш тидереп булмый торганны!

Вөҗдан аклап язган шигырь түгел,
Юк-бар юмор кирәк халыкка,
Уен-көлке, ирония кирәк,
Җим кирәккән сыман тавыкка.

Уйланасы, уянасы түгел,
Баш ватасы түгел исәбе.
Бар да сайлый күңел ачу юлын,
Син, дип, юләр шагыйрь кисәге.

Шигырь канатларың кояш өтмәс,
Канат очың шундук кисәрләр
Милләттәшең булган, пакь намустан
Коты чыккан мәнсез кемсәләр.

Милләт намусына пакьлек юрап,
Тик шигырьләр язам нибары.
«Каурыеңны көйдерерсең, диләр, –
Җүләрләнмә, Икар сыңары!»

## Шигъри мәкалә

Җанны талкый уйлар өермәсе.
Ничәнче кат, ничә мәртәбә
Шигырь язмак булып утырам да
Язып куям шигъри мәкалә.
Шигырем шул диеп кабул итәм.
Ургып чыга борчу, уйларым.
Менә кабат шигырь язмак булып,
Публицистик нотык сырладым.
Укыганда булгалады шулай,
Бирем, күнекмәләр үтәгән,
Имтиханны шигырьләтә язып,
Билгем «отлично»га күтәргән.
Рифмаларга салып сүзләремне,
Хатлар язган булды кызларга.
Ул чакларны искә алган чакта
Күңел скрипкасы сызлана,
Күзләрдә ут уйный, җанда курай...
Үсмерлекнең садә чакларын
Яңабаштан кичергәндәй булам –
Иярлим дә хыял чаптарым.
Шигыремдә янар, көяр идем,
Сөйләр идем сөю хисемне.
Ничә кабат утта төтәдем һәм
Өметләрем күпме киселде.
Ә бүген бар язганнарым юмор,
Көнкүрешем, тормыш хакында.
Бер чибәргә шигырь багышланса,
Ул – хыянәт төсле хатынга.
Җанны талкый хистән өстен уйлар,
Йөрәк – тоткын, уйлы ятьмәдә.
Әллә шуңа микән язганнарым
Шигырь түгел, шигъри мәкалә.

## Татарстан – кече Ватаным

Татарстан – кече Ватаным син,
Зур Ватаным минем – Дәште Кыпчак.
Хан-солтаннар бездә гаскәр-гаскәр,
Ил нужасы хәтсез, кочак-кочак.

Ватанымны йөрәгемдә йөртәм.
Анда сорнай уйный, дөрли учак,
Әләмнәре – буй җитмәслек биек,
Адәмнәре – баш бирмәстәй, уйчан.

Татарстан – кече Ватаным син.
Зур Ватаным – чиксез татар иле.
Хыялымда – тау силләре ургый,
Дуңгәләкләр куа дала җиле.

Ватанымны күңелемдә саклыйм,
Юк үзәге аның һәм юк чиге.
Кай төшенә бассам – шунда мәркәз,
Һәр мәхлукка җитеш сые-җиме.

Татарстан – кече Ватаным син,
Ачуланма, офыкларың чикле!
Зур Ватаным – татар җиһаныдыр,
Хөррияте – галәмнәргә тикле!



Марат
Әмирханов

# АТАТУШ

БӘЯН

Яңа ай дугалы туса, давыл булыр, дигән гыйбарә бар. Бүген дә ай дугалы булып күренде. Ләкин аңа карап, җил-гарасат чыкмады. Күрәсең, әлеге фаразның шарты килеп җитмәгәндер. Әнә җиһан, берни булмагандай, тымызык хозурлыкта сафа сөрә. Кырлач көрте эченнән борын төрткән коры кураны селкетерлек тә җил исми.

Җил-гарасатсыз, дугалы айлы, сыек шәүләле төн.

Шушы дәфгы табигый төн уртасында авылны сискәндереп, нәкъ сәвит Шәкүрә өе янында гына инде көндәлек кулланылыштан төшеп баручы сугыш чоры өндәмәләре яңгырады:

– За Родину, за Сталина!

– Смерть фашистам!

– Ур-р-а-а!

Шәкүрә кабалана-кабалана, җилкәсенә сырмасын гына элде дә, күзен ертып, урамга чыкты.

Анда агач мылтыгын иңенә салган бер кемсә марш атлап, ике адымның берсендә, тигез ритм белән чират-чират әлеге өндәмәләрне сибә иде. Ара-тирә җыр да кыстыргалый.

Айт-два, айт-два,
Мылтык асып, кылыч тагып,
Дошманнарга каршы китте
Комсомолка Гөлсара.

Ул арада таягына таянып, фронтовик Вәсим дә килеп җитте.

– Што за шум, драки нет, – диде авызын ерып, – хакимият ни карый?

– Бу хулиганның кем икәнен ачыклыйм да иртән кәнсәләриягә чакыртам мин аны, – диде Шәкүрә, күзләрен чекерәйтеп, – безабразие, панимаешь...

---

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) – *прозаик; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ф.Хөсни, Г.Афзал исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «И кылган догам минем», «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Ир-Мамай» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Нәрсәсен ачыклыйсың, Ататуш бу, фронт хәлләре исенә төшкән, күрәсең...
– Әле соң, ипле генә йөри иде бит.
– Контузия, – диде Вәсим, – бик күп фронтовикларның җәфасы ул контузия, иптәш персидәтел...
Аннан көрсенеп куйды да өстәде:
– Фронтта хет тамак тук иде...
Шәкүрә аны ишетмәдеме, ишетмәмешкә генә салындымы, үзенекен тукыды:
– Шул тилене өенә кертеп куй әле, пажалсты, адәм ыстрамы бит, – диде. – Район алдында миңа җавап тотасы.
– Мин титаккамы соң кеше куып тоту, – диде Вәсим, – башлыкны тыңламады.
Ә авыл өстендә һаман сугыш чорының тылсымлы вә ашкынулы өндәмәләре яңгырый иде:
– За Родину, за Сталина!
– Ур-р-а-а!..
Ататушның мулла кушкан исеме Хөббетдин. Тик аңа инәсе Бәдриҗамалдан кала берәүнең дә тулы исеме белән эндәшкәне юк иде. Авылда – Хөбби, фронтта – Харитон.
Ул 1941 елда Суслонгер дигән коточкыч фаҗигале лагерьда беткә батып, ике-өч ай җәфа чиккәннән соң, Мәскәү янындагы сугыш казанына барып эләкте. Күпләр шунда ятып та калды. Ә ул, Алланың рәхмәте, исән калды. Алай гынамы, дүрт ел орыш эчендә кайнап, энә очы кадәр дә җәрәхәт алмады, дошман ядрәләре аны ничектер урап уза иде. Иптәшләре дә:
– Бу Гиннесс китабына лаек гайре табигый факт, командир, син музей экспонаты булачаксың, – дип шаярталар иде.
Үзенең дә борыны чөйдә.
– Ә кәк же, шушындый күкрәге тулы орден-медаль кавалерының кануни урыны Сугышчан дан музеенда булмый, кайда булсын?
Тик язмаган икән. Сугыш бетәргә нәкъ бер атна кала, моңарчы кайдадыр посып яткан үз ядрәсе барыбер эзләп тапты, каһәр.
Юк, ул аңа тимәде, корбанын эзәрлекләгән ач карчыга кебек җилләнеп очып килде дә, бөтереп алып, күккә генә чөйде. Хәтта җирне ярып шартлаган тавышын да ишетергә өлгермәде.
Һәм дөм караңгы кабер тынлыгы. Аңына да атна-ун көннән соң гына килде. Килде, әйе, ә хәтере җуелган иде: кем ул, кайда ул, ник аяк-куллары бәйле – уянуга һәр яралының башын бораулаучы әлеге гадәти уйлар да күңелен кузгатмады. Хак, калган-сынган күңел – чыккан җан шул. Бүрәнәдәй сузылып яткан, боздай каткан тонык күзләр, төссез вә сөмсез төмсә чырай...
– Бернәрсәдә гаме юк, ай-һай, озакка тарта алмас бу, – дип, шиген белдерде табиб, – бәйдән ычкындырыгыз, тибенергә хәле калмаган инде аның.
Хак Тәгалә Хөббетдин колының фани гомерен кисәргә ашыкмады. Кыр госпиталендә өч айлап ятканнан соң, аны Мәскәүнең округ хәрби хастаханәсенә күчерделәр. Мондагы табибларның мөмкинлеге бөтенләй

башка иде, әлбәттә. Ярты елда азмы-күпме үзен-үзе карарлык хәлгә китерделәр. Аңы да ачыла төште, теле кайтты. Аннан консилиум, бу психик авыруны хастаханәдә тотуның хаҗәте юк, иң мәгъкуле, туган җиренә озатып кую, дигән карарга килде.

Озатып килүче медбрат чүмәләдәй йомры гәүдәле, тел бистәсе шаяншук бер Касыйм мишәре иде.

– Абзәби, акыл тышау, кылык ат, дип атәләр безләрдә, принимать итеп ал якташыгыз Актуш батырны, – дип, пациентын авыл советы рәисе алдына китереп бастырды, – цәц еланыдай хватлы, ашауга талымсыз, кесе заптрыклар ашап тормай, картуф беләң дә тора ала, самое главное, танавы зур, тол солдаткаларыгызга күп ләззәт китерәчәк әле ул шельма...

Шәкүрә, гадәтенчә, бүсенке аскы иренен чыпылдатып, бу озын һәм мәгънәсез вәсвәсәне ярты юлда бүлеп:

– Иптәш вәкил, сез дөрес килмәгәнсез, бу кемсә безнең авылныкы түгел, – диде.

Вәкил киртәдән чыккан бәбәкләрен акайтып, рәискә текәлде.

– Как-так, сезнең авылныкы түгел?

– Беренчедән, Безнең Күҗәкә авылында Ататуш исемле кешенең бервакытта да булганы юк, – диде Шәкүрә, кыска юантык бармакларын бөгә-бөгә. – Икенчедән, Фәхрелисламов Хөббетдин каен күмередәй капкара чәчле, ыспай сакал-мыеклы алдынгы колхозчы иде. Ә бу?

Кәнсәләрдәгеләр ниндидер ваемсыз кыяфәттә читтәрәк кенә басып торган кемсәне янә бер кат күз уңыннан үткәрделәр.

Аның тавык күкәедәй шоп-шома йөзендә бөртек тә сакал-мыегы юк иде. Үзе җиңел сөякле булырга охшаган, Хөббетдин дә ут борчасыдай хәрәкәтчән кеше иде анысы.

– Исемең ничек? – дип сорадылар.

Тегесе вак тешләрен күрсәтеп елмайды да:

– Ататуш, – диде.

– Бу мин шаяртып кушкан исем генә, ул бит контузия алган сугышчы, орден-медальләре дә бар, башы китү генә бер хәл, снаряд җиле аның бөтен килеш-килбәтен, төс-кыяфәтен үзгәрткән, – диде вәкил, җитди кыяфәткә кереп, – менә документлары, анда барысы да теркәлгән. Закон буенча аңа караучы тиеш. Ул вазифаны хатынына тапшырсагыз, үзегезгә уңайлырак булыр.

– Хөббетдиннең хатыны Мәликә бизгәк чиреннән үлеп китте шул, – дип кайтып төште Шәкүрә, документларга күз төшереп алганнан соң. – Кайгырмагыз, җаен табарбыз.

Кендек каны тамган туган җир нинди халәттә дә үз баласын читкә типми. Туган җирнең илаһи шифасы инсанның кальбенә, сулышы вә йөрәк тибешенә ана карынында ук мәңгелеккә сеңеп, зарури хаҗәте чыгуга ләйсән яңгыр кебек йөзен ача.

Хак, туган җирнең ялкыны да, дулкыны да җанга ягымлы. Ул Ататушны да үз агымына тартып кертте.Тамчылап-тамчылап кына булса да, аңы кайта башлады: кешеләрне таный, ара-тирә адашмыйча күрше авылларга да барыштырып кайткалый, авыл советы билгеләгән караучы корткадан да баш тартты. Үз чиратында, авылдашлары да аның яңа ай туган вакытларда саташкалап алуларына инде күнегеп баралар.

Тик болар әле барыбер, Мәнди анасы әйтмешли, башым да күзем, аягым да үзем генә.

Беркөнне аның янына, комган күтәреп, күрше малае Сәүбән килеп керде.

– Уртанчы улга ук та юк, чурт та юк, ди, әйдә-әйдә, уз бәгырь, – дип каршы алды хуҗа.

Малай, күл камышыдай нечкә төз муенын чайкап алды да вәкарь белән генә:

– Мин баш бала, – диде. – Былтыр тырмага йөрдем, быел бригадир сабан дип тора, миңа бит инде ун яшь тулды.

– Алай икән, – диде Ататуш елмаюлы кыяфәттә, – тишек комган күтәреп йөргән баш балага сабан тоттырырлармы – вәйт нидә мәсьәлә?

– Тоттырырлар, – диде Сәүбән эре генә, – бригадир Мәрьям апа сүзендә тора ул, ә менә комганның борыны сынып төшкән, шуны урынына утыртасы иде, бу әнкәйнең үтенече.

– И бәгырь, гыйлем генералдан өстен, ди, андый һөнәрем юк шул минем, – диде Ататуш, күзләрен челт-челт йомгалап, – бигайбә.

– Инструментларың бар бугай бит, – диде малай.

– Бар монда ниндидер кораллар, кемнекедер, белмим, тотып та караганым юк, – дип, җилкәләрен сикерткәләп алды Ататуш.

– Әнкәй сине элек алка-беләзекләргә кадәр коеп кына куя иде, – ди.

– Хәтерләмим, бәгырь, исемдә юк.

– Тәвәккәлләп кара, аның өчен сине асып куймыйлар ла.

Тәвәккәлләде. Ходайның рәхмәте, куллары ятып тора түгелме соң? Әнә ничек җаен алалар. Димәк ки, бу малай дөрес сукалый.

Чыннан да, куллары үзләреннән-үзләре комганның борынын урынына утыртып та куйды.

– Син Микулайлардан да уздырасың икән бит! – дип, тел шартлатты Сәүбән, – әлегә түләргә рәт юк, әнкәй дә көтәргә сөйләш, диде.

Ататушның малайда гаме юк иде инде, үз күзләренә үзе ышанмыйча торataштай каткан. Гаҗәп бит, валлаһи. Кул тотынса, эш карышмый, диюләре хак икән.

– Бәгырь, син әүлияләр затыннан булсаң кирәк, – диде, Сәүбәнгә комганын тоттырып. – Һөнәрле иттең бит, рәхмәт, шулай аралашып торыйк.

Сәүбән китеп, озак та үтмәде, аның ишеген Нәнекәй кортка ачып керде.

– Менә, Хөббетдин, кайчан түтәкәенең хәлен белешергә килер икән дип көттем-көттем дә, күзгә-башка күренмәгәч, таягыма таянып, үзем килеп җиттем әле, – диде. – Мин, әнәтерәк, бабаң Фәхрелислам солдатның сеңлесе, якын кардәшең, бәләкәй чакта бездә аунап үскән идегез бит, рәхмәт төшкере...

Ататуш, колагына тычкан оялагандай, карчыкның сүзләрен тыныч кына үткәреп җибәрде.

Сугыштан миңгерәүләнеп кайткан икән диюләре тач хак икән, дип сызланып куйды тегесе, тач хатынҗәмәй, ир-атның акылы да, дәрәҗәсе дә сакал-мыегында бит ул.

– Түтәкәй, ни хаҗәтең чыкты, тыңлыйм, – диде йорт хуҗасы, көлемсерәп. – Шикәрем булса, чәй эчерер идем дә, күмәчем юк.

– Рәхмәт яхшы ниятеңә, эчемнең бер буш урыны да юк, әнәтерәк, табыннан торып кына килдем, – дип алдады кортка, – килдем, күрдем,

шөкер, күңелем булды, үзең дә килгәлә, исеңдәдер, өем түбән очта, Таҗи буасы янында гына, ялан җирдә ялгыз гына яшәп ятам, әнәтерәк...

– Төенчекле кешенең йомышы да була ич инде, синеке дә бардыр, – дип, үзенекен тукыды Ататуш, – оялма, әйт.

Нәнекәй өстәл өстендәге эш коралларын күз очыннан үткәрде дә:

– Йомыш дип, Хөббетдин, бар инде ул йомыш, – диде төенчеген чишә-чишә. – Менә бу чулпыларымны бик тагып йөрер идем дә, чылбыры бушаган, төшереп калдырырмын, дип куркам. Фәхерелислам агаемның төсе бит ул, ундүртенче елгы Герман сугышына киткәндә бүләк иткән иде. Урап кына кайтмады, наныкаем, урыны оҗмахта булсын, бик тә игелекле абзыкаем иде...

Ататуш чулпыларны уч төбендә әйләндергәләп торды да:

– Бигайбә, әбекәем, сугыш минем хәтер җебемне өзгән, син сөйләгәннәрнең берсе дә миңа таныш түгел. Йомышыңа килгәндә, иртәдән калган эш – киртәдән качкан мал, ди, син менә монда мендәргә таянып тор, мин аны хәзер рәткә китерәм.

Авылда колак хәбәре чыбыксыз телефон белән бер бит ул, ә дигәнче, урам-тыкрыкларны әйләнеп чыга. Кичке якта Ататушка йомышчылар агыла иде инде. Берсенең чүлмәге су тотмый башлаган, икенчесенең чиләге яньчелеп, тоткасы төшкән, ни гаҗәп, самавырларын эретүчеләр дә шактый икән.

Ататуш башы-аягы белән эш дигән колачлы дәрьяга чумды. Берсе китәргә өлгерми, икенчесе капка кага. Араларында хәтта бер-ике күкәй, ике-өч бәрәңге калдырып китүчеләре дә очраштыргалый. Күпчелек исә, күрше малае Сәүбән кебек «күтәргә» дип килешүне мәгъкуль күрә. Үзе моңа җилкәсен генә сикертә, чөнки авылдашларының үтенечен ул әҗер бәрабәренә башкармый. Шөкер, аңа көн саен ярты литр сөт бирәләр, ике йөз грамм исәбеннән атна саен онга боерык язалар. Аш-суга талымлылыгы юк, шул җитә.

Иң мөһиме, бу игелекле шөгыль аны рухи баткаклыктан суырып алды, тормышы төбе-тамырыннан үзгәрде, ямьләнде, тулышты, зәнбүрәк ташыдай җилкәсен басып торган эч пошыргыч дуамал саташулы уйлары да сирәгәйде.

Шуңа күрә йомышчыларының ни өчен һаман «күтәргә» дип тәкрарлауларын сүз уйнату, шаярту дип кабул итә иде.

Чынында авыл искиткеч хәвефле фаҗига кичерә иде. Бу фаҗиганең исем-аты – фәкыйрьлек. Дөрес, ярлылык, мохтаҗлык, җитмәүчелек кичерүчеләр элек-электән булган. Аларга ярдәм кулы сузганнар, булышканнар, ачлык базына тәгәрәргә юл куймаганнар.

Күҗәкә дә тирә-юньдә иң тотрыклы, иң җитешле авыллардан санала иде. Колхоз ныклы, халык эшчән вә булдыклы. 1939 елда, мәсәлән, бер хезмәт көненә унике килограмм исәбеннән ашлык бүлеп бирделәр. Келәт-бура, абзар-кура, хәтта базлар да арыш-бодай белән тулды. Гомер булмаганны, ялгыш кына уалган ипи валчыгын да киртә белән әйләндереп алган сакчыл вә ихтирамлы җир хуҗасы токымы вәкилләре ашлыктан баш тарта башлады, китерелгәнен капка төпләренә, аяк астына бушатып китәләр иде.

Шунлыктан Күҗәкә халкы сугышка өч-дүрт еллык мая белән керде. Бер мең дә дүрт йөз унсигез көнгә сузылган сугыш чорында да башка җирләрдәге

кебек табыннардан ипи югалмады. Капка башыннан дәүләт салымында тәгаенләнгән 300 литр сөтне, 100 йомырка, 36 пот бәрәңге, 40 килограмм ит, 2 кило сарык йонын артык көчәнмичә, вакытында тапшырып бардылар.

Мәхшәр каһәрле заёмнан башланды. Заём – ул акчалата түләү, халыкның исә кесәсе такыр. Аңа әле ябышкактай танк, самолёт төзү өчен акча лотереялары, мәҗбүри страхованиеләр дә өстәлде. Китте талаш-кычкырыш, янау-әрләшү, күз яшьләре...

Еласаң – ела, көлсәң – көл, беркөнне чираттагы чакыруга җитмеш ике яшьлек Нәнекәй кортка кәнсәләргә кәҗәсен җитәкләп килде.

– Кәҗәмнең сөте болак, эче ылак, тиресе кап, мөгезе сап, – дип сөйләнә-сөйләнә, бүлмәгә үк алып керде.

Өстәл янындагыларның күзләре шар булды. Хәтта Шәкүрә булып Шәкүрә дә иренен бүлтәйтеп, аңышмыйчарак торды. Аннан:

– Кортка, ни пычагыма монда бу кәҗә?! – дип, өстәлгә китереп сукты.

Нәнекәй балчык җамыяктай кечерәеп калган йөзен какча учы белән сыпыргалап куйды да мут кына елмаеп:

– Чү, Шәкүрә, куй кытлыгы вакытында кәҗәгә Габдрахман җизнә, диләр иде, – диде.

– Акыл сатма, заёмыңа акча алып килдеңме? – дип сөрән салды рәис, – Селке кесәңне!

Карчык шундый ук астыртынлык белән такмаклый-такмаклый, бишмәтенең буш кесәсен селкеп күрсәтте.

Чабатаны киябез без,
Булмаганга аякка.
Акча дигәнне күрмибез,
Без эшлибез таякка.

– Аһ, әле син шулаймы, кәҗәңне алып калырга да күп сорамабыз, – диде Шәкүрә, – бу бит, панимаешь, колхоз строена яла ягу.

– Менә бу сүзләрең өчен мең рәхмәт Шәкүрәкәем, үзем дә шул ният белән алып килдем дә инде ул мур кыргырын, – дип, Нәнекәй кәҗәсенең муенчак җебен урындык башына элде. – Кичә Бишбүкән базарына да алып барган идем, әнәтерәк, гөнаһ шомлыгына, ия генә табылмады. Шуңа күрә заёмга үзен алып килдем менә. Миннән фыруntка шул булыр бүләк, иптәш Ыст...

Район вәкиле, сугыштан бер аягын өздереп кайтып, әле күптән түгел генә салым агенты вазифасына керешкән фронтовик, тәкә-мекә чама хисен югалткан тел бистәсе карчыкны сүз бәласеннән коткару ниятеннән булса кирәк:

– Әбисе, фронт синең кәҗәң көненә калмаган, – дип, аның хәвефле җөмләсен кисте. – Кош-кортсыз тормыйсың булыр, күкәйләрен җый, аларга ия табылмый калмас, заёмга җитәрлек сатарсың, шәт.

Нәнекәйнең исә үз туксаны туксан, күз очлары белән генә көлемсерәп, агентка карап алды да янә такмагын текелдәде:

Кыш салдым күкәй,
Яз салдым күкәй,
Тутыралмыйм нурмымны,
Үпкәләмә, түтәй.

Кәҗәкәй дә үзенә игътибар итүләрен теләде, күрәсең, аваз саласы итте:

– Мәә-әә-әә-әә...

– Җә-җә, мәәлдәмә, сиңа монда да ия юк, – дип сукранды карчык, – әнә нәчәлник кош-корт асрарга куша, ипле кешенең сүзе дә ипле, безнекеләр сыман җикеренми. Әйдә, булмаса, кайтаек.

– Мәә-әә-әә-әә...

– Фу, бүлмәне сасыттыгыз, – дип, борынын җыерды Шәкүрә. – Ярар, миннән булсын яхшылык, син эшкә яраклы кеше түгел, заёмнан азат итәм.

Нәнекәй күгәрчен башы кадәрле генә йодрыгын йомарлап:

– Нибуч, мине кеше рәтеннән чыгарып ташларга пырауаң юк! – дип, Шәкүрәгә төкерекләрен чәчте. – Фырунт ул барыбызныкы да, заём өчен менә ыруыбыз мирасы – алтын балдагымны калдырам, кая, бир дүкәмитеңне, кулымны куям.

* * *

Ататушның үз хәл-халәте: җамый, турайта, төзәтә, кисә, ялгый... Бу аңа әйтеп бетергесез шатлык-куаныч, канәгатьлек китерә. Шушы юлны ачкан күрше малае Сәүбәнгә бик рәхмәтле. Алар бик якынлашып киттеләр.

– Күрше, исемең җисемеңә туры килми, – диде малай беркөнне.

– Ихтималдан ихтыяр, ни-нәрсәсе туры килми?

– Үзең беләсең, мин китап укырга яратам, – диде Сәүбән, – мәктәп китапханәсендәгеләрне дә, уку йортындагыларны да укып бетердем. Иң ошаганы – Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» китабы. Менә кем кебек булырга кирәк! Ленин томнарына тотынырга ниятләгән идем дә, бераз үс әле, диделәр...

– Балта урынына шөшле тоттырма әле, бәгырь, – дип бүлде аны Ататуш, – салулап киттең бит.

– Беләм-беләм, болары белешмә өчен генә, – диде Сәүбән. – Беләсеңме, Ататуш нинди мәгънәне аңлата?

Малай башын чөя төшеп, әңгәмәдәшенә бәсәреп бакты.

– Ататуш Ататуш инде, тагын нинди мәгънә? – дип, тегесе кулындагы чүкечен уйнаткалап алды.

– Ататуш Касыйм мишәрләре сүзе икән, тиле, тинтәк мәгънәсендә йөри, – диде Сәүбән бармакларын бөгә-бөгә. – Ә мин сиңа бик шәп исем таптым. Гади дә, яңгырашлы да: Әбсәләм!

Ә тарихы болай: Габбас исемле бер мөгаллим урамда танышы Әбсәләмне очратып, кешеләр алдында: «Сабакташ, халык синең улың өстеннән зарлана, азып-тузып йөри, бу бер дә килешә торган хәл түгел инде, – дип чеметеп алгач, Әбсәләм:

– Иске авыздан яңа сүз, халык әйтер ул, халык Габбас мөгаллим улын да шулай сөйли, – дип, көндәшенең авызын каплаган. – Яратам мин тапкыр кешеләрне.

«Әбсәләм»нең мәгънәсенә килгәдә, сиңа суйган да каплаган инде. «Әб» гарәпчә «Әткәй» дигән сүз икән, ягъни әткәгездән сәлам, исән-имин йөрегез. Шәп бит!

– Түтәкәй Хөббетдин дип, бугазга баса, син Әбсәләм ягын каерасың,

миңа исә үз исемем бик якын, – диде Ататуш. – Аннан соң, бәгырь, кешене исем бизәми, кеше исемне бизи.

– Дүкәмитләреңне карыйк әле, анда ничек теркәлгәнсең икән? – дип тыкшынуын дәвам итте малай. – Закунча яшәргә кирәк.

– Минем дүкәмитләрне, орден-медальләрне сәвит Шәкүрә кәнсәләрнең тимер сандыгына салып, бикләп куйды шул, бәгырь, – диде Ататуш. – Мин, урысча әйтсәк, гол как сокол.

Сәүбән шалкандай йомры башын какча җилкәсенә авыштырыбрак карап торды да:

– Ататуш, авылда синең турында: «Аның теленә контузия түгел, шайтан төкергән», дип сөйлиләр, авызыңда мәкаль дә әйтем бит, – диде.

– И бәгырь, әллә нинди сораулар биреп, болай да мыж булып кортлар оялаган түнтәрмә башымны әйләндермәче, – дип, хуҗа эшенә тотынды.

– Беләсе килә бит...

– Беләсең килсә, бел, элеккеләрен хәтерләмим, бүгенгесе – үзеннән-үзе килә...

Әңгәмәне эт өргән тавыш өзде.

– Музгарка, ни булды? – дип, Сәүбән этенә дәште. Тегесенең ихатага борын тыгарга чамалаган ниндидер чит Бохар мәчесен куркытуы икән, урактай кәкре койрыгын боргалаштыра-боргалаштыра, әнисенең күкрәгенә сыенган нарасый шикелле иясенең түшенә сарылды.

– Җә-җә, кабаланма.

Сәүбән кесәсеннән бер сынык сөяк алып, өскә чөйде. Маэмай аны һавада ук эләктереп алды.

– Учённый, – диде Ататуш, – өйрәткәнсең.

– Шаяртып кына, миңа кизәнеп кара әле, – диде малай, – тагын бер һөнәрен күрерсең.

Ататуш йодрыгын йомарларга өлгермәде, урак койрык уктай атылып, өстенә ыргылды.

– Музгарка, пас!

– Афәрин.

– Мин аны узган ел яланнан табып алдым, – дип, аңлатма бирде Сәүбән. – Бер рәхимсезе күзләре ачылмаган көчекләрне чүплеккә чыгарып ташлаган. Аклы-каралы бу эт баласы туганнары кебек җан бирергә өлгермәгән иде әле. Алып кайтып җылыттым, сөт эчердем. Ул хәзер минем иң якын дустым. Бергәләп, күнегүләр ясыйбыз. Мин бит, Ататуш, унны бетергәч, очучылыкка укырга китәргә җыенам. Яраткан очучыларым Советлар Союзы Геройлары Николай Гастелло, Иван Кожедуб, Алексей Маресьев. Кожедуб фашистларның 62 самолётын бәреп төшерә, Маресьев аягы киселгән хәлдә дә штурвалын ташламый, 7 миссершмидтны дөмектерә. Шулай да, барысына караганда да, Гастеллоны үз итәм. Ул сугышның дүртенче көнендә үк каһарманлык үрнәге күрсәтә, инде ут ялмап алган самолётын немецларның танк колоннасына юнәлдерә...

Малайның бу ашкынулы нотыгы Ататушка да шул ук кимәлдә тәэсир итте булса кирәк:

– Бәгырь, агай-эне ак мыек, ди, ярапланыңда миңа да урын табылырмы соң? – дип кызыксынды.

– Парашут белән сикергәнең бармы соң? – дип, сорауга сорау юллады Сәүбән. – Шунсыз рөхсәт ителми.

– Белмим, бәгырь, мөгаен, сикермәгәнмендер, исемдә юк, – дип сүрәнләнеп төште Ататуш. – Миңа шул калай-шалай да җиткән, күрәсең.

– Борчылма, хәзер парашутымны алып керәм, – дип, Сәүбән урыныннан сикереп торды. – Музгарка, киттек!

Тиз урадылар.

– Үзем ясаган парашут, – диде малай эчке бер горурлану белән, – любуй лапас түбәсеннән кош кебек очып төшәргә була, әйдә, биштәрен ки.

Парашут дигәне арыш капчыгының авызына тимерчыбык белән кыршау беркетелгән, ян-якларына сүстән ишелгән дилбегә баулары тагылган җайланма иде. Дөрестән дә, җайланма, сикергәндә, капчыкка тулган һаваны кабарта, шул рәвешле тизлек кими. Гади дә, тормышчан да.

– Минем ише мие түнгән подаука башларның зиһене җитә торган гамәл түгел икән бу, бәгырь, – диде Ататуш, чуалулы биштәр бауларын әйләндергәли-әйләндергәли.

– Зерә куркасың, лапас түбәсеннән сикерү чүп кенә ул, – диде малай. – Хәзер сикереп күрсәтәм мин сиңа. Үзем исә Җиңү бәйрәме көнендә, бөтен авылны шаккатырып, пожар каланчасыннан сикерү турында хыялланам. Түлке моның өчен ике капчыклы парашут ясарга кирәк.

Ул биштәрен кия башлаган иде дә, бүленде, яртылаш кыйшайган читән уемында әнисе Хәдичә пәйда булды.

– Сәүбән улым, кая олактың, әтәң баядан бирле бәрәңге бакчасына тирес чыгарырга көтә бит сине, – дип оран салды.

* * *

Һәр тарафта яз исе. Бернигә карамый яз үз хокукын даулый. Ул гүя Илеш ягындагы Имәнлек тавыннан гына кочагын җәеп шуып төшә дә, туктала-тыела алмыйча, акын толпардай чабып бара. Ә анда, дөрестән дә, күз күреме җитмәс басу-кыр киңлекләрендә, кояш нурлары эреткән кар суларыннан күлләвекләр дә хасил булырга өлгергән икән инде.

Ататуш учы белән кояшны каплады да, күзләрен төймәләндереп, шушы күркәм манзарага текәлеп бакты.

Яз яз инде. Ул һәр җан иясенә, нинди хәл-әхвәлдә булуына да карамастан, рухи күтәренкелек, яшәү омтылышы, күңел көрлеге, балалы теләкләр, тагын әллә нинди ләззәтле хис вә тойгылар алып килә. Әнә, Сәүбәннәрнең бүрекле әтәче дә тирә-якны яңгыратып, тавык-җанкайларына аваз салды:

– Ки-кри-и-и-кү-ү-ү-к!

– Яз – күңелләр хуш, ике кесә буш, – дип көлемсерәп куйды Ататуш.

Шунда кемдер йомшак кына кулына кагылгандай итте. Борылып караса, сәләмә киемле, башыннан аягына кадәр канатлы бет сарган сигез-тугыз яшьләрдәге бер кыз бала шәрә кулларын сузып басып тора иде.

– Абзыкаем, Аллаһ хакына ярдәм итсәнә, әбекәем ачтан үләргә ята, зинһарлар өчен, абзыкаем...

Кыз, үкси-үкси, җиң очы белән күз яшьләрен сыпырып төшерде дә янә дәвам итте:

– Әткәем сугышта һәлак булды, әнкәем казна урман эшендә агач

астында калып үлде, хәзер минә әбекәем... Үзем өчен кайгырмаем мин, безгә мәктәптә чөгендер ашы ашаталар. Көн аралаш дежур да торабыз, ул көнне ашка өстәп, мичтә тәгәрәтеп пешерелгән кабыклы бер бәрәңге дә бирәләр. Анысын әбекәемә алып кайтам...

– Бер бәрәңгене икегә ярсаң, ике була бит ул, бәгырең майдан да йомшаграк икән, – диде Ататуш.

Мизгел эчендә күркәм яз манзарасын кара болыт каплады. Карап бакса, дөнья карасу-саргылт төстә икән ләбаса. Җир-су, күк-офык, йортлар, каралты-кура – барысы-барысы да, хәтта каршында кулын сузып басып торучы бичара теләнче баланың йөз-кыяфәте дә, шушы үләксәгә тартым төстә икән бит.

Фәкыйрьлек – сугыш-орыш кебек үк гомуми афәт ул, дигән бер акыл иясе. Хак. Һәм ул сугыш-орыштан аермалы буларак, дөньяны кешеләргә сиздерми генә, акрын-акрын гына үз кочагына ала, үз төсенә кертә.

– Син үзебезнең авылданмы, читтәнме? – дип белеште Ататуш. – Күземә чалынганың юк кебек...

– Мин Чыныктан, исемем Нәсимә, икенче класста укыйм, – диде кыз. – Авылыбыз моннан өч-дүрт чакрымда гына, безнең Баллы кәрәкә күлен бөтен тирә-як белә.

– Мин менә белми идем, – дип, җилкәләрен сикертеп куйды Ататуш. – Ни-нәрсәсе белән белекле ул Баллы кәрәкәгез?

Кызның ябык йөзеннән елмаюга охшаш дулкын йөгереп узды.

– Баллы кәрәкә турында түгел, аның яныннан башланган Байгыҗат атавы турында әйтәм мин, – диде. – Анда кызыл карагат мыж була, җыеп кына бетерерлек түгел.

– Ул Байгыҗат-кәрәкәләрең белән болай да буталулы башымны бутама инде син, бәгырь, – дип, Ататуш сул кулын селкеткәләп алды. – Лутчы шуны әйт, кем җибәрде сине минем янга?

– Түбән очтан бер бик тә мәрхәмәтле Нәнекәй исемле әбекәй, минем кан кардәшем, кеше хәленә керә торган фырантавик, буш итмәс , – диде.

– Ашаган бар, туйган юк, дигәндәй минем үземнең дә табыным такы-токы гына, бәгырь, – дип, башын кашып торды Ататуш. – Хак, түтәкәемнең ышанычын да аклыйсы килә анысы...

– Соранып йөрүе дә бик авыр, абзыкай, – диде кыз, зурларча җитдилек белән. – Бөтен җирдә хәерчелек, хәлемә керүеңә дә рәхмәт, абзыкай, исән-имин яшә, Ходай рәхмәтеннән ташламасын.

Теләнче кыз көпшәк карны шыгырдатып, урыныннан кузгалды. Ататуш аны Кызыл Яр тыкрыгы аша басу капкасы борылышына җитеп, күздән югалганчы, карашы белән озатып калды.

Аннан үзенең яшәү мәгънәсенә мөнәсәбәтле ниндидер бик тә кыйммәтле илаһи сыйфатын югалтканын төшенеп алган иде булса кирәк. Нишләп мин шундый туң йөрәк соң, бу мескен балага булыша ала идем бит, өч-дүрт умачлы ашлык оным бар иде ләбаса дип, яшьләренә буыла-буыла, үзен-үзе битәрләргә кереште.

Шунда кирәгеннән артык тәшвишләнүдән күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте, зиһене чуалды.

Ататушка контузиясе баш иде инде. Бу юлы яңа ай вазифасы теләнче кыз белән бәйле иде.

Ататуш нидер мыгырдана-мыгырдана, йомарланган йодрыклары белән үзен-үзе дөмбәсләп алды да атылып өенә керде, кабалана-кабалана, коралларын биштәренә тутырды, он янчыгын кесәсенә тыкты, агач мылтыгын иңенә салды һәм ажгырып урамга чыкты.

Күп тә үтми, Күҗәкә – Чынык юлы киңлекләренә сугыш чоры өндәмәләре таралды.

– За Родину, за Сталина!
Мылтык асып, кылыч тагып,
Дошманнарга каршы китте
Комсомолка Гөлсара...

* * *

Укудан кайткач, Хәдичә улы Сәүбәнне бәрәңге бакчасына алып чыкты. Кар әле эреп бетмәгән иде, шулай да туңы кайта башлаган икән. Көрәген кадап куйды да:

– Өстәрәк качып калган бәрәңгеләр бардыр әле бераз җыя алсак, әтәңнең эштән кайтуына кәлҗемә коймагы пешерер идем, улым, – дип, ниятен җиткерде, – бигрәк бетереште бит, умачлык та он калмады, орлык бәрәңгесенә ничек тә тимәскә иде...

– Монда лом кирәк, – диде Сәүбән, – алып килим әле.

Уң як күршеләре Әминә дә шул исәптә икән. Аның хәле тагын да мөшкелрәк, ире сугыш шәһиде, ике баласы белән тол калды. Өстәвенә, каенанасы урын өстендә. Әмма кайгыга бирешә торганнардан түгел, телгә бик маһир. Атына күрә камыты, сүзенә күрә калыбы, дип кенә җибәрә. Әле дә шаян-шуклыгын күрсәтеп, такмагын сиптерде:

Күкәлидән хат килгән,
Язга кайтырмын дигән.
Колхозчыларга әйтегез,
Ачка үтермәм дигән.

– Кайтсын иде инде тизрәк, тәмам коргаксыдык бит, – диде Хәдичә. – Иң өзек вакыт, үләннәр үсә башласа, бераз тын алыр идек, ичмасам, кычытканы-юасы дигәндәй...

– Бушны бушка аудара-аудара көтеп ятасы түгел, күршекәем, – диде Әминә бәбәген бәгырәйтеп. – Аның үзе авызга керәм дип торганнары бар, тәмләп йотасы гына...

– Уйнап сөйләшсәң дә, уйлап сөйләш, ди.

– Җә, хуш, инде тыңла, – диде Әминә җитди кыяфәттә, – карап кайттым. Үр басуыбыз Татыш тарлавы инде кардан арынган, анда бодай бик уңган иде. Башкалар җитешкәләгәнче авыз ачып калмыйк, дим.

– Күреп торасың, Әминә, корсагым борыныма җитеп килә, Татыш тарлавы җәһәннәм аръягында бит ул. Мин анда барып җитә алмам...

– Улың Сәүбән барыр, мин дә Әхмәтемне алып барам.

– Ярар алайса, бигрәк тә Вәсим өчен кайгырам мин, ачлыкны бик авыр кичерә мескенем.

– Кайгырма, бодай боткасы шәһвәтне тиз кайтара ул, – диде Әминә

уены-чыны белән. – Анысы инде, малайкай, безнең кебек тол хатыннарга тәтеми, безгә шул төнне мендәр юешләп чыгарга гына кала.

Татыш тарлавы өметне аклады. Хәтта басу читендә аунап яткан көлтәләргә дә тап булдылар. Ике-өч көндә җәйгә җитәрлек бөртек тупладылар. Ашау-эчү ягыннан, шөкер, кайгылары бетте.

Хәдичә икенче көнне бармагын чөеп кенә, Вәсимне үзе янына чакырып алды да мич башына ым какты.

Мич башы бодай башаклары белән чөмәкәй иде. Симез каз муенындай майлы, Идел эчендә генә үсүче кара бөрлегән тәлгәшләредәй эре башаклар. Бөртекләре, гүя ахак төймәләр, тәрәзәдән сибелгән кояш нурлары кочагында җем-җем җемелдәшәләр, авыздан сулар китереп, ымсындырып торалар.

– Менә, улың Сәүбән җыеп кайтты, – диде үтә бер горурлык белән. – Ярма яру синең өстә инде, җаным, ярма ташын да чистартып куйдым.

Вәсим кулын хатынының җилкәсенә салып уйланып торды да, көрсенеп әйтте:

– Фашистны җиңү, әнкәсе, ачлыкны җиңүдән күпкә җиңелрәк булган икән, – диде. – Сезне мин тәэмин итәргә тиеш тә бит...

– Ярар, ярар, кайгырма, – дип, Хәдичә учы белән иренең авызын каплады. – Ходайның рәхмәте киң, барысы да булыр, гомерләр алда әле, әнә, корсагымда тагын бер малаең, тизрәк әткәемне күрәсем килә, дип тибенеп ята, сыйпаштырып ал әле үзен, күңеле булсын.

Вәсим кулын хатынының итәк эченә шудырды.

– О-о, баһадирыбызга көч кергән икән инде, рәхмәт-рәхмәт, җанашым, сөендердең, – дип, фронтовик хатынын кочагына кертте.

Хикмәти Ходa, тук нәфес сайлана бит ул. Моннан бер атна элек кенә ачлы-туклы көн күргән Вәсимнәр гаиләсен дә ботка ялкытты булса кирәк, беркөнне Хәдичә:

– Атасы, үзегезне тәбикмәк-кыстыбыйлар белән дә сыйлыйсы иде, ярма ташын онга да көйләп булмый микән, башыңны эшләтеп кара әле, – дип, иренә елмаюлы караш ташлады.

Вәсимнең дә кәефе шәп иде.

– Есть, товарищ командир, – дип, учын чигәсенә куйды. – Боеру – сездән, үтәмәк – бездән!

Чынында да кичен Хәдичә өстәлгә булары чыгып торган зур табак китереп утыртты.

Умач,  
Аш булыр угач,  
Карыныңа кереп тулгач!

– Тотыгыз кашыкларыгызны, иртәгә, Аллаһы боерса, камыр ризыгы пешерермен.

– Ярый безгә – майлы көзгә, әйрән каткан шулпа-умач, – дип, Сәүбән дә әнисенең шатлыгын тулыландырды. – Шулай бит, әткәй!

Бу бәхетле көннең соңгы күрекле авазы булган икән. Икенче көнне иртә белән әнисе йорт-җир эшләрен бетереп кергәндә дә, Сәүбән урын өстендә ята иде әле.

– Йокы чүлмәге, мәктәбеңә соңарасың бит, тор, – дип, Хәдичә аның юрганын ачкандай итте.

Сәүбән, мине кем бимазалый дигәндәй, нурсыз күзләрен киереп бер ачты да:

– Әнкәй, бөтен авыз эчем, тамагым яна. – диде. – Салкын су биреп кара әле...

Ләкин бу януны кое суы да басмады. Кискә дә кискә, ул да кискә. Аратирә ыңгырашып куюы гына аның исән икәненә ишарә итә иде.

Хәдичә берара ифрат халәтендә нишләргә белмичә тораташтай катып басып торды, аннан кинәт кенә аңына килеп, тастымалын юешләде, аны, бизгәк чире шулай авыр инде, түзәргә туры килә, дип сөйләнә-сөйләнә, иплəп кенә улының уттай янган маңгаена япты.

Шулвакыт ишек ачылды, ире кайткан икән. Аның да йөзе качкан, шартлардай булып кызарган.

– Вәсим, Сәүбәнне бизгәк тоткан бит, – дип, иренә карап бакты да лып итеп урындыкка чүкте.

– Әллә син дә...

– Ерунда, – диде Вәсим, – фронтовикка чуртым да булмый аңа, ә Сәүбәнне аякка бастырырбыз.

Ул көр күренергә тырышып, хәтта елмайгандай да итте. Ләкин бу елмаю аның йөзен ямьсезләп чалшайтты гына.

– Хәзер урын көйләп бирәм, ятып тор, – дип, Хәдичә ястык-мендәрләргә ябышты.

– Атлар кайткан вакытка син кәнүшнигә барып тор инде, – диде Вәсим, – иртәнгә ничек тә аякка басармын.

Кая ул басу, тәмам бөрешеп төште. Хәдичә аның иске тире кебек кибешкән иреннәрен кашык белән ерып, тамагына су тамызгалады. Авызыннан сасы ис аңкый, уртлары каз куыгыдай бүртенгән, яргаланган урыннарыннан кан да сытылып чыга. Йөзе көл төсле. Берзаман эчләре суырылып чыгардай булып косарга тотынды.

– Җаным, җайлабрак ят, – диде Хәдичә. – Аллаһы боерса, үзең әйтмешли, бизгәкне генә җиңәрсең, Сәүбән, әнә, рәтләнеп килә, ыңгырашмый хәзер.

Вәсим хатынына нуры качкан күзләрен мөлдерәтеп карап кына алды, сүз әйтергә көче юк иде, күрәсең.

Хәдичә көн буе ике арада әвәләнеп, кичкә таба үзе дә тәмам бетерешге: башы әйләнә, күңеле болгана, тамагы шешеп чыкты, төкерек йотулары да авырлашты. Аннан, бераз хәл алыйм әле, булмаса, дип, ире янына менеп ятты...

Күршеләре Әминәләрдә дә шушы ук хәл иде.

* * *

Ататушның контузия мәрәкәсен чыныклылар театрда утыргандай, мөкиббән китеп тамаша кылдылар. Аннан соң да, тынычлангач та, үз иттеләр. Ул үзе дә бурычлы калмады, авылдагы барча тишек-тошык савыт-сабаны теләнче кыз Нәсимәнең әбисе исәбенә бөтәйтте, сәгатьләренә дә җан өрде.

Күршедәге Кенә Елга авылыннан килеп тә кодаладылар үзен.

– Бесдә картуфлы кешеләр шактый, маясы әйбәт булыр, – диде ар карты. – Мин үсем дә мачтыр ием, картайдым, кулларым калтырый, үсең пеләсең, песнең эштә кул нык булырга тиеш.

– Кешегә онга кермәсәң дә, көлгә керерсең, диләр, – диде Ататуш. – иртәгә килермен, көтегез.

Иртәгәсен ул иртән иртүк эт өрүеннән уянып китте. Чинапмы-чиный, өзгәләнә бәгырь. Күзләрен уа-уа, ишегалдына чыкса, аңа солдат хатыдай өчпочмакланып торучы кыска колакларын шәлперәйтеп, Музгарка килеп сарылды. Ышкыныпмы-ышкына, гүя каядыр алып барырга тели.

– Монда кадәр килеп, мине эзләп тапкансың икән, әйдә, киттек, бәгырь, – диде Ататуш, – кичәдән бирле йөрәгем тыпырчына иде, юкка булмаган икән.

Музгарка туры авыл зираты тарафына теркелдәде. Ә анда... анда җиде яңа кабер тезелешеп киткән иде.

Ататуш каберләр каршына тезләнеп, догага оеды: «Валлаһе әгъләм биссәваб, дөньяң – фани, гомерең – мизгел, үзең – балчык, рухың – мизах...»

– Бәгырь, мин сине ятим итмәм, – диде, үзенә моңаеп карап торган маэмайның сыртыннан сыйпаштыргалый-сыйпаштыргалый. – Кузгалыйк булмаса, әнә анда, Иманлек ягында болытлар да куерып килә, аек баштан явым-төшем астында калмыйк әле.

Кабарынкы көрпә болытлар бу юлы нишләптер Сөнне урап уздылар. Бу аларга мач кына иде. Әүвәл Сәүбәннәргә сугылдылар. Капкалары бәйдә, ишек-тәрәзәләренә аркылы-торкылы иске-москы такталар кадакланган. Ататуш үзенә кирәк әйберне лапас эчендәге каз оясыннан табып алды. Бу Сәүбәннең парашюты иде. Икенче капчыгын да көйләп бетергән булган икән инде, бәгырь.

– Бүгеннән мин яшь дустымның әманәтдары, – диде ул, Музгаркага карап. – Мин аның Җиңү көнендә каланчадан сикерү ниятен үземә әманәт итеп кабул итәм.

Маэмай, аңлагандай, койрыгын селеккәләп алды.

Кешеләргә күренмәскә тырышып, аулак җирләрдән генә мыштым-мыштым гына атласа да, Ататушның планы барыбер барып чыкмады. Ул ялан борылышында бөкре Хәбил белән йөзгә-йөз очрашты, әйтерсең лә, махсус сагалап торган. Исәнләшү-хәл белешү юк, колагына кайнар тынын өрде.

– Беләсеңме, фронтовик, бу афәт Гитлерның җинаяти үче бит, – диде. – Хак, ул үзенә тиешле җәзасын алды, әмма аның ышпионнары мыж. Шулар басу-кырларны зирәдән-зирә куркыныч агу белән агулыйлар икән. Хәзергесе баласы гына, алда булыр анасы...

– Туктале, ни...

– Бүлдерми генә тыңла, – дип, Хәбил аның касыгына төртте, – бәгъзеләр шушы критик вазгыятьтән усал ният белән файдаланып, ифрат та дошмани фаразлар тарата. Әнә, недобитый Илеш мулласы бу афәтне, мәчет манараларын кисеп аударган өчен Аллаһының каһәре, дип акыл сата икән.

– Нинди ышпион, бик беләсең килсә, үләт бу, – диде Ататуш.

– Нинди-нинди, менә син ул ышпион и точка! – дип, Хәбил кулын селтәп китеп барды.

Халык бу хастага бик тиз исем тапты – тамак чире. Рәсми медицинада

исә септик ангина дип атала икән. Һәм ул күптән мәгълүм, дәвалау ысуллары эшләнгән чир икән. Ататуш бу хакта район гәҗитендә басылган мәкаләдән укып белде. Ач тамакка бизгәк булып ябышкан микроблар организмда өч-дүрт атнага кадәр тын гына посып яталар да, аннан искәртмәстән генә уянып, китереп тә бирәләр икән. Әлеге санда «Көн кадагы» рубрикасында табиб әңгәмәсе дә тәкъдим ителгән иде. Соңгы минутта гына аны райком вәкиле алып ташлатты. Вәкил бигрәк тә: «Без бу хастага әзер түгел идек. Әйе, басу-кырларга сак куйдылар, ләкин соңлап башкарылган әлеге гамәлнең файдасы янгыннан соң су сиптерү белән бер. Даруларга кытлык, шул сәбәпле сырхауларга ярдәм күрсәтә алмыйбыз, күз алдында җан бирәләр, – дигән өлешенә бәйләнде һәм әңгәмәгә тулаем «антисоветчина» тамгасын чәпәде.

* * *

Беркөнне Ататушны колхоз рәисе чулак Хафиз чакырып алды.

– Амбарда синең генә кулыңнан килә торган эшләр чыгып тора, – диде, – бүгеннән үк тотын.

– Тотынырга дисәң, миңа куш, – диде Ататуш, күзләрен уйнаткалап. – Әҗере ничек була бит әле. Вәйт тибә раз, Ибрай таз гына булмасмы?

– Авыл тулы тол хатын, ә син һаман мендәр кочып яшисең, – диде рәис, мут кына авызын ерып, – шунда берәрсен табарсың, менә шул булыр әҗер. Әмма дә ындыр табагы мөдире Мәэмүнәгә ымсынасы булма, урыс колагыңны кисәр, ха-ха-ха...

Рәис белеп сайрый икән, чыннан да, Мәэмүнәне күргәч, аның тавык йомыркасыдай шома бите, мыймылдык тулы гәүдәсе, күлмәген тишеп чыгардай күпергән мул имиләре, мәмрәп пешкән бөрлегәндәй кабарынкы сусыл иреннәре игътибарсыз калдырмады, үзенә сиздерми генә күзсез ягы керфекләреннән үткәрде.

Мәэмүнә мондый «керфек үткәрүләр»гә күптәннән күнгән иде инде, ирләрнең селәгәй агызуыннан үзенә бер ләззәти тәм таба иде. Ататушның да кытыгын китереп алырга булды.

– Ирсез хатын дигәч тә нәфсеңне кузгатма, – диде, җилкәләрен уйнаткалап. – Сез, ирләр, барыгыз да бер калыптан.

– Хәлеңне аңлыйм, – диде Ататуш, – чәйнәргә ир булмау – кыз-хатын өчен үлем белән бер ул.

– Телең тоздан әче, дип сөйлиләр иде, хак икән, – диде Мәэмүнә. – Булды, аңлаштык, эшеңә тотын.

– Аягым күптәннән идәндә инде.

Эш дигәне ишек-тәрәзә, күгән, питлә, йозак ише әйберләр икән. Кайсы чергән, кайсы ватылган, кайсы сынган, кыскасы, тимер-томырга бәйле гамәлләр. Мөдир аны иң элек түр ягындагы, башкалардан зурлыгы, күренешкыяфәте белән аерылып торган келәт янына алып килде.

– Иң мөһиме, ишек-тәрәзә, алыштырасын алыштырырга, төзәтәсен төзәтергә кирәк, йозагы да авыр ачыла башлады, – диде. Аннан соң бармагын тырпайтып: – Матри, яныңа кеше китерәсе булма, бу секретный объект, бу эшне фронтовик, илгәзәк кеше буларак кына, сиңа ышанып тапшырабыз, аң бул, – дип кисәтте.

– Дәрәҗәсенә күрә тәрәзәсе, – дип, борынын чөйде Ататуш.

Аңа Мәэмүнә белән сөйләшү, аның елмаюлы ясалма кырыслыгы, кашларын уйнаткалап, иреннәрен ялмаштырып алулары бик ошый иде. Ул үзенең ир-ат кавеменнән икәнен тоя башлады. Ни хикмәт, үзе дә сизмәстән егет чагында җырлап йөргән шахта көе хәтеренә килмәсенме? Шул ашкынулы моңлы көйгә сүзләре дә агылып чыкты.

Сөн буйлары бөдрә урман,
Агыйделләргә җиткән,
Күңелем яна, йөрәгем ярсый,
Бу нинди ташкын икән?

Калай белән тышланган келәт ишеге тышкы яктан калын тимердән җыелган рәшәткә белән дә ныгытылган иде. Йозагы да шуңа тиң сайланган. Эт башыдай олы богау йозак. Кыскасы, келәткә алай-болай гына борын төртмәле түгел. Ләкин ошбу күркәм корылма янында озак юанырга туры килмәде, янына Мәэмүнә килеп басты.

– Онытып җибәргәнмен, бүген бит таң тишегеннән хатыннарны Бишбүкән загатзернасына җибәрделәр, аларның кайтуына симәнә келәтен тәртипкә китерергә кирәк, шунда бар, – диде.

– Эш кушарга ясап куйган кебек икән син, командирлардан ким түгел, – диде Ататуш баштагы уенчаклыгы белән. – Әллә яучы җибәрергәме, дип исәп коруым...

Мәэмүнә аны тыңлап бетермәде, үз сүзен кыстырды:

– И хәчтерүш, яучы җибәрер өчен гайрәт кирәк бит аңа, – диде. – Ә синең турында гайрәтен Герман җирендә өздереп калдырган, дип сөйлиләр, һе-һе-һе...

– Минем бар байлыгым, бар гайрәтем үзем белән, – диде Ататуш, гәүдәсен турайтып. – Менә аякларым, менә кулларым...

Мәэмүнә бот чабып көлә-көлә:

– И мескен, хәрәм агасы, күп сөйләшкән ир булмас, ди, бар, эшеңдә бул, – дип, бу вәсвәсәле сүз көрәштерүгә нокта куйды.

Кояш баер алдыннан ындыр табагына бер җепкә теркәлгән ристаннар кебек тезелешеп, хатыннар кайтып төште. Килеш-килбәтләреннән күренеп тора, бармак белән төртсәң авар хәлгә җитеп арыганнар, йончыганнар, мескенкәйләр. Шулай булмыйча, ачлы-туклы килеш кар суын ера-ера, аркаңа пот ярым йөк асып, ун чакрым (баруы-кайтуы – егерме) юл үтеп кара әле.

Капчыкларында бодай симәнәсе икән. Мәэмүнә һәрберсенең йөген квитанцияләренә теркәлгәнчә граммына кадәр үлчәп-тикшереп кабул итә.

Кызганычка, унтугыз йөкченең берсендә биш йөз грамм ашлык ким чыкты. Бу Җәннәт исемле тол хатын иде. Мөдирнең Ататуш мәмрәп пешкән бөрлегәнгә охшаткан сусыл иреннәре чалшайды, чәчрәп чыгардай булып бәсәргән күзләреннән очкын чәчелде.

– Бирән, тыгындыңмыни, кабул итмим, – дип сөрән салды.

Җәннәтне мөдирнең дорфалыгы бик рәнҗетсә дә, кабынып китмәде, сүзен орылмыйча-бәрелмичә генә җиткерергә тырышты. Сәбәбе дә җитди иде шул.

– Аллам сакласын, өч баламны ятим итеп, ахирәтем-җан дустым

Сәлимәбикә көненә төшәсем килеп тормый әле, – диде. – Бер кесә арыш өчен сигез елга утыртып куйдылар бит җанашымны. Хәзер әнә Сак-Сок кебек үзе өтермәдә, улы белән кызы детдумда иза чигә. Безнең ише солдаткаларны этеш тә төртеш инде ул. Капчыгымны яңабаштан үлчә.

Ул капчыгын үлчәү табасына утыртты.

Пошаманга төшкән унтугыз бичара хатын вафат затның җәсәден урап алган җеназачылар кебек сүзсез генә түгәрәкләнеп басты. Тыннар кысылды, йөрәкләр суырылды, күзләр генә пәрәвезгә эләккән чарасыз бөҗәкләр шикелле әҗе-мөҗе килеп бәргәләнә иде.

Ни булыр?

Мәэмүнә дикъкать белән генә үлчәү ташын әкрен-әкрен әле уңга, әле сулга шуыштырды.

Ниһаять, күрсәткеч ук, берара дерелдәп алганнан соң, шым булып тукталып калды.

– Егерме өч кило да җиде йөз грамм, – диде Мәэмүнә, – барыбер өч йөз грамм җитми.

Хәл катлауланды. Җәннәтнең дә сабырлыгы сынды булса кирәк, үзен-үзе белештермичә калтыранулы иреннәре арасыннан йөрәк өзгеч тавыш белән:

– Тагын үлчә! – дип кычкырды. – Капчыкны ачканмы мин, юкмы, әнә, башкалардан белеш.

– Ачмады-ачмады, – дип шаулашты аяклы йөкчеләр.

Ататуш бу күңелсез тарткалашуны читтән генә күзәтеп тора иде, хатыннар шаулаша башлагач, тиз генә урыныннан купты да кулындагы төенчеген Мәэмүнәгә сузды.

– Бу бүген син биргән өч йөз грамм паек, шуны Җәннәт исәбенә теркә, – диде. – Эчмә солдаткаларның канын.

Матурлык күз өчен, холык күңел өчен, ди, шушы мизгелдә Мәэмүнә Ататуш алдында бөтен күркәмлеген, сөйкемлелеген җуйды, табак битле, арыш капчыгыдай ишелеп төшкән, кешегә нахак бәла эстәүче дуамал аздыкы көянтәсенә әйләнде.

Мәэмүнә иреннәрен кыйшайтып, ниндидер мыскыллы елмаю белән елмайгандай итте дә:

– Дивана, синең паёгыңны чәчеп, иген үстереп булмый, кысылма, нишләргә икәнен мин үзем беләм, – диде. – Бар, юлыңда бул.

Низаг ни кимәлдә тәмамлангадыр, анысы караңгы, ул эшкә килгәндә, кичәге йөкче хатыннар тезелешеп, Бишбүкән юлына төшеп баралар иде инде.

Беренче карашка җитеш вә күркәм булып күренсә дә, келәттә эшләр шактыйга җыелды. Җентекләбрәк карап бакса, ишек бер күгәндә генә асылынып тора икән. Астагысы төбеннән чатнап ярылып, гамәлдән чыккан.

Әүвәл шул күгәнне алыштырды, аннан ишек-тәрәзә рәшәткәләрен сүтеп алып, ныгытасын ныгытты, беркетәсен беркетте.

Богау йозакка кич-кырын гына чират җитте. Аңа да күптәннән кеше кулы тимәгән, күрәсең, тышына шактый калын саргылт-сары күгәрек утырган, кыршылган җирләре дә бар. Ә менә механизмы үзгәрешсез, һәр келтинкәсе менә мин, дип чатнап тора. Авыр ачылуының сәбәбе фәкать шул, әлеге дә баягы, кул тимәүдә. Йозак, майлап җибәрүгә, элеккечә үзенә генә хас корыч моңы чыгарып, ачыла-бикләнә башлады.

– Дың-дың-дың...

Инде келәтнең эченә керсәң дә ярыйдыр.

Ишекне ачты да, ике күзе дүрт булып, баскан урынында катып калды. Нәкъ шигырьдәгечә:

Миң төрле уй, катты баш,
Нишләргә дә аптыраш;
Яртым яна, яртым туңа,
Яртым үлде яртылаш...

Уптым илаһи акбур белән буялган келәт эче бодай көшеленнән чөмәкәй иде. Тәрәзә уемыннан сузылган тонык яктылык кочагында көшел асылташтай җем-җем җемелди. Сайлап кына тутырылган эре, әле генә юып алгандай саф-чиста бөртекләр.

Илаһи кадыйр!

Халык гаиләсе-гаиләсе белән ачтан кырыла, солдаткалар җелекләре суырылганчы капчык асып, тәпи-тәпи симәнә ташый. Ә монда, кул сузымында гына, тонна-тонна бодай саклана.

Ататуш иелеп, учына бодай алды да, бер-ике бөртеген авызына капты.

Мәэмүнә күзәтеп торган икән.

– Сүкәлмә, глубинка бодае ул, – дип ысылдады.

– Авыл кабер казып өлгерә алмый, ә монда никадәр ашлык! – диде Ататуш. – Кәнсәләрдә ни уйлыйлар икән?

– Кәнсәләр-кәнсәләр, – дип, урта бармагын чигәсе тирәсендә әйләндергәләп алды мөдир, – әйтеп торалар сиңа, глубинка бодае дип, ягъни дә дәүләтнеке, аңа сүкәлергә беркемнең дә хакы юк.

– Фәрештәләрне хаким итсәң, аларга да мөгез чыга, ди, ә безнең түрәләр мөгезле булып ук туа, ахрысы, – диде Ататуш. – Кабат үсмәслек итеп сындырып ташларга ул мөгезләрне, чурту-матыр...

– Миңа контузияңне чыгарасы булма, – диде Мәэмүнә, – шуны бел, синең авызыңа йозак эленгән.

* * *

Паёк алган көннәрендә Ататуш түтәкәе Нәнекәй карчыкка умачлы аш пешереп бара торган иде. Катык катып, гәпләшә-гәпләшә икәүләп кенә тамак туйдыралар иде. Чынлыкка киткәч, әлеге күңелле очрашулар тукталып калды.

Күрешүләр кайткач та тиз генә ялганып китмәде, арага ындыр табагы мәшәкатьләре килеп керде. Инде иркен суларга да була дип торганда, мөдир янә эш йөкләде. Каравылчы Сәлимгәрәй карт сырхаулап киткән икән, хәзер шуны алыштырып торырга туры киләчәк. Ярый әле, анысы төнге эш.

Әбәт умачын пешереп, ул, ниһаять, түтәкәенең җил капкасын ачты.

Нәнекәй кортка сәке түрендә бала кебек кенә булып ята иде. Ататушны күргәч, башын калкытып караган иде дә, көче җитмәде, күрәсең, сыгылып төште. Тавышы алай да көр чыкты.

– И-и, Хөббетдинкәем, сине күрми, синең белән бәхилләшми бакыйлыкка күчәм бугай, дип бик кайгырып ята идем, – диде, тыны кысылыбрак. – Килүең бигрәкләр дә әйбәт булды әле, рәхмәт төшкере...

– Җә-җә, түтәкәем, андый юк-бар сүзләр сөйләшмик әле, бу ачлык галәмәте генә, – дип, башын селеккәләде Ататуш. – Менә умач пешереп алып килдем, катыгым да бар, учак тергезәм дә, сайраша-сайраша ашарбыз, күңелең үсеп китәр.

– Аллаһының мәрхәмәте чиксез бит аның, Хөббетдин, эчем эчкә беркә инде дип, тәшвишләнеп йөргәндә, түбән оч Мисбах Әминәсе бер коштабак сары гәрәбәдәй басу бодае китереп киткән ие, кулы-аягы сызлаусыз булсын, – диде карчык, – Аллага шөкер итәм, тик нимәгәдер тамагымнан гына үтми башлады, төкерек тә йота алмыйм, башым да әйләнә, хәлемне шул бетерәдер инде...

Дөрестән дә, Нәнекәй бер-ике умачны авызында әйләндергәләде дә, йота алмагач, кире җамаякка төкерде.

Төкереге кан төсендә иде.

Ататуш аны җайлап кына урынына яткырды.

– Хөббетдин, наным, күршем Мөршидәне чакырып керт әле, – диде карчык, – тәһарәт алдырсын әле, яткан килеш булса да намазга керәсем килә.

Ататуш Мөршидәне ияртеп кайтканда, өй эче караңгыланып килә иде инде, учактагы соңгы кисәү дә актык тапкыр ялкынын ялмап, күмергә әйләнде.

– Түтәкәем, хәзер су җылытам, бераз көт, – дип, Ататуш Нәнекәй карчыкның юрганын рәтләмәк иткән иде дә, кулы канга буялгач, туктап калды. Мендәре дә шыр кан иде, ютәле кузгалган булган, күрәсең.

Нәнекәй күзләрен мөлдерәтеп, бер карап алды да, күкрәгеннән соң сулышын чыгарып, учактагы кисәү кебек сүнеп тә китте.

Күр, нә рәсма тулган иман берлә Коръән садремә.

* * *

Ферма янында Ататушның юлы бүленде. Колхоз малларын бәкегә эчертергә куалар иде. Көтү өстеннән куе томан шикелле булып бу күтәрелә, сыерлар тәмам карлыкканнар, күрәсең, түземсезләнеп, уттай кызган иреннәре белән бара-барышка кар ялмап алалар. Кызыгып китеп, Ататуш та алар үрнәгендә җепшек карны кушучлап көрәп-көрәп алды да авызына шудырды.

Кар башына кар җитәр, дигәннәр. Ишелеп-ишелеп яуган бу карның да гомере кыска, әнә, малларның кызган сыртларына куналар да болганчык тамчы булып агып төшәләр...

Күр, кырмыскалардай ишле булып, урамны тутырып баралар. Күпме мал, келәт тулы бодай!

Хак, бу ачлык, егерме беренче ел ачлыгы кебек, һич тә табигый шартларга, корылыкка бәйле түгел. Иген уңышы елдагыча, гектарыннан 10-15 центнер җыеп алалар, план да үтәлә. Хикмәт шунда: дәүләт үстергән икмәкне кырып-себереп алып бетерә.

Игенченең ачтан үлүе үзе бер башка сыймастай хәвеф инде ул.

Иртәнге ыгы-зыгы. Эш бүлешү шау-шуы төгәлләнеп, амбар мәйданы тынып калган иде. Пычкыларын чыж-чыж китереп, такта яручы ике-өч инвалид фронтовиктан башка кеше-фәлән күренми.

Ататуш, Мәэмүнә күренмәсме, дип, бераз капка янында аң-саң итеп

торды да, шушы иртәнге аулак вакытта черем итеп ала торган гадәте бар иде, оясына кереп поскан, ахры, дип, кеше күзеннән читтәрәк урнашкан түр келәт тарафына юнәлде.

Аны күрепме, ләззәти шөгыльләре тәмамланган чакка туры килдеме – шыпырт кына ачылган келәт ишегеннән үлән арасыннан шуышып үткән елан кебек тавышсыз-тынсыз гына чырае кып-кызыл булып бүртенгән колхоз рәисе чулак Хафиз килеп чыкты да киртә аша зират ягына сикерде.

– Өтәләнмә, Газраилнең болай да эше күп, – дип кычкырып калды Ататуш аның артыннан.

Ачкычларын челтер-челтер челтерәштерә-челтерәштерә бик эшлекле кыяфәттә Мәэмүнә үзе дә күренде.

– Хафиз Газраилне эзләп, зиратка кереп китте, – дип, юлын бүлде Ататуш, – койрыгына ут кабарлык ни-нәмә кылдыгыз анда?

– Кара сарыкның да йонын агарттырырсың, валлаһи, – дип, үзе һөҗүмгә күчте чибәркәй, – паёгыңны алдың гына бит әле, убыр, каравыл вакытың җиткәч килерсең, бар, кеше үртәп йөрмә.

Ататуш муенын кыегайта төшебрәк, хатынны баш-аяк күз уңыннан үткәрде. Аның бөтенләй башка мәсләк буенча йөрүе иде. Һәм акрын-акрын гына мәсләгенең чөен ярыктан чыгара башлады.

– Син гөнаһларыңны ярлыкавын сорап, Аллаһка мөрәҗәгать итәсеңме? – дип текәлеп бакты.

Каракның бүреге яна, ди, бу көтелмәгән сораудан Мәэмүнәнең калын иреннәре дерелдәп алды, җан өшеткеч хафалы дулкын эчен сызып үтте. Хафизның хатыны ишетсә, көт тә тор, тавыш кубачак. Эштән кудырырга да күп сорамас, шадра тәре, ә моңа юл куярга ярамый. Шуңа күрә ул Ататушны да читкә типмәскә, беренче очрашуда куштан чәчбиләргә хас юри-чари башланган кыланчык уен-муенын дәвам итәргә карар итте.

– И-и, гөнаһ дип, теге, тол хатыннарны Ходай гөнаһ кылганчы ук ярлыкый, дия иде Мөслимә абыстай, – диде чытлыкланып. – Бик галимә зат иде, белми әйтмәгәндер.

– Мenә-мenә, – дип элеп алды Ататуш, – Ходай шулай гөнаһлардан арындыргач, кешенең кальбе каз куыгы кебек булып кала, ди бит.

– Шуннан?

– Шуннан шул, кальбне изге ниятләр, күркәм гамәлләр белән һәрдаим тулыландырып тору зарур, ди. Бу да мәрхәмәт иясе зат, минем түтәкәем Нәнекәй абыстай сүзе. Әлеге җәһәттән сиңа ярдәм кулы сузарга кирәк. Мин әзер.

– Ничек?

– Мин бүген иртән Сәлимгәрәй карт янында булдым, – диде Ататуш, – хәле мөшкел. Бөтен тәне өреп кабартылгандай шешенгән. Ярый әле, басу ярмасы бодаен авызына кертмәгән. Югыйсә мәрхүм күршеләре керткән булган. Кыскасы, глубинка келәтеннән бабакайга бер ярты пот ашлык биреп тор әле. Үзем түләрмен. Менә шушы булыр изге гамәлең, кальбең дә тулыланыр, Ходай гөнаһларыңны да ярлыкар.

– Кит моннан, тинтәк!

Мәэмүнә күзләрен акайтты да мыгырдый-мыгырдый китеп барды: болай да бер аягы гүргә кергән карт мудый өчен төрмәгә керер, ди, кеше, көт.

* * *

Чәршәмбенең килеше сишәмбедән билгеле, ди халык мәкале. Кичә кояш баегач та, һавада алсу кызыллык шактый вакыт сүнмичә торды, әйтерсең лә, астына ут төрткәннәр иде. Бу исә иртәгәсе көннең аяз һәм матур буласына ишарә иде. Тик әлеге фараз акланмады. Кояшны, әнә, аксыл томанлы калын болыт каплап алган, шәүләсе дә тәгаенләнми.

Шулай, кешеләрнең генә түгел, табигатьнең дә салулап алган чаклары булгалый.

Ындыр табагына җыелган халыкның гына табигать хәлләрендә гаме юк, шаулашалар, әрепләшеп тә алгалыйлар, көлешеп-көлешеп тә куйгалыйлар. Нәрәт вакыты бит, эш бүлешкәндә төрлесе була, моңа гаҗәпләнәсе түгел.

– Бүген эшкә баручылар егермешәр граммнан җитен оны алачаксыз, – дип шатлыклы хәбәр җиткерде колхоз рәисе, – бәрәңгене манып ашарга менә дигән.

– Ярма булса, ботка пешерер идем дә, май юк, – дип төрттерде Җәннәт, – бәрәңгесен каян алырга?

Мондый чакта, гадәттә, Шәкүрә калкып чыга. Кечкенә генә ризасызлыкны да сәяси калыпка төреп куя да сүз иясенең авызын каплый. Әле дә аскы иренен бүлтәйтеп, нотыктан нотыкка кабатланудан сыер тизәгедәй изелеп-тапталып беткән җөмләләрен тезәргә тотынды.

– Иптәшләр, партия-прауителства...

Бу мөһим сәяси нотыкны Ататуш өзде. Килә-килешкә, аркасына аскан капчыгын карлы боз өстенә ташлады да:

– Әби авыз, синең көртлек маена мануларыңнан гарык инде, туктап тор әле, мине тыңласыннар, – диде. – Бүген төнлә авылыбызның хөрмәтле аксакалы, амбар каравылчысы Сәлимгәрәй бабай вафат булды. Ачлыктан шешенеп үлде.

Берара тынып калган авылдашларына текәлеп карап торды да үрелеп, капчыгын кулына алды.

– Мин аның янына менә шушы ярты пот бодайны илтергә барган идем. Соңладым. Эш кешесенә җитен онын да чеметемләп кенә биргән бер вакытта, бу кадәр бодайны каян алдың, дип сорарсыз, мөгаен. Нух каргасы да очып җитә алмастай ерак җирдә түгел, култык астында гына, әйдәгез, күрсәтәм.

Ул аптырашта калган кешеләрне ияртеп, түр келәт янына килеп басты да, йозагын тибеп очырып, ишеген киереп ачты.

Ә анда Габидулла кибәнедәй очы күккә җиткән көшел өеме.

– Әстәгъфирулла!

– Бодай!

Халык телсез калды. Шуннан файдаланып, Мәэмүнә кулларын җәеп, ишек аралыгына килеп басты да:

– Бу хөкүмәт бодае, калхузныкы түгел, – дип кычкырды, – бөртегенә дә сукәлдермим!

– Кит аннан, күтләк, без дә хөкүмәтнеке бит, – дип, Җәннәт аны бусагадан өстерәп төшерде.

Бодай көшеле аның зиһенен тәмам чуалткан иде, ахирәте Сәлимәбикә фаҗигасе дә онытылды булса кирәк, чын бунтарьларча йодрыгын төйнәп, югары күтәрде дә:

– Нәмә каккан баганадай катып калдык, тутырыйк бөрмәкәйләргә! – дип, алга атылып чыкты.

Аның юлын сугышка кадәр ревкомиссия рәисе булып сайланып торган Мөхәммәтгани фронтовик кисте.

– Җәмәгать, – дип мөрәҗәгать итте бүреген учына йомарлап, – җүләрләнмик, башыбызга бәла алмыйк, 1932 елгы «Өч башак» кануны буенча бөртек түгел, колхоз милкеннән рөхсәтсез алган ике-өч данә кыяр өчен дә суд җаваплылыгы каралган иде. Сугыш вакытында законнар тагын да катгыйланган, ә бу – дәүләт милке...

– Дәүләт кешеләрне ачтан үтерергә тиешмени, Мөхәммәтгани, ярты авыл кырылды лабаса, – дип, Җәннәт янә вазгыятьне кыздырып алды.

– Юкны юк итсәң, бар булыр, ди халык мәкале, – дип дәвам итте сүзен фронтовик, – әлбәттә, колхоз рәисе, авыл советы район җитәкчелеге белән уртак тел табып, мәсьәләне кануни кимәлдә уңай хәл итә ала иде, бу аларның зур җитешсезлеге...

Әлеге шау-шулы манзараны читтәнрәк күзәтеп торган Шәкүрәнең түземлеге төкәнде, күрәсең, кулы белән һаваны ярып:

– Бу бунт! – дип кычкырды, – яхшы чакта таралышыгыз. Һәм дә шуны белегез, бу собутажны оештырган адәм актыгы тиешле җәзасын алачак, без совет законнарын бозарга юл куймаячакбыз!

– Шаһит бул, әби авыз, менә бодаемны кайдан алдым, шунда бушатам, – дип, Ататуш капчыгын селеккәләде дә китеп барды.

* * *

Ататушның башына, әйтерсең лә, кыршау кигезгәннәр, кысыпмы – кыса. Хәлбуки, аның башы су белән мөлдерәмә чиләктәй, һәрвакыт тулы үзе, чайпалып-чайпалып тора. Ул бу халәтенә күнеккән иде инде. Монысы ничектер үзгә, әле чигәсен сызып уза, әле арт чүмечен уттай кыздырып ала.

Төшкә кадәр шулай кулы эшкә бармыйча әрле-бирле йөрештергәләде дә, тамак ялгап алганнан соң, ятагына ауды. Шунда гына башы җибәрде, йоклап ук киткән.

Ул Музгарканың өзелеп-өзелеп өрүеннән уянып китте. Ни булды икән дип ишегалдына чыкса, капка янында ике милиционер белән Шәкүрә басып тора иде.

– Этеңне бәйгә куй! – дип, әмерен яңгыратты погонындагы ике йолдызлы колгадай озын гәүдәлесе, – без прокурор юлламасы белән килдек.

– О-о, ишеттеңме, тауариш персидәтел, син мине күчән баш чутында йөртә идең, күр, абзыеңны пыркрур булып пыркрур белә икән ләбаса, әнә нинди яугирләрне җибәргән, мондый әфтәритит теләсә-кемгә тәтеми, – дип, Шәкүрәне чеметеп алды.

Амбар хәлләре Шәкүрәне тәмам куркуга салган иде. Шулай булмыйча, җитәкче буларак, гаепне аның өстенә аударачаклар. Баш күтәрү уен эш түгел, дәүләт кануннарына каршы чыгу, аның тамырына балта чабарга маташу дигән сүз. Бу инде сәяси тамга. Шуңа күрә шау-шу купкалаганчы кирәкле хәстәрен күрергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килеп, иртән иртүк прокуратурага, район үзәгенә төшеп китте.

Прокурор Әхмәт Кәбиров белән аралары әйбәт иде, ул йомышчыны елмаеп каршы алды.

– Әйдүк, әйдүк, Шәкүрә ханым, бергәләп чәй эчеп алыйк әле, – дип, самавыр да керттерде.

– Рәхмәт, Әхмәт Арсланович, чәй чәй инде ул, ә менә сезгә атап симертергә куйган бәрән сарыкны чалгач, бер иркенләп утырырбыз әле, – диде Шәкүрә, – хәзерендә бик хәвефле хәбәр белән килдем бит әле мин, ярдәмеңә бик мохтаҗмын.

Бүлмә хуҗасы алдындагы кәгазь өемен өстәл читенәрәк шуыштырып куйды да, шакмак ияген учларына сылап, әңгәмәдәшенә карады.

– Тыңлыйм, Шәкүрә ханым.

Шәкүрә түкми-чәчми узган көн вакыйгаларын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Кәбиров берара башын артка чөебрәк уйланып утырды да:

– Бодайга тиюче булдымы? – дип сорады.

– Юк, ул мокыт үзе дә урлаган бодаен кире көшелгә бушатты.

– Монысы яхшы, – дип, җиңел сулап куйды Кәбиров, – ошбу гамәл коллектив җинаять маддәсенә туры килми.

– Ә бунт оештыручы?

– Беренче группа психик инвалид фронтовикка да статья чәпәүнең хаҗәтен күрмим, борчылуларың нигезсез, тыныч күңел белән кайтып китә аласың.

– Бу сәяси мәсьәлә, Әхмәт Арсланович, аны каплап калдырсак, баштан сыйпамаслар. Беренченең дә нинди четерекле кеше икәнен үзең дә бик яхшы беләсең, әгәр җинаять эше ачылмаса, мине дә, сине дә сәяси сукырлыкта гаепләячәкләр. Бу бит бунт!

Кәбиров урындыгыннан торып, бүлмәне аркылыга-буйга иңләде дә, Шәкүрә янына килеп, кулын аның җилкәсенә салды.

– Мин синең белән тулысынча килешәм, рәхмәт, күзләремне ачтың, чын сәясәтче син, көт, иртәгә милиционерлар килер, ул бунтарьны кулга алырлар, калганын суд хәл итәр.

Шәкүрә Байсар бикәсе шикелле әзергә-бәзер булып яшәүчеләрдән түгел. Ул барысына да үз кулы, үз көче, үз тырышлыгы белән иреште. Дүрт сыйныф белемле килеш менә алтынчы ел инде авыл советын җитәкли, булдыклылыгы өчен аңа район үзәгеннән дәрәҗәлерәк эш тәкъдим итү турында да сүз бара. Барып чыгарга охшый.

Ул характеры белән албуын кардәш-ыруларына тартым. Үз дигәненә ирешү кимәлендә теләсә-нинди адымга да барырга әзер.

Егерме беренче ел ачлыгы вакытында, әйтик, чит илләр дә ярдәм кулы суза. Моны халык «Америка паёгы» дип йөртә. Күҗәкәлеләргә дә тия әлеге азык-төлек. Карын – патша, теләсә ни эшне дә эшләттерә, ди, бәхетсезлегенә, бер ишле балалы гаилә атасы, ничектер җаен китереп, ашамлык тутырылган бер пакетны урлый. Аның бик тиз эзенә төшәләр. Ачның ата-анасы юк бит аның. Шушы ук тамак фаҗигасе әсирлегендә кешелек сыйфатларын җуя барган авыл кешеләре бу мескенне үзеннән кабер казытып, тере килеш гүргә кертәләр.

Ул нәрсәдер әйтмәкче, хәлне аңлатмак булып, авызын да ачып карый.

Ләкин совет тирәсендә бөтерелеп йөрүче бер активист аның башына ломын тондыра.

– Эткә эт үлеме!

Күп еллар үткәч, шул ачыклана, бу бичара лом иясенең котыртуы һәм булышлыгы белән башкарган була әлеге җинаятьчел гамәлне.

Шәкүрә дә нәкъ менә шушы лом иясе нәселеннән...

– Музгарка, сантыйга сан юк инде ул, каршыла кунакларны, – дип, Ататуш этенең муенын сыйпаштырды. Тегесе урак койрыгын селкештерә-селкештерә, җиңелчә генә өреп алды.

– Хау-хау-хау!

Милиция эшне кызу тотты. Лейтенант күн сумкасыннан бер кәгазь суырып чыгарды да:

– Сез Фәхерелисламов Хөббетдин Мирзасалихович буласызмы? – дип сорады.

– Түтәкәем Нәнекәй абыстай Хөббетдин дия иде, ә менә маэмаем мине Ататуш дип белә, – диде йорт хуҗасы, авызын кыйшайтып. – Шулай бит, Музгарка?

Эт койрыгын болгаштырып, янә өреп куйды:

– Хау-хау-хау-хау!

– Сәерсенмәгез, ул шулай кирегә беткән бәндәбез инде, менә хәрби билеты, анда Фәхерелисламов Хөббетдин Мирзасалихович исеме белән теркәлгән, – дип, Шәкүрә милиционерларга кызыл тышлы таныклык сузды.

– Сез, иптәш Фәхерелисламов Хөббетдин Мирзасалихович, Якты юл районы прокуроры карары белән Күҗәкә авылы халкын дәүләт милкен үзләштерү максатыннан бунт күтәрергә өндәгәнегез өчен гаепләнеп, кулга алынасыз, – диде лейтенант. – Без өегездә тентү үткәрергә тиеш, бәлки, үзегез әйтерсез, өегездә кораллар тотасызмы?

– Тотам, ә кәкже, – диде Ататуш, – корал эшләр, ир мактаныр, диләр бит, минем кебек егет солтанына коралсыз булмый, тауариш милиционер, мылтыгым да бар, Сәүбән дустымнан калган парашут, пычак, балта, кискеч, тишкеч, игәү, чүкеч, аларны санап бетерерлек кенә түгел...

– Мылтыгыңны сержантка тапшыр, – дип бүлде аны лейтенант, – аннан актка кул куярсың.

Ататуш контузиясе кузгалган чакларда күтәреп йөри торган агач мылтыгын алып чыгып, сержантка тоттырды.

– Сак кылан, аның үзеннән-үзе ата торган начар гадәте бар, – дип кисәтте милиционерны, – запас патроннары да хәтсез, алары да кирәкме?

– Телеңә салынма, – дип, бармак янады лейтенант, – үкенергә туры килмәгәе.

– Минем орден-медальләрем дә бар, имеш, югары дәрәҗәле җиргә барганда, шуларны тагып бару мәслихәт булыр, – дип саныйм, кире кирегә саплый инде ул, югыйсә кәгазегезгә тамга салмыйм, – дип, Ататуш һаман үзенекен сукалады.

Милиционерлар читкәрәк китеп, пышылдашып алдылар.

– Суд карары булганчы бу законга сыя, – диде лейтенант, – авыл советында тагарсың.

Гимнастёркасына Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары, өч медален

таккан арестант фронтовикны район төрмәсенә алып киттеләр. Авыл халкы белми дә калды.

Музгарка гына аны ташламады, койрыгын сыртына салып, чана артыннан теркелдәде.

Кояшның куянга атланган чагы инде хәтсездән Сөн аръягында калды. Күп тә үтми, болай да томанлы офык чите эңгер-меңгер пәрдәсенә уралды. Акрын-акрын күк күчәренә эленгән карасу-зәңгәр болыт челтәрләре арасыннан йолдызлар да шәйләнә башлады. Җемелдәшепме-җемелдәшәләр. Бу аларның яңа туып килгән айны сәламләүләре иде булса кирәк.

Ататушның йөрәге дә шул җемелдәшкән йолдызлар көенә кушылып, ашкынулы халәтенә керде. Җәсәденең һәр күзәнәге, бөтен тәне нindидер илаһи көч, үзенә бер һиммәтле гайрәт белән тулышты. Әлеге халәт аңа шундый өрфә җиңеллек, шундый ярсулы куәт китерде ки, әйтерсең лә, фәрештәләргә генә фарыз канатлар үсеп чыкты. Ул үзен-үзе белешмичә атылган уктай җиргә ыргылды.

Ататуш инде яңа ай туганда гына, баш калкыта торган сугыш афәте кайтавазы чолганышында иде.

> – За Родину, за Сталина!
> Айт-два, айт-два,
> Мылтык тагып, кылыч асып,
> Дошманнарга каршы китте,
> Комсомолка Гөлсара.

– Ур-ра-а-а-а, – дип, маршка да баскан иде дә, җитешә алмыйча калды, аңга килгән милиционерлар аны тотып алдылар да, аяк-кулларын бәйләп, авызын бияләе белән томалап, чана артына китереп салдылар.

Музгарка хуҗасын яклап, милиционерларга ташланды. Ул гап-гади йорт маэмае. Тәбәнәк гәүдәле, кыска аяклы, көч-куәте дә ташка үлчим. Бөтен күркәмлеге – койрыгында. Ләкин әлеге очракта ул аңа комачаулады гына. Сержант койрыгыннан эләктереп алды да болгый-болгый, юл читенә томырды.

– Бу хөрәсән тончыгып үлмәсен тагын, – диде лейтенант, арестантка ым кагып, – бәладән баш-аяк.

Иптәше тиз генә Ататушның йөзенә ябылган япмасын ачып карады.

– Борыны – мөшкә, сиернкыннан ким түгел, мыш-мыш, – диде көлемсерәп, – күз генә йомык.

– Әби авызның төенчеген дә чишәргә вакыт җитте, кара әле, ниләре бар? – диде лейтенант, – эчтә бүреләр улый монда.

– Бер тавык та, бер савыт, – дип, авызын ерды сержант, – савыты – мари көмешкәсе.

– Әйбәт, мариларныкы каты була, әйдә, сал...

Ләкин ашларына таракан төште, Музгарка исенә килгән икән, элеккедән дә яманрак өрә-өрә аларны куып җитте дә, чанага менмәкче булып ыргылыпмы-ыргыла.

– Үзе дурак, эте дә дурак икән, – дип, йөзен чытты лейтенант. – Бу безгә тынгылык бирмәс, мылтыгыңны кор.

Сержант әмерне үтәде, кешесез аулак юлда төнге һаваны кисеп, ату тавышы яңгырады. Музгарка бер чинап алды да чана юлына ауды.

Милиционерлар иркенләп, табын хәстәренә керештеләр. Бераздан лейтенантның хәмери кәефе мари көмешкәсе кебек күбекләнеп, җыр тәгаенләнде:

Талы, талы,
Талы бөгелеп тора,
Тагын бер күрәсе килеп,
Үзәк өзелеп тора.
Их, метрополитин,
Яратам, ни хәл итим.

* * *

Глубинка кенәтен район үзәгеннән килгән махсус осталар бригадасы яңабаштан ремонтлап чыкты. Тоташ тимердән торган ишек куйдылар, тәрәзә рәшәткәләрен дә калынрагы белән алыштырдылар. Йозагын инде тибеп очырып кына ачармын димә, ат башыннан да зуррагын элделәр.

Бодай бөртегенә нәфсехур затлар бур-караклар белән генә дә чикләнми бит әле ул, кумак-тычкан ише кимерүче мәхлуклар да үлеп ярата аны. Осталар аларны да ризыктан мәхрүм итте, идән сайгакларын яңартып, астына калай җәйделәр.

Шулай итеп, Күҗәкәдә дәүләткүләм әһәмияткә ия, чебен-черки дә үтеп керә алмаслык, Мәэмүнә әйтмешли, «сикеритни» объект барлыкка килде. Ә анда саклана торган бодай НЗ икән, ягъни неприкосновенный запас, безнеңчә әйткәндә, кагылгысыз мая. Ул афәтле бәла-каза туганда гына, особуй очракларда гына хөкүмәт карары нигезендә кулланышка керә икән.

Ататуш булса, авыл кешеләренең ачтан кырылуы хөкүмәт өчен особуй очракка саналмыймыни, дигән сорау бирер иде. Кызганыч, ул юк шул инде хәзер.

* * *

Карлар эреде, шаулый-шаулый язгы сулар акты, дөнья яшелләнде, матурайды. Май ае фәкыйрьлекне дә азмы-күпме чигендерде, шөкер, инде ачтан үлүчеләр юк. Чөнки ризык күзгә күренеп артты, төрләнде. Хәзер табынны кычыткан, песи борчагы, кәҗә сакалы, акы, чыпчык кузгалагы, балтырган, юа, камыш тамыры кебек тоташ файдалы витаминнардан гына торган деликатес үләннәр бизи.

Бирсен Ходай!

Беренче июнь көнне дә Шәкүрә ындыр табагына нәкъ иртәнге сәгать дүрттә аяк басты. Һәрвакыттагыча, кашлары җыерулы, чырае төмсә, күкрәге киерүле. Гадәттә, ул үз дәрәҗәсен белеп кенә, салмак кына, кабарган күркәдәй башын турыга катырып кына йөри. Ә бүген тырт та тырт, әйтерсең лә, артыннан куып киләләр. Аскы кабарынкы ирене дә төртеп кузгаткандай мелт-мелт килеп тора. Халыкка болары да мәгълүм, димәк, җиткерәсе мөһим хәбәре бар.

– Әби авыз нотык сөйләргә җыена, – дип, Җәннәт күршесенең колагына өрде, – надаел инде, валлаһи.

– Тсс, ишетә күрмәсен.

– Иптәшләр, авыл советы рәисе Шәкүрә Исламовнаның бик мөһим сүзе

бар, якынрак килегез, – диде колхоз башлыгы, – сөйләшүләрне бетердек, тыңлыйбыз.

Шәкүрә, күрегез, бу мин дигәндәй, бүксә гәүдәсен киерә төшеп, алга чыгып басты да иң элек кырыс күз карашы белән җыелган кешеләрне барлап чыкты. Аннан соң йомры учын авызына терәп, тамагын кыргандай итте. Шуннан соң гына:

– Иптәшләр, кичә район халык суды бунт оештырып, дәүләт милкенә кул сузган җинаятьче Фәхерелисламов Хөббетдинне ун елга ирегеннән мәхрүм итте...

– Әнекәем, Ататушнымы? – дип аваз салды тиктормас Җәннәт, – мескен...

– Колагыңа киртлә, Халикова, мескен түгел, җинаятьче, аңладыңмы, җи-на-five-че! – дип, күзләрен чекрәйтте рәис. – Алай күп лыгырдасаң, үзеңнең дә ахирәтең Сәлимәбикә көненә калуың бар.

Җәннәт калын иреннәрен кыйшайтып, нидер әйтмәкче булган иде дә, бүленде.

– Пырауилны, бик дөрес, яшәсен Совет власте, афәрин, иптәш персидәтел, – дип, халык алдына йомгактай тәгәрәп кенә бөкре Хәбил атылып чыкты, – мин кайчаннан бирле тукып киләм, Ататуш дигәннәре, ул – Һитлер ышпионы...

Хәбил ашыгу-кабаланудан үз төкерегенә үзе тончыгып, берара кых-кыхлап торды да янә яшелле-зәңгәрле тавышы белән дәвам итте:

– Безнең Хөббетдинебезне үтергән дә, дүкәмитләрен үзләштергән ул дошман. Чирне дә шул тарата, җәмәгать, кхе-кхе-кхе.., ун ел төкерек кенә аңа, атарга ки...

Хәбилнең нотыгы арасына бума ютәле кереп кысылды.

– Кхе-кхе-кхе...

Шәкүрә болай да борынын җыерган иде инде. Ник, дисәң, Хәбил ала каргадай алдан-алы кычкырып, белер-белмәс Күҗәкәдә Совет властеның кануни илчесе, ягъни ул, Шәкүрә Гарифуллина, сөйлисе сүзләрне мәкелдәп маташа лабаса. Балта чапты ул ахмак аның алдан уйланылып, чын сәяси камиллектә башлаган чарасына.

Ләкин Шәкүрә яманатка кала торганнардан түгел, бик тиз нотыгының юнәлешен үзгәртеп, чыгышын тагын да отышлырак, тагын да саллырак кимәлдә төгәлләде.

– Совет суды – дөньяда иң гадел суд, – диде, йодрыгын төйнәп. – Без район суды карарын да бердәм рәвештә хуплыйбыз. Юлбашчыбыз иптәш Сталинга дан!

Ататушның авылдашлары, оялчан киленнәр шикелле бер-берсенә күтәрелеп карамыйча гына, күзләрен яшереп кенә, кул чаптылар.

Шулвакыт, күктән ашкан фәрештәдәй, чәрдәкләнгән сынын өстерәп, Музгарка пәйда булды.

Музгарканың бу үз ирекләре белән сәясәт колына әверелгән умырткасыз бичара бәндәләргә әйтер сүзе күп иде. Тик, нишләмәк кирәк, Ходай аңа тел куәсе бирмәгән. Шуңа күрә булдыра алганын гына эшләде.

Ырылдап өреп, гарип гәүдәсен Шәкүрә өстенә очырды да аяк балтырын умырып тешләп алды.

– Хау-хау-хау!



Рафис
Корбан

# КАЗАН*

ПОЭМА

*Бу шәһәр, бәхәссез, Россиядә Мәскәүдән кала беренче... Бөтен нәрсәдән Казанның зур патшалыкның башкаласы булуы күренеп тора.*
Екатерина II-нең 1767 елда язган хатыннан.

*Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;*
*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*
Г.Тукай

## 1.Казанга азан

Уянасың таңда дәртле азан белән.
Азан таушын тыңлап, синдә кояш чыга.
Төнгә калса, адашмыйча барсын өчен
Нурлы аең юлдаш синең юлаучыга.

Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!
Яшәсә дә җирнең кайсы кыйтгасында,
Әверелдең син татарның газиз күргән,
Тезен чүгеп сәҗдә кылган кыйбласына.

Аз да түгел, күп тә түгел, бу җиһанда
Нибары бер мең ел гомер сөргәнсең син.
Җир йөзеннән сине сөреп ташларга дип,
Ярсып килгән күп яуларны күргәнсең син.

Җилләр искән, сулар аккан, вакыт үткән,
Дәрыйгъ, беткән мәмләкәтләр, күп заманнар.

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Поэма» номинациясендә 2 урынны алган әсәр.

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. «Алмалы төн», «Бәхет телим», «Яра» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Нинди генә янгыннарны кичсәң дә син,
И Казаным, син яшисең, син һаман бар!

Җимерелеп, көл-күмергә калсаң да син,
Халкың каны акканда да Идел тулып,
Баскансың син, тузан-көлдән күтәрелгән
Феникстай, аягыңа кабат торып.

Казан, Казан! Татарстан башкаласы.
Татарстан мәмләкәте йөрәге син.
Кыйбла итеп, сиңа сөеп карап торган
Бөтендөнья татарлары терәге син.

Казан, Казан! Кайныйсың син, кайнатасың!
Кунакларга шулпа, бәлеш пешерәсең.
Рәсәй өчен, сандалыңда чыныктырып,
Күренекле шәхесләрең үстерәсең.

Синдә пешкән Державиннар, Толстойлар,
Икмәк белән бергә Горький пешкән синдә.
Яшь Ульянов: «Рус илендә болай яшәп
булмый!» дигән хәтәр уйга төшкән синдә!

Ульяновтан әле бик күп алдан, синдә
Тоткын булып яткан чакта казематта:
«Рус илендә болай яшәп булмый!» – диеп,
Пугач-бунтарь уйлап яткан шушы хакта.

Казан, Казан, Александр Пушкин синдә,
Йөргән чакта Емелянын эзләреннән,
Язарына гыйбрәт-азык алган аның,
«Болай яшәп булмый!» дигән сүзләреннән.

Суконкада чиркәү хоры җырын тыңлап,
Шаляпинны җырчы итеп кайнаткансың.
Син Апушны, илтеп Печән базарына,
«Асрамага бала бирәм!» – дип саткансың!

Ә аннары шул Апушны Тукай итеп,
Таныткансың бөтен төрки кавеменә!
Урыс телен әгәр Пушкин әвәләсә,
Тукай татар Пушкинына әверелә!

Шагыйрьләр һәм язучылар шәһәре син!
Такташ, Туфан шагыйрь булган синдә кайнап.
Ибраһимов, Тинчурин һәм Бурнашны син
Пләтәндә үтергәнсең аннан кыйнап.

Үстергәнсең Җәлил, Кутуй, Алишларны
Ватанына тугры кыю уллар итеп.
Йөрәгендә сиңа сөю йөрткән алар,
Тотканда да фашист әсир-коллар итеп.

Казан, Казан! Каршылыклар шәһәре син.
Бер карыйсың сокланып һәм горурланып.
Бер карасаң, синдә минем күргәннәрем
Ковид кебек буа бугазымнан алып.

Бүре булып улыйсылар килә кайчак,
Куям да мин уйлап бәгырь Сәйдәшеңне.
Әле һаман кадерсездә йөрткән өчен
Гарьләнүдән түгәм бары күз яшемне.

Казан, Казан! Күпне күргән, күп кичергән.
Ташларыңа басып синең кемнәр йөргән?!
Эзем калды минем дә ул ташларында.
Язмышыма Казан бәхет булып кергән.

Бер бәхетле улың синең мин дә, Казан!
Хисләремне бүген дастан итеп язам.
Аллаһ әкбәр, лә иләһә илләл-лаһ, дип,
Җырым башлап, әйтәм әнә сиңа азан!

## 2. Олуг Мөхәммәд

*Мин Олуг Мөхәммәд ханның атка атланган сыны Казанның матур, күренекле бер урынында урнаштырылырга тиеш дип саныйм. Ул Татарстанның үзенчәлекле символы булып торыр.*

Д.Исхаков, тарихчы галим

Казан тарихы катмарлы,
Казан язмышы серле.
Башлана Казан тарихы
Болгар чорыннан бирле.

Болгарны яулап алырга
Гаребтән яулар килгән.
Казан-суның тамагына
Алтынбәк корган кирмән.

Казан-суның тамагында –
Биек Казан кирмәне.
Ерактан торган күренеп
Дошман явы килгәне.

Урыс явыннан саклаган
Болгарны Казан-кирмән.
Ә бер көнне яулар килгән
Бер дә көтмәгән җирдән!

Гаребтән түгел, Шәрыктан
Яулар килгән Болгарга.
Комачаулап торган Болгар,
Урыс илен яуларга.

Бер мең ике йөз дә утыз
Алтынчы елның көзе.
Болгар гаскәренә каршы
Батый хан килә үзе.

Буйсындырыр өчен Бөек
Идел Болгарстанын,
Төгәл ун елга картайган
Гомере Батый ханның.

Һәм җир белән тигезләгән
Болгарны Батый аннан.
Хәрабәләр генә калган
Бөек Болгарстаннан.

Тормаган төрки кавем дип,
Кардәшем дип, болгарны.
Әвәләгән татар белән
Бергә кушып ул аны.

Йә, әйт хәзер, кемдә хаклык,
Без – татармы, болгармы?
Мин үземә сорау бирәм,
Уйлыймын да шуларны.

Каф тауларында (Кавказда)
Күп тапкыр бар булганым.
Яши анда кардәшләрем –
Якын балкар дусларым.

Тылмачсыз да аңлашабыз,
Болгар ни дә, балкар ни.
Минем татар телемдә дә
Аерма юк әлләни.

Болгар ни дә, балкар ни – бер
Кубрат хан оныклары.
Бөек Болгар дәүләтенең
Соңгы кыйпылчыклары!

Барыбыз да төркиләр без!
Бер итеп телебезне,
Татар итеп әвәләгән
Олуг Мөхәммәд безне.

Бөек Чыңгыз оныклары
Ызгышып тәхет өчен,
Бердәм буласы урында,
Юк иткән берсе берсен.

Таркалган татар дәүләте,
Югалта барган көчен.
Татар башын татар ашый,
Ызгышып тәхет өчен.

Олуг Мөхәммәд ханны да
(Татарның соңгы ханын),
Алтын Урда тәхетеннән
Куган үз туганнары.

Нишләсен, сыену эзләп,
Барып ул билен бөгә,
Үзе ярлык биргән кенәз
Василий Икенчегә.

Ә Василий мескен хәлгә
Төшкәнен ханның күрә.
«Китсен безнең җирләрдән!» – дип,
Илчегә әмер бирә.

Шуның өстенә, артыннан
Куа барырга тагын,
Кырык меңлек гаскәр белән
Җибәрә яраннарын.

Ни эшләргә? Тик өч меңлек
Кешесе бар янында.
Мең ярымы кыз-кыркын һәм
Бала-чага аның да.

«Син булмасаң, Алла бар, – дип, –
Ул ярдәм итми калмас», –
Тәһарәт алып укый хан
Ике рәкәгать намаз.

Укып бетерә дә, аннан,
Иярләп тулпар атын,
«Аллаһ әкбәр, лә иләһә
иллэл-лаһ!», – диеп, халкын

Алып китә кырык меңлек
Дошман явына каршы.
Бу сугышта покос булып
Коела дошман башы.

Тәкәббер кенәз Василий-
Икенче үзе кала
Хурлыкка, Олуг Мөхәммәд
Әсиргә аны ала.

Хан, кичеп аннан Иделне,
Нәкъ ике гасыр элек
Батый яулары җимергән
Болгар җиренә килеп,

Идел белән Казан-суның
Кушылган урынында,
«Монда ханлык булачак!» – дип,
Белдерә илгә шунда.

Болгарның бу элек Казан
Кальгасы булган урын.
Болгар-татар болганышып,
Бергә кушылган урын.

Күтәрелә яңа Казан.
Салына яңа кальга.
Көл-күмергә калган җирдә
Казан ханлыгы калка!

Татарның соңгы дәүләте
Төзелә биек үрдә.
Тагын йөз елга озайта
Гомерен Алтын Урда!

Олуг Мөхәммәд хан менеп
Баскан да Кальга-Тауга,
Караган Мәскәү ягыннан
Килүче хәтсез яуга.

Бер кулында аның – Коръән,
Кылычы – бер кулында.
Башын чайкап басып тора
Тулпар аты янында.

Күңелдә һәйкәлен салдым
Олуг Мөхәммәд ханның.
Казанда шундый һәйкәле
Булырга тиеш аның!

## 3. Сөембикә манарасы

*Сөен-бикә, үзенең матурлыгы илә бөтен Казанда атаклы булдыгы кеби гакыллылыгы илә дә атаклы иде. ... Сөен-бикәнең яхшылыклары кояш нуры кебек Казан халкының һәрберсен каплаган, һәртөрле кешегә шул яхшылыктан өлеше чыккан иде.*
*Казанлыларга, руслар янына барып, ярлыкаш эстәүдән башка чара калмаганга күрә, алар Зөядә торучы Шәехгали һәм рус башлыкларына илчеләр җибәреп, үзләрен олуг князьнең багышлавын, гөнаһларын гафу итеп, аларны тоткын иттермәвен, Казанга хан буларак, Шәехгалине җибәрүен, Сөен-бикә илә Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә алдыруын үтенделәр. Бу хәбәрне Шәехгалигә килтерүчеләр Казанның иң атаклы галимнәреннән булган Колшәриф мелла илә Бибарс Ростов исемле кеше иде.*

Һади Атласи. Сөен-бикә

Ак кирмәннең уртасында манара.
Күктән төшеп Ай ял итә очында.
Сөембикә-ханбикәнең ядкәре
Мәңгелеккә кунып калган шушында.

Бәхәс бара ничә гасыр, ни заман,
Манараны урыс корган дип һаман.
Мөмкинме соң? Дошманына кем әле
Корган шулай сәҗдә кылу һәйкәле?

Сафагәрәй ханның монда җәсәде.
Хан мәчете – Сафагәрәй ханга бу
Олылыгын зурлап аның салынган.
Хатыныннан соңгы бүләк аңа бу.

Ул ханлыкта тиңсез хатын иде бер.
Нугай мирзасы Йосыфның кызыдыр.
Тирә-юньдә тиңдәше юк чибәргә
Җиһанның бар шаһзадәсе кызыгыр.

Казан ханлык булып торган дәвердә
Унбиш ханы булды аның тәхтендә.
Кайсы аның, Олуг Мөхәммәд кебек,
Җанын фида кылды Казан бәхтенә?

Кайсы ике яклы уен уйнады,
Мәскәү белән көрәшергә кыймады.
Мәскәү күңлен күрсәм, Казан тәхтендә
Озаграк утырырмын дип уйлады.

Илен саклар ир калмаган Казанда!
Илен саклар ир калмаган татарда!
Бу ни соң бу? Моны ничек аңларга?
Казан булган ханбикәсен сатарга!

Кем гаепләп бүген Сөембикәнең,
Сөйли анда илен ташлап киткәнен?
Ни эшләсен, корал алып кулына,
Күргәч, илен саклар ирләр беткәнен.

Улы белән бергә килеп, иреннән,
Сөембикә, бәхиллеген сораган.
Кызганып ул бөтен Казан гавамын,
Сафагәрәй каберендә елаган.

Казан, Казан, шанлы Казан, бу синме?!
Сафагәрәй хөрлегенә бу тиңме?
Олуг Мөхәммәднең шанлы исемен
Шулай итеп мыскылларга мөмкинме?!

Шаһгали хан тәхет даулый урыстан!
Чыңгыз варисы булуын оныткан.
Илен саклап ат менәсе урында,
Ният кора илен сату турында.

Азан әйтер чакта сәед Колшәриф,
Мөритләрен газаватка чакырып,
Уйламый да Явыз Иван берзаман,
Китәр диеп халкын канга батырып,

Илче булып үзе бара Зөягә:
«Сөен-бикәне генә тик алыгыз,
Калдырыгыз, дип, тынычта Казанны,
Шаһгали, дип, булсын безнең ханыбыз».

Нәкъ бер елдан Колшәриф үз хатасын
Аңлагандыр, әмма инде... әмма соң!
Саклап калыр өчен ул чак Казанны
Шулай кирәк булды микән әллә соң?

Ак кирмәннең уртасында манара,
Хәсрәтеннән торган кебек аварга.
Яңа мәчет күтәрелде янында –
Аумас өчен терәк булып аңарга.

Торып басты мәчет булып Колшәриф,
Хаталарын юар өчен тарихның.
Еллар узгач хатаның иң зурын да
Тәкъдиреңдә язылган дип карыйсың.

Сөембикә манарасы, Колшәриф...
Көн уянса ишетелә иң алдан,
Азан таушы яңгырата Казанны:
«Аллаһ әкбәр, лә иләһә илләл-лаһ!»

## 4. 1552. 15 октябрь

КОРАБ

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөрәдер:*
*Юл бара ят ил карап...*

*Чыкты җилләр,*
*Купты дулкын –*
*Ил корабын җил сөрә!..*
*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!.*

Дәрдемәнд

*Вакытында җирне селкеттек,*
*Инде беттек, инде беттек...*

Г.Тукай

Бу шундый көн! Онытырга
Мөмкин түгел бу көнне.
Дәүләтең беткән бу көнне
Онытырга мөмкинме?!

Безгә моны оныт диләр,
Өстәге дәү абыйлар.
Безнең ише шагыйрь халкын
Аңламый шул андыйлар.

Хәер, алар да хаклыдыр,
Уйлап баксаң бер яктан.
Тукай тиккә язганмыни?!:
«Тотса Мәскәүләр якаң!»

Нәкъ менә шул көннән бирле
Ходайның мескене без:
«Тотса Мәскәүләр якаң!» – дип,
Яшәп яткан көнебез.

Бу шундый көн, онытырга
Мөмкин түгел бу көнне.
Бөтен Рәсәй халкы өчен
Изге көн – Хәтер көне!

Рәсәйнең яңа тарихы
Башлана шушы көннән.
Әллә соң бу көн Мәскәүнең
Чыкканмы хәтереннән?!

Европа кыл урталайга
Бүленә шушы чакта.
Мәскәү юнәлә Себергә,
Европа – кире якка.

Кызыктыра Колумб ачкан
Америка җирләре –
Океанга чыккан ул чак
Европа илләре.

Ә Мәскәү алдында – Казан.
Ул тора комачаулап,
Алыр өчен Урал, Себер,
Ерак Шәрыкны яулап.

Урал, Себер, Ерак Шәрык –
Барсы да татар өе.
Дөнья картасында аның
Аты бер: Тартария.

Тартария – татар иле!
Казан – соңгы кирмәне.
Ачыла юллар Шәрыкка,
Алда – Себер җирләре.

Мең биш йөз дә илле ике.
Кысылып куя бәгырь.
Шушы елдан Рәсәй өчен
Башлана яңа дәвер.

Башлана дәвер сугыштан!
Ава Казан ханлыгы.
Идел тулып каны ул көн
Ага Казан халкының.

Канга батыра Казанны
Рәхимсез Явыз Иван.
Бу кабихнең йөрәгенә
Бөтен явызлык сыйган.

Тәхет өчен дип саташкан,
Акылын җуйган морзалар
Өстерә берсен берсенә –
Татарны суя татар.

Бу көнне соң Хәтер көне
Дими, тагын ни дисең?!
Шуны таныйсы килмәгән
Затларга китә исем!

Тагын да бер хәлне искә
Аласым килә минем:
Пожарский белән бергә –
Татар морзасы Минин,

Мең алты йөз уникенче
Елда, Казан яуланып,
Алтмыш ел үткәч нибары,
Литва, поляк яуларын,

Чыгара куып Мәскәүдән,
Ополчение җыйнап.
Күпләр, Рәсәй аягына
Инде тормас, дип уйлап

Яшәгәндә, татар Минкә
Рәсәйне кала саклап!
Ә бу көнне күпме татар
Үлгән Рәсәйне яклап?!

Хәзер бу көн Россиядә
Халыклар бердәмлеге
Көне дип бәйрәм ителә.
Бу да бер Хәтер көне!

Ә безнең соң, юкмы безнең,
Ханлыкның ауган көнен
Хәтер көне дип атарга
Юкмы хаккыбыз безнең?!

Без дә бит күпме яуларда,
Уртак ватанны саклап,
Җаныбызны фида кылдык,
Шул хаккыбызны хаклап.

Без дә бит тыныч тормышта
Эшләдек аттан артык.
Бүген дә Рәсәй арбасын
Барабыз бергә тартып.

Ел да килә октябрьнең
Унбише көне безгә.
Ел да кызыллык булып ул
Ягыла йөзебезгә.

Ягыла Казан ханлыгын
Саклап калмаган өчен,
Хәтер көне өчен рөхсәт
Ала алмаган өчен.

Хәтер көне – матәм көне.
Казанның ауган көне.
Йөрәгемнең әрнүләрдән
Кара кан сауган көне.

## 5. Аксак Каратун

*Казан буйсындырылганнан соң да аның халкы үзенең гореф-гадәтләрен, телен һәм динен саклаган. Татар бистәсендә яшерен гыйбадәтханәләр булган, ераграк урнашкан татар авылларында мәчетләр эшләгән. Патша Фёдор Иоаннович 1593 елда, Казан архиепископы ясаган донос буенча, яулап алынган җирләрдә бөтен мәчетләрне һәм мәдрәсәләрне җимерергә дигән фәрман чыгарган. Әгәр дә авылда христиан динен кабул итүчеләр булса, ул авылдан чукынмаучыларны сөрергә һәм аларга өстәмә салымнар салырга кушыла. Конашевичның икенче бер доносы нигезендә императрица Елизавета Петровна указы белән Казан һәм аның тирәсендәге авыллардагы 536 мәчетнең 418е җимертелә.*

Көчләп чукындырулар турында тарихи мәгълүматлардан

*«Шәһәр хакимнәренең, Мәрҗани мәчетенең биек манаралы итеп салынуын күреп, Екатерина Икенчегә: «Син мөселманнарга мәчетләр төзергә рөхсәт бирдең бирүен, ләкин алар аны бик биек итеп салалар», – дигән сүзләренә җавап итеп, ул: «Мин аларга җирдә генә урын бирдем, ә күкләр минем биләмәм түгел, нинди биеклектә төзесәләр дә үз ихтыярларында», – дип җавап бирә.*

К. Насыйри

Җимерелә Казан, тузгытыла.
Мәет белән тула урамнары.
Казан өчен шәһит киткәннәрнең
Идел тулып ага ал каннары.

Идел тулып татар каны ага.
Диңгезгәчә барып җиткәндер ул.
Идел буендагы кавемнәргә
Казан хәлен бәян иткәндер ул.

Аңладылар микән Казан хәлен?
Аңлашыла булыр аңлаганга.
Киңәйтергә урыс биләмәсен
Юл ачыла хәзер Әстерханга.

Юл ачыла башкорт тарафына.
Кирәк түгел сугыш башкортларга.
Мескен башкорт канлы кабалага
Сугышсыз да мәҗбүр баш тыгарга.

Бер каптырса, Иван тырнагыннан
Җиңел булырмы соң ычкынырга?
Шәфкатенә тарыйм дисәң аның,
Бары бер юл – кирәк чукынырга!

Чукынганнар татар морзалары.
Ибраһимнар Иван булып алган.
Чукынырга теләмәгән морза
Чабаталы морза булып калган.

Чукынганнар. Көчләп чукындырган
Конашевич кебек туң-аяклар.
Авыллары-авыллары белән
Керәшенгә күчкән бик күп яклар.

Кубарылып туган нигезеннән,
Тугры калып газиз диннәренә,
Авыллары-авыллары белән,
Күченгәннәр башкорт җирләренә.

Җирдә яшәп михнәт күрмәгәннәр
Татар булып бераз карасыннар.
Их, татарым! Каккан-суккан сине
Конашевич-Аксак Каратуннар.

Кагылгансың, куылгансың, татар,
Кубарылып туган нигезеңнән,
Сусыз җирдә сусап яшәсен дип,
Кырык чакрымга Иделеңнән.

Фёдор атлы чиркәү өрәгенә[1]
Донос килә: имеш, татар анда,
Мәчет арты мәчет корып ята,
Бистә төзеп Кабан аръягында.

Фәрман бирә Фёдор Иоанн улы,
Мәчетләрнең барын сүтәргә, дип.
Ә Каратун, аксак, әмер бирә:
– Патша боерыгын үтәргә! –дип.

Сугыш бара, кавем генә түгел,
Бу – ике дин, мәсләк, ике караш
Ызгышы бу! Белмим, бик тиз генә
Тукталырмы канлы бу тарткалаш?

Тузгытыла кабат мәхәлләләр,
Җимерелә Казан мәчетләре.
Онытырга бирми газабымны
Ай өстенә кадап куйган тәре.

Бу татарны күрә алмаган зат
Бар микән соң тагын Җир йөзендә?!
Чиркәү арты чиркәү чыга калкып,
Җимерелгән мәчет нигезендә.

Инде бар да артта калды торып,
Тузан булып тарих анналында.
Артта калды егерменче гасыр –
Инкарь иткән дәвер Алланы да.

Кабат калка Казан мәчетләре,
Манаралар белән күккә ашкан,
«Күкләр минем биләмәгә керми!» –
Дигән көннән бирле Әби-патша.

«Күкләр минем биләмәгә керми!»
Каратунның бу сүз кара йөзен
Фаш иткәндәй тарих анналыннан,
Манарадан ясин чыга мәзин.

[1] Явыз Иваннан соң, аның патша булып калган өченче улы Фёдор Иоаннович, дәүләт эшләре белән шөгыльләнмичә, күп вакытын чиркәүдә үткәрә торган була.

## 6. Университет

*XIX гасырның беренче яртысында Казан Россиянең көнчыгыш өлешендә эре фәнни һәм мәдәни үзәккә әверелә. Бу илнең социаль-икътисади үсеше өчен сәнәгать, сәүдә, хакимият һәм дипломатия өлкәсендә белемле кадрларга зур ихтыяҗ кичерүче белән бәйле була. Бөтен Идел-Урал төбәгенең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында зур әһәмияткә ия вакыйга булып, Казанда университет ачыла. Бу – Россиядә шундый әһәмияткә ия булган өченче югары уку йорты.*

Казан тарихы. 1 нче китап, 164 б.

*Казань, Казань, татарская столица,*
*предположить ты даже не могла,*
*как накрепко Россия настоится*
*под крышкою бурлящего котла.*

*И в пахнущий казарменными щами,*
*Европою приправленный настой*
*войдут Державин, Лобачевский, Щапов,*
*войдут и Каракозов, и Толстой.*

Е.Евтушенко

Россияне китерә дә алмыйм
Күз алдыма мин Казаннан башка.
Мәскәү түгел, Питербур да түгел,
Җир йөзендә Казан булган башта!

Казан – Рәсәй башкаласы, диеп
Аталмаган бары сүздә генә.
Әверелгән Казан Россиянең
Фән, мәгариф, сәнгать үзәгенә.

Кайнап торган монда гавам, тормыш.
Толчок кына, базар гына түгел,
Кешедә бит корсак кына түгел,
Бар белемгә сусап торган күңел.

Һәм аксөяк, бояр улларына
Бирер өчен дөньяви белем,
Россиянең тик өч шәһәрендә
Император ачкан дәрелфөнүн.

Аның берсе – Казан. Дәрелфөнүн –
Ул үзе бер казан – кайнап торган.
Шунда кайнап Казан галимнәре
Россиянең фән нигезен корган.

Исемнәрен генә атасаң да,
Исең китәр кылган эшләреннән.
Лобачевский, Зинин, Бутлеров һәм
Фукс монда... Клаус, Щапов белән.

Казан университеты! Ничек инде
Татарлардан чыкмый калсын галим?!
Казем-Бек һәм Ибраһим Хәлфин
Укытканнар анда татар телен.

Мәхмүдовны кем генә соң белми –
Казан артындагы бер авылдан,
Ялантәпи, Ломоносов кебек,
Шул Казанга килеп галим булган!

Иң беренче булып әлифбасын,
Нәкыш тезеп, матур язу серен,
Күрсәткән ул бөтен матурлыгын
Шәрикләргә, туган телебезнең.

Аксаков һәм Лев Толстой белән
Федосеев анда белем алган.
Пешков өчен монда кереп уку
Якты хыял гына булып калган.

Яшь Ульянов монда үзләштергән
Юриспруденция нигезләрен.
Актлар залы әле һаман анда
Ульяновның саклый эзләрен.

Альма-матер! Безнең дә бит синдә
Матур чагы үтте гомерләрнең.
Синдә ишеттек без исемнәрен
Аристотель, Эсхил, Гомерларның.

Альма-матер! Күпме егет-кызның
Язмышын син бергә кавыштырдың.
Яшәр өчен рухи азык бирдең,
Әнкәйләрне безнең алыштырдың.

Безнең өчен Казан бишек иде,
Альма-матер – рухи анабыз син.
Инде күптән башка булсаң да син,
Саклый күңел сине сөю хисен.

Инде күптән башка статуста.
Күптән ябык татар бүлеге дә.
Ятим бала кебек калды торып,
Укучылар татар бүлегендә.

Альма-матер, бөек уку йорты –
Безнең Казан университеты.
Әрни йөрәк, күреп шәрикләрең
Белем алган өчен ярым-йорты.

## 7. Тукай

*Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман:*
*«Тор, шәкерт, җиттек Казанга, алдымызда бит Казан!»*

*Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;*
*«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»*
Г.Тукай

Күп булды үз гомеремдә
Машина әрҗәсендә
Казанга килеп кергәнем
Йолдызлы җәйге төндә.

Тезелеп киткән утлары
Җемелди Казан-суда.
Йөрәк, Тукайга кушылып,
Җилкенеп куя шунда.

«И Казан, дәртле Казан!» – дип,
Кабатлый Тукай җырын.
Каршылый Казан, кабызып
Җем-җем утлар чылбырын.

Яшьлеген читтә уздырып,
Туган җирдән аерылып,
Җаектан Казанга кайта,
Апуштан Тукай булып!

Бар иде заманнар: безне
Каршылаганда, Казан,
Мәчет манараларыннан
Әйтмәде моңлы азан.

Үзгәрде дөнья, үзгәрде.
Үзгәрде заманалар.
Түбәсенә кабат аен
Кабызды манаралар.

Тукай урамында йөрим,
Телгә килә, фаразан,
Җанны иркәләгән сүзләр:
«И Казан! Дәртле Казан!»

Тукай урамыннан киләм.
Йөрәгем сызлый яман:
Әйтерсең Тукай яшәгән
Көннәрдә йөрим һаман.

Һаман шул җимерек йортлар,
Һаман шул тап-тар урам.
Үзе күренмәс микән дип,
Тукталып карап торам.

Һаман шул трамвай юлы.
Арып беткәндә көтеп,
Буш кесә кебек шалтырап,
Трамвай китә үтеп.

Тукай музее. Трамвай,
Кыймылдый – арган-талган.
Әйтерсең бер экспонат,
Музейга сыймый калган.

Трамвайлар күптәннән юк.
Сүткәннәр юлларын да.
Күптән сүтеп ташладылар
Болгар номерларын да.

Тукай яшәгән чорлардан
Калган йортлары белән,
Тукай урамы калган да,
Калган соры П(е)ләтән.

Танырлык түгел Казанны!
Танымас иде Тукай.
Югыйсә, шул ук мәчетләр,
Манараларда – шул Ай!

Казанга килеп керәсең,
Хәзер кайтсаң ерактан,
Габдулла Тукай исемен
Йөртүче аэропорттан!

Үзгәрде ләкин заманнар
Гел кире якка таба.
Татарның Тәкъдир сәгате
Кирегә таба чаба.

Тукай урамында йөрим.
Әйтерсең әле һаман,
Тукай, газиз татарым дип,
Милләт дип янган заман.

Тукай урамыннан барам,
Тукайны уйлап барам.
И Тукай, син – йөрәгемдә
Төзәлми торган ярам.

## 8. Казан урамнары

*Дәртле Казан.*
*Таныш урамнарның*
*Ташларына басып йөргәндә,*
*Хыялларым сәяхәткә китә*
*Еракларга, узган көннәргә.*
*Гүя нәкъ мин басып торган җирдә,*
*Ат уйнатып шушы ярларда,*
*Минем бабам басып торгандыр күк,*
*Өмет баглап килер таңнарга.*

Н.Арсланов

*Тукай,*
*Җәлил,*
*Такташ,*
*Туфан йөргән*
*Урам ташларында җылы бар.*
*Сигез гасыр аша ишетелгән*
*Кол Галинең бөек җыры бар.*

С.Гәрәева

Йөрим Казан урамнары буйлап,
Исем китеп исемнәренә.
Маркин, Гассар, Шейнкман... Исемнәрен
Калдырмаган соң кемнәр генә?!

Межлаук һәм Ершов, Волков, Зайцев –
Нинди җәнлек заты болары?
Имеш, Казан азатлыгы өчен
Корбан булган халык уллары.

Гладилов, Галактионов кем?
Городецкийны кем белгән?
Голубятников дигәненең имеш,
Казан өчен гомере өзелгән.

Ә Саммер кем? Юдин, Красинны,
Тренёвны белә кайсыгыз?
Павлюхин, Петров, Петряевлар –
Болар кем соң? Яле, әйтегез.

Азин, Красин... Казанга бар нинди
Дәхелләре? Һәлак булганар?
Исемнәрен шулай яд итәрлек
Нинди батырлыклар кылганнар?

Йөрим үзәк Бауман урамында.
Уйлыйм Олуг Мөхәммәд турында.
Күрәм уйда аның һәйкәлен мин,
Нәкъ шушында, шушы урында!

Эх, күрәсе иде бу урамның
Олуг Мөхәммәд дип аталып,
Һәйкәлендә Коръән тоткан килеш
Утырганын атка атланып!

Бик күрәсем килә Сөембикә
Урамын да минем Казанда.
Һәм күрсәтер идем адресын,
Мэриягә хатлар язганда:

Сөембикә урамы, 1, диеп.
Казанымның иң төп бинасы!
Юк-бар сорау белән мэрны борчып,
Хатлар язып тормам мин ансы.

Сатып җибәргән дә ханбикәсен,
Йоклый Казан, чыкмый тыны да.
Мәйдан димим инде, юк һич югы
Урамы да, һәйкәл-сыны да,

Әле ярый үзе исән чакта
Манарасын корып калдырган.
Рәхмәтебез олы – Минтимергә –
Колшәрифкә мәчет салдырган.

Татарның күп бөек ул-кызлары,
Исемнәрен саклап тотарлык.
Харап итә ләкин безне тарлык,
Харап итә безне татарлык.

Казан урамнары буйлап йөрим.
Урап кайтам Тукай урамын.
Йөреп кайтам Сәйдәш урамыннан,
Әрнү-сагышларга уранып.

Милләтемнең ике бөек улы!
Милләтемнең ике ятиме.
Милләтемнең ике пигамбәре.
Милләтемнең ике хәдиме.

Урап кайтам Сәйдәш урамыннан.
Казан өчен кайтам хурланып.
Күңелемдә проспект итеп күрәм
Мин Тукай һәм Сәйдәш урамын!

Әллә нинди салкын, шыксыз урам.
Һәм яшәми анда кеше дә.
Бер ягында аның тоташ дивар,
Иске йортлар – икенчесендә.

Шушы урам Сәйдәш йөрәгенә
Авыр таштай кереп урнашты.
Шушы урам Кәрим Тинчуринны,
Якын дусты Фәтхи Бурнашны,

Командарм Шамил Усмановны,
Бергә йөргән күпме дусларын,
Илтеп япты Пләтән төрмәсенә,
Барсын ясап «халык дошманы».

Ачы итеп көлде аннан Тәкъдир.
Үтермәде аны, атмады,
Хәсрәт юлы булган шул урамны
Аның исеме белән атады.

И Казаным, синең хакта мактап
Күпме шигырь язган шагыйрьләр!
Барып чыксам Җәлил урамына,
Өзгәләнеп куя бәгырьләр.

Җырлый алмый диләр тоткынлыкта
Сандугачны, япсаң читлеккә.
Ничек яза алды икән Муса
Таш капчыкта иза чигеп тә?!

Көрәшмәсә әгәр җыры белән
Дошманына каршы, ул аның
Уйлагандыр шунсыз кидерәсен
Бөтен илгә коллык богавын.

Дөнья гизеп әгәр читтә йөрсәң,
Танышыйм дип шунда кул бирсәң,
Муса диләр шундук, Җәлил диләр,
Татар булуыңны белдерсәң.

Батыр диләр, бөек шагыйрь диләр,
«Җырларым»ны яттан сөйлиләр.
Таш капчыкка япкан сандугачны
Кыю лачын белән тиңлиләр.

Читкә чыксам, юлым уңсын диеп,
Җәлил үзе гүя кайгырта.
Ул үзенең горур җыры белән
Милләтемнең йөзен яктырта.

Ә Казанда аның урамына
Барып чыксам, китәм имәнеп.
Өч тыкрык, биш чат булып чыга,
Авыз тутырып, урам дигәнем.

Йөрим Казан урамнары буйлап.
Уйлап йөрим ул һәм кызларын.
Шулар белән йөрим горурланып,
Шулар өчен йөрим сызланып.

## 9. Хатимә

*Рус илендә без әсәрле, эзле без,*
*Тарихында бер дә тапсыз көзге без.*
*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*
*Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,*
*Без шаярыштык, вакытлар алмашып.*
*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.*
*Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*
*Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –*
*Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!*

Г.Тукай

И укучым, түземлегең өчен сиңа
Рәхмәтемне җиткерәсем килә минем.
Аллаһ әкбәр, лә иләһә иллэл-лаһ, дип,
Азан белән аны башлап киткән идем.

Рәхмәт сиңа аны укып чыккан өчен.
Ошадымы, белмим, сиңа ошбу әсәр.

Инде менә җиттек килеп хатимәгә.
Җитте вакыт әсәремә йомгак ясар.

Казаныбыз тарихы зур, мөмкинме соң
Колачларга аның барлык кичкәннәрен.
Искә алдым мин аларның азын – бары
Хәтеремне тырнап искә төшкәннәрен.

Әйе, әйе, язмадым гел мактау гына,
Лаек булса да Казаным макталуга.
Сөйләр идем мин Казаным тарихында
Халкым күргән михнәтләрнең барысын да.

Түрәләрдә дәвам итә әле һаман
Яшәү уйлап: тотса Мәскәүләр, дип, якаң.
Урыс белән яшибез дус-тату булып,
Зарланырлык түгел бездән һич ул яктан.

Аз-маз гына яздым Казан ханлыгын да.
Узды Казан шәһәренә мең яшь тулып.
Казан шанын еракларга яңгыраткан
Тәүге ханы бара ләкин онытылып.

Күп калмады, киләчәк ул матәм көне:
Куячаклар һәйкәл Явыз Иоаннга.
Мескен татар курка һәйкәл торгызырга
Казан дәүләтен төзегән бөек ханга.

Курка татар, бакча ясап, бастырырга
Сөембикә-ханбикәнең мәрмәр сынын.
И татарым, ханнарыңны зурлап шулай
Һәйкәл кую сиңа язык микәнни соң?

Сөембикә урамы, йорт номеры – 1
Адресына хат язарга уйлап торам,
Сәйдәшев һәм Җәлил өчен, әфәнделәр,
Табыгыз дип, үзләренә лаек урам.

Казан, Казан – Татарстан башкаласы!
Җир йөзендә барча кавем белә сине.
Кем ул сөйли рус иле дип Россияне?
Россия ул – урыслашкан татар иле!

Казан аның башкаласы. Россияне
Казанстан дип мин бүген атар идем.
Кай урыстан сорасаң да әйтер кебек:
«Өч-дүрт буын элек мин, – дип, – татар идем!»

Мин яратам сине, Казан, нурлы калам!
Тумасам да, синдә үтте гомер юлым.
Җырым белән сине таг(ы) да зурлар өчен,
Нурлар өчен җан атучы мин бер улың!



Рәфкать Шаһиев

# ГАЙШӘ-ФАТЫЙМА

ПОВЕСТЬ

*Кешене ышаныч дигән бөек көч*
*яшәтә, шул аңа егәр бирә.*
*Андый көч, ышаныч – иман.*
Әбҗәд, иман шарты һәм
утыз өч аять

Кыз бала өчен әнинең иң кирәк вакытында ятим калды Гайшә. Алай дисәң, әнинең кирәкмәгән чагы бармы икән? Җидене бетергән иде ул бу елны. Әнисе Фатыйма, озак ятмыйча гына, бер атна эчендә китеп барды. Гайшә – өч кызның иң кечесе. Ике апасы инде тормышка чыккан, үз гаиләләре бар. Ә Гайшәгә кадәр туган икесе бала вакытта ук Ходай хозурына күчкәннәр. Шуңа Гайшәне әти-әнисе иркәләп кенә үстерделәр. Гайшә дә әти-әнисен яратып туймый иде. Әнисе авырып киткәч тә, янынннан китмәде ул. Апалары чиратлап килеп торсалар да, Гайшә, төнлә әнисе ята торган агач карават кырына чүмәшеп, башын әнисенең аяк очына куеп арып йоклап китә. Шулай әнисе терелер кебек иде Гайшәгә. Терелә аның әнисе, терелә. Көчле, сабыр хатын бит. Алай гына да түгел, атаклы Мөшәрәф мулла кызы бит әле ул. Өченче көн күрше Миңсәрвәр әби хәл белергә кергәч: «Балам, тәһарәтем дә бар, өс-башым да чиста, әллә булмаса ясин укыйммы? Файдасы тияр, җиңеләеп китәрсең бераз, – дигәч, – Сәрвәр астай, иртәрәк булыр, вакыты җитмәгән әле, мин үзем әйтермен», – диде. И куанды инде Гайшә әнисенең шул сүзләренә, и шатланды. Димәк, әле өмете өзелмәгән, ризыгы бетмәгән болай булгач. Әнисе белми сөйләми аның. Тик әтиләре генә җилкәсенә аскан йөген сала алмаган төсле, башын аска иеп, аякларын көчкә сөйрәп йөри. Сугышларны кичеп кайткан Хөсәен, димәссең.

Нииндидер яшел болында күбәләкләр куып йөргәндә, әнисенең тирән-тирән итеп тын алганына уянып китте Гайшә.

---

Рәфкать ШАҺИЕВ (1968) – *язучы; Р.Төхфәтуллин, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Сагыну исе», «Элеккечә түгел без генә» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

– Әни, әллә эчәсең киләме? – диде ул. – Хәзер менә шушы чүпрәкне юешләп, башта бит-кулларыңны сөртеп алыйм әле тиз генә.

– Шулай ит әле, кызым, чиста булсын, – диде Фатыйма, ничектер елмаеп, гел сау-сәламәт кеше кебек. Тавышында бер сыкрану, ыңгырашу калмаган иде. Гайшәгә канатлар үскәндәй булды.

– Әле дә ярый син бар, кызым, – диде Фатыйма, бит-кулларын сөрткәннән соң. – Кызым, син хәзер минем өс-башымны да алыштыр инде, матур булып ятыйм.

Гайшә әнисенең өстенә, ак җирлеккә вак зәңгәр җитен чәчкәләре төшкән күлмәген кидерде. Чәчләрен тарап үргәннән соң, ак яулыгын таратып бәйләтте дә ике битеннән үбеп алды. Бигрәк матур инде аның әнисе.

– Кызым, ятканда, чәчкә эләгеп җәфалый, син ипләп кенә алкаларымны салдыр әле, – диде Фатыйма. – Юганда-ниткәндә җайлы булыр.– Әллә ничек җаным тарыга, менә бу беләзегемне дә салдыр әле, яме, – диде әнисе. – Хәзер инде бар, Сәрвәр астайны дәшеп чык. Әни чакыра диген.

Гайшәнең йөзендәге елмаюы юып алган кебек юкка чыкты. Ул әнисенең күзләренә карады. Аларда эчкерсез моңсу елмаю иде. Гайшә тиз генә, тыкрык аша торган Миңсәрвәр карчыкка йөгерде.

– Балам, бер-бер хәл юктыр бит, – дип каршы алды аны карчык.

– Юк, юк, киресенчә, әнинең кәефе яхшы бүген. Гел елмаеп кына тора. Чәчләрен дә үрдем, өс-башын да алыштырттты. Менә әле, кереп чыксын дип, сине чакырды, – диде Гайшә.

– Хәзер кереп җитәрмен, кызым. Бар, син әниең янына чыга тор, – диде карчык, күңеле нидер сизенеп.

Гайшә ишекне ябуга, Миңсәрвәр тәһарәт яңартты. Алъяпкычын салып, ике яклап, ыштан бөрмәсенә кыстырган күлмәген төзәтте дә, ишегенә таяк кына терәтеп, Фатыймаларга кереп китте.

– Кызым, бар, Ташкоега чишмә суына төшеп мен, – диде Фатыйма, авырлык белән генә тын алганын кызына сиздермәскә тырышып. – Нәрсәдер үзебезнең чишмә суын эчәсем килеп китте.

Гайшәнең үсмер йөрәге нindидер хәтәр нәрсә якынлашканын сизенгәндәй, көзге яфрак кебек калтыранып куйды. Ишек төбенә җиткәч, ул әнисенә тагын бер борылып карады. Аларның карашлары очрашты. Әнисенең күзләренә мөлдерәмә ярату тулган иде. Фатыйма елмайды.

Кыз көянтә-чиләкләрен асып тыкрыктан Ташкоега төшеп китте. Җәйнең кыл уртасы. Су буендагы Талип талларыннан әрекмән яфракларына тып та тып бал тама.

Гайшә чиләкләрен тутырып, чишмәдән су алды да йөгерә-атлый өйләренә ашыкты. Аның тизрәк әнисе янына кайтасы килә иде.

Гайшә чишмәгә дип чыгып китүгә, ишектә Миңсәрвәр карчык күренде.

– Ни хәлләрең бар, Фатыйма балам? – диде ул, тыныч булырга тырышып.

– Йомгак чорналып бетте, Аллага тапшырыйк, Сәрвәр астай. Син ясин чык инде миңа. Менә хәзер вакыты җитте, – диде Фатыйма, кипшенгән иреннәрен ялап. – Мендәрем астында бирнәм белән килгән Коръәнем, шуңардан чык.

Ул әкрен генә күзләрен йомды.

Карчык юатып, бер сүз дә әйтмәде. Чөнки Фатыйманың күзләрендә нур бетмәсә дә, күз алмасының акларына кадәр сары суккан иде. Миңсәрвәр карчык ипләп кенә Фатыйманың мендәрен күтәреп, китапны алды. Урындыгын җайлап, аның күкрәк турысынарак утырды да, бисмилла әйтеп, китапны ачты.

«...Фәсубухәәнәлләзии бийәдиһии мәләкуту кулли шәйъиү вә иләйһи турҗәгүүн. Амин», – дип, Миңсәрвәр карчык кулларын догага күтәргәндә, ишектән Гайшә килеп керде.

– Ходай хәерле кылсын. Аллаһы теләсә, барысы да әйбәт булыр. Ходай кушып, менә җиңеләеп китәрсең әле, – дип сөйләнә-сөйләнә, карчык Коръәнне кайдан алган булса, яңадан шул урынга куйды.

Көтүләр кайтып, малларын җыеп япканнан соң, Гайшәнең олы апасы Гаҗилә килде. Миңсәрвәр карчык чыгып, азрак торуга, Фатыйма тирән-тирән тын алып, күзләрен ачмыйча гына ята башлаган иде инде.

– Син укы, укы, кызым. Бабаңнан ятлаганнарны укы, – дип пышылдады ул. Гаҗилә әнисе ишетерлек итеп, иман кәлимәсен әйтә башлады. Фатыйма кипкән иреннәрен көчкә генә кыймылдатып, кызы артыннан кабатлады. Гайшә исә, әнисенең аяк очында тезләнеп утырган килеш, апасына ияреп «ля иляһы илла Аллаһы» дип, мышык-мышык еларга тотынды. Фатыйманың тын алуы әкренәйгәннән-әкренәя барып тынды. Гаҗилә укудан, Гайшә елаудан шып туктап, нәрсә булганын аңышмыйча, әниләренә төбәлделәр. Фатыйма, күзләрен зур итеп ачып, мөлдерәтеп кызларына карады да әкрен генә күзләрен йомып, бөтенләй тынды. Ире Хөсәен белән кызы Гамилә йөгерә-йөгерә өйгә кайтканда, Фатыйманы аяклары белән кыйблага каратып, сузып куйганнар иде инде.

Гайшә әнисенең аякларына капланып үкседе.

Әнисе шулай үзе белән ашның тәмен, өйнең ямен, җылысын алып китте.

Авыр, ләкин ни хәл итмәк кирәк. Апалары Гаҗилә белән Гамиләнең үз гаиләсе, үз оя-куышы бар. Иң авыры Гайшәгә калды: үзенең ятимлеге, әтисенең ялгызлыктан бәргәләнүе. Әтисенә авыр булмасын дип, Гайшә яшен күрсәтмәскә өйрәнде. Инде һич тә түзәрлеге калмаганда, качып кына, әнисенең истәлеге булган Коръәнне кулына ала, шуннан җанына тынычлык таба торган булды.

Ике ел дуадак каз кебек каңгырып йөргәннән соң, әтисе кызларын җыеп, өйләнү хакында сүз кузгатты. Каршы килүче булмады. Ятимлек ачысы, өйгә үги әни килгәч, тагын да куерып китте, җанга тагын да авыррак була барды. Гайшәнең балалык белән үрелгән шат үсмер чагы, әнисенең җеназасын алып китәргә ачкан капкадан чыгып, каядыр югалды.

Бөтен юанычны эштән тапты Гайшә. Җиде классны тәмамлаганлыкка алган таныклыгын, такта чәйдән бушаган укага төреп, сандыкка салды да колхоз эшенә чыкты. Бер атна гына бригад эшенә йөргән иде, ферма мөдире Гарифҗан абыйсы:

– Үскәнем, Хәдичә апаңның кулы гөбе кебек шешеп чыкты. Аның урынына кардага сыер саварга чыга алмассыңмы икән? – диде. – Тыңла, зинһар, берәүне дә ризалата алмыйм. Кулының шеше кайтканчы гына ризалаш инде.

– Ярар, – диде Гайшә. Кеше арасында әз булса да хәсрәтләре таралып китәр. Сыерлар арасында елаганы да күренми. Күрсәләр дә, чыш-пыш сөйләмиләр.

– Кайчан барырга, Гарифҗан абый?

– Бүген кичке савымга кил инде син, үскәнем. Җинан апаң Хәдичәнең чиләкләрен, феләкләрен күрсәтер.

Баштагы ике көндә кеше рәтенә савып өлгерә алмый интекте Гайшә. Шомырт белән Буян һич кенә дә сөтләрен бирмиләр. Хәдичәнең исенә, төсенә ияләнгән әлеге ике сыерның Гайшәне тыңлыйсылары килми иде.

– Гайшә гөлкәем, эштән кайтканда, Хәдичә апаңның яулыгын кереп ал әле син. Кайсы мал чит кул тотынса, сөтен төшерми торган була. Без үзебез дә шулай итә торган идек, йә яулыгын бәйлибез, йә халатын киябез, – диде Нәмига апасы.

Гайшә кергәндә, Хәдичә кулына ниндидер үләннәр ябып, шуларны бәйләргә азапланып утыра иде.

– Ходайның хикмәте, ничекләр генә бәйлим икән инде дип уйлап кына куйган идем. Аллаһ бар шул ул. Әйдә, уз, кызым. Менә шуны гына бәйлә, зинһар. Их, шул ялгызлыклар, – диде Хәдичә, уфтанып. – Хәзер чәйләп алырбыз.

Габдулла абзый Хәдичәсе диләр аны авылда. Бер тапкыр да тормышка чыкмыйча ялгыз картайган карт кыз. Чалгы чүки, печән чаба, утын яра, ат җигә, сыер сава – колхозның тоткасы.

– Хәдичә апай, Шомыртың белән Буяның һич кенә дә сөтләрен төшерәселәре килми. Нәмига апа, «Яулыгын булса да сорап тор, Хәдичә исе килгәч җайланып китәләр алар», – дигән иде. Шуңа гына керүем.

– Алай гына булса ярар. Мә, истә чагында алып куй, аннан онытыла да башлар. Әйдә, әйдә, кунак кызы кебек торма, ал чынаякларны.

Гайшә, Хәдичә апасы биргән яулыкны артка чөеп бәйләде дә, чәй ясарга керешт е. Хәдичә, ниндидер эш тапкан булып, Гайшәне күзәтте. Йөреше, хәрәкәтләре, бөтен булмышы белән әнисе Фатыйманы хәтерләткән Гайшә, яулыкны чөеп бәйләгәч, тач әнисе булды да куйды. «Гайшә-Фатыйма булган бит бу», – дип эчтән генә уйлап куйды Хәдичә. – Сагынмаклык өчен туган икән, – дип, Гайшәгә күрсәтми генә күзләрен сөртеп алды.

Үзеннән өлкәннәр белән эшләү Гайшәгә күп нәрсә бирде. Сабырлыкка, кеше алдында сер бирмәскә өйрәнде. Әнисенең: «Авызың тулы кара кан булса да, ятлар алдында түкермә», – дип әйтә торган сүзенең мәгънәсен менә шушында аңлады ул. «Эшкә өйрәтеп үстермәгән», – дип, әнисен начар исем белән телгә алмасыннар өчен, кайда нинди эш бар, шунда йөгерде, батырып эшләде.

Беркөнне көтүләр кайтып, ябасын карап япканнан соң, арып-талып, Гайшә өйгә кергәндә, үги әнисе Закирә Фатыймадан калган сандыктан нәрсәдер эзләп маташа иде. Гайшәнең кергәнен абайламый калды булса кирәк. «Закирә апа, нәрсәдер югалттыңмы әллә?» – дигәненә сискәнеп китте. Сандык капкачы, кулыннан ычкынып, шапылдап ябылды. «Абау, Гайшә, куркыттың бит, җаным», – диде Закирә, әйбер урлап тотылган кеше кебек уңайсызланып.

– Анда әнинең төсе итеп саклап тота торган кием-салым да, үз кулы

белән миңа бирнәлек итеп суккан ашъяулык-тастымаллары гына, – диде Гайшә.

– Ай Аллам, мин ул киемнәргә калмаган инде, Гайшә. Бер көнне әтиең Фатыйманың Коръәне бар дип сөйләнгән иде. Шуны гына карый идем.

– Закирә апа, син, зинһар, ачулана күрмә. Әни аны үзе исән чагында да кешегә бирмәде. Ясинны да шул китаптан чыгарга кушкан. Ачуланма, бирә алмыйм мин аны сиңа, – диде Гайшә, эчке бер тынычлык саклап.

– Кит моннан, комсомол башың белән шул хан заманыннан калган, тетелеп беткән китапка ябышып ятмасаң. Төннәрен Коръән актарып утырганыңны белсәләр, идарәдәгеләр дә рәхмәт әйтмәсләр. Харап икән, миңа бирсәң, кырыен кимермәс идем, тычкан түгелмен. Эчеңә бәйлә инде алайса, – диде дә почмак якка кереп китте. Гайшә сандык янына тезләнде, азрак сандыкны кочаклап торды. Аннан сандыкны ачып җибәрде. Борынга әнисе исе килеп бәрелде. Гайшә иплән кенә әнисенең Коръәнен алды да күкрәгенә кысты. Шундый да җылы, шундый да рәхәт, ә җанда әйтеп аңлата алмаслык юксыну ачысы иде. Вакыт-вакыт әнисен юксынудан урамга чыгып кычкырырдай була да, тиз генә шушы китапны ала. Әнисенең җаны шушы изге китапның Ясин сүрәсенә кереп урнашкан кебек Гайшәгә. Алай гына да түгел, Гайшәнең бөтен сере шушында. Шушы дусты гына бөтен хәсрәтне, бөтен шатлыкны сыйдыра.

– Кызым, әйдә, ашарга чык. Әле бит син эштән кайтканнан соң, һаман ашамаган килеш йөрисең.

Әтисенең тавышы Гайшәне айнытып җибәрде.

– Чыгам, чыгам, әти, хәзер, – дип ул, китапны әнисе кебек итеп, ак киндер намазлыкка төрде дә сандык төбенә салды. Аннан иплән кенә, сандыкның капкачын ябып, өс-башын рәтләгәч, табынга чыгып утырды.

Шул көнне Гайшә белән үги әни арасыннан кара мәче үтте. Кара-каршы талашмадылар, закон эзләп, сәвиткә бармадылар, тик сердәшләр дә булмадылар. Эләгешеп алырга Закирә җай эзләп кенә торды. Ә тормыш булгач, төрле вакыт була. Теләгән кеше җаен таба. «Хастын күрсәң, астын күрәсең», дия торган иде Миңсәрвәр карчык. Гайшә аңламый иде элек бу сүзләрне. Менә хәзер аңлый башлады. Хәзер ул бик күп нәрсәне аңлый. Үги тормыш рәхәт булса, экияттә дә рәхәт итеп язарлар иде аны. Әкият ул әкият түгел, чын икән.

***

Ерак утардан икенчесенә күчкәндә, сыерларның су эчә торган улакларын күчерергә дип, Гарифҗан абый председательдән тракторы белән Минвәлине сораган иде. Ялгызы төяп бетерде улакларны трактор арбасына. Гайшә булышыйм дип янына барган иде, кычкырып көлде.

– Гайшә, синең чәең тәмле була, диләр, бар булмаса миңа да ясап чык әле син. Улак төяү кызлар эше түгел ул, – диде Минвәли.

– Кем әйтә аны тагын? – дигән булды Гайшә.

– Сүз иясе белән йөрми инде, – дип кычкырды Минвәли, трактор гөрелтесен күмеп.

– Менә анысы начар, Минвәли абый. Сүз иясе белән йөрсә, дөрес була ул. Ә болай... әллә мин тәмле ясыйм, әллә Нәзирә апа. Ярар, әз генә ял итә

тор, болай мактагач, ясап карыйм инде, – дип, Гайшә савымчылар йортына кереп китте.

Чыннан да, тәмле пешерә Гайшә чәйне. Башкаларның савып бетергәннәрен көткән арада Сәлимә тау итәгеннән әллә ниткән генә үләннәрне җыя да шуларны сөт өсте белән салмак утта пешереп ала. Эчеп туймаслык була.

Гайшә чәй күтәреп чыкканда, Минвәли иртәнге кояш нурларына изрәп, җир җылысына оеп, йокыга китеп бара иде. Гайшә, дәшәргәме, юкмы дип басып торганда, буш чиләкләрен юри шалтыратып, әллә каян гына Сәкинә килеп чыкты.

– Әстәгъфирулла, кызлар. Улаклар күчерергә Минвәли килде дигән буласыз. Әзрәк сыер астыннан башларыгызны күтәрегез инде. Кызыбызны урлап китәләр бит, – дип, бөтен урман буена шәрран ярды.

Сәкинәнең тавышына Минвәли сикереп торып, чак кына Гайшәнең кулындагы чәйне түртеп төшермәде. Минвәли сүзсез генә чәйне эчте. Аннан соң, Сәкинәгә әйткән булып, савымчы хатыннар ишетелерлек итеп:

– Мондый да тәмле итеп чәй пешерүче кызны урласаң да, начар булмас, – диде. Гайшә авыз ачып, сүз әйтмәде. Чәйне эчеп бетергәнен көтеп торды да буш кружканы алып өйгә таба юнәлде.

Минвәли инде егерме бишне тутырды. Күптән өйләнергә дә исәбе, тик авыру әнисе булгач, кызлар аңа тормышка чыгарга бик атлыгып тормыйлар иде.

Ерак утарга улаклар күчерергә баргач, Гайшәне күреп, Минвәлинең эченә корт керде. Үги әни белән бик борчаклары пешмәгәнен дә, уңганлыгын ишеткән булса да, ничектер артык игътибар бирмәгән иде. Ә менә ул пешергән үлән чәен авыз итеп карагач, күңеле күкәй салды Минвәлинең. Кайда эшләсәләр дә, Минвәли Гайшә белән күрешергә җай таба башлады.

Беркөнне кибеттә ипи чиратында торганда, Сәкинә Закирәгә:

– Кызый, нәрсә соң әле, туйлар кайчанрак? Анда Минвәли артын өзгән кигәвен урынына кайнаша Гайшә тирәсендә. Исе чыкканчы, җибәрү ягын карагыз инде, – диде.

– Башка кайгың булмаса, аның өчен бер генә дә кайгырма син, Сәкинә. Ис чыгара торган нәсел баласы түгел, – дип, Закирә бик тиз авызын каплады. Кеше арасында үги кызын шулай яклаган ананы кем инде начар дип әйтә алсын? Өйдә Гайшәне көндәш күрсә дә, кеше арасында сер бирми иде ул. Үзе Сәкинәгә шулай диде, үзе эчтән сөенеп куйды Закирә. Җайлап кына, Хөсәенгә бу хакта әйтергә кирәк, дип уйлады ул.

Каткак, кара туң җирне каплап, беренче кар төшкән көн иде. Көн дип, җомга киче иде. Кичке ашны бүлеп, табынга утырганда, ишек шакыдылар.

– Керегез, кер. Бу вакытта ишек бикләп утырмыйбыз, кайсыгыз анда? – диде Хөсәен, урыныннан кузгалып. Ул арада ишек ачылып китте дә, елмаеп, Минвәли килеп керде.

– Нихәл, Хөсәен абзый, – диде ул, ике кулын сузып. Исән-сау гына яшәп ятасызмы?

Гайшә каушады. Табын янында тиз генә торды да, этиләре хәл-әхвәл

сорашкан арада, эчке якка кереп китте. Закирә дә чаршау артына кереп югалды, үзе шыпырт кына ирләр сүзенә игътибар итте.

– Әйдә, уз, Минвәли. Мактап кына йөрисең икән, әле генә табын янына утырган идек. Әй, тараканнар кебек кая качтыгыз?! Әйдәгез әле, Минвәлигә аш бүлегез. Кызым, Гайшә, син кайда?

– Гайшә, этиең дәшә бит, – дип ысылдады Закирә чаршау артыннан гына.

Гайшә кыенсынып кына чыкты да, почмак яктан аш бүлеп, Минвәли алдына китереп куйды. Үзе тагын тиз генә эчке якка үтте.

– Әйдә әле, Минвәли, тартынып торма. Эшләр барамы? Колхозны алга җибәрәбезме? – диде Хөсәен, ит кимереп.

– Тырышабыз инде, Хөсәен абзый. Бөтенесе дә авылны ташлап, нефтьче булып китсә, авылда кем эшләр соң? – диде Минвәли, авызына капкан ашын йотып. – Аннары, әнине калдырып китүе дә уңайсыз. Самат кыстап караган иде Кичүгә. Нәрсәдер барасы итмәдем. Башы күренсә дә, башка авыл бит. Болай җае чыкканда, өйгә кайтып, әнинең хәлен белә алам, – диде ул, тәмләп ашый-ашый.

– Әниеңне ташламавың әйбәт. Эшләгән кешегә кайда да эш бетми ул. Тик колхозда ялы юк, шунысы авыр.

– Баш исән булсын, Хөсәен абзый. Эштән курыккан юк анысы, – диде дә туктап, ничек сүз башларга белмичә торды Минвәли. Аннан бөтен батырлыгын җыеп:

– Хөсәен абзый, мин бит олы бер эш белән килдем. Сез каршы килмәсәгез, Гайшә белән башлы-күзле булырга иде исәп. Нәселне беләсең, яман аты белән даныбыз чыкканы юк. Алтын-көмешкә күмәрмен дип, вәгъдәләр бирә алмыйм, ләкин мохтаҗлыкта яшәтмәм, тел белән дә, кул белән дә рәнҗетмәм.

– Алай икә-ә-ә-н, – диде Хөсәен абзый. – Хәерле булсын. Үзе нәрсә ди соң? Кызым, Гайшә, син ишетәсеңме безне?

– Ишетәм, әти. Син каршы килмәсәң, мин риза, – диде Гайшә эчке яктан.

Әлеге сөйләшүне шыпырт кына почмак якта тыңлап торган Закирә куанычыннан нишләргә белмәде.

Ашлар ашалып бетеп, дога кылганда, никах көнен инде тәгаенләп куйганнар иде.

***

Гайшәне ак мендәрләргә бастырып, бал-майлар каптырып каршы алучы булмады. Трактор кабинасыннан төштеләр дә бирнәләргә кагылмыйча, өйгә уздылар. Минвәли ишекне ачып, Гайшәне уздырды, аның артыннан үзе керде.

– Исәнмесез, – диде Гайшә куркыбрак һәм сүзсез генә елмаеп, Минвәлигә карады.

– Балалар, сезме? – диде чаршау артыннан Гадилә карчык.

– Без, әни, без, – диде Минвәли һәм Гайшәне җитәкләп, әнисе ята торган якка узды.

Гадилә карчык үрелеп, чаршауны ачты.

– Исәнме, әни, – дип, Гайшә Гадилә карчыкка ике кулын сузды.

Әни! Ничек рәхәт бу сүзне әйтүе. Җанга гына түгел, хәтта авызга да

рәхәт икән бит. Бу сүзнең җылылыгы, йомшаклыгы! Әйткән саен әйтәсе килеп кенә тора. Юк, бу сүзне әйтүнең рәхәтен энилеләр белмиләрдер. Белсәләр дә, аңлап җиткерми торганнардыр.

– Төкле аягың белән, балам. Хәерең, бәхетең белән кил! Улымны санлап, минем авыру икәнне белеп безнең йорт бусагасын атлап керүеңә рәхмәт. Бу йортта сиңа да рәхәт булсын, миңа да рәхәт булсын. Икебезгә рәхәт булса, безнең яндагыларга начар булмас, – дип, догага кулын күтәрде. Гайшә белән Минвәли дә янәшә урындыкларга утырып, кулларын күтәрделәр. «Ходаем, шушы күтәргән кулларыбызны буш итмә, тигез мәхәббәт, бәхет бир», дип пышылдады Гайшәнең иреннәре.

– Улым, Гайшәне язмыш шактый елатты. Син елатма. Ходай каршында ир хакы гына түгел, хатын хакы да бар. Шуны хаклап яшә. Гайшәне нахакка елатсаң, риза-бәхил түгел. Йорт җылысы хатында. Син балам, Гайшә, бүгеннән йортны үз кулыңа ал.

– Әни, рәхмәт яхшы сүзеңә. Ышанычыңны аяк астына салмам, – дигәндә, Гайшәнең иреннәре дерелдәп куйды.

– Хуҗабикә булсаң, хуҗабикә бул, әйдә, чәй көйләп җибәр алайса, – диде бу моңсу сөйләшүгә дәрт өстәп Минвәли. – Менә шушында хәзер өстәл көйләп куябыз да, өчәүләп бергә чәй эчәрбез.

– Ай Аллам, сиңа әйтәм, безнең бит бөтен бирнә тракторыңда калган, – дип көлеп җибәрде Гайшә.

– Яшьлек шулай инде ул. Улым, бар, син алып кер, Гайшә чәй куя торыр, – дип, улына күрсәтми генә, Гадилә карчык яшь киленнең җиңеннән тартты. Минвәли тиз генә күздән югалды.

– Иреңне – ир, мине – әни ит, балам. Тормышта төрле чак булыр, кешегә сер бирмә. Сине кызганган булып тыңлар да, яныңнан киткәч, «шул кирәк сиңа», дияр. Шул сүземне исеңнән чыгарма, – дип, ул ялварулы моңсу күзләрен килененә текәде. Гайшәнең күзләреннән мөлдерәмә яшьләре бәреп чыкты.

– Кайда син, мәле, мендәр-ястыкларны алып куй, – диде ишектән башын тыгып Минвәли. – Әле сез һаман аерыла алмыйсыз икән, мин инде чәй эчәргә җыендым.

***

Гайшә эшләп туймый торган җан. Инде эштән кайтканнан соң, мал-туар яныннан кереп, аш-су хәстәрләп ашагач, тагын берәр эш таба. Аркасын түшәккә терәп, гәҗит карап утырган Минвәли вакыт-вакыт: «Ничек арымый да, ничек гел эшлисе килеп тора икән моның?» дип уйлап куя иде.

Гайшә үзенең авырга калганын белгәч, сөенеченнән елап җибәрде. Шатлыгы эченә сыймады. Минвәлинең эштән кайтканын көтеп арып бетте. Ире исә, Гайшәдән дә ныграк куанды.

– Гайшә, авылда миннән дә бәхетле кеше юктыр. Берүк үзеңне сакла, – диде ул.

– Син кешегә әйтә күрмә. Үзем дә куркам. Чокырны сикергәнче, алдан «хоп» димик. Алла сакласын.

Бу шатлыкны каенанасы белән уртаклашасы килсә дә, түзде. Вакыты җиткәч белерләр дип, шатлыгын җанына яшерде. Кеше күрмәгәндә генә,

намазлыгын да сүтмичә, Коръәнне күкрәгенә кысып җанына тынычлык, рәхәтлек алды.

Гайшәдәге үзгәрешне Гадилә карчык үзе сизде.

– Гайшә, балам, түгәрәкләнеп киткәнсең бугай. Исәнлек белән табып, тигезлектә үстерергә Аллаһ насыйп итсен. Уңганлыгың алдан йөгерә. Сакланыбрак йөре, күз тидермәсеннәр, – диде ул беркөнне. – Пункытка барып, Гыйльмери килененә күрен.

Бу яңалыкка, әнисе әйткән Гыйльмери килене – авыл фельдшеры Лениза да куанды. Гайшәне исәпкә куйганнан соң, карап-танышып чыгарга бер китап биреп җибәрде.

Каенанасы эчке якта яткан булса да, өйдә әллә ниткән рәсемле китап актарып утырырга уңайсызланды. Мунчага китте. Карындагы бала рәсемен күргәч, Гайшә чак кына кычкырып җибәрмәде. Әстәгъфирулла, кара әле, сәҗдәгә тезләнгән кебек бит бу.

Лениза янына күренергә баргач, Гайшә:

– Кара әле, бөтен бала да карында шулай сәҗдәгә тезләнеп торамы? – диде.

Лениза башта аңламый торды. Аннан соң гына:

– Ни чыкмаган синнән чыгар. Әйе инде, бөтен бала да карында шулай ята, – диде.

– Минеке дәме?

– Юк, синеке аягүрә кыямда басып тора һәм биш вакыт намаз укый, ди.

– Укыйдыр, укыйдыр, Лениза. Тугыз ай буе сәҗдәдә ничек намазсыз булсын.

Соң да түгел, иртә дә түгел, үз вакыты җиткәч, Гайшә тупырдап торган кыз бала алып кайтты.

– Кыз бала булуы бик әйбәт. Игелекне кыз баладан көтәр заман килер сезгә. Имезгәндә, балаңа бәхет кенә сорама, тәүфикъ та сора. Үзе бәхетле булып та, ул бәхеттән сезгә өлеш чыкмаска мөмкин, балам. Тәүфигы булса, бәхете дә булыр. Ул бәхеттән сезгә дә өлеш тияр.

Гадилә карчык үзе Гайшәгә сөйләде, ә кипкән, коргаксыган куллары, килене аның күкрәгенә китереп салган нарасыйны иркәләделәр.

***

Бәрәңгеләрне алып, урнаштырып бетергән көннәр иде.

– Әни, эшкә киткәнче мин әтиләргә барып, хәлләрен генә белеп килим әле, – диде Гайшә каенанасына.

– Бар, бар. Миннән дә күп итеп сәлам әйт. Берәр нәрсә хәстәрләргә идең, буш кул белән төп йортка бару килешми. Кичә оеткан катыгыңны булса да ал, кодагыйдан ару түгел.

– И-и, баш инде үзеңдә, әни. Син ничек шулай булдыра аласың соң?!

– Гайшә, балам, киленем булса, телемне әйләндереп, авыр сүз әйтмәс идем, дип елаган чакларым әз булмады. Барысы да үтте инде. Ходай хәерле кылсын. Шуңа да сине рәхәт яшәтәсем килә, – диде әнисе.

– Рәхмәт, әни! Алайса, мин, теге катыкны алам? – дип елмаеп, каенанасына карады ул. – Без озак тормыйбыз, хәзер кайтабыз.

Гадилә карчык, бала җитәкләгән киленен, җылы карашы белән озатып

калды. Атлап йөрүләре үк нык шул килененең. Ашаса – батырып ашый, эшләсә – җир җимертеп эшли, әйтсә – ике сөйләргә урын калдырмый. Гадиләнең үзенә охшаган.

Гайшә килгәндә, этисе бакча якта нәрсәдер казына, ә Закирә апасы тавыкларга пешергән бәрәңге төя иде.

– Нихәл, Закирә апа? Әнә, кара әле, кызым, безнең әби тавыклар сыйларга йөри бугай, – диде Гайшә.

– Атакаем, кемнәр килгән безгә, – дип сөйләнә-сөйләнә, Закирә алъяпкычына кулларын сөртеп, Нәсимәне кулына алды. – Әйдәгез, өйгә узыгыз.

– Бабасы, кайда йөрисең син? Кызларыңны каршыла, – диде Закирә, бакча якка таба карап.

– Монда, монда, – дип сөйләнеп, бакча яктан этисе килеп чыкты. – Нихәл, кызым, – диде ул, ике кулын сузып. Өйдәгеләрең исән-саулармы?

– Аллага шөкер. Әни сәлам әйтте.

– Үзенә дә Ходай сәламәтлек бирсен, – диде Хөсәен.

– Әйдәгез, өйдә дә сөйләшеп була, – диде Закирә, Нәсимәне җитәкләп.

– Закирә апа, менә бу катыкны алып куярсың әле, әни бирде, – диде ул, галошын салып.

Өйдә таныш ис иде. Һаман шул балачак исе. Әле дә югалмаган, бетмәгән.

– Менә, син килергә булган икән. Кабакны кырып, шуңардан коймак пешергән идем. Авыз итеп кара әле. Без картларның хәзер йомшак нәрсә ашыйсы килә бит. Әзрәк аш төрләндерү булсын дигән идем этиеңә дә. Көн саен умач белән токмач та туйдыра, – дип, Закирә чәй табыны көйләргә тотынды.

Чәйләр эчкәч, Гайшә Ташкоедан су алып кайтты да:

– Озак булдым инде, әни югалткандыр. Ярар, киттек, исән булып торыгыз, – дип, ул бер кулына кызын, икенчесенә алмалар салган сеткасын күтәреп, йөгерә-атлый Хафиз тыкрыгыннан гына өйләренә ашыкты.

– Без бу, әни. Югалттыңмы? – диде ул керә-керешкә.– Өйдән чыгып китсәң, вакыт үтә шул. Ничек хәлләрең, әни?

Гайшә Гадилә карчыкка таба иелде. Ул юрганын башыннан ук бөркәнеп яткан иде. Карчык Гайшәнең тавышына юрган астыннан башын чыгарды.

– И-и-и, монда сез китүгә әллә ниткән кешеләр кереп тулды. «Тәһарәтең бармы?» дип, әллә кай җирләргә үреләләр. Берсе басып ятмакчы була, – дип, Гадилә карчык, гомер булмаганны, әшәке сүз әйтеп куйды.

Гайшә куркып, як-ягына каранды. Каенанасының күзләре тоныкланып, нурын югалтканнар иде.

– Беркем дә юк бит, әни. Йокымсырап китеп төшләнгәнсең генәдер.

– Күрмисеңмени, әнә бит бер юаны һаман сандык өстендә утыра, – диде Гадилә карчык, өеп куелган мендәрләргә төртеп күрсәтеп.

– Юк, юк, әни, анда мендәрләр генә. Син әшәке төш кенә күргәнсең, – дип, Гайшә каенанасының юрганын рәтләп куйды да тиз генә Сәкинәгә йөгерде.

– Сәкинә апа, мин бүген кичкесенә бара алмыйм. Зинһар, кызлар белән минем сыерларны гына савыгыз әле, ярыймы. Әни авырып китте, – дигәндә, Гайшәнең иякләре дерелдәп куйды.

– Ай Аллам, авырып китте, ди. «Терелде» дисәң, менә анысы гаҗәп булыр иде. Мин белә-белгәннән бирле чирли торган Гадилә карчык бит инде ул. Ярар, юкка борчылма. Бүген синекен саусак, иртәгә син безнекеләрне саварсың, – диде ул, чәй ясый-ясый. – Әйдә, утыр.

– Юк, рәхмәт, – диде Гайшә.

– Эчкәч әйтерсең рәхмәтне. Әйдә инде, берәрне генә эч.

– Чынлап, Сәкинә апа, рәхмәт, – дип чыгып китте.

Гайшә әйләнеп кергәндә, Гадилә карчык, берни булмагандай, яны белән борылып, тәрәзә буендагы караватында уйнап утырган җиреннән йоклап киткән Нәсимәгә карап, авызын кыймылдатып, нидер укып ята иде.

– Чәй кертимме үзеңә, әни? – диде Гайшә шыпырт кына, кызын уятудан куркып. Гадилә карчыкның ул әйткән сүзләргә ничек тәэсир иткәнен беләсе килә иде аның.

– Юк әле, эчәсем килми. Син кызымны бүген Мәдинәгә кертеп торма инде. Әле генә йоклап китте, – диде әнисе.

– Бүген мин эшкә бармыйм, әни. Шулай берәр-берәр ял итәргә сөйләштек, – диде ул, кинәт кенә шундый фикернең башына килүенә куанып. Кызының өстенә япты да, урындык куеп, каенанасы кырыена килеп утырды. – Ничек соң хәлең? Алай бер җирең дә авыртмыймы үзеңнең? Бая бит куркыттың, – диде Гайшә.

– Ник? Нәрсә булды, Ходаем? – диде карчык, күзләрен кыса төшеп, кинәт кенә башы авырткан кеше кебек.

– Куркыттың. Нәрсәдер саташып алдың, – диде Гайшә, каенанасының юрганын төзәткәләп.

Карчык телсез кеше кебек кулы белән изәп, Гайшәгә үзенә таба иелергә кушты да, ике кулы белән беләгеннән тотып:

– Балам, Гайшә. Эшеңә дә барасың булмагач, Минвәли кайтканчы бер гозеремне үтә әле алайса. Коръән укып өшкер әле үземне, – диде пышылдап.

– И-и-и әни, мин булдыра алырмынмы икән соң?

– Булдырасың. Син булдыра алмаган эш юк. Аллага тапшыр да эшлә әле шуны.

Гайшә аптырап калды. Юк дияргә дә уңайсызланды, абыстай урынына, кулына Коръән тотып, каенанасын өшкереп утырырга да читенсенде. Берәрсе килеп керсә, дип тә курка иде ул. Тик каенанасына булган хөрмәте шул кадәр зур иде, ул тәвәккәлләргә булды.

– Хәзер, юынып керим инде алайса, – дип, Гайшә урыныннан күтәрелде.

Гайшә мунчадагы су белән юынды да, күлмәк-яулыкларын алыштырып, сак кына сандыгыннан әнисенең суккан намазлыгына төргән Коръәнен алды һәм ике куллап күкрәгенә кысты. Аңардан килгән җылылык күкрәкләрен пешереп алган кебек булды. Капкада кеше юкмы икән дип, тәрәзәгә күз салды да, бисмилласын әйтеп, каенанасы янына килеп утырды. Бер мәлгә өйдә тынлык урнашты. Гайшә бөтен күңеле белән дөньядан китеп, бар булмышын бер ноктага җыйнап тынып калды. «Әйдә» дигәнне аңлатып, Гадилә карчык килененә карап ым какты. Эчтән генә пышылдап ниятләде дә, бисмилласын әйтеп, Гайшә китабын ачты. Өй эченә талгын гына булып, моңлы Коръән мәкаме таралды. Гадилә карчык килененең авызына керердәй булып, һәр сулышын җанына сеңдерергә

тырышып ятты. Карчыкның бөтен җанын, күңелен әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык бер рәхәтлек биләп алды. Ул Гайшәнең тавышын ишетми, ә шундый килене булуга шөкерана кылып кына ята иде. Гайшәнең, аның бит-кулларыннан сыпырып, җылы куллары белән чәчләрен рәтләгәнне тоеп яту аңа бик рәхәт иде. Әйтерсең, Гадилә – сабый бала. Ул бераз тын ятканнан соң күзләрен ачты.

– Шифасы тисен, әни, – диде дә, Гайшә, күзләрен мөлдерәтеп каенанасына карады. Үз әнисенә күрсәтелмәгән, сарыф ителмәгән хөрмәт иде ул. Гайшә урыныннан торды. Коръәнен, намазлыгына төреп, киредән сандыгына салды. Чаршауны, сыдырып, кырыйга җыйдыргач:

– Хәзер кура җиләге яфрагы салып, чәй ясап бирермен. Шуны эчкәннән соң әзрәк ял итәрсең, – диде.

Гайшә банка капкачын ачып җибәрүгә өйгә җәй исе – мәтрүшкә, бөтнек, кура җиләге исләре таралды. Гадилә карчык, күзләрен гадәттәгедән зур ачып, түбә тактасына карап ята иде.

– Әни, әйдә, чәй эчеп җибәр әле. Менә үләннәр салып кына, чәй пешердем. Мәдинә ападан бал да алып чыктым. Җаннарың тынычланып, җиңел булып китәр, – диде Гайшә.

– Ә? – диде карчык кисәк кенә уйларыннан бүленгән кеше кебек. Һәм, беренче тапкыр күргән кеше төсле, Гайшәгә карап тора башлады. Ул караш Гайшәне үтәли чыгып, билгесезлеккә юнәлгән иде. Гайшәнең эче жу итеп китте.

– Әни, чәй эчеп алмыйсыңмы? – диде ул, яңадан каенанасына таба иелеп. – Менә Мәдинә ападан бал да алып чыккан идем.

Гадилә карчык карашын бушлыктан әкрен генә Гайшәгә күчерде, аннан сузылып, күзләрен кыса төшеп, Нәсимәгә карады.

– Әллә нәрсә буталып киттем әле мин, балам. Бүген эшкә барма син, яме. Нәрсәдер куркам мин. Син янымда булгач куркытмый. Син бит әнием кебек миңа. Гел әни дип әйтәсем килә, – диде ул.

Гайшә салып биргән чәйне дә, балны да Гадилә карчык ничектер хаптыр-хоптыр китереп, тәмен сизмичә, чүбек чәйнәгән кебек капты. Аның болай ашаганын-эчкәнен Гайшәнең бер дә күргәне юк иде. Эчкән чәе дә буш торбага су салган кебек төшә.

– Кызым, бар син уйный тор, мин хәзер сиңа да чәй ясап бирәм, – диде ул, һаман әбисенең караваты янында ышкынып йөргән кызына.

Гадилә карчык үлән чәен голт-голт китереп аз гына эчте дә, рәхмәт әйтеп, чынаягын килененә бирде. – Мине шулай сыйлаган өчен сине Ходай үзе сыйласын, – дип, битен сыпырды һәм юрганын башыннан ук бөркәнеп ятты.

Сарыклар кычкырган тавышлар ишетелә башлауга, әзерләп куйган ипи кисәкләрен алып, Гайшә тизрәк урамга чыкты. Сарыклар артыннан ук сыер көтүе дә керде. Гайшә, кайтырга уңай булсын дип, алдан турап куйган бәрәңгене алларына салып, тизрәк өенә ашыкты.

Сыер савылып беткәндә, капкада Минвәли дә күренде.

– Ухү... тулы чиләккә очрадым мин, – дип, авызын ерды ул. Аннан бераз аптырап: – Ә син нишләп өйдә соң әле бу вакытта, эштә түгел? – диде, хатыны кулыннан сөтле чиләкне алып. – Нәсимә чирләмәгәндер бит?

Өйгә кергәнче Гайшә көндезге хәлләрне энәсеннән җебенә кадәр тезеп сөйләп чыкты.

Минвәли өсләрен дә чишенеп тормыйча әнисе яткан якка узды. Ишектән этисе күренүгә Нәсимә йөгереп, этисен кочаклап алды.

– Нихәл, әни. Менә мин дә кайтып җиттем, – дип, Минвәли әнисе янындагы урындыкны тартып, аяк очынарак утырды.

– Ы-ы-ы, – дип сузды Гадилә, Минвәлигә карамыйча гына. Малае аңа әллә бар, әллә юк иде.

– Әни, син бик кырыйга килеп яткансың, эчкәрәк ятарга иде. Егылып төшә күрмә, дим.

– Анда кая ятыйм инде? Артта ике бала, алар өстенә ятмам бит, – дип, әнисе артына борылып карады. Бераздан «атлар, арбалар» дип, ниндидер буталчык нәрсәләр сөйләнде дә көлеп җибәрде. Аннан соң, Минвәлине яңа гына күргән, хәзер генә таныган кебек бик текәлеп, җентекләп карап торгач:

– И-и, нәрсәдер буталып китә башладым бит әле мин, улым, хәерле булсын. Вакыты җитеп килә торгандыр, – диде дә стенага таба карап ятты. Минвәли, идәннән югалткан әйберен эзләгәндәй, башын күтәрми генә алгы якка атлады. Гайшәнең ирен бервакытта да мондый хәлдә күргәне юк иде.

– Әйдә, юын да утыр, аша, – диде Гайшә иренә шыпырт кына. – Әйтеп карыйм әле, әни дә ашамас микән.

– Әни, әз генә шулпа салам, ашап ал, – дип, каенанасына иелде.

– Кит инде, әле генә ашадык лабаса. Гел ашап торырга, бирән зәхмәте түгел бит миндә. Әнә кунакларыңны ашат, баядан бирле, тыз-быз, бер өйдән бер өйгә йөриләр. Утырмага алырга килдек дип, мине дә кыстыйлар. Барыйм микән әллә, әни?

Гайшә, ни дияргә дә белмичә, баскан урынында аптырап калды. Ул да булмады:

– И, кайтыйм инде. Югалтканнардыр. Шул гомер кешедә кем утыра инде, Әптеки хәерчесе кебек. Әти дә килештермәс, – дип, әйберләр җыйнаган хәрәкәтләр ясап алды. Гайшә аяк очларына гына басып, ире янына чыкты.

– Узмаса, иртәгә кич-кырын булса да, Барый абый белән Әлмәткә төшеп, апаларга әйтеп кайтырга кирәк булыр инде, – диде Минвәли.

Гайшә каенанасының сызланулы ыңгырашуына уянып киткәндә, Чүрәгәй чокырында аксыл-тонык таң яктысы сизелә башлаган иде инде. Ул башта төшләнеп аңышмый торды. Аннан, ире белән кызын уятмаска тырышып, әкрен генә тормакчы иде, тик тимер караватның сиртмәсе ямьсез шыгырдап куйды. Гайшә каенанасы яткан якка узды. Тавышка Минвәли дә күзләрен ачты.

– Ни булды? Әллә?

Йокысы бик тиз ачылды иренең. Урындыктан чалбарын алып киде дә тиз генә әнисе янына керде.

– Гайшә, кил әле якынрак, – диде әниләре, кипкән иреннәрен ялап. Әйтерсең лә, улын күрми дә, танымый да. Ул Гайшәне генә күрә иде кебек.

– Эчәсең килдеме әллә, әни? Хәзер, – дип чыгарга борылам дигәндә, каенанасы баш кагып туктатты.

Гайшә каенанасына таба иелде. Гадилә карчык, сак кына, кечкенә бала әнисеннән әйбер сораган кебек, күзләрен мөлдерәтеп карап:

– Гайшә, балам, сиңа да рәхәт булсын, миңа да рәхәт булсын! – диде. Гайшәнең тәннәре чымырдап китте. Ул күзләрдә кичәге саташуның әсәре дә калмаган. Алардагы наз, алардагы җылылык бөтен дөньяны җылытырга җитәрлек иде.

– Шулай булсын, әни. Берүк шулай гына була күрсен. Амин, – диде Гайшә. Каенанасы аның кулларын сыйпап сыпырды да:

– Мин үләм инде, – диде. Гадилә карчыкның ак яулыклы башы ястык читенә таба салынып төште. Гайшә мондый борылышны көтмәгән иде.

– Минвәли! Әни! – дип кычкырды Гайшә. Тик тавышы гына ни елау, ни кычкыру булмады. Ә Минвәли исә боларның барысын да күреп, ишетеп, хатынының артында ук тораташ кебек бер хәрәкәтсез басып тора иде.

Авыл халкы бик бердәм бит ул. Өйләгә кадәр, авылдашлары, Гадилә карчыкны мәңгелек йортына урнаштырып та кайттылар. Мәетне озатып, өйләрне юып чыгаргач, өйнең бөтен почмагын бушлык сарып алды. Тәрәзә эленгеләренең, чаршау-кашагаларның булмавы бу бушлыкны тагын да куертып җибәрде кебек. Өйдә шыксыз, салкын иде.

Эшләр тәмамлануга, Гайшәнең апасы туганнарны, кардәш-ыруны чәйгә алып китте. Өйне ялгыз калдырмыйк дип, Минвәли берүзе капка төбендәге утыргычта утырып калды. Күңелен әйтеп-аңлата алмаслык ялгызлык, ятимлек ачысы көйдерде. Инде үзең әти булгач та, әнисез калу бик авыр иде. «Гайшә ничек яши икән әнисез?» дип уйлап куйды ул. Шул вакыт, әрнегән җанны тагын да әрнетеп, зәңгәр күкне ярып очкан казлар тавышы ишетелде. Минвәли казлар тавышы килгән күккә башын күтәрүгә, мөлдерәп торган яшьләре бите буйлап тәгәрәде. Ишегалдына керде дә, капканың калын җепсәсенә башын салып, киң җилкәләрен калтырата-калтырата рәхәтләнеп елады. Шул кирәк булган икән. Ул тынычланып калды. Казлар, түгәрәк ясап, Салих буасы өстендә әйләнделәр-әйләнделәр дә, җырларын ертык болытларга урап, сыек күгелҗем төтен булып, күздән югалдылар. Тынычланып, яшьләре кибеп беткән иде инде, капкада хатыны белән апалары күренде.

Һәркемнең үз гаиләсе, үз мәшәкате. Апалары да китте. Минвәли хатыны һәм кызы белән буш, шыксыз өйдә утырып калды.

Үлемнең көтелгәне булмыйдыр инде. Каенанасының үлемен икесе дә авыр кичерсәләр дә, ашын ашаган, яшен яшәгән дип, акыл белән килешергә тырыштылар. Гадилә карчыкның үлеме килергә тиешле, көтелгән иде инде. Кайберәүләргә бит көтмәгәндә, бөтен тормышларын җимереп килеп керә.

Быел көз коры килде. Яфраклар да тигез генә саргаеп утырдылар да, бер-ике көн эчендә коелып беттеләр. Озакламый әниләренең кырыгы җитә. Минвәли каралты-кура тирәләрен җыештырып, тәртипләп куйды.

Бер көнне, кичке якта, Минвәли янына Хәниф килеп, капка төбендә сөйләшеп торганнар иде.

– Хәниф нәрсәгә килгән ул? – диде Гайшә, ире өйгә кереп өсләрен чишенгәндә, аш бүлеп.

– Ташлы борын өстендә еккан имәннәр бар, шуларны сөйрәтеп кайтып булмасмы, дип килгән.

– Нәрсә диден соң? – диде Гайшә хатын-кызларга хас кызыксыну белән.

– Ай Аллам, чистый сорау ала. Әнвәргә әйтерсең, андый-мондый эш килеп чыкмаса, төштән соң барып кайтырбыз, дидем. Кеше гозерләнеп килгән бит, – дип, Минвәли табынга утырды.

Ашына катык туглап, дүрт-биш кашык капты да Минвәли күтәрелеп, хатынына карады. Гайшә, беренче тапкыр күргәндәй, йотлыгып, керфекләрен дә селкетми иренә карап тора иде. Ул акыллы, зур коңгырт күзләргә җылылык, ярату, наз тулган. Аларда әйтеп бетергесез якынлык, хөрмәт. Гайшәнең карашы Минвәлинеке белән очрашкач, ул уңайсызланып китте. Шулай карап торуыннан оялган сыманрак:

– Минвәли, мин сиңа моның кадәр дә ияләнермен дип уйламаган идем. Синсез нишләр идем икән мин хәзер?! – дип елап җибәрде.

– Ай Алла, нәрсә булды сиңа? Тик торганнан кем инде елап утыра?! – дисә дә, Минвәлигә бу сүзләрне ишетү рәхәт иде. Әйе, җырларда җырланган, хатлар язып, хатлар көтеп килгән ярату түгел иде аларның мәхәббәте. Сандугачлар моңын тыңлап, таңнар да аттырмадылар. Тик алар мәхәббәтнең «бер-береңне хөрмәт итү» дигән ягын, тормыш итәргә лаеклы икәнлекләрен аңлап кавыштылар. Картлар әйткән «никах мәхәббәт тудыра» дигән сүз аларга бик тә туры килә иде. Андый сүзләргә әллә ни исе китә торган булмаса да, Минвәли яши-яши төшенгән иде аларның хаклыгына. Шуңа да, эчтән генә сөенеп, чын йөрәге белән яратып яши ул хатынын. Ә авыз ачып «яратам» дип әйтергә, үзенең яратуын күрсәтергә ничектер җай тапмый. Матур итеп сөйли белми шул.

– И-и-и, тапкан елап утырырга, – дип, Минвәли ашавыннан бүленеп, гомер булмаганны, хатынын үбеп алды. – Мин дә, әле ярый син бар дип яшим.

Гайшә иртән эшкә киткәндә, Минвәли уянып калды.

– Ят әле, иртәнге өчтән үк тормасаң да өлгерерсең. Алай янып килгән эшең юк, – диде Гайшә иренә.

– Хатын-кыз торып эшкә киткәндә, урын өстендә аунап калу оят инде. Уянмаган булсам бер хәл, – дип, Минвәли дә торып киенә башлады.

– Син эшкә киткәнче, бәлки, кайтып та өлгерермен, – дип, ишекне ачкач, иренә тагын бер кат борылып карады. Караватта йон оекбашларын киеп торучы Минвәлинең майкасы тыгыз, нык тәненә сыланып, тартылып тора иде. Майка уемыннан кап-кара күкрәк йоннары бөдрәләнеп күренә. Оекбашка үрелгәндә генә дә, беләк мускуллары уйнаклап-уйнаклап ала.

Гайшә кайтканда, Минвәли эшкә киткән иде. Төшке ашка да кайтып тормады. «Хәниф белән киткәндер инде», дип уйлады Гайшә.

***

Зоотехник Әнәс килгәндә, Гайшәнең ике генә сыеры калган иде савылмыйча. Исәнләште дә аргы башта савучы хатыны янына атлады. Тик озак тормады, башын аска иеп, тиз генә чыгып та китте. Ул китеп өлгермәде, Сәҗидә янына Фәһимә белән Наҗия, алар янына Җинан апай белән Сания дә килделәр. Аптырашып басып торгач, Җинан апай Гайшәгә таба атлады. Аңа калганнар иярде. Гайшә бер кулына – чиләк, икенче кулына Минвәлие ясап биргән утыргычын тотып, Күбәләге яныннан чыгып килә иде.

– Пленный нимесләр урынына, башларыгызны түбән иеп, кая юл тоттыгыз? Кайтабыз дигәндә генә, кызыл почмакка тагын берәрсе доклад укырга килгәнме инде, Ходаем. Гел кеше ясап бетерәләр үзебезне. Әлмәткә алып китмәсәләр ярый, – диде ул, елмаеп.

– Гайшә, балам, – диде Җинан апай, карашын читкә борып. – Минвәли... Минвәли ауган бит... трактор белән.

Гайшәнең сөт тулы чиләге кулыннан төшеп китте. Куе, җылы сөт, җәелеп, тирес тарта торган чокырга акты. Калтыр-колтыр тоньк тавыш чыгарып, чиләк тәгәрәде.

Ул, Җинан апасының бар икәнен дә онытып, тиле кеше сыман үзен-үзе белештермичә, өйләренә йөгерде. Гайшә кайтып җиткәндә, капка төбен тирә-күрше сырып алган иде. Ике якка аерылып, аңа юл бирделәр.

– Гайшә, Гайшә балакаем, сабыр бул, – дип, өйләреннән аңа каршы әтисе чыкты. Аның артыннан Закирә белән апалары күренде.

– Кайда ул, кайда ул? – дип кычкырды, ачыргаланып. – И-и-и әти! Никләр һаман бер минем башка гына икән бу кайгылар? Апа җаным, нишлим инде хәзер?! Ничекләр яшәргә соң инде хәзер безгә? – дип, апасының иңнәренә сарылды. Гайшә еламый иде. Карлыккан тавышы иңрәп, ыңгырашып чыкты.

– Нишлисең бит, сеңлем?! Син күрәсен кем күрсен?! Сабыр ит, сабыр. Синең бит кызыңны үстерәсең бар, – диде, сеңлесенең иңнәреннән кочып. Гайшә башындагы яулыгын сыдырып төшерде дә, битләрен, күзләрен сөртте. Сөртте, ә күз төбендә тамчы да яше юк иде. Еларга яше юк иде Гайшәнең. Тик уртага ачылган аерманың уң ягыннан бер тотам чәче ап-ак булып агарып чыккан иде. Моны апасы күрсә дә, авыз ачып сүз әйтмәде.

Җыелган күрше-тирә сузылып кына, сөйләнә-сөйләнә таралышып, капка төбе бушап калды. Гайшәнең күңеле таштай катты. Бөтен тәне кыйнап ташлагандай авырта, маңгаена кул тидерерлек тә түгел, тиресенә кадәр әрни. Ул башын аска иеп, аякларын көчкә генә сөйрәп, апасы белән Мәдинә артыннан өйләренә кереп китте.

Минвәлинең җидесе әнисенең кырыгы белән бер көнгә туры килде. Ул көнне иртән беренче кар төште. Моңа кадәр сандыкта гына сакланган Коръән, Минвәли үлгәннән соң, Гайшәнең мендәре астына күчте. Бөтен нәрсәдән саклаучысы да, яклаучысы да, иптәше дә, сердәше дә шул Коръән булды.

Һәр кешенең үз гаиләсе, үз мәшәкате. Кешенеке – кештәктә, үзеңнеке – үзәктә, дип белеп әйткәннәр. Никадәрле генә синең хәлеңә керергә тырышсалар да, бер кеше дә сине саклап утырмый. Аш та узды, кунаклар да таралышты. Гайшә, кызы Нәсимәне кочаклап, үз хәсрәте белән бергә-бер калды. Иренең кырыкларын уздыргач, Гайшә әкренләп «яши» башлады: сөйләште, кайгырды, елмайды, көлде. Тик... тик елый гына алмады. Бөтен хәсрәтен эш белән капларга, алай гына да түгел, изәргә, сытарга тырышып эшләде дә эшләде. Рәхмәтулла абыйсына ияреп, баздан силос төяргә дә чыкты, Барыйга сөт флякләрен төяште. Эшкә барышлый, сихер белән кайнаша дип, авыл кешеләре керергә куркып йөргән ялгыз карчык Мәгъшук Мәхтүмәсенә су да китерде. Чөнки эштән туктаса, башына әллә нинди яман уйлар килә башлый иде.

Мәхтүмәгә су кертүенең сәбәбе шунда, беркөнне судан кайтканда, тыкрык почмагында көтеп торып Лениза:

– Син нәрсә эшлисең үзең белән? Өеңнән чыкмыйсың, чыксаң да кешегә күтәрелеп карамыйсың, сөйләшмисең, өстеңдә һаман шул бер бишмәт тә башыңда шакмаклы шәл. Мәгъшук Мәхтүмәсенә әйләнәсең бит. Үлгән артыннан үлеп булмый, кызың бар икәнен онытма, – диде. Шуннан соң Гайшә көне буе Мәхтүмә карчыкны уйлап йөрде. Ә нинди икән соң ул Мәхтүмә? Бер авылда, бер урамда яшәп, моңа кадәр ул хакта аның уйланганы юк иде. Эшкә барганда да, кайтканда да, Гайшә Мәхтүмә карчык йортын күзәтте.

Чыннан да, нindirәк җан иясе икән бу ялгыз карчык? Гайшәдә шулай итеп яшәүгә, тормышка кызыксыну уятты Ленизаның ачулануы. Гайшә эштән кайтып ашап-эчкәннән соң, көянтә-чиләген алды да нефтьчеләр ясап киткән колонкадан су алып, Мәгъшук Мәхтүмәсенә китте.

Карчык ничек, нәрсә белән эш иткәндер, аның янына килүчеләрнең машиналары Уразай урамы буйлап сузылган була иде. Якын-тирәдән генә түгел, Мәскәү тикле Мәскәүдән дә киләләр дип сөйли иде халык. Берсендә су керткәч, Гайшә чиләген күтәреп, мич буенда торган кисмәгенә салыйм дигәндә, Мәхтүмә карчык:

– Балам, утыр әле азга гына. Аякларың ял итсен, – дип, мич буенда торган урындыкка ымлады. Ялгызлыкның ни икәнен яхшы белгән Гайшә сүз әйтмәде. Чиләген кырыйга алып, кисмәкне такта капкач белән каплады да артын урындыкка төртте. Мәгъшук Мәхтүмәсенең өе җылы иде, утыруга мамык шәлен артка сыдырып төшерде Гайшә.

– Менә, мине авылда сихерче диләр инде. Миннән куркалар. Мин сихерче булсам, бердәнбер кызымны исереккә кияүгә бирер идемме? Үзем, ялгыз башым, ирсез торыр идемме?! Сихерләп булса да, берәүнең яхшысын күземә генә каратып, үз янымда тотар идем мин, балам. Шул хакта берсенең дә башына китереп караганы юк. Утыз өченче елны, бер уч кибәкле бодай өчен дип, өтермәнгә тыктылар. Теге, сезнең очның Нәгыймә карчык белән икебезне. Кызым Мөнәвәрәгә сигез тулмаган иде. Соңлап тапкан идем. Мин өтермәндә шундыйга әйләндем, балакаем. Бик каты кыйнаганнан соң. Ә бодай ул болай гына, аның сәбәбе башкада.

Комлык өстендә утауда идек. Әбәт ашарга туктагач, бераз ял итеп, такмак әйтеп биеп алыйк дип, Хаҗәр белән такмак әйтә башладык. Нәгыймә белән без уртада биибез, мин урман буен яңгыратып, такмак әйтәм.

Кемдер әләкләп йөргән дип, гөнаһыга батарга урын калмады. Без такмак әйтеп туктаганда, Ярулла Мотыйгы безнең янда басып тора иде. Өтермәнгә эләгүнең төп сәбәбе менә шул аның, балам. Бодай ул болай гына, дукумитка язар өчен генә кирәк булды. Нәгыймә минем аркада китте өч елга өтермәнгә. Шундый гаебем бар Нәгыймә алдында. Ходай кичерсен. Беләм, Нәгыймә үзе кичерде инде, тик аның күңеле катып калды. Шуннан кайтканнан бирле авыз ачып сүз дәшкәне юк. Син, кызым, күңел катудан саклан. Аннан да яманы юк.

Карчык сүзсез калып, Гайшәнең кулларына карап торды. Аның исә, бу кадәр озаклап утыруына эче поша башлаган иде инде.

– Бу кулларың әле бер генә күзне йомдырмас. Тик кайда гына булсаң да,

сине бер Аллаһ саклап йөртә, шул көч бирә сиңа. Әниең бик разый булып киткән синнән.

Ай Аллам, гомер булмаганны бер еллык сөйләп ташладым. Сине дә тоткарладым, китәсең дә килә башлады, – дип, саран гына елмайды Мәгъшук Мәхтүмәсе һәм бер кулы белән өстәл читенә таянып, урынынннан торды.

Гайшә дә урыныннан торып, чәчләрен җыеп, шәл астына кыстырды да чиләкләрен алып, ишеккә юнәлде.

Әнисен югалткач, кайгысын эш белән күмеп, шул хәсрәт белән яшәргә өйрәнгән иде. Бу югалтуын да шулай җиңәр. Фатыйма кызы бит ул! Кызы да ишелеп килгән кайгыны аңлады кебек, әтисен таптырмый, кемдә калдырса да кала торган булды. Гайшәнең вакыты булмаса, бабасы килеп ала. Шулай эштән өйгә, өйдән төп йортка, аннан тагын өйгә чабып, көн артыннан көн үтә торды. Көн генәме?! Еллар үтә! Исәннән дә үтә, үлгәннән дә үтә икән.

Каенанасының ел ашын җиренә җиткереп уздырды Гайшә. Табыны мул, кешесе күп булды. Тик, китәргә чыккач, кечкенә апасы:

– Гомерсез булды шул. Куйган көче, җыйган малы кешегә калды, – диде, өйләренә таба борылып. Бөтенесе дә барган җирләреннән кинәт туктап калдылар. Ишегалдына җәелгән тынлык авыр таш кебек Гайшәнең күкрәген кысты. Ул тынлыкның авырлыгын гына түгел, хәтта салкынлыгын да тойды Гайшә.

– Апа, нигә алай дисең? Кешегә шул – кызына. Этләргә түгел бит! – диде. Күкрәк турысына укмашкан төер авырттырып, бугазны ертып, бер өскә күтәрелде, бер аска төште. Минвәлине җирләгәннән бирле елаганы юк Гайшәнең, елый алмый. Тынлыкны олы җизнәсе бозды.

– Кит инде, балдыз, булмаган нәрсә сөйләмә. Гайшә урынында башка берәү булса, бер елда түгел, бер айда йонын очырыр иде йортыгызның. Әниеңнең артын юучы ул бит, син түгел. Алай мәгънәсез булмыйлар. Гайшә, син инде әллә ни уйлап, күңелеңә авыр алма. Бар да әйбәт, юкка борчылып калма, – диде ул, балдызына ачуы килеп.

Шәһәр хатыны шәһәр хатыны инде. Балдызы, җизнәсенең әйткәнен яратмыйча, эттән өреккән кәҗә кебек, ишегалдына җәйгән ташларга шык-шык басып, алдан чыгып китте.

– Әлмәткә килгәндә керми китмә, – диде олы апасы, әлеге салкын сөйләшүгә җылылык өстәргә тырышкан кебек.

– Ярый, үзегезгә рәхмәт, җизни. Онытып бетермәгез, – диде Гайшә, бугазын авырттырып торган төерне йотарга тырышып.

Туганнар Әлмәткә кайтырга дип, Кичү юлына чыгып китте. Әбелгата күперен узып, борылыштан югалганчы, Гайшә белән Нәсимә капка төбендә, аларны карашлары белән озатып калдылар. Алар китте. Гайшәнең колагында апасының «...кешегә калды» дигән сүзләре яңгырады. «Кешегә диме, кызым? Кешегә шул, Аллага шөкер! Кешелекне югалтудан үзең сакла, Ходаем», дип, эчтән уйлап куйды.

Шул көнне Гайшә тәүге тапкыр намазлыкка басты. Ул, кызы уянмасын дип, сак кына торды да комганына су таманлап юынып керде. Аннан аккан су тавышын каплар өчен буш тагаракка идән мунчаласын ташлады, бисмилла әйтеп, тәһарәт алды. Бит-кулларын сөртеп, сызганган җиңнәрен

төшергәч, күзләрен йомып, беравык басып торды. Авыр икән бу, бөтен дөньяңны онытып, бер Аллаһ каршына тезләнү. Юри үртәгән кебек әллә нинди уйлар килә башка. Ул, караватчитенә генә утырып, оекларын киде дә түр якка узды. Ут кабызып тормады Гайшә. Алдагы якның уты өй эчен яхшы ук яктырта иде. Сакланып кына, сандыкның йозагын ачты да әнисенең төсе итеп тота торган күлмәге белән яулыгын алды. Шактый еллар узуга карамастан, алардан сандык исе, әнисе исе килә иде. Өйдә башка кеше булмаса да, өйрәнгән гадәт буенча, чаршау артына кереп, беренче тапкыр әнисенең күлмәген киде. Азрак тынычлангач, сандык өстеннән яулыкны алып, башына таратып бәйләде һәм стенага элгән көзгә каршына килеп басты. Көзгедән Гайшәгә яшь Фатыйма карап тора иде. Түшенә кадәр изү ясап, күкрәк турыннан киңәеп киткән, ике рәт бәби итәк тоткан, ак җирлеккә күк чәчәк белән вак кына чыпчык күзе төшерелгән күлмәк, яшел бөрчекле яулык бик килешә икән аңа. Хәзер Хәдичә апасы күрсә: «Әтекәем-әнекәем, бу бит Гайшә-Фатыйма булган», – дияр иде.

Гайшә чаршау артына керде. Каенанасыннан калган намазлыкны идәнгә җәйде дә кыйблага таба карап басты. Басты, тик күңелен бер ноктага туплап, намазын ниятли алмыйча, озак торды. Ниһаять, бер онытылып, бер ирен, әнисен, бер ятим кызын уйлап, ул да булмый яңадан бар булмышы белән күңелен Ходай хозурына тапшырып, ерып чыкты. Битен сыпырып торып басканнан соң, Гайшә үзен җиңеләеп, бурычын түләп тынычланып калган кешедәй хис итте. Хәтта күңеленең кай җире беләндер «кешегә калды» дигән сүзләре өчен апасын да кичерде бугай ул.

Вакыт дигәнең үлгәннән дә үтә, исәннән дә китә. Адәм баласы шундый бит ул, кайгы килгәндә иркәли-юата да, аннан үз мәшәкатенә чума. Тол хатынның мәшәкате күп. Шуңа күрә аңардан читләшә дә башлыйлар. Беренче тапкыр бу хәлне Гайшә әтиләренә – төп йортка баргач сизде. Минвәлие исән чагында, «кияү, кияү» дип, бер алларына, биш артларына төшеп йөргән Закирә апасы үзгәреп китте.

Закирә, авыз эченнән генә мөнәҗәт көйләп, чәй табыны хәстәрләп йөри иде. Кызын җитәкләп, Гайшәнең үзләренә килгәнен күргәч, чырае качты.

– Син әзрәк әйткәлә, йортыннан кузгалмасын, – диде ул иренә, бер почмак якка кереп, бер өстәл янында әйләнеп. – Монда кайтырга уйламасын тагын.

– Кысыр хәсрәт белән сару кайнатып торма әле. Бала дигән татлы газапның ни икәнен беләсеңме соң син? – дип, Хөсәен ипи кисәргә тотынды.

– Ай Аллам, син генә беләсең инде. Кайдан килгән Рабига белеклесе?! – диде Закирә, иренең әйткәнен яратмыйча.

– Ярар, күп сөйләнмә. Синең янга кайтам дип торган кеше юк әле. Әнә балага кәнфит-прәннекләреңне әзерләп куй, – дип, әтисе кызы белән онығын каршы алырга утырган урыныннан торды.

Ишек ачылды да, башлап, өйгә кочагы белән җылылык, рәхәтлек җәелде һәм Нәсимә кыяфәтендә Хөсәенгә килеп сарылды, аннан Закирәгә күчте. Аның артыннан, моңсу күзләренә кояш җылылары чыгарып, Гайшә күренде. Почмаклап бөкләгән яулыгын матурлап, артка чөеп бәйләгән. Авылда яулыкны аның кебек башка берәү дә бәйләми. Мәрхүмә әнисе

шулай бәйли иде дә, менә хәзер Гайшә шулай. Берәү белән дә бутамыйсың аларны. Башындагы яулыгын күреп кенә дә кем икәнен белеп була.

– Минем үскән кызым килгән икән бит. Кара әле, бабасы, безнең Нәсимәбез мине куып җиткән, – дигән булды Закирә, зәһәр теленә бал ягып.

– Нихәл, эти, – дип, Гайшә күрешергә ике кулын сузды. Аннары:

– Закирә апа, исәнме. Менә бу кабартмаларны алып куй әле. Ипи салган идем. Камырны күбрәк куеп, кабартмалар ясадым. Синең пешергән чәеңнең исе килде дә, әйдә мин әйтәм, кызым, әбиең безне көтә бугай дип, сезгә йөгердек. Әйеме, кызым? – дип көлде Гайшә.

Закирә чәй әзерләде. Дүртәү утырып, чәй эчтеләр.

– Бер генә дә буш кул белән йөрмисең, кызым. Безне шулай зурлаган өчен Ходай зурласын үзеңне. Килер җирләрең киң, бәхетең алда булсын, балам, – дип дога кылып, этисе битен сыпырды.

– Амин, – диде Гайшә, этисенең теләкләренә кушылып.

– Син инде, кеше сүзенә карап, берүк йортыңнан кузгалырга уйлый күрмә, – диде Закирә, өстәл өстенә җәйгән клеёнканың пычак тиеп ертылган урынын бармак очы белән ышкып. Гайшә сагышлы күзләре белән мәгънәле генә елмаеп, этисенә карап куйды.

– Әй, юк нәрсә белән баш катырма әле син, – диде Хөсәен, ачуын эченә яшереп.

Әтиләренең күршесе Нурсинәләргә Таҗикстаннан каенсеңлесе Әкълимә гаиләсе белән кунакка кайткан иде. Әкълимәнең ире Гарәфетдин Минвәлиләрдән ерак түгел яшәүче Галләмнәргә туган тиешле. Кем әйткәндәй, чыбык очы. Шулардан чәйдән кайтышлый, Нурсинә белән Әкълимә Гайшәләргә тукталдылар. Ул, бакча ярганнан соң калып, инде песи койрыгы кадәр баш чыгарган алабуталарны җыеп, бәрәңге бакчасыннан кереп килә иде.

– Бу Гайшә бер генә дә тик тора белми. Икенче Фатыйма булсаң да булырсың икән, – диде Нурсинә, капкадан керә-керешли, калын тавыш белән.

– Әссәламегаләйкем, – диде ялтыр-йолтыр яулык бәйләгән, таҗик күлмәге кигән хатын. Күлмәк астыннан ялтыравыклы балаклы ыштаны җилферди.

– Әйдәгез, әйдә, Нурсинә апай, узыгыз. Орлык койганчы, азрак йөреп чыгыйм дигән идем, шушыларны җыеп. Инде берсен дә калдырмый, бер утап чыктым. Кайда гына качып калалар, – дип, кочагындагы алабуталарын утар ягына ташлады. – Башын казлар йолыккалыйлар кайткач, берни калдырмыйлар.

– Менә, Әкълимәгә Уразай урамы буйлап, «монда фәләннәр тора, монда төгәннәр тора» дип, һәрберсен әйтеп бара идем. Сиңа кереп чыгасы иттек. Күрше бит.

Йортка бер дога кылгач, самовар җырлап өстәлгә килеп утырганчы, мәрхүмә әнисе Фатыйманы, каенанасын, Минвәлине рәхәт бер сагыну белән искә алдылар.

Гайшә ни бар, барын куеп, табын әзерләде.

– Авылда җимешләр юк, Әкълимә апа, син ачуланма инде. Бары белән сыйланып утырыгыз әле. Тәскирә әйткәндәй, авылда каймак та катык,

җимерек тә ватык. Зарланып әйтүем түгел, болай гына. Ходайның биргәненә шөкер. Без монда шулай яшәргә өйрәнгән, әйе бит, Нурсинә апай, – диде, әйткәннәрен аңардан раслаткандай.

– Һай, җаным, безнең бит анда гел башка. Ел әйләнәсе өстәлдән җиләк-җимеш өзелми. Җәннәттә яшибез инде, – дисә дә, Әкълимә үзе катыкка ябышты. – И-и-и катыгына кадәр Шарлыктагы үлән исләре килгән кебек. Мондый тәмле катыкны безнең авылда гына оеталар, ие бит, абыстай.

– Әкълимә апа, әллә тәмле булмадымы? Эчегез инде тагын берәрне, – диде Гайшә, урыныннан торып.

– Тәмле, тәмле. Яса миңа тагын берне. Сиңа керүебез шул. Минвәлидән соң Галиянең шулай сине мыскыл итеп, өйне алам дип йөргәнен сөйләгәч, Әкълимә апаң, үзебез белән алып китәбез Гайшәне, ди.

– Кара сакалың, кая гына барсаң да, үзеңнән калмас инде анысы. Фәрештә йоклаган арада, шайтан нишләмәс, дигәндәй. Аллаһының амин дигәненә туры килсә, китеп тә барырсың, – дип шаяртты Гайшә.

– Шулай да син уйла әле, бала. Монда бит ялгыз хатынга тормышны тартып барырга бик авыр. Анда халкы да ярдәмчел, яшәү дә җиңелрәк. Кием-салым да бу кадәр күп кирәкми. Хөсәен абзый белән үзем дә сөйләшермен. Ул бик төпле, акыллы кеше. Уйла. Без әле тагын бер атна-ун көн булырбыз.

– Уйла, уйла, Гайшә. Монда ялгызың чиләнгәнче, – дип, аңа Нурсинә дә кушылды.

– Әйдә киттек Чиләбегә, ничу монда чиләнергә, дисеңме?

Гайшә ике тәрәзә арасындагы Минвәли белән икесенең зурайтып элгән фотосурәтләренә моңсу караш ташлады. Тирән итеп алган сулышы өзелеп-өзелеп китте.

– Әйдә, абыстай, кузгалыйк инде без. Мәрхүмә әнкәй кемнедер, ыштан җөе артына батканчы кешедә утыра, дия торган иде. Безнеке дә шуңардан ким булмады. Дога кылыйк та кузгалыйк. Киленнән яхшы түгел.

Нурсинә белән Әкълимә китте. Артык чынга алмаса да, Әкълимәнең сүзләрен Гайшә күңеленең кайсыдыр бер җиренә салып куйды.

Ике-өч көн үтте микән, эштән кайтып, өсләрен генә алыштырып өлгерде, ишектән фырт кына киенгән Галия апасы килеп керде. «Исәнме», – дип, авызын ачкан иде Гайшә, ябарга өлгерми дә калды. Галиянең теле-телгә йокмый, автоматтан аткандай, сиптерә башлады.

– Нәрсә, йортны сатып, читкә таярга җыендыңмы? Җимеш ашыйсың килдемени, ә?! Бар, бар, берүк китә генә күр. Алдыңнан артың яхшы. Тик әнкәй йортына тырнак белән дә кагыласы булма, ишетсен колагың! Әле Минвәлидән соң куып чыгармаганга рәхмәт әйт. Чүпрәк-чапрагыңны җый да ычкын. Мин икенче кайтуга эзең дә булмасын.

Шулай диде дә Галия ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Гайшә мичкә сөялгән килеш басып калды. Бөтен тәне калтырады, күкрәгеннән күтәрелгән әрнү, төер булып укмашып, бугазында буылып калды. Ул да булмады, бөтен дөньясы зырылдап әйләнә башлады, аяк астыннан идән шуып китте. Гайшә, ике куллап чигәсен кысты да, чытырдатып, күзләрен йомды. «Эх, бер еларга иде эчләрне бушатып. Никләр генә елап булмый соң, Ходаем, ник соң шуны да кызганасың миннән?» дигән уй яндырды

Гайшәнең җанын. Шашып, илереп, бер улап еларга иде. Ургып аккан язгы ташудан, җәйге яшенле, күкрәүле яңгырдан соң сафланып, җиңеләеп сулыш алган табигать кебек, бәлки, Гайшәнең дә җаны тынычланып китәр иде. Юк шул, булмый, елап булмый бит...

Гайшә, исерек кеше кебек, көч-хәл белән сөйрәлеп кенә, ишегалдына чыкты да, бакчага керә торган капка баганасына Минвәлие урнаштырган юынгычтагы салкынча су белән битләрен юып алды. Чигәсен кысып, башы авыртуы узмаса да, йөрәгенең калтыравы басыла төште. Ул яңа гына күргән кебек ишегалларын, абзар-каралтыларны, утын сараен, Сембер бакчасыннан алып кайтып, икесе бергә өй артындагы бакчага утырткан алмагачны күзәтте. Боларның барысы да Минвәлинеке белән бергә Гайшәнең дә кул җылысын саклыйлар. Ул да бит, өяз эте кебек, урамда чапмады. Бөтен эшне бергә эшләделәр. Йә кадак, йә чүкеч биреп торды. Такта башы тотарга да Гайшә йөгерде. Аның тагын ике күкрәк арасы ачыттырып әрни башлады. Мондый чакта нишләргә соң әле? Башы да эшләми тора бит аның кирәк вакытта, йа Аллам. Их, әни булса, дип уйларга өлгермәде Гайшә, кылт итеп «бүләге» исенә төште. Хәлсезләнгән аякларына хәл кергәндәй булды. Ул тизрәк өенә ашыкты.

Гайшә, бисмилласын әйтеп, мендәр астыннан Коръәнен алды да, намазлыгын да сүтеп тормыйча, ике куллап, күкрәгенә кысты. Менә шул гына, шушы гына ярдәм итсә инде Гайшәгә. Ул күзләрен йомды. Тәне буйлап, рәхәт бер дулкын узганын тойды. Аннан килгән таныш ис әниле, ирле чагын исенә төшерде. Ул ипләп кенә намазлыгын чиште дә, китапны тезенә куеп, такта чәйнең укасы белән почмаклап куйган битен ачты. Фатиха сүрәсен күзләрен йомган килеш яттан гына укыды да, Ясинга күчкәч, беренче класс баласы кебек бармак йөртеп укып китте. Элекке кебек берәрсе килеп керер дип тә тормады. Һәр тынышына тукталып, нәкъ әнисе кебек көйләп укыды да укыды. «Елап бушануны Ходай насыйп итмәсә, аның урынына менә бу хикмәтне бирде», дип уйлады ул. Гайшә үзендә ниндидер ышаныч, тәвәккәллек тойды. «Бүләген» төреп, урынына куйгач, Гайшә яулыгын салып, көзге каршына килеп басты. Иртән эшкә киткәндә, ашык-пошык кына үргән толымнарын таратып җибәрде. Кыл уртадан агарган бер тотам чәчен санамаганда, төсен җуймаган кара чәчләре тез астына җитеп тора иде. Киң маңгаена сай гына ике буразна сызылган. Кашлары турыга гына килә дә, нечкәреп аска таба төшә. Кыска гына гомеренә инде җитәрлек хәсрәт күргән булса да, моңсу соры күзләре яктылыгын югалтмаган. Өскә күтәрелеп торучы күз читләре карашына бер серлелек өсти. Әле ирен читләрендә сызыклар да күренми. Гайшә карашын түбән юнәлтте. Күкрәкләр, билләр, билдән түбән төшләре дә алай зарланырлык түгел әле. Гайшә шулай уйлады да, уйларыннан үзе оялып, колакларына кадәр кызарып чыкты. Аннан тиз генә чәчләрен тарап, бер толым итеп үрде, түбәсенә урап, кәкре тарагы белән эләктереп куйды. Караватбашындагы яулыгын чөеп бәйләгәндә, билгеле бер карарга килгән иде инде.

Гайшә бакча коймасына элеп куйган чиләкләрен алып, көянтәсенә асты да йөгерә-атлый чишмәгә китте. Чиләкләрен тутырып, Нәҗмиләр тыкрыгыннан Уразай урамына чыккан гына иде, каршына Тәслия очрады.

– Атакаем, шыпырт кына урамның бу башына килен төшкәнме әллә?

– диде ул, мыскыллы елмаеп. – Үз өең белән Җәүдәтнекен бутамадыңмы син, Гайшә?

– Бутасам да гаҗәп түгел, тол хатын бит мин, – диде ул, артык исе китми генә һәм берни булмагандай Мәхтүмә карчыкка кереп китте. Аның:

– Сезнең ише толларга везде почёт, бөтен ишек ачык инде. Әле Галия өшкереп чыгарса, Җәүдәткә дә, башкасына да барырсың. Бармый хәлең түгел. Закирә көтеп тора ди сине, – дип сөйләнгәнен Гайшә ишетмәде.

* * *

Гайшәнең китәргә җыенуын белми дә калдылар. Дошманнарны куандырмыйм, якыннарны борчуга салмыйм дип, алдан әйберләрен дә алып кайтмады әтисе йортына. Китәргә билетлар алгач кына, Әкълимәнең энесе Әзһәр белән бик кирәк вак-төякләрне алып кайтты. Алары да шул бер бирнә сандыгына сыеп бетте.

– Әзһәр, син калганнарын әти белән алып кайтырсың инде, ярыймы, – диде Гайшә, сандыгын өйгә керткәндә. Әзһәр күршесенең сүзләрен ишетмәгәндәй:

– Син чыннан да шулай авылны ташлап китәргә булдыңмы? – диде.

– Юк, авылны ташлап китмим мин, Әзһәр. Бишектәге авылдашымнан башлап, ләхеттәге якыннарыма кадәр, хәтта Хафиз тыкрыгындагы кычытканга, Шарлыктагы исле үләннәргә кадәр җаныма салып, үзем белән алып китәм. Җыясы ризыгы йөртә бит адәм баласын. Туфрагым моннан булса, кайтырмын, Алла теләсә. Тәкъдиргә язганы булыр, – диде.

– Син гел Вәсилә абыстайга әйләнгәнсең, – дип, Әзһәр, иелеп аягына кигән җиреннән күтәрелеп, күршесенә карады. Түзмәс, елап җибәрер дип уйлаган иде ул. Тик Гайшәнең күзендә сыңар яшь тамчысы да юк иде.

– Әй, Әзһәр, әйләнмим дисәң дә, язмыш әйләндерә икән ул. Шундый да итеп әйләндерә икән... Зырылдап торасың. Иң мөһиме, әйләнеп туктагач егылып китмәскә дә кыйбланы бутамаска.

Гайшәнең тыгыз күкрәкләре авыр тын алганын сиздереп күтәрелделәр дә, өзек-өзек тын алганнан соң, җай гына калтыранып куйдылар. Күзеннән яшь чыкмаса да, җаны сулыгып-сулыгып елый иде. Их, күзеннән яше дә чыкса, җиңелрәк булыр иде дә бит. Юк шул. Ул Әзһәргә арты белән борылып басты. Чибәр җиңгиләр турыннан зират каеннары күренеп тора икән. Гайшәнең моңа кадәр бер дә игътибар иткәне юк иде. Бигрәк матур.

Әзһәр исә бер алма өзеп алды да шатырдатып ашый-ашый, капкадан чыгып китте.

Кичке ашны күңелле генә сөйләшә-сөйләшә ашадылар. Гайшә ул-бу сиздермәде, күңелсезләнергә урын калдырмады. Аллаһтан сабырлык сорый, ул бирә. Шулай булуына кайчакларда үзе дә аптырап китә. Шундый булып тугандырмы, яши-яши шундыйга әйләнгәндерме? Синең хәсрәтең кемгә хаҗәт? Җанындагысын җилгә җилгәреп йөри торган булмады Гайшә. Яшь булса да, җор теле, акыллы киңәше белән кешеләрнең җанында өмет уты кабыза белде.

Ашап-эчкәннән соң, бик олы эш башларга җыенгандай, озаклап юынып керде Гайшә. Аннан эчке якка кереп, шактый гына кыршылган чемоданына сандыгыннан әйберләрен күчерә башлады. Анда бер кирәк әйбер юк кебек:

әнисенең төсе итеп саклап тота торган күлмәге, кызының Минвәлие кырып алган беренче чәче, иренең күлмәге... Тик болар Гайшә өчен бик тә кадерле, якты сагышка уралган истәлекләр. Ә иң изгесе – бүләк, әнисенең ядкаре булган ак киндер намазлыкка төрелгән Коръәне.

Ул иң кирәк нәрсәләрен генә алырга тырышты. Аларның һәркайсын сыйпап яратып, чемоданына сала барды, телләре булса, бер җылы сүз әйтми түзмәсләр иде. Бөтен әйберләрен таслап ипләп тутырганнан соң, Гайшә суккан ак намазлыкка төргән Коръәнен кулына алды. Аннан, җай гына әйберләр өстенә куеп, намазлыгын сүтеп җибәрде. Шактый кыршылган, таушалган инде. Гайшә китапны алды да күзләрен йомып, күкрәгенә кысты. Андагы җылылыктан борчылган җанына тынычлык иңгәндәй булды.

Гайшә, уйларына чумып, Нәсимәнең шыпырт кына үзе янына килеп чүгәләгәнен сизми дә калган икән. Кызы, әнисенә ияреп, догага кул күтәргән иде.

– Әни, ә син мине калдырып китәсеңме? – дип, Нәсимә, балаларга хас булмаганча, сагыш тулы күзләрен мөлдерәтеп, әнисенә карады.

– Юк, кызым, юк. Әзрәк кенә торам да, сиңа матур күлмәкләр алгач кайтам. Аннан соң бергә китәрбез, – диде Гайшә, кызының чәчләреннән сыйпап. – Мин сине, кызым, гел кояш көлеп торган илгә алып китәрмен. Без бик бәхетле яшәрбез, әйеме?!

– Ә монда кояш елап торамы?

– Юк, юк, кызым, еламый. Туган җирдә кояш елый димени?!

Моңа кадәр ничек төрелгән булса, Гайшә Коръәнен шулай төреп, иң өскә куйды да, көлә-көлә кызын кочаклап, битләреннән, муеннарыннан үпте. Гел генә елап утырып булмый бит. Авызындагы кара канын кеше алдында төкермәскә күнекте инде ул. Кызы алдында бигрәк тә. Хәсрәт белән кешене шаккатырып булмый. Күтәрмәстәй йөкне бирми ул Ходай. Язганын гына бирә.

– Кызым, әйдә, булыш әле миңа. Син бит инде хәзер зур кыз. Менә боларны ипләп куй да, ябыйк. Ятсыннар шунда безгә бәхет теләп.

Нәсимә шап итеп чемодан капкачын япкач, Гайшә сакланып кына бикләрен эләктереп, карават астына этеп куйды.

– Иртәгә Гашурә бәйрәме түгел, ут яндырып утырмагыз. Ятыгыз инде, – диде Закирә алар янына узып тормыйча. Чырт итте дә, ут сүнде. Әтисенең, үзалдына сөйләнгән кебек кенә итеп: «Ярар, сиңа нәрсәгә соң?! Ятарлар. Нишләргә икәнен үзе белә торгандыр, бала-чага түгел», – дигәне ишетелде.

Йокылы-саташулы үтте Гайшәнең төне. Шулай булса да, кәефсез уянмады йокыдан. «Бүре улап, татар юрап китерә», дип, ни күрсә дә, хәерлегә юрарга күнекте ул.

Иртән өчәү бергә утырып, чәй эчкәч, Гайшә:

– Закирә апа, әле киткәнче шактый вакыт бар. Казан астына гына ягып, су җылытсак, юасы олырак әйберләреңне юып китәр идем, – дип, табыннан алдарак торган Закирәгә дәште.

– Кирәкмәс иде инде, Гайшә. Юлга да җыенасың бар, – дисә дә, Закирә, – хәзер ут тергезеп җибәрим әле алайса, – дип, тиз генә утынлыкка чыгып китте.

– Мин инешкә генә төшеп менәм, – дип, ишеккә борылган Гайшәне әтисенең сүзләре туктатты.

– Бу сиңа кирәкме, кызым? – диде Хөсәен, тәрәзәдән урамга караган килеш.

– Нәрсә? – диде Гайшә бусагада тукталып. Ул да әтисенә карый алмады, башын аска игән иде.

– Безнең пычракны чистарту. Ике апаңның берсенә дә кирәкмәгәнне, бер син өзгәләнәсең. Синең үз мәшәкатең дә баштан ашкан бит, балакаем. Эшнең бетәсе юк аның. Утырыйк әле икәү сөйләшеп, – дип, әтисе борылып, кызына карады. Әтисенең күзләренә күтәрелеп караган иде, Гайшәнең тәннәре калтыранып китте. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды. «Җебемә, Гайшә, – диде ул үзенә. – Әтиеңне кызгансаң, сыгылма».

– И-и-и әти! Эш бетмәсен инде. Аннан нишләрбез, – дип, бөтен өй эчен балкытып елмайды да, әтисе янына караватка килеп утырды. Кызын кочаклаган кебек итеп, әтисен үзенә таба тартып кочты да:

– Әти, бүтән алай димә. Синең пычрак – минем пычрак ул. Мин юган күлмәкне киеп, кул җылымны тоеп йөрерсең. Мин бит синең төпчегең. Ник малай булмадым икән мин, әти?! Беркая китми, сезне тәрбияләп, сезнең белән генә яшәр идем, иеме? – дип көлеп, кытыршы битләреннән сыйпап куйды. – Апаларга син рәнҗемә. Һәркемнең үз тормышы, үз тәртибе. Ә без синең белән бергә бик күпне күрдек бит, әти. Исән булыйк әле, безнең урамда да бәйрәм булыр, – диде дә, күзен кысып, әтисенең борын очын бармагы белән югары чөеп ишеккә юнәлде. Ишектә Закирә белән чак кына маңгайга-маңгай бәрелмәделәр.

– Син булган суларны салып, ут куеп җибәрә тор, мин хәзер, – дип Гайшә чыгып китте.

Керләрен чайкап элгәннән соң, Гайшә кичә сандык актарганда, кырыйга гына куйган француз яулыгын почтальон Миңниса китергән «Хезмәт байрагы» гәҗитенә төрде дә Мәхтүмә карчыкка китте. Кайдан чыккандыр, француз яулыгы, имеш. Бала юрганы кадәр бу кызыл яулыкка борма-борма ап-ак татар бизәкләре төшкән югыйсә. И Аллам, башыңдагы яулыгың да үзеңнеке булмагач соң...

Гайшә, тыкрыктан урамга чыгуга, Мәхтүмә карчык капка төбендә ике җиңел машина күреп алды. Вакытсызрак килдем бугай, дип уйлады ул. Килеп җиткәнче, машиналарның берсе кузгалып та китте. Гайшә ишек тоткасына үрелгән генә иде, ишектә алты-җиде яшьлек малай иярткән яшь хатын, аның артыннан Мәхтүмә карчык үзе күренде.

– Нихәл, Мәхтүмә астай, – диде Гайшә, артка чигенеп. – Кунакларың бар икән.

– Китәләр инде. Малаен алып килгән. Самардан, ди.

Карчык кунакларын капкага кадәр озата китте. Ярдәм сорап, шифа өмет итүчеләр Мәскәүдән кадәр килә икән, күчтәнәчне дә мулдан калдыралар икән, дип сөйләсәләр дә, ирсез хатынның ихатасы «мескен» шул. Аталары кулак дип, Себергә сөрелсә дә, күршедәге Гыйльманның тормышы да, йорт-җире дә гөлт итеп тора. Гайшә уйларына батып ике каралтыны карап торганда, Мәхтүмә борылып та килде.

– Байлардан калган гадәт буенча капкага кадәр озаттым әле үзләрен, –

дип, ягымлы елмайды карчык. Гайшә аның күзләренә карады. Сагышлы бу күзләргә август кояшының куе җылысы тулган иде.

– Ник байлардан калган дисең, Мәхтүмә астай?

– Кергән кеше байлыгымны эләктереп китмәсен дип, алар шулай озаткан булып, карарга чыкканнар инде, – диде дә кеткелдәп көлеп җибәрде.

Көлә дә белә икән бу карчык. Нишләп элек бу кешедән куркып йөрде икән Гайшә? Кайдан гына алып сихерче диделәр икән? Гайшәнең башыннан шундый уй узды.

– Әйдә, уз. Нәрсә, китәргә уйладыңмы? Ходай хәерле кылсын. Ризык йөртә инде бәндәне, – дип сөйләнеп, карчык өенә узды. Гайшә аңа иярде.

– Уйладым-уйладым да тәвәккәлләргә булдым. Ялгыз башка кайда да бер – таң ата да кич була.

– Син ялгыз түгел, булмаганны сөйләмә. Йортка бер дога кылыйк. Утыр.

– Мәхтүмә астай, тиле сүзен тиз сөйләр, дигәндәй, сиңа кечкенә генә бүләк. Төсем итеп бәйләрсең, – диде дә, гәҗиткә төргән яулыгын таратып, карчыкның башына япты.

– Аллакаем, шундый зур бүләк белән йөриләрме?! Рәхмәт инде. Мине зурлаган өчен сине Ходай зурласын. Барган җирләреңдә юлдашың Хозер булсын, рәхмәт фәрештәләре саклап йөртсен үзеңне. Бәндәгә ышанычың югалганда да, Аллаһка югалмасын. Иманыңны җуйма, өметеңне өзмә. Эшне үзеңә юлдаш ит. Аллаһының бүләге сиңа көч бирер.

Шулай диде дә карчык түрдәге ике тәрәзә арасына элгән Аятел Көрсигә озак итеп карап торды. Карашы анда гына туктап калмыйча, үтәли тишеп, еракка сузылган иде. Әйтерсең лә, ул Гайшәнең барасы юлын күрә.

– И-и-и, нәрсә сөйләп утырам. Син үзең дә бик акыллы, бик булган хатын. Минем киңәшкә мохтаҗлыгың юк. Әйдә, чәй эчик әле Самар күчтәнәчләре белән, – дип, карчык җиңеллек белән урыныннан торды.

– Юк, юк, Мәхтүмә астай. Мәшәкатьләнмә. Эчеп тормыйм. Юлга җыенасым бар. Өйдәгеләр дә белми калды кая барганымны, – дип, Гайшә ишек тоткасына үрелде.

– Әллә… син дә куркасыңмы? Сихерләмим мин, балакаем, берәүне дә сихерләмим, – дип, карчык кызып-кызып, чәй әзерләп йөргән җиреннән туктап калды. Баягы дәртнең, җиңеллекнең эзе дә калмады. Ул Гайшәгә арты белән торган килеш, дәшмичә, озак кына тәрәзәгә карап торды.

– Нишләп куркыйм ди, юк, курыкмыйм. Юлга җыенасым бар. Аннан, кызым бит әтиләрдә кала, аз гына булса да, аның янында торасым килә, Мәхтүмә астай. Ю-у-у-к, курыкмыйм. Элек курка идем, хәзер юк. Ачуланып калма. Догада бул.

– Ярый алайса, кызым, тоткарламыйм. Өйләдән соң аерым укып, дога кылырмын. Юлларың уң булсын.

– Амин. Хуш, Мәхтүмә астай.

Гайшә өйләренә җиткәндә, Нәсимә бабасы белән урамнан кайтып килә иде.

– Әнисе кайдадыр йөргән арада, без кызым белән кибетне урап кайттык әле, – дип, Хөсәен абзый үргән сеткасын алга таба сузып, Гайшәгә күрсәтте. – Фәния баетып җибәрде.

Сеткада ике пачка такта чәй һәм шикәр балы белән агарткан прәннекләр иде.

Алар капкадан кергәндә, өйдән кулына сүс бау тотып, Закирә чыкты.

– Син кайда гына йөрисең соң, бабай? Әйдә, бер тавыкны тотыйк әле. Гайшә киткәнче тавык шулпасы пешерик. Юлга да алыр, – дип, ул бабай кулындагы сетканы алып, бауны тоттырды. – Сугым пычагыңны келәттә күргән идем бугай.

Гайшә чәй табыны көйләп йөргәндә, алдан сөйләшеп куйган кебек, ике апасы бергә килеп керделәр. Исәнләштеләр дә, ишек төбеннән узмыйча, бер-берсенә карашып туктап калдылар.

– Мактап йөрисез икән, әйдәгез, узыгыз, – диде урыныннан кузгалмыйча гына Закирә.

– Нәрсә ят кеше бусагасында кебек торасыз, балалар? – дип, әтиләре урыныннан торды, кызларына каршы килеп, кул сузып күреште. Нәсимә йөгереп килеп, апаларын кочаклап алды. Гайшә үзе дә ясый башлаган чәен куеп, апалары белән исәнләшеп, аларны табынга чакырды. Апалары дәшмичә өстәл янына утырыштылар. Дәшсәләр, һәр икесе, елап җибәрүдән курка иде. Гайшә, моны аңлап, тиз генә сүзне уен-көлкегә борып җибәрде. Чәйне тәмамлап, амин тоткач, Гайшә:

– Туганлык менә шундый вакытта күренә инде. Рәхмәт килүегезгә, бик күңелем булды. Бөтен борчуым бетте. Әтиләр өчен дә, кызым өчен дә җаным тыныч булыр, Аллаһ теләсә, – дип, әчке якка керде дә бөтенесен үз янына чакырды.

– Тагын ни кыландыра инде безнең Гайшә, – дип сөйләнсә дә, Закирә урыныннан иң соңгы булып кузгалды. Гайшә сандыгын ачты да кичә кичтән әзерләгән бүләкләрен иркәләп-сыйпап, һәркайсына изге теләкләрен теләп өләшеп чыкты. Әйтерсең лә, кулына алган һәр әйберенә Гайшә күз нурлары белән җан җылысын кушып өләшә иде.

– Аллакаем, ничек күңелең җитә дә, каян башың эшләп бетерә синең, иркәм?! Бөтенебезнең сабырлыгын, юмартлыгын Ходай сиңа биргән, күрәсең, – диде олы апасы, сеңлесенә карап, соклануын яшермичә.

Өйне моңсу бер шатлык тутырды. Гайшәнең бу гамәле аерылу сагышын җиңеләйтеп җибәрде.

– Әйдәгез, бер дога кылыйк. Кызым, бик зурлагансың. Шулай миннән соң да туганлык җебен өзми саклагыз. Сез өч кенә бөртек. Исәнлектә күрешергә язсын, – дип, Хөсәен догага кул күтәрде. Аңа башкалар кушылды. Ул арада ишегалдыннан Әзһәрнең көр тавышы ишетелде.

– Күрше, син әзерме? Әллә кире уйладыңмы?

Әзһәрнең дәшкәнен ишетсәләр дә, бер-беренә күтәрелеп карарга кыенсынгандай, дәшми утыра бирделәр

– Ярый, юлчының юлда булуы хәерле. Көттереп тору килешми, кузгалыйк, – дип, Гайшә урыныннан торды. Әйбере әллә ни күп түгел: бер чемодан да бер сумка. Бер апасы чемоданны, икенчесе сумканы тотты. Үзе исә кызын кысып кочаклады да, җанындагы әрнүен сиздерүдән куркып, идәнгә бастырды. Аннан, башыннан сыйпап, җитәкләгән килеш ишеккә юнәлде. Калганнар барысы да аның артыннан иярделәр. Беркем берни дәшмәде. Кечкенә Нәсимә дә язмышы белән килешкән сыман әнисенең ботларына ук сыланып, дәшми генә атлады. Җебеп кенә төшмәсәм ярар иде, дип уйлады Гайшә.

Кызының җанын яраламый гына, ышанычын, мәхәббәтен югалтмый гына китәргә иде.

Әзһәр Гайшәнең әйберләрен алды да ипләп кенә машинасының әрҗәсенә, апасының әйберләре янына урнаштырды. Әкълимә кабина ишеген ачып:

– Нәрсә мәет озаткан кебек торасыз. Бер дә борчылмагыз, Хөсәен абзый. Бар да әйбәт булыр, Аллаһы теләсә. Менә бит үземне күреп торасыз. Кайтып та китәм, посылка да салам. Өс бөтен, тамак тук. Гайшә дә җимеш белән сыйлап ятар әле, боерган булса. Менә бу былбыл баласына матур күлмәкләр алып кайтыр, шулай бит, кызым, – диде, бөтенесенә берьюлы сөйләп.

– Авызыңа бал да май, Әкълимә апа, – диде Гайшәнең апасы. – Амин, шулай була күрсен. Хөсәен дә, нидер әйтергә дип авызын ачкан иде, тик калтыранган иреннәре сүз әйтергә мөмкинлек бирмәделәр. Нәсимә дә, бала күңеле белән, аерылу минутлары җиткәнен аңлап, күзләрен тутырып, әнисенә күтәрелеп карады. Кызының сагыш тулы күзләрен күргәч, Гайшә калтыранып китте. Яшь әсәре булмаган ул күзләр, төн чыкканчы, Минвәлинекенә әйләнгәннәр иде. Әнисе кызының кулын кысты да, иелеп, маңгаеннан үпте һәм бөтен барлыгын бер йодрыкка җыеп елмайды. Аннан көчкә генә кызының кулын үзенекеннән ычкындырып, әтисенә борылды.

– Ярар, һәркайсыгыз белән аерым кочаклашып тормыйм. Рәнҗеп калмагыз. Исәнлектә күрешергә язсын, – дип, машина әрҗәсенә, сумкалары янына менеп утырды. Озатучылар аңга килгәнче, машина «пуф-пуф» килеп ютәлләгән кебек куе төтеннәр калдырып кузгалып та китте.

Әнисе кулыннан ычкындыруга Нәсимәне бабасы күтәреп алган иде. Машина Миңхәйдәр картлар турыннан борылып күздән югалуга, Хөсәен оныгының җилкәсенә башын салып елап җибәрде. Бабасының тозлы яшьләре Нәсимәнең колак артына кыстырган чәчләрен чылаттылар. Беркем бер сүз әйтмичә, тын гына, тыныч кына елыйлар иде.

Әбелгата күперен үткәч, Гайшә әкрен генә башын калкытып, урамга карады. Әзһәр ул килен булып төшкән, Минвәлие белән бәхетле гомер иткән йортны узып китте. Шулчак, әйтерсең лә, кемдер, Гайшәнең йөрәген салкын учларына алып шытырдатып кысты, ул авыртудан күзләрен йомып куйды. Гайшә күзләрен ачканда, машина инде Уразай урамын чыгып килә иде. Нәҗми тыкрыгыннан, чиләкләрен мөлдерәмә тутырып килеп чыккан, Әфзүниянең авыру кызы белән капка төбендәге карт өянкесенә сөялгән Мәгъшук Мәхтүмәсе – бүген Гайшә күргән соңгы авылдашлары шулар булдылар.

«ГАЗ-53» машинасының тимер арбасында, даңгыр-доңгыр селкенеп, күз күрмәгән җиргә ни дип китеп бара инде бу тол хатын дип, үзалдына сөйләнеп куйды Гайшә. Уң якта Ташлы борын инешкә кадәр сузылган. Әнә Хөсәен кулы арасы – Минвәлие белән печән чапкан, таш-тавыш, себерке әзерләгән җирләре. Барысы да кала, хәерле булсын. Аллаһ теләсә, барысы да яхшы булыр. Җан дусты, бүләге исән булсын. Аллаһ ташламасын.

Бөгелмә станциясендә Әкълимә чемоданнарын бушата башлагач, әллә кире кайтып китимме икән дип тә уйлап куйды Гайшә. Тик бу уеннан бик тиз кайтты. Ю-у-к, Гайшә бер нәрсәгә алынган икән, ахырына җитмичә туктый торган түгел. Бу юлы гына үзенең яшәү рәвешенә үзгәреш кертмәс.

Алар вагонга кереп урнашканда, караңгы төшкән иде инде. Гайшәгә

плацкарт вагонның ян яктагы ятагы эләкте. Бу урында да кешеләр бара, маллар япмаган дип, үзен тынычландырды Гайшә. Әкълимәләр ире белән аслы-өсле урнаштылар. Гайшә чемоданын аларныкы белән бергә куйды. Авыр булса да, сумкасын үзе янына ук күтәреп, баш астына алды. Акча, документ ише әйберләрен кая куярга кирәген Әкълимә апасы алдан ук өйрәтеп куйган иде.

Ул гомер буе поездда йөргән кеше кебек әйберләрен ипләп урнаштырды да, Әкълимә апасының ире проводницадан алып килгән урын-җирне җәеп, яту ягын карады. Йоклап, бөтенесен онытырга тели иде ул. Һәм бөтенесен өр-яңадан, яңа биттән башларга. Әкълимә апалары чәй эчәргә кыстасалар да, эчәсе килми дигән булып, ятарга ашыкты. Поездда селкенеп, өч көн бик акрын үтте.

***

Гайшәләр утырган поезд кояшлы илгә таң атканда килеп җитте. Туып-үсеп, гомер иткән Кичүчаты ук булмаса да, ул уйлаганча төссез, килешсез түгел иде алар төшкән станция. Тик мондагы хатыннарның берсе дә, Әкълимә апасы киеп кайткан кебек ялтыр-йолтыр күлмәктән түгел иде. Урап-чорнап бәйләгән яулыклары да, өсләрендәге күлмәкләре, җиләннәре дә нинди дер төссез, кара-кучкыл төсләрдә иде.

Әкълимәләргә кайтып, чемоданын ачуга, Гайшә телсез калды. Калтыранган куллары белән бөтен чемоданын айкады. Энә түгел бит. Өскә генә куйды. Коръән юк иде чемоданда. Намазлыгы-ние белән юк иде. Гайшә бу турыда берәүгә дә әйтмәде. Урлаган бер гаепле, урлаткан мең гаепле, дип әйтә иде әнисе. Шуңа да, кемнедер гаепләп, гөнаһлы булудан курыкты. Кәефе юклыгын Гарәф тә, Әкълимә дә сагынудан дип, үзләренчә юатырга тырыштылар. Онытылыр өчен апасы белән мамык җыярга чыкты. Әле ярый көннәр бераз сүрәнләнә төште, утыз биш градусны гына күрсәтә, диде Әкълимә эштән кайтканда. Баштагы көннәрдә, кешедән калышмыйм дип тырышып җыя-җыя, билләре катты, беләкләре тырналып-сыдырылып бетте Гайшәнең. Тора-бара гомер буе мамык җыйган таҗик хатыннарын да узып китте. Көнлек егерме килограмм норманы икешәр тапкыр арттырып үти башлады.

– Баерга килдеңме монда, татар хатыны? – диде, авыз-борынын каралып беткән яулык белән чорнаган, соры халаты өстеннән зур гына чүпрәк капчык-сумка аскан юан гына таҗик хатыны. – Коммунистмы әллә?

– Коммунистмы, юкмы икәнемне белү сиңа кирәкми. Ә менә татар хатыны икәнемне белеп торуың әйбәт. Башкаларга да әйт, алар да белеп торсын, – дип, эшен дәвам итте.

– Золмәт, кеше башына сугып, чикләвек ватарга яратасың да, – диде, арттарак баручысы.

Гайшә сүз озайтуны кирәк санамады. Кулы эшләде, ә күңеле белән Коръәнне эзләде Гайшә. Аллаһының бүләге булган, әнисенең, иренең җан җылысын, кызының сулышын сеңдергән Коръәнне кайда, ничек җуйды соң ул? Кайсысына гына кирәк булды икән?

Әкълимәләр какмасалар да, кешедә яшәү авыр иде. Гарәф, хуҗалар белән сөйләшеп, үзләренең күршесендәге саманнан салган буш йортта Гайшәгә

яшәп торырга ризалык алды. Гайшә, эштән соң җыеп-юып чыгарды да шул көнне үк күчте. Төннәр буе Аллаһка ялварды, җае туры килгәндә, намазын калдырмаска тырышты. Тик янында Коръәне белән кызы булмавы җанын көйдерде.

Бакча тулып, җирдә таралып яткан өрек тә, тәлгәшләрен чак-чак күтәреп торган йөзем җимешләре, биек таулардан агып төшкән елгаларның шаулаган тавышлары да йөрәгенә ял була алмады. Монда көзләр тагын да сагышлырак иде. Ул башын артка чөеп, тауларга карап торды да сагышын җилләр иркенә куеп җырлап җибәрде.

Иртән торып тышка чыксам,
Сөяләм баганага.
Нишләтермен бу башымны,
Әйләнсә диванага?

Юк, дивана булма. Елмай. Шушындый таш-кыяларда, ком чүлендә чәчәкләр үсә, агачлар җимеш бирә, ә син булдыра алмыйсыңмы, Гайшә? Син бит Фатыйма кызы, син бит татар хатыны. Шулай диделәр бит үзеңә. Татар башың белән җебеп-агып утырырсыңмы? Дүрт саның сау-сәламәт, тагын ни кирәк сиңа? Мәгъшук Мәхтүмәсе сиңа нәрсә диде? Сора да сәбәбен кыл. Эшлә.

Ак күлмәгедәй ак күңеле күршедәге, кояшта каралган таҗик малайларын-кызларын үзенә тартты. Нәсимәсенә тиясе яратуын Гайшә күрше балаларына өләште. Ә бирү ул сорау түгел, булганны өләшү җиңел. Яхшылык җирдә ятмас, үз балама да шулай кайтыр, диде. Нияте изгедә булды. Аллаһ кына ташламасын.

Гайшә барган Талибжонның өй тулы баласы иде. Сигез баланың икесе инде гаиләле. Ике кечкенәсенә дүрт тә алты гына яшь. Әниләре үлгәнгә ике ел үткән икән. Кара чутыр кебек бу малай белән кызның әнисезлеге кечкенә күзләреннән мөлдерәп күренеп тора. «Юк, кирәкми, мин риза түгел», дип, кире борылам дигәндә, шушы ике пар күз «риза» дияргә мәҗбүр итте. Ятимлекне бит Гайшә ишетеп кенә түгел, ә үз җаны, үз йөрәге аша үткәрде. Энҗедәй асыл яше белән әз юмады ул Кичүчатның бәбкә үләнле чишмә сукмакларын. Шушы балаларның гөнаһсыз яшьләрен түгелүдән сакласам, үземнең бәгырь итем – Нәсимәм дә бәхетле булыр дип уйлады бугай Гайшә.

Никах укыганнарын чаршау артында күзләрен йомган килеш тыңлап торды. Кап-кара сакаллы, чалма-чапанлы хәзрәт укыган Коръән аятьләре башка мәкамдә булса да Гайшәнең яралы җанын тагын бер айкап куйды. Йа Аллам, шул җан тынычлыгым булган Коръәнемнән дә яздырдың. Бу кадәр сынаулар биргәч, сабырлык белән көчен дә үзең бир инде, Раббым, дип, авыз эченнән дога пышылдагандай кабатлап куйды.

Уйлары Минвәлие белән никахланган көннәренә алып китте. Тик татлы хыялдан Гайшәне Әкълимә апасы йолкып алды.

– Мулла синнән сорый, риза булып барасыңмы, ди?

– Ә? Нәрсә сорый? – диде Гайшә йокысыннан айный алмаган кебек.

– Талибжонга чыгарга ризамы, ди? Йоклап утырма инде, җан кисәгем. Ач күзеңне, – дип, Әкълимә аның җилкәсеннән сыйпап куйды. Гайшә ишетми генә түгел, ишеткән тәкъдирдә дә, сүзләрен аңламый иде.

– Риза.

Гайшә көч-хәл белән әйтте. Иреннәре арасыннан түгел, ә җанының кайсыдыр җиреннән кысылып, тырышлык белән чыкты.

Ул, үзен кулга алып, чаршау артыннан чыкты һәм кунакларга пылау бүлә башлады. Өйнең «мехмонхона» дип аталган зур кунак бүлмәсе чаршау белән ирләр һәм хатыннар ягына аерылган иде. Мехмонхонаны майлы пылау исе тутырды. Гайшәгә Талибжонның олы килене Торсоной ярдәм итте. Ирләргә пылауны уллары Әминжон белән Баһодор кертә торды. Никах мәҗлесенә Талибжонның да, вакытсыз бу якты дөньяны ташлап киткән беренче хатыны Шөкронаның да җиде яшьтән җитмеш яшькә кадәрге бөтен туганнары җыелган. Әйтерсең, бөтен кышлак халкы шушында. Йоласы, тәртибе шулай, күрәсең. Аларның һәркайсы сынап, ләкин бик илтифат белән Гайшәне күзәтте. Ак җирлеккә туган ягының вак кына җитен чәчәге төшкән, аяк йөзеннән үк торган күлмәге Гайшәнең якты сагыш тулы йөзен тагын да яктыртып җибәргән. Ике толым итеп үргән чәче биленнән узган. Юка ак сатин яулыгын чөеп бәйләп куйган. Тыйнак, ләкин мәми авыз түгеллеге йөзенә, йөрешенә чыккан. «Менә мин нинди татар хатыны!» – дигән кебек. Чәчәкле-чуклы чуар күлмәк-ыштан кигән кара-кучкыл таҗик хатыннарыннан бик нык аерылып тора иде ул. Алар беркадәр көнләшеп тә, сокланып та карадылар Гайшәгә. Талибжонның балалары да соклануларын яшереп тормадылар. Ул исә, эчке бер горурлык белән Гайшәдән күзен алмады. Мәҗлес азакка якынлашканда, Талибжон сүз алды.

– Гайшә, бире кил, – диде ул гөбердәп чыккан күкрәк тавышы белән. Гайшә башын аска иеп, оялып кына Талибжон янына килде. Карашын аска юнәлтеп, кулларын кая куярга белми торды. Алъяпкыч япкан булса, шуның астына гына яшерер иде дә бит, юк шул.

– Балаларым, – диде Талибжон, бик вәкарь белән, дастархан артында утырган малайларына, читтәрәк торган кызларына, киленнәренә карап. – Әниегезнең рухы рәнҗемәс дип уйлыйм. Начар яшәмәдек. Мәрхүмәнең урыны җәннәтнең җиденче катында булсын. – Шулай дигәндә, аның тавышы калтыранып китте. Хатын-кызлар ялтыр яулыклары белән күзләрен сөртеп алдылар. – Исәннәргә яшәргә, тормыш итәргә кирәк, – дип, ул сүзен дәвам итте. – Дала лаләсенә, йөзем җимешенә кояш җылысы кирәк булган кебек, өйгә дә хатын-кыз җылысы, балаларга ана тәрбиясе кирәк. Гайшә күршегә килгәч тә, Гарәфетдиннәрдә аның ничек үзен тотышы, уңганлыгы күзгә ташланды. Шактый күзәтеп йөрдем мин аны. Хушназар белән Шахноза да гел аның янында булырга тырышты. Бала күңеле бик сизгер. Ятимнеке тагын да сизгерләнә. Елан да җылыга елыша, дия торган иде минем бер татар дустым. Минем ятим балаларым Гайшәдә җылы тапкан икән, димәк, начар түгелдер, дип уйладым. Шуңа күрә олыгыз да, кечегез дә аны әни итеп кабул итегез. Сүз белән дә, күз белән дә рәнҗетмәгез, хәтерен калдырмагыз. Туган илендә ятимлекне дә, авырлыкны да күргән. Кечкенә кызы да анда калган. Аны да үз канатыбыз астына алырбыз. Кош авызыннан төшеп калгандай, бүген ялгыз башы ул монда. Менә шуңа күрә Гайшәнең якташлары Әкълимә белән Гарәфетдин алдында, әниегез Шөкронаның туганнары һәм үземнең туганнарым, балаларым, сезнең алда, Гайшәне рәхәттә яшәтермен дип ышандырам.

Бөтенләй аңлап бетермәсә дә, Гайшә сүзнең нәрсә турында барганын

төшенде. Талибжонның нотыгы бик озын булды, тик беркем дә аны бүлдерергә батырчылык итмәде.

– Шушы бүләгем сүземә дәлил булсын.

Шулай диде дә чапанын бәйләгән билбау-яулыкны сүтеп, алтын беләзек алды һәм Гайшәнең кулына кидерде. Кунаклар «ах!» иттеләр.

– Кирәк түгел иде болары. Без андыйга күнекмәгән бит, – диде Гайшә, бик уңайсызланып. Үзе эченнән генә, Ходай хәерле итсен, диде. Көтелмәгәндә әйтелгән мактау сүзләреннән, сыер бәясеннән дә артык булган алтын бүләктән ул хәтта куркып та куйды. Әйе, бу алтын бик кыйммәт, тик Гайшәнең бабасыннан, әнисеннән бүләк булып күчкән, таушалып беткән Коръәне бәһалерәк булган, күрәсең. Кеше бит кыйммәтле нәрсәне урлый. Шул уйлар белән уңайсызланып, чаршау артына кереп китте. Хушназар белән Шахноза аңа иярделәр. Кунаклар да рәхмәт әйтеп таралдылар.

Шулай итеп, Кичүчатның Хөсәен кызы колак ишетмәгән, күз күрмәгән Янгыйабад дигән таҗик кышлагындагы мамык игү бригадиры Талибжон хатыны булды да куйды. Нык бәдәнле, эре сөякле иде Талибжон. Янып тора торган кап-кара күз, йөзенә килешеп торган карчыга борын. Кул астында эшләүчеләргә бик кырыс булса да, туры сүзле, гадел кеше. Үлгәнен белми эшли, башкалардан да шуны таләп итә.

Киткәненә ел тулып узгач, көзге эшләр тәмамлаганда, Гайшәләр авылга кайттылар. Күп бүләкләр, күчтәнәчләр белән. Сагынуын аңлатырлык сүз булмаган кебек, аның сабырлыгын үлчәрлек үлчәүләр дә юк иде. Нәсимәне алып китәргә дип кайтканнар иде алар. Нәсимә шатлыгыннан нишләргә белмәде, кайда барса да, әнисенең үкчәсенә басып, артыннан йөрде. Коръән турында әтисенә әйтергә дип, берничә тапкыр талпынып куйса да, Гайшә кире уйлады.

Әтисе дә, апа-җизнәләре дә, кечкенә Нәсимә – берсе дә Талибжонны чит итмәделәр. Тик китәр вакыт җитәрәк, әллә берәрсе өйрәтеп куйды, әллә чыннан да китәсе килмәде:

– Әни, мин китмим. Мин бабакай янында калам, – диде дә әнисен кочаклап елап җибәрде. – Син үзең кайт, яме.

– Балам, мин бит сине алырга кайттым. Сине сагынып, – диде дә, Гайшә тезләнгән килеш ике битеннән тотып, кызының күзләренә карады. Алар инде күптән бала күзләре түгел иде.

– Кызым, әйдә безнең белән. Анда синең кебек кызлар да, малайлар да бар. Тәмле-тәмле җимешләр, биек таулар, – дип, Талибжон да чакырып карады. Нәтиҗәсе булмады.

– Ярар инде, кызым, әзрәк исәйсен әле. Аннан үзе карар. Авырдыр, нихәл итәсең. Капчыкка салып алып китеп булмый, песи баласы түгел бит, – диде әтисе.

Яше акмаса да, җаныннан каннар агызып китте Гайшә. Күңелендә ниләр актарылганын бер Ходай да үзе генә белде. Һәм Нәсимә үзе.

* * *

Гайшә бүген йокыдан ниндидер бер күңел күтәренкелеге белән уянды. Уянгач та, әле шактый тормыйча, уйланып ятты. Матур төш күрде ул бүген. Имеш, келәтләренә капчык-капчык иген кайтарып тутырдылар. Ул

капчыкларны нindидер яшь ир-атлар ташый кебек. Араларында Гайшә бик танымаганнары да бар. Кыз балалар да бар, имеш, шунда. Гайшә чүмеч төсле бер савыт белән капчыктагы икмәкне ала да бармаклары аша уздырып, янәдән капчыкка сала. Шулай әле берсен, әле икенчесен карый. Шул капчык ташучылар арасында кызы Нәсимә дә бар. Ә Гайшә үзе әнисенең төсе булган ак күлмәк-яулыктан, имеш. Һәм нәрсәдер укыймы шунда авыз эченнән генә, әллә җырлыймы – аңлашылмый. Шул халәттә уянып китте Гайшә. Бүре улап, татар юрап китерә, ди, төшне. Гайшә төшен яхшыга юрады. Капчык-капчык икмәк китергәннәр икән, димәк, начар булмас.

Ул төшен Талибжонга сөйләде. Сөйләгәндә үк, ничектер елмаясы килә иде аның.

– Аллакаем, – диде Талибжон, – хәерлегә булсын. Күптән мин сине болай күргән юк иде.

Шул көннән башлап, Гайшә, әкияткә ышанган бала кебек, могҗиза көтеп яши башлады.

Башка гаиләләрдә, ата-баба йоласын саклап, малайлар-киленнәр өерелеп бергә яшәсәләр дә, Талибжон ике улына да аерым учак тергезде. Дөньяга башкачарак карап, алдан күреп яши торган кеше ул. Үзенең әллә ни белеме булмаса да, гыйлеме бар. Балаларына да гел «укыгыз» дип тукып килде. Олылары үзенә ярдәмче булсалар, калганнарын җаныннан өзеп булса да, шәһәргә укырга җибәрде. Мәликә белән Мәдинә укытучылыкка киттеләр, Мохитобон табиб һөнәрен сайлады. Рөстәмжон юристлыкка укырга керде. Алар укуларын тәмамлап, башлы-күзле булуга Хушназар белән Шахноза шәһәргә киттеләр. Талибжон белән икесе генә торып калганнар иде төп йортта.

– Әй, бигрәк кызганам шул Талибжон балаларын. Үз әниләре Шөкрона исән булса, бергә укмашып, шушында яшәп ятарлар иде. Тараттың да бетердең, төрлесен төрле якка, Гайшә. Үзеңнән өзелеп төшмәгәннәр шул, – диде Гөлибодом, эштән кайтканда.

– Аллаһка шөкер, тапкан аналардан ким итеп үстермәдем берсен дә. Сукыр, күзле ике куллап ашый дип уйлый икән, ди. Гөлибодом, сиңамы соң минем җанымда ниләр ятканын аңларга, – дип, сүзне кырт кисеп куйды.

Эштән соң, Талибжон күршедә генә яшәгән улына азрак булышыйм дип кергән иде. Шуннан хәле китеп чыкты.

– Гайшә, теге, Нәсимә җибәргән үлән белән чәй пешер әле. Нәрсәдер хәлем китеп, күңел болганып тора, – дип, тизрәк түшәккә ауды.

– Гайрәтләнеп, авыр күтәрдеңме әллә? Әзрәк үз рәтеңне үзең белергә бит инде. Вакыты белән артык егетләнәсең.

Үзе шулай сөйләнгән булды, үзе чәй пешергән арада Талибжонга күз салгалады. Талибжонның күз акларына кып-кызыл булып кан йөгергән иде. Шулай булса да, бер генә дә начар уй килмәде күңеленә. Эчтән җырлый-җырлый чәй көйләде. Җимешләр салып, чәй ясады да:

– Торма, хәзер үзем китерәм, – дип, Гайшә касәсен күтәреп, Талибжон янына чүгәләде. Авыз-борыннары кыйшайган, сул күз кабагы асылынып төшкән иде аның.

– Ходаем, ни булды сиңа? – дип кычкырып җибәрде. Талибжонның

нәрсә әйткәне аңлашылмый иде. Гайшәнең коты очты. Башына килгән иң беренче уй: «балалар нәрсә әйтер?» булды. Ул, тиз генә, күршедәге малайларына йөгерде.

– Керегез әле тизрәк, әтиегез авырып китте, – диде ул койма аша. – Кайсыгыз бар анда? Ишетүче бармы соң?

Гайшә, әле Әминжоннарның, әле Баһодорларның коймасын какты. Аннан янәдән өйләренә торып йөгерде. Ул арада хатыннары белән ике малай да кереп җиттеләр.

– Нәрсә булды, Гайшә әни? – диде Әминжон, башкалардан арткарак калып.

– Сездән чыккач, нәрсәдер хәлем юк, арып киттем дип яткан иде. Миңа үз илеңнән килгән үлән белән чәй пешер әле, диде. Ул арада килсәм, әнә шулай булган, – дип куркынган күзләре белән Әминжонга күтәрелеп карады. – Таза гына эшләп йөри иде бит юкса.

Ул да булмады, оныкларның берсе фельдшер Солтонойны ияртеп килеп тә җитте. Авыруны игътибар белән караганнан соң, Солтоной Гайшәне һәм малайларны алдагы бүлмәгә дәште.

– Талибжон әкәгә инсульт булган. Мин хәзер район больницасына шалтыратам. Аннан докторны алып килерсез. Больницага салырга дияр.

Баһодор тиз генә кесәсен капшап, кәгазь акча алды да ипләп кенә фельдшер кызның халат кесәсенә шудырды. Моның ише нәрсә Гайшә өчен баштарак бик ят тоелса да, хәзер исе китми. Тик аңламый гына.

– Бәлки, өйдә генә калыр, – диде Солтоной берни булмагандай һәм ишеккә юнәлде. Аннан туктап:

– Янында теләсә ни сөйли күрмәгез. Сөйләшә алмаса да аңында ул, – дип чыгып китте.

Баһодор районнан докторны алып килде. Ул Талибжонны больницага салуны кирәк санамады. Йөрәге таза, бу хәлдән чыгар, диде. Атнага бер үзен алып килеп йөрергә сөйләшеп, кесәсенә акча салгач, янәдән илтеп куйдылар.

Гайшә бу йортка килгәндә, Талибжонның ике баласы башлы-күзле иде инде. Аннан соң зурлап туйлар ясап, икесе бергә килен төшерделәр, өч кызны кияүгә бирделәр. Туган якларына кайтып Нәсимәсенең дә туен үткәреп килгәннәр иде. Талибжон үз балаларына никадәр чыгым тотса, Нәсимәгә дә шулкадәр чыгарды. Хәтта Әминжон белән Баһодор гаиләләре дә туйга дип, бүләк биреп җибәрделәр. Әле бергә-бергә яшиселәре, кыз биреп, килен төшерәселәре алда иде.

Балалары таралганнан соң, Гайшә урындык алып, Талибжон янына утырды. Талибжонның уң ягы бөтенләй хәрәкәтсез иде. Шулай булса да, үрелә-сузыла, Гайшәнең арка җылысына ябышкан ниндидер чүпне кармалап тапты. Ала алмаса да, елмайган кыяфәт чыгарды. Гайшә иренең күзләренә карарга читенсенде. Дөресрәге, курыкты бугай. Чөнки кылт итеп, авылыннан киткәндә, Мәгъшук Мәхтүмәсенең әйткән сүзе исенә төште дә, йөрәге жу итеп китте. Бу күзләрне йомдыру да миңа калыр микәнни, Ходаем, дип куркып уйлап куйды. Аннан, эш тапкан булып, Талибжон яныннан торып, тышка чыгып китте.

Гайшәнең куркуы юкка булды. Балаларның берсе генә дә, ялгышып та,

аңа гаеп ташламадылар. Баланың күп булуы менә шушындый вакытта кирәк икән ул. Көнгә бер тапкыр хәл белергә булса да ярый. Шәһәрдәгеләре дә җай табып кайтып-китеп тордылар. Әлбәттә, аталарын карау Гайшә өстендә. Нихәл итәсең инде, никахлы ирең булгач. Талибжон тамакка да яхшы ашый иде. Шуңа күрә иң авыры астын алыштыру. Баштарак малайлар булышты. Тик, гел-гел алар да кереп бетерә алмый башлады. Тора-бара Талибжон әллә ябыгып, җиңеләеп калды, әллә Гайшә җаен алды. Малайларны бик борчымаска тырышты.

Җиңел түгел иде Гайшәгә. Талибжон урын өстендә яткач, тирә-күршеләр сирәк керә башлады. Әкълимә апасы гына ике арага тузан кундырмады. Бер кергәч:

– Бала тәрбияләгәндәй тәрбиялисең, сабый караган кебек карап торасың. Талибжон гомер буе бай яшәде. Аталарыннан соң куып җибәрерләр дип курыкмыйсыңмы? Ата малы талаштыра бит ул. Кеше, Баһодорның хатыны Дилором, каенатайның байлыгына кызыгып кына карый инде ул аны, дип сөйли, – диде.

– Кеше дигәнең синме инде ул? Кереп, чәемне эчәсең дә аннан соң каныма тоз салып чыгып китәсең, Әкълимә апа. Әйтсә әйткәндер, анысын мин үзем җайлармын, – диде дә утырган җиреннән торып китте.

– Бабаем югалткандыр, – дип, Әкълимә тиз генә чыгу ягын карады.

Гайшә тимерне кызуында сугарга булды. Сүз куып йөрү әйбәт булмаса да, Әминжонга, кичкә ике гаилә бергә җыелып керерсез әле, сөйләшәсе бар иде, диде. Бакчага мул итеп табын корды: пылау әзерләде, авылыннан килгән үләннәр белән чәй пешерде.

Һәр ике килен дә кучтәнәч күтәреп кергәннәр иде. Рәхмәт үзләренә, бервакытта да буш кул белән кермиләр.

– Йокламыйсыңмы? Әнә, малайлар-киленнәр хәлеңне белергә кергәннәр, – дип, Гайшә Талибжонга иелде. Ул йокламый иде. Гайшә азрак әйләндереп куярга җыенганда, Баһодор:

– Син нәрсә, Гайшә әни. Хәзер үзебез. Без монда булганда, аз булса да, ял ит инде, – дип, әтиләренең астындагы җәймәләрен рәтләп, бер яккарак борып, яннан вак мендәрләр белән терәтеп куйдылар. Гайшә киленнәр белән бакчадагы дастарханга чыгып, табын көйли башлады. Бераздан, әтиләре яныннан, Әминжон белән Баһодор да чыкты. Бишесе дә табынга утырды.

– Әтиегезне сез керер алдыннан гына ашаттым, – диде, акланган кебегрәк итеп, Гайшә. – Әйдәгез әле, ашыйк, тәмле чагында.

Берәү дә ризыкка кагылмады, барысы да Әминжонга караганнар иде.

– Гайшә әни, син безне пылау ашар өчен чакырмадың бит. Нәрсә булды? – диде Әминжон, әтисенеке кебек кап-кара күзләре белән Гайшәгә карап. Әминжонның да чигәләре дала кылганы кебек көмешләнеп килә икән...

– Әйе. Тик ничек башларга белми торам әле. Бәлки, бу сөйләшү кирәк тә түгелдер. Ләкин үзем чакыргач, аңлашырга кирәк дип саныйм.

Балалар, миннән әллә ни артык кече булмасагыз да, әни дип зурлап дәшүегез өчен Аллаһының рәхмәте яусын. Әтиегез белән дә, сезнең белән дә начар яшәмәдек. Байлык артыннан кумасак та, мохтаҗлык күрмәдек. Язмыш менә безгә сынау җибәрде, монысын да кеше көлдермичә узарга

Ходай ярдәм бирсен. Сез беләсез, мин әйтсәм турыдан әйтәм, арттан сөйләп йөри торган гадәтем юк. Шуңа да бүген сезне дәштем. Талибжон белән бер-бер хәл булса, балалары сине куып җибәрәләр, Дилором: «каенатайның байлыгына алданып карый ул», – дип сөйли икән, диделәр. Әгәр дә сез шулай уйлыйсыз, ниятегез шулай икән, минем ниятемә дә Ходай шаһит. Тик ни генә булса да, атагыз сәламәт чагындагы кебек төп нигезгә җыелып хәл итик. Син ни әйтерсең, Әминжон? – дип, сүзен тәмамлады Гайшә.

Хатынының исемен ишетүгә Баһодор, усал итеп, хатынына карады да сикереп торды. Тик Гайшә Әминжонга дәшкәч, кире утырды.

Балалар бер-берсенә карашып, сүзсез калдылар.

– Болар барысы да юк сүз, Гайшә әни, – диде Әминжон, туганнарына карап. Безнең китек күңелне түгәрәкләр өчен безгә авыр вакытта, әтиебезгә терәк булып килдең. Сигезебезнең берсе дә сиңа, ялгышып та, «кит» дип әйтергә батырчылык итмәс. Моңа кадәр ничек яшәгән булсак, шулай яшибез. Алда да шулай яшәрбез, – диде Әминжон. Аннан соң, «әйдә, хәзер син әйт», дигәндәй, Дилоромга таба борылды.

– Гайшә әни, кемдер явыз шаярткан. Юк сүз. Беркөнне, базардан кайтканда, Әкълимә апа белән сөйләшеп торган идек. Безнең әти Гайшә әнинең изге хатын икәнен алдан сизеп алган. Алай булмаса, никах көнне үк алтын бүләк итмәс иде, дигән идем. Бу шул сүзләр. Тик аны Әкълимә апа үзенә кирәкчә сөйләгән. Әкълимә апа сөйләгән бит, шулаймы, Гайшә әни? – диде ул. Бик чая иде Дилором.

– Әйе, Әкълимә апай әйтте. Мин аның дөрес түгел икәнен белдем. Шулай да, үзеңнән ишетәсе, бөтенебез бергә җыелып сөйләшәсе килгән иде. Менә, бер төер дә калмады, бөтенесен юып алган кебек булды. Әйдәгез, килен булсагыз килен булыгыз, пылау суынырга өлгермәгәндер, табынга алып килегез инде, – дип, малайларга карап, күзен кысып алды Гайшә.

Бүтән бу хакта сүз кабатланмады. Гомер йомгагы үз җае белән тәгәри торды. Дүрт ел әйтергә генә ансат. Сирәк кенә килгән фельдшер Солтоной да гаҗәпләнә. Әле кичә дә:

– Гайшә апай, ничекләр шулай оста карый беләсең син? Ничә ел ятып, бер генә җире дә суелып чыкмады. Кешеләрнең бер-ике ай эчендә янбашлары тишелеп бетә, – диде, хисап өчен генә Талибжоннарга кергәч.

– Яратырга кирәк, Солтоной үскәнем, яратырга. Һәм ышанырга, – диде Гайшә, серле итеп.

– Аңламыйм мин сине, Гайшә апай, – дип аптырап карап торды да чемоданын күтәреп капкадан чыгып китте.

– Аңламавың бер дә гаҗәп түгел, Солтоной. Мин бит башка чишмәнең суын эчеп үстем.

Аның карашы әллә кая, еракларга, таулар артына киткән иде. Әйтерсең лә, шул тау артында гына калган иде ул рәхәт мизгелләр.

Соңгы вакытта Талибжонның хәле начарлана төште. Тамакка да ашамас булды. Гайшә күбрәк карты янында булырга тырышты. Шәһәрдәгеләр, бигрәк тә Рөстәмжон, бернәрсәгә мохтаҗ итмәделәр. Кибеттән, базардан кирәк-яракны Әминжонның, Баһодорның балалары алып кайтты. Төннәрен дә йокылы-уяулы уздырды.

Гайшә янәдән кулына Коръән алды. Кичен хәл белергә кергән Әминжонга:

– Озак торса, әтиегез ике-өч көн торыр. Балаларның барысына да хәбәр салырга кирәк. Авызыннан җаны чакканчы, исән чакта күреп калсыннар, – диде. Әминжон, әтисе яткан якка кереп, озак кына карап торды да башын аска иеп чыгып китте.

Әминжон чыгып киткәч, Гайшә ире янына килеп утырды. Аннан, әллә Талибжонга, әллә үзенә сөйләгәндәй, «И Талибжон, әле бит безнең икебезнең эшлисе эшебез бар иде. Без бит Коръәнне табарбыз дигән идек. Табылмасмы икәнни инде?» – дип, Талибжонның кулын үз кулына алды. Шулвакыт Талибжон нидер әйтергә теләп ыңгырашып куйды. Гайшә, тиз генә бисмилласын әйтеп, иренең авызына су тидерде. Талибжон көч-хәл белән генә күз кабакларын күтәрде һәм пышылдап диярлек:

– ...лыр, – диде.

Тагын ике көннән Гайшә, мәңге ачмаска дип, үз куллары белән Талибжонның күзләрен йомдырды. Болын кадәр йорт шыр ялангач калды. Гайшәнең җаны өзгәләнсә дә, күзеннән яшь чыкмады. Соңыннан, күзеннән сыңар яшь тә чыгармады, яшьләй кавышкан кешесе түгел шул, диючеләр булса да, сүз куып йөрмәде. Аның яшьләре күптән беткәнен белмиләр иде шул алар. Авыр вакытта балалары янында булды. Ашларын да бик зурлап, бергәләп уздырдылар.

Гайшәнең җанына тынычлык, акылына сабырлык биргән нәрсә, Талибжонның әйткән соңгы сүзе булды. Ул ялгыш ишетмәде, «Коръәнең табылыр», – диде бит. Димәк, табыла, Алла кушса.

Талибжон үлеп, ел узуга, башта Шахноза тормышлы, аннан соң Хушназар башлы-күзле булды. Кешенекеннән ким-хур булмасын дип, бик нык әзерләнде Гайшә. Калган алты туган да, барысы бер йодрык булып, бөтен шартына китерделәр. Кунаклар бик күп булды. Нәсимәләрне дә чакырып, телеграмма сукканнар иде, тик килә алмадылар. Шулай да, котлап җибәргән телеграммалары артыннан ук зур гына ике посылка килеп төште. Каз мамыгыннан ясаган ике пар мендәр янына кипкән мәтрүшкә дә тыккан иде Нәсимә.

Нәсимәләр җибәргән туй бүләкләрен Талибжон балалары зурлап кабул иттеләр. Килгән кунакларга күрсәтеп, Гайшә әниләренә рәхмәтләрен җиткерделәр. Шахноза тормышка чыгып, шәһәргә китте, ә Хушназар яшь килен Гәүһәр белән Гайшә әниләре янында яшәп калды.

Олы абый буларак, бер кичне Әминжоннар яшьләрне кунакка дәшүне сәбәп итеп, барысын да үзләренә җыйдылар. Мәҗлес бик күңелле булды. Ваграклар абыйлары янында калдылар. Гайшә малайлары һәм киленнәре белән кайтырга чыкты.

– Кызганыч, әти күрмәде бу көнне, – диде Баһодор тын гына барган җирдән.

– Әтиегез белмәстәй кеше түгел иде, белми калмас. Иманлы җаннарга барысы да мәгълүм, дия иде минем әнием. Ә әтиегез, шөкер, имансыз кеше түгел иде, – диде Гайшә, каядыр тауларга карап. Кара тут йөзле, ялтыр-йолтыр күлмәк кигән, инде үзләре дә олыгаеп килүче киленнәре, малайлары арасында Гайшә берүзе ап-ак булып яктырып бара. Баштарак

ул да, бөтенесе кия торган, чәчәкле-чуклы күлмәк киеп карады. Яңа бергә яши башлаган вакытлары гына иде әле. Талибжонның туганы Камилжоннар кунакка дәштеләр. Шунда барырга дип, базардан яшел җирлеккә кызыл мәк чәчәкләре төшкән бик матур күлмәк алды Гайшә.

– Ничегрәк? Матур булганмы? – дип, яңа күлмәген киеп, Талибжон янына чыкты.

– Бик матур күлмәк, – диде Талибжон, озак итеп карап торгач. – Ләкин синеке түгел. Күңелеңә авыр алма, Гайшә. Булдыра алсаң, никахка кигән кебек аксыл күлмәктән йөре син. Сиңа бик тә килешә аксыл төс. Фасоны да бик матур аның. Мондый күлмәк бөтен хатында. Ә минем хатын андый булмасын, син бит татар кызы, – диде Талибжон, елмаеп.

Гайшәгә шул сүз җитә калды. Таҗик Талибжон хатыны гомере буе өстеннән ак күлмәген, башыннан ак яулыгын төшермичә татар хатыны булып гомер итте. Ничек кенә арып кайтса да, кичтән юып куяр иде дә, иртән чип-чиста ап-ак күлмәк-яулыктан барыр иде эшкә. Талибжон да Гайшәгә бүләккә гел аксыл тукыма, йә булмаса яулык ала торган булды. Балалар да шуңа күнекте. Гомумән, һәммәсе дә аны актан күрергә ияләнде, башкача кабул итмәделәр.

– Әни, әллә чәй эчеп алабызмы? – диде Гәүһәр, өйгә кергәч. – Пылаудан соң тагын эчәсе килеп тора.

– Эчегез, эч, миңа карамагыз. Ятар корсак, ярты булса да ятар, ди. Мин әзрәк укыйм да ятам, – диде.

Гайшә ут яндырып тормады. Юынды да кулына Коръәнен алды. Алды да, озак итеп, күзләрен йомып торды. Әйтерсең, моңын, тавышын, мәкамен тыңларга, серен аңларга тырыша иде. Әйе, иптәш, терәк иде бу Коръән дә. Тик тегесенә Гайшәнең туган ягы, иң кадерле истәлекләре, җан рәхәте, күңел газаплары сеңгән иде. Авылында торганда, Гайшәнең бөтен сере үзен мәңгелек белән бәйләүче Ясин сүрәсенә сыеп беткән кебек тоела иде. Хәзер инде, ул Коръәнен җуйгач, серле, изге китапның һәр бите, андагы әнисенең сөлге, кашагага чиккән бизәкләре кебек матур, һәр хәрефе аның нәселенең тарихын сөйли кебек. Шул уйлары, Гайшәнең борсаланган җанын, тагын да әрнетеп җибәрде. Ничек тә табарга кирәк. Әлбәттә, шактый вакыт узды. Тик теге вакытта күргән төше, аннан соң Талибжонның соңгы сүзләре Гайшәгә ышаныч өстәде. Шуларны искә төшергәч, үзендә көч сизгәндәй булды. Ул, уйларыннан арынып, Турсоной Коръәнен ачты.

Вакыт уза торды. Дала тутырып, тагын кыргый лаләләр чәчәк атты. Таҗик иленә тагын шаулап яз килде. Талибжонның «табылыр» дигән сүзе, көннән-көн җанына тынгы бирмәде. Табылыр, тик кайчан? Кайдан?

* * *

Нәсимәдән килгән хат Гайшәнең уйларын тиешле юлга салып җибәрде. Турыдан ярып әйтмәсә дә, кайтмыйсыңмы дигән мәгънәдәрәк язган иде Нәсимә хатны. Шул хат бөтенләй җанын алгысытты.

Бер көнне Гайшә эштән Әминжон һәм Баһодор белән бергә кайтты. Башкалардан аерылып, азрак баргач:

– Әминжон, алдагы шимбәгә Гайшә әни барыбызны да парлап чакыра дип, һәммәсенә хәбәр сал әле. Ә Хушназар бер таза гына куйны чалыр.

Хатыннарыгызга әйтерсез, булышырга кирәкләр. Үзебез генә өлгереп җитә алмабыз, – дип, Гайшә җилән кесәсеннән кулъяулыгын чыгарды да битендәге тирләрен сөртеп алды. Ак яулыгы астыннан чыккан тирләп юешләнгән чәчләре тотам-тотам булып чигәсенә ябышкан иде. Ничә ел шушында гомер итеп, яулыкны һаман үзенчә бәйләде ул.

– Нинди дер бәйрәм түгелдер бит, Гайшә әни? – диде Баһодор, елмаеп. Аннан абыйсына карап куйды.

– Ярар, борчылып торма, әйтермен. Тагын нинди дер ярдәм кирәкме? Башын иеп барган Әминжон Гайшәгә сынаулы караш ташлады.

– Әлегә юк кебек. Кирәк булса Хушназарга да, сезгә – икегезгә әйтәм инде. Тагын кемгә барыйм. Бөтен карап торганнарым сез. Үзем белән бергә картаеп барасыз бит, – дип елмайды ул.

– Нинди картаю, ди, ул, Гайшә әни. Әле син кызлар кебек, кияүгә бирерлек, – дип шаяртты Баһодор.

– Авызыңнан җил алсын, диләр татарлар. Аллаһының «Амин!» дигәненә туры килмәсен, – диде Гайшә.

Әминжонга бу шаярту ошамады.

– Юкны сөйләп кайтма син, малай. Тапкан шаярыр нәрсә. Бала-чага төсле, – диде ачуланып.

– Менә бергә җыелгач, бер бәйрәм булыр. Күптән бөтенебез бергә җыела алмыйбыз, – диде Гайшә, Баһодорның шаяртуына артык әһәмият бирмичә. Арыган тәннәрне иркәләп, таулар арасыннан язгы җил исте.

– Шулай сөйләштек алайса. Сезгә ышанам, балалар. Ярар, киленнәргә, балаларга сәлам, – дип, үз ихатасына китте Гайшә. Ике бертуган, сөйләшеп, урамда басып калдылар.

– Ни булды соң әле бу? Мин нәрсәдер аңлап бетермәдемме? – диде Баһодор абыйсына.

– Нәрсә аңламыйсың? Нинди дер сүзе бар аның. Әллә кечкенәләр кыерсытамы икән? Ярар, малайларга, кызларга әйтергә кирәк. Тагын сөйләшербез әле, – дип саубуллашып, өенә китте.

Өйдәгеләр шатланышып, кунаклар кабул итәргә әзерләнә башладылар. Сәбәбен алар сорамады, Гайшә үзе кузгатмады. Әкрен генә әзерләнә торды. Ничек итеп балаларының күңелен җәрәхәтләмичә, матур итеп китү турында уйланды. Монда килгәч тә таҗик хатыннарының хушын алган бавырсагын пешерде. Балаларның кечерәкләре бигрәк тә ярата лар иде. Болай да аш-суга уңган Гайшә, читтән генә күзәткәләп, таҗик ашларын да оста итеп әзерләргә өйрәнде. Әйтерсең, шушында туып, шушында гомер буе яшәгән.

Билгеләгән көнне, Хушназарга булышырга дип, Баһодор керде. Абыйсы кергәч, Хушназар бу җаваплы эшне аңа тапшырды. Тиз арада бер симез сарыкны чалып, эшкәртеп бирделәр. Ул да булмады, килендәшләр Гәүһәргә табын әзерләшергә кереп җиттеләр. Аллага шөкер, киленнәренең нинди генә эшкә тотынсалар да, куллары ятып тора. Киленнәр кергәндә, Гайшә бер казанга пылау куеп, икенчесендә шулпа әзерләргә җыенып йөри иде.

– Һай безнең Гайшә әни, арымаса да арымас икән! Кызлар кебек йөгереп йөри, – диде капкадан кереп-керешли Дилором. Шуның Гайшә әни дигәнен бик ярата Гайшә. Дилором ашыкмыйча гына, һәр иҗеген аерып, ә-ни дип өзеп әйтә.

– Киленнәрең күп булгач, шулай йөгереп йөрисең инде, – дип шаяртты Гайшә, алар белән күрешкәч. Әйтми белсен, кушмый эшләсен, дияргә ярата ул. Аллага шөкер, ул яктан һич кенә дә теш агартып, сүз әйтә торган түгел. Малайлар да, киленнәр дә эш рәтен белеп үскәннәр. Бу юлы да, килеп кереп исәнләшүгә, икесе тиң эшкә тотындылар. Гәүһәр, олы килендәшләренә илтифат күрсәтеп, алар белән бергә кайнады. Гайшә үзе дә, гомер буе, ялкау татар хатыны диюләреннән куркып, бөтен эшкә кешедән алда барып ябышты. Аннан инде, авырлыкны җиңү ләззәтен эш белән сабырлыктан тапты, Коръәннән җанына җылы алды.

– Гайшә әни, нинди бәйрәм соң бүген? Син бездән яшереп кенә, нәрсә уйлап таптың тагын? – диде олы килен Турсоной.

– Бәйрәмдерме инде, әйрәндерме... Бездә, бер күрешү – бер гомер, диләр. Сөйләшеп утырырбыз. Туганлык җепләрен дә ныгыту булыр. Гаилә бит ул – бер учак. Көлләрен таратып, күмерләрен бутап, утын ташламасаң, җылысы кими, – диде Гайшә, казан капкачын җайлап.

Җил Язгөлемә даласыннан тәүге чәчәк исләрен кышлакка ташый. Бакчадагы өрек, гранат, алмагач чәчәкләренең исеннән башлар әйләнә. Күп тә үтмәде, гаиләләре белән Мохитобон, Мәдинә, алар артыннан озак та тормый Рөстәмжоннар белән Шахнозалар, күчтәнәчләрен төяп, кайтып җиттеләр. Өй эче, ишегалды кочаклашу-күрешү, уен-көлке белән тулды. Малае-кызы, килене-кияве – һәммәсе Гайшә әниләрен кочаклап, ике бит алмасыннан үбеп, чын күңелдән яратуларын, хөрмәтләрен белдерделәр. Гайшәнең үзендә алай артык төчеләнү булмаса да, монда тәртибе шулай булгач, ияләнде. Аннан балаларның да чынлап якын иткәннәре сизелеп тора. Шахноза белән Хушназары аеруча якын. Үз янында озак яшәгәнгәдерме, әллә инде самими бала күңелләре белән ялгызлыгын бүлешкәнгәме икән? Гайшә читтән генә балаларын күзәтте. Ничекләр генә калдырып китәрмен икән шушыларны, дип уйлап куйды ул. Бу кадәр дә якын булырлар, бу кадәр дә үз итәрмен дип, башына да китермәгән иде бит.

Ярый, алдан хәсрәтләнмә әле, Гайшә, бер Ходай үзе җаен чыгармый калмас, дип уйлады ул. Аннары олы бер оркестр белән оста дирижёрлык иткән кебек һәркайсын урынына куеп, үз «рольләрен» уйната башлады. Монда берәүгә дә әйтергә түгел, һәрберсе ни эшләргә кирәген үзе белә. Гайшә әниләренең күзенә дә кулына гына карап торалар. Иң соңгы булып, төп йортка Әминжон белән Баһодор килде.

– Барыбыз да җыелдыкмы? Әйдәгез, табынга утырышыйк, балалар, – диде Гайшә, дилбегәне үз кулына алып. Алай дисәң, Талибжон үлгәннән соң дилбегә үзеннән-үзе Гайшә кулына күчте. Берәү дә, миңа бир, димәде.

– Гайшә әни, барыбыз да җыелып беттек шикелле. Әллә тагын киләсе кешең бармы үзеңнең? – диде Әминжон, карашын табындагылардан Гайшәгә күчереп.

– Юк, юк. Бер көтәр кешем дә юк. Бөтен көткәннәрем монда. Сездән башка тагын кемем бар инде минем? Алай дисәң, бар икән шул... Йөрәгем астыннан өзелеп төшкән балам бар. Тик кулым сузып җитәр җирдә түгел шул, – дип моңаеп куйды.

– Кем белгән... – дип, шаяртып, әлеге киеренкелекне йомшартасы иттеләр киленнәр.

– Шулай, фәрештә йоклаганда, шайтан әллә ниләр эшләп куюы да бар, – дип, киленнәренә кушылып көлде Гайшә. Аннары йөзендәге елмаюын әкрен генә бөтен барлыгына таратып:

– Әминжон, ирләр булганда, миңа табынчы булып утыру килешмәс. Атагыз урынына калган абый кеше буларак, мәҗлесне син алып бар инде. Бер күрешү – бер гомер, ди безнең татар. Сине өйрәтәсе юк, үзең җаен беләсең, – дип, кулъяулыгы белән ирен кырыйларын сөртеп куйды Гайшә.

Әминжон әкрен генә торып басты да һәммәсенә күз йөртеп чыкты.

– Туганнар, – дип башлады ул сүзен. Җыелуның сәбәбе сезгә сер булган кебек, миңа да билгесез. Шулай да, Гайшә әни, мине олылап, табынчы вазифасын йөкләгән икән, каршы килү әйбәт түгел. – Ата йорты, Аллаһка шөкер, утын сүндермичә, ишек-капкага йозак элмичә безне көтеп яши. Без моның өчен барыбыз да Гайшә әнигә, Хушназар белән Гәүһәргә рәхмәтле. Ана назыннан мәхрүм калган вакытта, Гайшә әни, безне үз канаты астына алды. Вагракларыбызны какмый-сукмый үстерде, балигъ булганнарыбызга кулыннан килгән кадәр булыштылар. Дүрт ел әтине карап тәрбияләде. Әйтергә генә җиңел. Барыбыз да җыелганнан файдаланып, һәммәбез исеменнән, Гайшә әни, сиңа зур рәхмәт. Безгә дөнья яктысын бүләк иткән газиз әниебезне доганнан калдырмадың, безгә дә шул тәртипне сеңдердең. Син безнең йортның бусагасын атлап кергәндә, ак яулыктан, ак күлмәктән кергән идең. Шул аклыгыңны югалтмадың. Таҗик илендә татар хатыны булып гомер иттең. Без генә түгел, кышлактагы бер генә кеше дә сине чәчәкле таҗик күлмәгеннән күз алдына да китерә алмыйдыр. Нигә боларны сөйлимме? Минем аңлавымча, Гайшә әни безне болай гына җыймаган. Нидер әйтәсе, сөйлисе сүзе бар кебек. Ул сөйләгәнче, башта шуны әйтәсем килде. Әллә мин ялгышаммы?

Шулай диде дә Әминжон кара күзләрен тутырып, Гайшәгә карады.

– Рәхмәт яхшы сүзеңә, Әминжон. Дөрес әйтәсең. Чыннан да, җыелуның сәбәбе бар, – дип, утырган урыныннан торып басты. Командиры алдына баскан солдат кебек күкрәк өстендәге изү сәдәпләрен кытыршы бармаклары белән капшап чыкты. Яулыгын рәтләп, күлмәк итәген тарткалап куйды да сүзен дәвам итте.

– Балалар... – Гайшәнең тавышы калтыранып куйды. Һәммәсе ризыкка сузган кулларын кире алдылар да Гайшәгә текәлделәр. – Минем шушы йорт бусагасын атлап кергәнгә шактый вакыт узды. Әлбәттә, миңа җиңел булмады. Сезгә дә шулай булгандыр. Аллаһка шөкер, без ул сынауларны кеше көлдермичә уза алдык. Атагыз мәрхүм белән дә аңлашып яшәдек. Менә нинди өйләр җиткердек. Дөнья булгач төрлесе булгандыр, тик шулай да сез дип яшәдем. Мин үз бурычымны үтәдем, атагызны тәрбияләдем, авыргач карап, үлгәч, җиренә җиткереп, соңгы юлга озаттым. Сез дә ач-ялангач йөрмәдегез, үз балаларым кебек күрдем, назымны, җылымны кызганмадым. Үзегезгә дә рәхмәт, авыр сүз әйтеп, күңелемне рәнҗетмәдегез. Күршедәге йөз яшьлек Сәйметдин әкә: «Ватаны булмаган кеше – бакчасы юк сандугач», – дияргә ярата. Шөкер, һәркайсыгыз башлы-күзле булдыгыз. Үз оягыз – үз Ватаныгыз, илегез бар, – диде дә Гайшә туктап калды. Аннан, тыныч тавыш белән уңайсызланып кына:

– Мин, балалар, сезнең рөхсәт белән, үз илемә кайтыйм инде... – диде.

Гайшә карашын һәр балага туктатып, һәркайсының күзенә туп-туры

карады. «Кайтыйм инде, җибәрегез», дип карый иде ул күзләр. Табында гына түгел, бөтен бер бакчада, ишегалдында тәннәрне чымырдата торган тынлык урнашты.

Тынлыкны Шахноза бозды. Ул әллә нинди ят тавыш белән:

– Ник? Әни, ник китәсең? – дип кычкырып җибәрде. Үз тавышыннан үзе куркып китте. Калганнар берсе дә дәшмәделәр.

* * *

Артык озак утырмыйча ашап-эчкәннән соң, китәселәре рәхмәт әйтеп таралыша башладылар. Вакыт соң иде инде. Өй тынгач, юыныпчистарынып, Гайшә Талибжон белән икесенә уртак булган йокы бүлмәсенә керде. Намазлыкка төргән Коръәнен алып алдына салды да ипләп кенә сүтеп җибәрде. Тик, намазлык та, китап та башка иде шул. Гайшәнең бөтен җан-бәгыре кереп урнашкан, газизе – Нәсимәсе «бүләк» дип йөртә торган Коръән, әнисенең кул җылысын саклаган намазлык түгел. Нихәл итәсең инде, Ходай кушып табылмасмы әле? Могҗиза бар бит ул дөньяда. Шулай уйлап, Гайшә Коръәнне күкрәгенә кысты.

– Үзең ярдәмеңнән ташлама, бер Ходаем, – дип пышылдады Гайшә. Ул бөтен барлыгын, бөтен булмышын онытып, хәтта үзенең тәнен тоймас дәрәҗәгә җитеп, могҗиза булуын теләде. Шулай оеп, күпме утыргандыр, янына Шахноза кергәнен дә сизми калды. Ул Гайшә янына тезләнеп утырды да башын әнисенең иңнәренә салды. Гайшә бер мәлгә күзләрен ачарга куркып торды. Әйтерсең лә, Нәсимәсе килеп сыенды. Шул кадәр дә рәхәт булып китте Гайшәгә. Уяу килеш төш күрә, диярсең. Күзләрен ачса, җил тузгыткан тузганак мамыгыдай, барысы да очып юкка чыгар кебек тоелды.

– Әни, арыгансың инде, ят. Ял ит, – дип, Шахноза әнисенең чал кунган, инде юкарып бара торган сыңар чәч толымын кулына алды.

– И-и-и балакаем, – диде Гайшә, күзләрен ачарга куркып. Әллә Шахнозага әйтте, әллә күңеленнән бер генә минутка да китеп тормаган Нәсимәсенә эндәште.

* * *

Якшәмбе гадәттәгечә үтте. Төшкә кадәр җыясын җыеп, юасын юып, вак-төяк эшләр караштырдылар да китәргә җыендылар.

Гәүһәр төяп, күчтәнәчен бирде, Гайшә изге теләкләрен теләп, машинага озатырга чыктылар. Инде машина кузгалып китәм дигәндә, Шахноза ашыгып, машинадан чыкты да Гайшәне кочаклап алды. Иңнәреннән тотып, ике битеннән үпте һәм колагына:

– Риза бул, әни, яме. Кал, китмә, – дип пышылдады. Сөрмә тарткан кара күзләреннән эз ясап, яшьләре тәгәрәде.

Тапкан ана түгел – баккан ана, дип, юкка әйтми халык. Үз анасы булмаса да, Шахноза кечкенәдән, Гайшә кебек, аклыдан киенергә яратты. Аның шулай киенүе әтисенә дә ошый иде. Тик кечкенә чагында күрше кызлары гына: «Ник андый күлмәк киясең, син татар түгел», – дип кыерсыттылар. Бүген дә ул өстенә озын җиңелчә аксыл күлмәк кигән, башына, килешле итеп, таң шәүләседәй алсу яулык япкан иде.

– Ярар, елама. Буявың агып, битеңне пычрата. Алдан хәсрәтләнеп куйма әле, – дип, Гайшә кытыршы бармак очлары белән Шахнозаның битен сөртеп алды. – Алдыгызны-артыгызны карап йөрегез. Исәнлектә күрешергә язсын.

* * *

Көн кичкә авышкан иде. Гайшә Хушназарларга барып кайтырга булды. Килене ачык чырай белән каршылады. Гайшә эчкә узды да урта бер җирдә туктап калды. Бөтен нәрсә таныш иде монда.

Гәүһәр Гайшәне мехмонхонәгә дәште. Көрпәчләрне җайлап куйды да, Гайшәне кулыннан тотып, шунда утыртты. Ул ара ишектә күршедә генә яшәүче Торсоной белән Дилором күренде.

– Менә, безгә килми, ә кече киленгә килә ул Гайшә әни, – дип гөлдер-гөлдер елмаеп, Дилором Гайшәне килеп кочаклады. Аннан, үз урынын белеп, Гайшә янына утырды.

– Ассалому алеймум, Гайшә әни, – диде Торсоной. – Корхо чихел?

– Аллаһның биргәненә шөкер. Үзегез ничек? Балалар ни хәлдә? Әйдә, утыр, – дип, үз яныннан урын күрсәтте.

Бизәкле келәмнәр, сүзаниләр белән бизәлгән мехмонхонәдәге ялтыр-йолтыр күлмәкләр кигән киленнәре арасында, какча гәүдәсен төз тотып, ак җирлеккә ал лаләләр төшкән күлмәктән Гайшә утыра иде. Чал башына урап килгән олы ак яулыгын Кичүчатында бары тик әнисе Фатыйма гына бәйләгән кебек итеп чөеп бәйләде дә догага кул күтәрде.

– Гайшә әни, менә килендәшләр сөйләшәбез дә, синең сабырлыкка, көчеңә исебез китә. Иләңне калдырып, сигез бала өстенә курыкмыйча, безнең каенатайга килдең, урын өстендә ятканда, ничә ел тәрбияләдең. Бер тапкыр зарланмадың, сукранмадың. Серен безгә дә әйт әле, – диде дә Гайшәнең алдына капланып елап җибәрде. Гел шаярып-көлеп йөргән Дилоромның кинәт кенә болай җебеп төшүе барчасын да аптыраште калдырды.

– Сереме?.. Сер микән инде ул?

Шулай диде дә Гайшә киленнәренә үзенең бүләк Коръәне турында сөйләп бирде.

– Инша Аллаһ, табылыр. Болай гына берни дә булмый. Шуңа да ул миңа сынау җибәрә. Сынавына күрә ярдәмен бирә. Мин сорыйм – ул бирә. Ничек түзәсең, дисең, балам. Ничек түзмисең, ди. Илемнән аерылган хакка яхшы ир, тәүфикълы балалар насыйп итте. Алар өстенә менә сезне – иманлы киленнәрне бирде бер Аллаһ. Көчне дә, өметне дә, сабырлыкны да ул бирә.

– Ник сиңа гына бирә дә, башкаларга бирми соң? – диде Ясмин, авыр сулап.

– Әстәгъфируллаһ, тәүбә диген, балам. Бирә. Бирүче дә, алучы да ул. Менә, миннән күз яшен алды. Ә мин өметемне өзмим. Күземне йомганчы, ул Коръәннең табыласына ышанам. Аллаһының рәхмәте белән, берәрегез әле миңа шуннан Ясин да чыгар, – дип, Гайшә моңсу гына елмаеп куйды.

– Гайшә әни, кайда ничек югалттың син аны? Шуны сөйлә әле.

Гайшә билгесезлеккә карап торгач:

– Әминжон, белсәм икән кайда югалтканны... Авылдан киткәндә,

чемоданымны тутыргач, өскә генә куйдым. Килеп җитеп, Әкълимә апаларда чемоданымны ачсам, Коръәнем юк иде.

– Гайшә әни, берәр төрле аерым билгесе юк идеме? – диде Әминжон. Һәм үзләре йоклый торган бүлмәдән бер китап алып керде. – Менә шундыйрак.

– Бар, бар, – дип җанланып китте Гайшә. Ясин сүрәсе битендә, өченче аять тәмамлангач, кызыл каләм белән сызып куелган. Кырыйга латин хәрефләре белән «Әти вафат. Җеназаны Шәкерт абзый укыды», дип язган. Әнием, үзем язып куйдым, дигән иде. Шул битнең почмагын такта чәйдән бушаган ука белән почмаклап куйган. Шуңардан күрмәкче, каенана әни үлгәч, үзем дә ясин тәмамланган битнең читенә «Гадилә әнигә үзем ясин чыктым. Җеназаны Гарәф абзый укыды», дип язып куйган идем. Аның ише килде-китте язулар шактый анда. Бабай артка үзе бер кәгазь ябыштырып, бөтен балаларының туган вакытын язып барган. Анысы гарәпчә, карага манып язган иде. Нәсимәм тугач, мин дә язып куйган идем.

Гайшә туктап калды һәм эчке бер ышаныч белән:

– Әминжон, атагызның авызыннан чыккан соңгы сүзе «табылыр» булды. Табылыр Аллаһ теләсә, – диде.

Малайларның, кызларның шәһәрдә яшәүчеләренә хәбәр салырга кирәк дигән фикердә, Әминжон өйләренә кайтып китте.

Гайшә төне буе күңеленнән шул көнне кичерде.

* * *

Чемоданга бөтен нәрсәне тутырып бетергәннән соң гына әнисенең намазлыгына төргән Коръәнне иң өскә куеп бикләп, карават астына этеп куйган иде Гайшә. Икенче көнне Мәгъшук Мәхтүмәсенә юл сәдакасы бирергә дип китте. Ялгызы калудан файдаланып, Закирә дөбердәтеп, чемоданны тартып чыгарды. Аннан койрыгы пешкән мәче кебек бер тәрәздән икенчесенә йөгереп, кеше юклыгына ышангач, чемоданны ачты. И-и-и-и, мин арурак нәрсәләр тутырган дип торам. Ходаем, Фатыймадан калган иске-москыдан башка бер адәм рәтле әйбере дә юк икән мескеннең, дип, үзалдына сөйләнде. Аннан Коръәнне төргән намазлыкны сүтеп җибәрде. «Менә монысы ярый торган», – дип куйды. Намазлыгы белән Коръәнне алды да шартлатып, чемоданны япты һәм аягы белән генә урынына этеп куйды. Ул тиз генә сандыгына, хәстәрләгән үлемтекләре астына ук тыкты. Йозак чыртлап бикләнде. Кулы да калтырамады Закирәнең.

Намазлыкка төргән Коръән сандык төбендә ята бирде. Хөсәен карт үлгәнче, бер тапкыр да сандыктан чыгармады Закирә. Нәсимәдән дә шикләнде. Балалы йортта бур тормас, диләр бит. Кеше-кара алдында ычкындырыр дип курыкты. Аннан соң, бер ялгызы торып калгач та, ике генә тапкыр кулына алды.

Бөтен кеше өчен җан тынычлыгы бирә торган Коръән, Закирәнең тынычлыгын алды. Картая барган саен авыл өстендә карак дигән исеме чыгар, шул исемне күтәреп үләрмен дип курыкты. Кая куярга, ничек котылырга белми йөргәндә, таныш түгел ике хатын-кыз ияртеп, Сәхәп Әнвәренең китапханәдә эшләүче кызы Гөлфия килеп керде.

– Закирә әби, менә Әлмәттән килгәннәр. Искечә язылган китаплар, дәфтәрләр җыеп йөриләр, – диде Гөлфия.

– Әйдәгез утырыгыз. Иске китаплар дисеңме? Алай-й-й-й. М-м-м-м, – дип озак кына сузып, кергән кызларның һәркайсын баштанаяк күзәтеп чыкты.

– Әби, сез курыкмагыз. Без алган һәр китапны журналга язып, кемнән алганны теркәп барабыз. Бер кәгазь дә югалмый бездә, – диде кызларның берсе, сумкасыннан калын гына дәфтәр чыгарып.

– Кемнән алганын язмасаң да ярый инде, кызым. Хәзер, бабагыздан калган төргәкләрне карап карыйм. Син, Гөлфия, бар, Фәхриҗиһанга кереп чык. Аңарда булмый калмас. Каенатасы бик гыйлем иде, – дигән булып, Гөлфияне чыгарап җибәрәсе килде. Исәбе – Коръәнне күрсәтмичә генә биреп котылырга иде.

Гөлфия чыгып китүгә, Закирә, шалтор-шолтыр китереп, сандыгын ачты да, үлемтекләре астына ук тыгып куйган, суккан намазлыкка төргән Коръәнне тартып чыгарды.

– Менә, алыгыз. Кемнән икәнен язып тормасагыз да була. Башка нәрсәм юк, – дип, икенче кызга тоттырды. Кыз намазлыкны сүтә башлаган иде, Закирә, корт чаккандай, урыныннан сикереп торды да:

– Ал, ал. Аның анысы да хан заманыннан калган намазлык. Кирәкмәсә ташларсыз, – диде. Яшь кыз сүтә башлаган намазлыгын кире урап, сумкасына салды.

– Әби, исем-фамилиягезне, туган елыгызны әйтегез әле. Язып куям, – диде дәфтәрен ачып.

– Гәҗиткә-фәләнгә яза күрмәгез инде балакаем. Мин алай зур кеше түгел. Ишниязова Закирә. Бабагызга килгәнче Хәйретдинова идем. 1907 елгы. Борчак чәчәк атканда таптым, дия иде әни. Син кызым боларын яза күрмә инде, – дип елмайгандай итеп, яулык очы белән авыз тирәсен сөрткәләп алды.

Кызлар чыгып китте. Закирә белгәннәрен укып, битен сыпырды да, алар артыннан ук ишеген бикләп, Мөнәвәрәгә китте.

* * *

Гайшәгә Коръән хакында башкача сүз катучы булмады. Намаз саен Аллаһтан саулык сорап дога кылды, Коръәннең табыласына өметен өзмәде. Хәсрәт-борчулар гына Гайшәне Гайшә булудан туктатмады. Хәрәкәттә – бәрәкәт дип, һаман эштә булды. Өстеннән ак күлмәге, башыннан ак яулыгы төшмәде. Су ташып, кер юмаса да, пылау пешерә, татарча токмач та ясый. Коротны килене әзерләсә, тандырда лавашны Гайшә әле үзе хәстәрли. Чөнки яңа гына тандырдан алган лаваштан авыл исе килә. Ата йорты, килен булып төшкән Минвәлиләр йорты искә төшә. Юк, дөрес түгел. Искә бит онытылган әйбер төшә. Аларның бит онытылганнары юк. Бары тик, иман яңарткан кебек яңара гына. Онытыла торган булса, бүләк Коръән онытылыр иде.

Әлеге хәбәрне ишетүгә, беренче булып, сугышта яраланган аягын сөйрәп, Баһодор да кереп җитте. Аның артыннан ук Хушназар йөгереп керде. Ирләр, киңәш-табыш корып, шактый озак утырдылар.

Кара-каршы утырып сөйләшүдән соң Шахноза Коръәнне кайдан, ничек эзли башларга кирәклеген Рәсүл белән киңәште. Үзәк китапханә дә, шәһәр архивы да калмады. Тик тотынырга җепнең очы күренми иде.

Рухшон исә, Әлмәттәге таҗик диаспорасының җитәкчесе Мәрхәбәнең телефон номерын кулга төшерде. Төшке ашка киткәнче телефонында Мәрхәбәнең номерын җыйды.

– Ассалому алейкум. Миңа Мәрхәбә әкә кирәк иде, – диде Рухшон, кабинетының ачык ишеген ябып.

– Вагалейкум салом. Мин тыңлыйм. Ә кем соң әле бу? – дип дәште каршы яктагы тавыш.

Рухшон үзенең кем булуын, ник шалтыратуын кыскача гына аңлатып бирде.

– Миңа һич югы тиешле кешеләрнең адресын яки телефоннарын гына табарга булыш. Борадор, бәясеннән тормабыз. Салом алейкум, – диде ул.

Телефоннан туганнарының номерларын, үзенең электрон адресын җибәрде. Рухшон, һәркөн иртән компьютер артына утыруга, почтасын карады. Тик бер хәбәр дә юк иде. Эш көне тәмамланып килгәндә планёркага кереп утыруга, түш кесәсенә тыккан телефоны тавышсыз гына дырылдарга тотынды. «Ал инде, ал инде», дигән кебек телефон озак бәргәләнде. Алай ярамаганын белсә дә, Рухшон рөхсәт сорап, коридорга чыкты. Тик төймәгә басарга өлгермәде. Бәргәләнүдән туктаган телефонда «Мәрхәбә» дигән исем чыккан иде.

– Ассалому алейкум, Мәрхәбә. Гафу ит, начальник янында идек, вакытында ала алмадым. Нинди хәбәр белән сөендерәсең, кардәш? – диде. Рухшонның чалара башлаган мыеклары калтыранып куйды.

– Вагалейкум салом, борадор. Менә шушы номер белән шалтыратып сөйләшеп кара. Бу ханым музей мөдире – Венера Кыяметдиновна.

– Рәхмәт, борадор! Сәламәт бул, – диде ул. – Югалма, Ватанга кайткач, кунакка кил. Салом алейкум.

Рухшон яңадан җыелышка кереп тормады, Рәсүлгә шалтыратырга булды. Исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашканнан соң:

– Рәсүл, миңа Әлмәттәге музей мөдиренең номерын бирделәр. Ул хатын-кыз. Шахнозага уңайлырак булыр дим, ул ханым белән сөйләшергә. Җепнең очы табылмасмы икән?

Шахноза шул көнне үк Рухшон биргән номерга шалтыратты.

– Ало, слушаю Вас, – диде мөлаем хатын-кыз тавышы.

– Ассалому алейкум. Хәерле кич. Миңа Венера Кыяметдиновна кирәк иде, – дип, ул каушаудан кипкән иреннәрен ялап алды.

Шахноза үзенең кем булуын, кайдан, ни сәбәпле шалтыратуын сөйләп бирде.

– Безнең музейның һәм филиалларның саклау фондларында Коръәннәр бик күп. Телефоннан сөйләп кенә эзләү мөмкин түгел. Шахноза ханым, сез эзли торган Коръәннең, әгәр дә булса, аерым үзенчәлекләрен әйтеп, тәфсилләп, безнең электрон почтага язсагыз иде. Аерым детальләр никадәр күбрәк булса, сез эзли торганын ачыклау күпкә җиңелрәк һәм тизрәк була. Хатыгызны көтеп калабыз, – дип, мөдир ханым трубканы куйды.

Шахноза Гайшә әнисенең Коръәне турында аерым детальләрне белми иде. Рәсүл белән киңәшкәннән соң, әнисе янына кайтырга булдылар.

Гәүһәр белән Хушназар ачык йөз белән, бик шатланып каршы алдылар туганнарын. Кичкә ул Гайшә әнисе янына китте. Аяк йөзенә үк төшеп торган

аксыл күлмәк, Гайшә кебек итеп чөеп бәйләгән күлмәгенә төстәш яулык. Күлмәгенең фасоны таҗикныкы булса да, төсе татарныкы, Гайшәнеке иде.

– Бүген иртәннән үк борын очым кычыткан иде. Сезнең күчтәнәчләрдән авыз итәргә булган икән. Бездә шулай диләр иде, – дип, Шахнозаны кочаклап алды Гайшә. – Әйдә, уз, ничек кайтасы иттең соң әле? Ул-бу юктыр бит?

Алар хатыннар ягына уздылар. Әнисенең, «ул-бу юктыр бит», дигәнен Шахноза үзенчә аңлады.

– Үзең бит, өметсез – шайтан гына, дисең. Өметләнәм, әни, бик нык өметләнәм. Ничек соң син, моңа кадәр, әйтми саклап йөрдең? – диде. Һәм, ничек саклап йөргәнен белергә теләп, күзләренә карады. Ул зур, кап-кара күзләргә татар хатынына карата сүз белән әйтеп-аңлата алмый торган ярату тулган иде. Илле ел элек, «Ое ман модарам» дип, итәктән тартып, аңа күтәрелеп караган күзләр иде бу. Зур итеп ачылган ул кара күзләрдә Гайшәнең ак яулыгы чагыла иде.

– Әле син дә шуның артыннан йөрисеңмени? Ай пешмәгән, тишек авыз. Бөтенегезгә мәшәкать ясадым бит, ә?! – диде ул, уңайсызланып.

– Гайшә әни, син алай димә. Аллаһы Тәгалә, сез сәбәбен кылыгыз, мин ярдәмен бирермен дигән, ди. Аллаһ ярдәменнән ташламас.

Ул шулай сөйләнде, үзе һаман дастарханга ризык ташыды. Телефонындагы диктофонын кабызып куйды да сөйләшә-сораша чәй эчтеләр. Гайшә үзе сөйләде, үзе Коръәннең һәр битен күңеле аша уздырды. Шахноза тавышсыз гына елады. Гайшә туктады. Аннан соң аларга карап:

Агыйдел күпере, чуен мәллә, чылтырый,
Каш астында ике күзе энҗе кебек елтырый, –

дип җырлап җибәрде.

– Әни, нинди кеше соң син? Ничек син боларны шул гомер сөйләмичә саклап килдең? Ничек түздең? – диде Шахноза.

– Көне җиткәнен көттем. Аллаһтан вакыт җитмәгән булгандыр. И-и-и бала, сорамаганда сөйләгәнне кем ярата?! Түзми кая китәсең? Урамда кычкырып йөри алмыйсың, Аллаһ сакласын. Сабыр төбе – сары алтын, ди, минем татарым. Үзе югалса да, көче югалмады. Гомер буе менә шунда булды ул, – дип, Гайшә йөрәк турысына төртеп күрсәтте. – Сабырлыкны да, исәнлекне дә, яратуны да шул бирде. Аннан мехмонхонәне балкытып, бер елмайды да: – Менә, капчыгымны чыгарып селкедем. Эш бетте, көлтә җыясы гына калды, дигәндәй, Аллаһка тапшырыйк. Әйдәгез, дога кылыйк, – диде.

Шәһәргә кайтуга, Шахноза беренче эш итеп, әнисе сөйләгәннәрнең бер сүзен дә калдырмыйча компьютерда басты да, сүз башы язып, Венера ханым биргән адреска җибәрде. Озак та тормый, «Язмагызны алдык. Кулыбыздан килгән кадәр ярдәм итәргә тырышырбыз. Ихтирам белән, Венера Кыяметдиновна», дигән җавап килде.

Айга якын вакыт узды. Хәбәр булмады. Эш көне тәмамланып килә иде. Сискәндереп, телефон шалтырады.

– Исәнмесез, – диде, телефонның теге ягыннан, мөлаем хатын-кыз тавышы. Бу Венера ханым иде. – Без сезнең почтага фотолар җибәрдек.

Сезгә кирәклеләре юкмы икән? Әгәр дә булса, хәбәр итәрсез. Шулай диде дә, Венера ханым саубуллашып, телефонын куйды.

Шахноза рәхмәт әйтергә дә онытты бугай. Ул өстенә кигән җиңел пальтосын урындык аркасына гына салып ташлады да сүндергән компьютерын яңадан кабызды. Музей мөдире җибәргән җиде фоторәсемдә аерым-аерым төшерелгән Коръән битләре иде. Хәдичә телефоныннан әнисе сөйләгән язманы кабызды. Венера ханым җибәргән икенче рәсемдә Ясиннан соң Саффат сүрәсе алдыннан кызыл каләм белән сызылган да, китап битенең кырына «Гадилә әнигә үзем ясин чыктым. Җеназаны Гарәф абзый укыды», дип, рус хәрефләре белән язылган иде. Аны Коръәннең табылганы гаҗәпләндермәде, ә әнисенең аны табасына ышануы гаҗәпләндерде. Шулай да, иренә шалтыратканчы, әнисенең язмасын тыңлап, калган рәсемнәрне дә карап чыкты.

– Рәсүл, әнинең Коръәне табылды. Хәзер кайтам мин, – диде ул, тыныч кына. Шахноза фоторосемнәрне икешәр нөсхәдә чыгарды да саклык белән сумкасына салды.

Ул кайтып кергәндә, Рәсүл дә, балалар да өйдә иде. Бу хәлләрнең чын булуы Шахноза аңына хәзер генә барып житте. Ул, «табылды», диде дә өстен дә салып тормыйча урынга ауды һәм үксеп-үксеп еларга тотынды. Әллә шатлыктан, әллә табылгач, әнисе китәр дип куркудан елады. Үзе дә белмәде. Тынычланып, башкалар янына чыкканчы, бер кеше дә дәшмәде.

Рәсүл Рухшонга шалтыратып, хәлләрен белешкәч:

– Котлыйм, табылган бит Коръән. Синең тырышлык инде бу, Рухшон әкә. Татарстандагы мөдир ханым Коръән битләренең фотоларын җибәргән, – диде.

Таҗик даласы чигелгән келәм кебек чәчәккә күмелгән апрель аеның кыл уртасы иде. Гайшә йорты халык белән тулды. Кайсы сакаллы, кайсы сакалсыз ирләр, чәчәкле-чуклы бәйрәм күлмәкләре кигән хатын-кызлар өйгә генә сыймыйча, ишегалдын, урамны тутырдылар. Ирләр дастарханны бакчага – карт өрек астына, хатын-кызлар мехмонхонәгә әзерләделәр. Малайларның, кияүләрнең яшьрәкләре казан тирәсендә кайнашты. Күзләрне камаштырырлык төсләр диңгезендә ап-ак яулыгын яшь киленнәрдәй чөеп бәйләгән, ак күлмәген таулар арасыннан искән язгы җилдә җилфердәтеп, зур ыруның төп хуҗасы – Гайшә йөри. Таза-таза таҗик киленнәре арасында аның шәмдәй төз гәүдәсе әллә каян аерылып тора. Гайшәнең яшьлеге булып, алма бизәкле алсу күлмәктән Шахноза күренде. Ак яулыгын да шулай, нәкъ әнисе кебек итеп өчпочмаклаган да, артка чөеп бәйләгән. Йөз-кыяфәте, буй-сыны Шөкронаныкы булса, җаны, күңеле, бөтен булмышы белән Гайшә иде ул.

– Гайшә әни, син әйдә, кер инде, утыр. Син утырмагач берәү дә утырмый, – диде Ләйлә.

– Хәзер, керәм, керәм, балам. Утыра торыгыз, – дип, бакча ягына китте.

Шулай диде дә, яратып, аркасыннан кагып алды. Гайшәнең куллары карт йөзем агачының кайрыларыдай яргаланып, буй-буй эзләр белән бизәкләнгән. Гайшәнең йөзендә ирләр ныклыгы, тынычлык хөкем сөрә иде.

Шахноза кызларга-киленнәргә Коръәннең ничек табылуын сөйләде.

– Барысы да Аллаһының рәхмәте, сезнең тырышлык белән. Сабыр

иткән морадына җиткән. Барыгызга да Аллаһ күркәм сабырлык бирсен. Ирләрегезне санлап, бәхеттә яшәгез. Сез мине зурлаган кебек, кызларыгыз, киленнәрегез сезне зурласын. Ә хәзер, әйдәгез, бәйрәм булгач, бәйрәм булсын. Сыйланып, кунак булыгыз.

Шуны гына көткән кебек Дилором җырлап җибәрде. Яшьрәкләр торып биергә тотындылар.

Гөр килеп сөйләшкән ирләр, бакчада Гайшәнең ак шәүләсе күренүгә шым булдылар. Дистәдән артык таҗик ирләренең, үзен күргәч, тып-тын калуларына Гайшә бераз уңайсызланып та куйды. Аны түргә әзерләп куелган урынга утырттылар. Дога кылганнан соң, Гайшә торып басты.

– Балалар, – диде ул, – сезгә әйтәсе сүзләрем бар.

Шулай диюгә, дастархан артында утырган ундүрт ир-атның берсе генә – Баһодор гына басмады. Баса алмады. Яралары мөмкинлек бирми иде. Какча гәүдәле ап-ак татар хатыны янәшәсендә кыя ташларыдай тезелгән, кояшта каралган таза-таза таҗик ирләре кечерәеп калгандай булдылар.

– Бүген сез миңа зур бәйрәм ясадыгыз. Сез ирләргә сөйләсәм дә, беләм, хатыннарыгыз да колакларын торгызып тыңлап тора. Шуңа да алар хатыннар. Мин сезнең белән бик бәхетле булдым. Соңгы сулышыма кадәр сезне табып үстергән әти-әниләрегезне догамнан калдырмам. Инде үтенечем: миңа шул Коръәнне, кулыма алып күкрәгемә кысарга ярдәм итегез. Шахнозага әйтермен, Нәсимә белән сөйләшер. Калганын туган якта ул хәл итәр. Аңа әйтмәсәгез, аны санламау булыр. Коръәнне кулга тоту мөмкинлеге тәгаен ачыклангач, мине Рәсәйгә Әминжон алып кайтып килер. Сүзем шул иде. Дәвам итегез, – дип, хатын-кызлар янына китте.

* * *

Шахноза шалтыратканда, Нәсимә дәрестә иде. Тәнәфес булуга ул телефонын алып, урамга йөгерде. Мәктәп ишегалдына җәйгән асфальттан җылы күтәрелә. Бакчадагы каеннарда кара каргалар шау-гөр килеп, туй ясыйлар. Нәсимә телефонындагы исемлектән «Әни» дигәнен табып, чакыру төймәсенә басты. Телефонда әнисенең тавышын ишеткәч, Нәсимә елап җибәрде.

– Әни, шул гомер син ничек безнең «бүләк»сез яши алдың? Ник моңа тикле әйтмәдең? – диде ул, яшьләренә буылып.

– Ни хәлләрең бар, балам? Кияү, балалар исән-саулармы? Елама, менә табылган бит. Бабаңны да, сине дә борчыйсым килмәде. Син инде, кызым, миңа рәнҗемә. Булдыра алсаң, мондагыларга ярдәм ит, ярыймы? Табыласына югалган көннән алып ышандым. Аллаһ ташламасын гына, – диде әнисе.

Нәсимә килгәндә, Әлмәтнең туган якны өйрәнү музее директоры Венера ханым эш бүлмәсендә иде. Бераз сөйләшкәч, музей хезмәткәре Нәсимә алдына саклык белән генә Коръәнне китереп куйды. Нәсимәнең маңгаена тир бәреп чыкты. Тик үзен бик тиз кулга алды. Гайшә кызы бит ул. Бисмилласын әйтеп, Коръәнне кулына алды, күкрәк турысына китерде. Күзләрен йомды да иелеп иснәп карады. Башларны әйләндерә торган татлы балачак исе, иске буяу, кәгазь исе. Әнисе исе. Әтисе исе. Нәсимә Коръәнне

ачмыйча да таныды. Әйе, бу Нәсимәнең мендәре астында, аларны саклап, яклап торган Коръән иде. Ул тиз генә Коръәннең соңгы битен ачты. Саргаеп беткән авыш сызыклы дәфтәр битенә гарәп хәрефле язулардан соң, иң соңгы итеп Нәсимәнең туган көне язылган иде.

– Шулмы, сез эзләгән Коръән? – диде директор, тынлыкны бозып.

– Әйе, – дип, китапны япты да күкрәгенә кысты. Йөрәге күкрәген ертып чыгардай булып тибәргә тотынды.

* * *

Кирәкле документларны эшләргә Рухшон булышса да, вакыт сузылды. Җәй уртасы җитте. Гайшә юлга чыгар алдыннан барысы белән саубуллашты.

– Аллаһ язмаган эш булмас, исән булсам кайтырмын, балалар. Шулай да бәхилләшеп китим. Борынгылар, өч көнгә киткәндә дә, бәхилләшеп китәргә кушканнар, – диде Гайшә балаларына. Юлга үзе теләгәнчә Әминжон белән кузгалды.

Казан вокзалында аларны Нәсимәнең улы Булат каршы алды. Җыйнак кына кара сакал җибәргән Булат, кай ягы беләндер, Талибжонга охшап китте. Сөйләшеп кайта торгач, дүрт сәгатьлек юл сизелмәде дә.

Әбисенең, машина тәрәзәсеннән чыгардай булып, тауларга карап барганын күзгедән күргәч, Булат машинасының тизлеген әкренәйтте. «Татар радиосы»нда салмак кына җыр агыла иде.

Татлы инеш, гел элекке килеш,
Элеккечә түгел без генә...

– Әби, авылга кайдан керик? Мишәр очыннанмы, әллә зират буеннан төшикме? – диде Булат, тагын да әкренәя төшеп.

– Мишәр очыннан керик, улым. Монда әллә төшәм, әллә юк әле. Ә зиратка, Аллаһы теләсә, барыбер бармыйча булмас. Син әкрен генә бар, яме, – диде. Булат төймәгә басып кына, машинасының тәрәзәсен төшерде.

Улы, кайтырга чыгабыз дип, телефоннан хәбәр итүгә, Нәсимәнең бөтен эчләре калтырый башлады. Моңа кадәр әнисе кайтмый тормады югыйсә. Машина капка төбенә килеп туктаганда, мунча томаланган, шулпа кайнаган, бәлеш мичкә тыгылган иде.

Булат, тиз генә машина ишеген ачып, әбисенә төшәргә булышты. Гайшә эчен-тышын бер учка җыйды да өс-башын төзәтте. Нәсимә әнисен кочып алды.

– Балам минем, – диде Гайшә. – Балакаем. Ходай үземә гомер биргәч, миңа тагын күрешергә насыйп булды.

– Әни, Әминжон абый, әйдәгез, узыгыз. Улым, дәш абыеңнарны, – дип, Нәсимә Булатка төртеп алды.

Әминжон, багажниктан зур-зур чемоданнарны, сумкаларны алып, Гайшә артыннан атлады.

Кереп, йортка дога кылуга, Гайшә:

– Кызым, инде дә хак булдымы үзебезнең бүләкнең табылуы? – диде.

– Хак, әни, хак, менә, – дип, Нәсимә түрдәге китап киштәсенә үрелде.

– Ашыкма, балам. Шул гомер биргән сабырлыкны, Аллаһ бүген генә

бирми калмас. Тынычланыйм әле аз гына. Тәһарәтсез тотыну ярамас, Коръән бит ул, – диде Гайшә.

Чәйләр эчкәннән соң, Булат абыйларын авылны күрсәтергә алып чыгып китте. Нәсимә исә, иртән генә Шарлыктан җыеп төшкән исле үлән суында каен себеркесен пешерде дә, әнисе белән мунчага җыендылар.

– Кызым, Нәсимә, син боларның барысын да ипләп кенә салдыр инде. Юынганда җайсыз булыр, – дип, кып-кызыл гранат төшедәй ташлы йөзеген, Талибжон бүләк иткән алтын беләзеген салып, Нәсимәгә бирде. – Болары Әдилә бәбекәемә, кызым. Каршы килми генә алып куй. Авыл мунчасы кызу була, алкалар белән муендагы гәрәбәне дә ычкындыр. Уралып, чәбәләнеп бетәрләр. Әйдә, хәзер рәхәтләнеп чабынып, мунча керик әле бер. Чәч юарга катыгың бармы?

– Әем, хәзер бит әллә нинди яхшы шампуньнар бар, – диде Нәсимә, бераз гаҗәпләнеп.

– Кызым, чәч өчен татар катыгыннан да яхшысы юк инде ул. Начар булса, безнең әбиләр юмас иде. Берәр касә ал әле, яме.

Кичкә Нәсимәнең ире Илдус, шәһәрдә балалар хастаханәсендә эшләүче кызы Әдилә эштән кайттылар, туганнар җыелды. Апалары Гаҗилә белән Гамиләнең балалары да килде. Инде яше сиксәннең өстендә булса да, Минвәлинең дә кечкенә апасын Әлмәттән малае алып килгән иде. Күршеләр җыелган. Әллә кайда, таулар илендәге Талибжон йортында башланып киткән бәйрәм Кичүчат авылында дәвам итә иде. Ишекләр каерып ачып куелган. Өйдәге шау-гөр килеп сөйләшкән-көлешкәннәр, су буена иңгән томан кебек саркып кына, урамга җәелә. Нәсимә, бер басасы урынга биш басып, килгән һәркемне сыйлый, шатлыгы эченә сыймый.

– Балам, менә бу чемоданны ач әле, – дип елмайды Гайшә. Таҗик кояшы астында янган бит алмалары мунчадан соң, алсуланып, агарып киткән кебек тоелдылар. Гайшә чемоданнан алып, өйдәге һәммә кешегә бүләк өләште. Кулына алгач, күз нурлары сеңсен дигәндәй, һәр бүләгенә карап сыпырды да:

– Төсем булсын, – дип, кулларына тоттырды һәм аларның күзләренә карап, берара кулларын җибәрми торды.

– Апа, – диде, чират Минвәлинең апасы Галиягә җиткәч, һәм, урыныннан торып, үзе аның янына килде. – Без синең белән мондагылар белмәгән бик күп нәрсәләрне беләбез. Төрле чаклар булды. Аллаһ үзе кичерсен. Аның рәхмәте чиксез, кодрәте киң. Белмәгән гөнаһларыбыз да җитәрлектер. Аллаһ хозурына йөк төяп бармыйк. Мин синнән риза-бәхил, апа. Менә бу күлмәк җиңел дә, тәнгә дә рәхәт. Киеп, намаз укырсың. Җылы тәнеңдә тузсын.

Гайшә иренең чалымнарын күрәсе килеп, Галиягә текәлде. Тик җанга якын бер генә сызык та тапмады.

– Кит, юләр, бу тузганчы яшәсәң... – дип елмаеп куйды Галия. Аннан бераз дәшми торгач, – Аллаһ сиңа ике дөнья рәхәтен насыйп итсен. Без күрсәтмәгән рәхәтне, Аллаһ сиңа җиде җир читенә илтеп күрсәтте. Аллаһ разый булсын синнән, Гайшә, – диде.

– Амин, – дип, ул урынына барып утырды. – Кияү үзебезнеке, дигәндәй, сезнең белән, балалар, иртәгә иркенләп утырырбыз.

– Әйдәгез, иртәгә Яфрак бәйрәме түгел. Хуҗаларның иртән торасылары бар. Кунаклар да ял итсен, – дип, хәл белергә килүчеләр әкрен генә таралышып беттеләр.

Өйдә өлкәннәрдән ире белән Нәсимә, Әминжон гына калган иде. Булат белән Әдилә шыпырт кына диван почмагына сеңделәр.

– Кызым, китер. Аллаһка тапшырып...

Нәсимә китап киштәсеннән ак җитен намазлыкка төргән китапны алып, әнисенә сузды. Өйдәгеләр тын да алмый әниләренә текәлделәр. Гайшә өчен мизгел эчендә берәү дә калмады. Ул кулындагы намазлыкка карап, тынсыз калды. Битенә якын ук китереп иснәде дә күкрәгенә кысты. Әллә кайдан, җанының үзәгеннән яндырып менгән төер бугазына тыгылды. Ул да булмады, күз алмаларының астын әчеттереп, ике бите буйлап яшьләре тәгәрәде. Гайшәгә сүз дәшәргә берәү дә батырчылык итмәде. Ул саклык белән генә намазлыкны сүтте. Кытыршы куллары белән озак кына китапның тышлыгын сыпырып торды. Бөтен гомере шушында иде бит аның: әнисе дә, Минвәлие дә, Гадилә әнисе дә... Ә яшьләре акты да акты. Ирен читендәге җыерчыгына җыела да тып итеп, Коръәннең тышлыгына тама. Ул үзенең елаганын да белми иде кебек. Гайшә бер ялгышмыйча Коръәннең Ясин сүрәсе язылган битен ачты. Ул, үз куллары белән язган язуларны күргәннән соң гына, китапны япты. Янәдән намазлыкка төрде.

– Коръәннән һәм эштән аерылмагыз, балалар. Шул икесе бөтенесен бирә адәм баласына. Шулар яшәтә.

Гайшә үзе сөйләде, үзенең бертуктаусыз яше акты. Ул яшьләр җыерчыклары буйлап, бөтен битенә таралдылар. Елаган саен җанының гына түгел, тәненең дә җиңеләя баруын тойды. Күзләре яктырып, тагын да нурланып киткән кебек булдылар. Вакыт шактый соң иде. Тик берәү дә арыдым дип, ятарга ашыкмады.

– Гайшә әни, рөхсәт итсәң без дә күз салыйк әле, – диде Әминжон. – Синең гына түгел, ничә еллар буе безгә дә бәхет биреп торган Коръән нинди икән ул?

Гайшә намазлыгыннан алып, Коръәнне Әминжонга сузды.

– Гайшә әни, чиста чакта, әйдә, мин Аллаһка шөкер итеп, шушы Коръәненнән берәр аять укыйм. Хуҗаларга да, юлдан кайтучы безләргә дә шифасы булыр, инша Аллаһ.

Юлда кайтып, чыннан да арылган иде. Нәсимә кунак иргә урынны, салкынчарак булсын дип, верандага җәйде. Үзе әнисе янына ятты.

Йокламадылар да бугай. Төне буе сөйләшеп яттылар. Кай арада гына күз йомып алганнардыр. Гайшә уянганда, Нәсимә урында юк иде. Өйдә дә хәрәкәт сизелмәде. Ул өсләрен алмаштырып, башына яулыгын чөйде дә ишегалдына чыкты. Нәсимә бакчадан кереп килә иде.

– Кызым, мин су буйларын әйләнеп меним әле, үзем генә, – диде Гайшә. – Югалтмагыз.

– Ярар. Син шулай да бик озак йөрмә, яме.

Гайшә, капкадан чыккач, озак кына зират ягына карап торды. Карт агачларын кисеп чистарткач, йөзәр яшьлек наратлар гына утырып калган. Ә менә Чагыл тавы шул килеш. Чүрәгәй дә, Ташлы борын да үзгәрмәгән. Минвәли белән печән чапкан таулар да урыннарында. Су буена төшә торган

тыкрык, койма буендагы кычытканнар, тал төбендәге әрекмән яфраклары, инеш, тау астындагы Ташкое – һәммәсе элеккечә. Гайшәнең колагында кичә юлда ишеткән җыр яңгырады.

Татлы инеш, гел элекке килеш,
Элеккечә түгел без генә...

Ә менә Талип таллары картайганнар. Коры кабык-сөяккә калып, бөтенләй бөкрәйгәннәр. Җир тарта, күрәсең, өчесе тиң аска иелгән. Гайшә кытыршы куллары белән сукмак кырыендагы карт талның ябалдашларын сыпырып куйды. Шулай булса да, ярны тотып торалар. Үзәкләре өзелсә дә, тамырлары нык, күрәсең. Туган җирләрендә хуҗа булып утыралар шул. Ә төпләрендәге әрекмән яфракларына тып та тып әллә бал тама, әллә... Гайшә кул аркасы белән күзләрен сөртеп алды.

Йә, кем әйтер могҗиза юк дип?! Көтте бит, бик көтте Гайшә бу көнне. Киләсенә, буласына ышанып көтте. Өметен өзмәде. Аллаһ ярдәменнән ташламады. Шатлыкларына шөкер итеп, хәсрәтләренә сабыр итүчегә әҗерен бирми калмам, дигән бит. Мең шөкер. Өеп бирде аңа: ир хөрмәтен, балалар рәхмәтен, сәламәтлекне, кабаттан елый алу бәхетен һәм иман нигъмәтен. Соңгысы бик күпләр тоймый, татымый торган бәхет. Анысын бөтен адәм балаларына бирә, тик аны татырга сабырлыклары җитми, күрәсең... Аллаһының бәндәләргә бүләк итеп биргән, нәсел җебен саклаган Коръәне дә бүген янәдән Гайшә кулында. Аның битләрен шатлык яшьләре юды.

Кояш инде шактый күтәрелгән. Озак тордым бугай дип, Гайшә кайту ягына борылды. Тәнендә җиңеллек, җанында тынычлык иде аның.

* * *

Нәсимә китап шкафының иң югары шүрлегеннән ак җитен намазлыкка төргән Коръәнне алды. Озак кына күкрәгенә кысып торганнан соң, итәгенә куеп, намазлыкны ачты. Кайчандыр әнисе такта чәйдән калган ука белән почмаклап куйган Ясин сүрәсе битен саклык белән генә ачты һәм калтыранган кулы белән китапның уң як кырына «28 нче июнь, 2012 ел. Әни үлде. Ясинны, Гайшә әниемә дип, Әминжон чыкты. Җеназаны Мисгать хәзрәт укыды», дип язып куйды. Нәсимәнең бите буйлап күз яшьләре тәгәрәде.

Табигатьтә Талип талларыннан бал тамып торган җәй иде.



Эльмира
Шәрифуллина

# СУГЫШ КЫРЛАРЫННАН МИН КАЙТСАМ?..

## Днепрны кичү

*«Сож, Десна, Днепр елгалары аша күперләр салганда, сапёрлар 8әр, 24әр, 36шар сәгать судан чыкмый эшли...»*

Владимир Поляков

Үкереп тә, ажгырып та туплар ява,
Җире-күге актарылып, өскә ава,
Кара төтен, кара болыт – бармы дәва? –
Төкәндеме барасы юл, сулар һава?

Койган канның чамасы юк, чарасы юк,
Елгаларның, кире якка агасы юк.
Максатның да башкасы юк, сеңгән аңга:
Баш ярылып, күз чыкса да – каршы ярга!!!

Артка юл юк. Ватан-ана алга дәшә.
Ак сөлгесен билгә салып, ил көрәшә:
«Җиңү өчен! Ватан өчен! – фәкать алга,
Днепрны даёшь! – диеп, – бүген таңда!»

...Чыгарырга елга аша техниканы,
Танкларны, пулемётын, сырхау-сауны
Күпер кирәк! Күпер кирәк, булмый салда,
Тынычлану табар йөрәк бәлки валда.

Киң елганы иңләп, күпер салу өчен
Һәрбер солдат урман кисә, мин дә кисәм.
Ут яңгыры... – егылалар урман белән...
Ә мин исән, әле... исән... – урман кисәм...

Субайларны кул көченнән кага-кага,
Үзебез ат, трактор да, арба, чана,

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА (1947) – *шагыйрә; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Яңгыр җиле», «Уйлы еллар», «Сөюемнән мин бер чибәр идем» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Миномётчы – балта остасы, сапёр, монтёр,
Ездовое су астында водолаз да...

Киң һәм тирән ике як яр тоташканчы
Көннәр үтә, төннәр үтә, атна үтә,
Ә дошманга әзер юлны юк итәргә
Самолёттан бомба чөеп төк(е)рү җитә...

...Җан ярсуы белән җыеп соңгы көчне,
Күренмәслек итеп өстән нәфрәт-үчне,
Манёврлар уйлап табып, яңа күпер –
Су өстеннән ярты метр түбән үтте...

Ул көннәрдә кеше башы күргәннәрне,
Кичү өчен күпме корбан бирелгәнне,
Су төбеннән җыеп алып саный калсаң,
Тере күпер булыр иде, тезеп салсаң...

Тарихында Бөек Ватан сугышының
Батырлыкта тиңдәше юк ноктасы бу.
Геройлары, орденлысы күп булса да
Елъязманың тәмугка тиң кыйссасы бу!

## Набат

***(Сугыш кырында һәлак булган Ата авазы)***

*Мөздәлифә! Күксел ташларыңны*
*Барлый-барлый җыйдым атмага.*
Зөлфия Ханнанова

Набат! Набат!! Набат!!!
Сугам Набат!.. Шуның өчен
Салдыммыни газиз башымны?
Балаларым телен «йотсын» өчен,
Калдырдыммы өлеш-ашымны?

Набат! Набат!! Набат!!!
Сугам Набат, җан яңарып,
Сугыш кырларыннан Мин кайтсам?..
Мөздәлифә аланы[1]ннан җыеп,
Шайтаныңа төбәп, таш атсам?..
Җир ярылып, күк ишелеп төшеп,
Минем янга кереп ул ятса –
Җир астында тел көрәше барыр,
Ычкыну юк моннан, бер капсаң...

Набат! Набат!! Набат!!!
Утка – ут! – дип янап,
Җире, җене бергә янганда,
Кәфенлегем муеныма урап,
Дошманнарга каршы барганда –
Җан фәрманы белән: сине, аны саклап,
Ут эчендә ятып калганда,
Кисмәдегез телне! Кирәк иде,
Дошманнарның «телен» алганда...

Набат! Набат!! Набат!!!
Ни әйтерсең, Набат!? Куласаны
Кире якка борып тиктомал,
Түл җыямы, шайтан?
Аз күренгән сыман купшы мал?

Набат! Набат!! Набат!!!
Иңрәп чыга Набат, ә ул Набат –
Ватанына тугры хезмәт итеп,
Һәлак булган Ата авазы:
«Туган телем – иркә гөлем» минем!
Мәхәббәтем, Ана тел назы!..
Сагынамын, бик сагынам сезне!!
Онытмагыз безне!!!» Һәм кушыла аңа
Миллионлаган исән аналарның
Әрнеп чыккан йөрәк газабы:
«Туган телем, газиз Йөрәк телем!.. –
Хәере белән бетсен азагы!..»

[1] Мөздәлифә аланы – Хаҗ гамәле вакытында, шайтанга ыргыту өчен таш җыя торган урын.

## Изге сугыш

Җан сораучы Газраилме,
кан теләүче Әҗәлме?
Байлыгына күзе кызып
йөргән мәхлук Дәҗҗалмы? –
Көтмәгәндә арттан килеп
хәнҗәр батырган кебек,
Утка төрде чит дәүләтне,
игълансыз басып кереп.
Туган илен, туган халкын
коллыктан саклау өчен,
Үз җирендә, ирегендә
төз басып атлау өчен
Күтәрелде барча халык,
чыкты бөек орышка.
Ярсып янган нәфрәт белән
керде кайнар сугышка.
... Күпме даһилар югалды
таңы атмаган килеш.
Илен гөл итәр балалар
сүнделәр, егет килеш.
Асыл башлар, зирәк затлар –
яңа Такташ, Тукайлар,
Галәм яулар Гагариннар,
пәһлеваннар – Усайлар,
Нобель бүләген алачак
акыллар калды ятып,
Фатихлар, Кутуй, Мөҗәйләр
җитәлмәделәр кайтып...
Корбан булды, курган булды
миллионлаган газизләр.
Чичәндә дә, акында да
тасвирга җитмәс сүзләр...
Шуңа да Изге бу сугыш,
шуңа да, әйе, Бөек?! –
Саклаганга Ватанымны утларда
Янып...
Көеп...
Сөеп!!!

## Җиңү байрагы

*Үлем турында уйлама!..*
Фатих Кәрим

Суырып алды бу сугыш
Җир-суларның бар ямен.
Илнең сулышы кысылды,
Аш-суның бетте тәме.

Тиздән кайтырбыз, – дигәннәр
Ятып калды мәңгегә.
Җан-шәрифен кызганмады,
Азат булсын Ил генә! –

Бу миллион йөрәкләрнең
Катгый максаты иде.
Иңрәде иген кырлары,
Басу, далалар көйде.

Кайчагында чигенделәр,
Гаскәрне саклау өчен,
Ачыклау кирәк булганда
Дошманның шәхси көчен.

Аямады кара еллар,
Аямады беркемне.
Шөкер, Аллаһ бүләк итте
Бәйрәм килер бу көнне.

Җиңү байрагын күтәреп,
Батырлар кайткан юллар –
Юл кырыена тезелгән:
Яшькә коенган толлар,

Читәнгә сөялгән чатан,
Чулаклар, «самоварлар»[2],
Чукрагы, үксезе... үксеп –
«Изге сугыш»[3]ны тыңлар...

## Хыянәтем нидә?

Күзләремне йомам, йомам кысып:
Әллә йөгерә кеше, әллә бара очып.
Иңнәренә илнең тире тама,
Кайнар күкрәгеннән: тып-тып, тып-тып.

---

[2] «Самоварлар» – аяксыз да, кулсыз да калып гарипләнүчеләр.
[3] «Священная война» җыры күздә тотыла. Кайбер чыганакларда бу җырның Беренче Бөтендөнья сугышына багышлануы һәм шигыренең дә, көенең дә авторы Александр Адольфович Боде булуы әйтелә.

Ашкыныплар зур сугышка керде,
Җанын бирергә дә әзер иде.
Бер көн килеп чолганышта калды,
Әсир, дигән яман исем алды.

... Күзләремне йомам, йомам кысып:
Тораташтай кеше тора посып.
Туган җиркәенә яше тама,
Хыянәтем нидә?.. Тып-тып, тып-тып...

## Инану

*Картлар йортында яшәүче*
*ветераннар сөйләшүеннән*

Яши монда барлык «артык кашык», –
Сталинга әмма барысы гашыйк,
Икеләнеп тора бик азы.
Минем һаман колагымда чыңлый
Җиңеп кайткан солдат авазы:

«Кәфенлекне урап муенбызга,
Антлар эчеп, алга ыргылдык.
«Ватан өчен! Корыч атам өчен!» –
Дигән теләк белән нык булдык.

Ул инану бүген кирәк түгел,
Кирәк түгел, күрәм, беркемгә.
Мин үзем дә буталанып беттем,
Иманнарын саткан төркемдә.

Сугыш тынгач, батыр хәттин аша,
Сөрелмәгән кырны чүп баса.
Кара якны гына күперткәндә
Мәгънә җирлегеннән ак кача.

Хаталардан халимы соң бәндә?..
Карыйк әле чәчәк аткан илгә:
Нахак яла... комсыз хөсетлекләр
Күпме җанны болгап бәрә силгә...»

## Иң ямьсезе, дисәм...


*Рухи затсызлык та китерде сугыш.*
Газетадан

Йорт-куралар мәет чыккан кебек,
Көз пычрагы күмгән эзләрне,
Төн томаны сарган урамнарны,
Кара туткыл баскан йөзләрне.

Аяусызы, мәнле, мәнсезе бар,
Дөнья бит ул, тере җаннары.
Тукның күзе ләкин хикмәт тели,
Тук бичәнең кайный каннары.

Тыллардагы җенси ачлык чире
Калкып чыккан шуның берсендә.
Үсмерләрдә ир-ат исен эзләп,
Ләззәт тапкан бала хисендә...

Сугыш биргән ямьсез афәтләрнең
Иң ямьсезе, дисәм, ялгышмам.
Шул адымга мәҗбүр булганнарның
Табын юып кара язмыштан?



Вәрис
Гали

# СОҢГЫ СӘФӘР

БӘЯН

*Сугышта 8 улы да һәлак булган якташым Фатыйха Әхмәдиевага багышлыйм.*

**1**

Кырык бишенче елның көзе җылы һәм озын килде. Август ае бик явымлы булды. Җәй көне яңгырларын кызганып кына биргән, бик галәмәт кыздырган иде, күкнең төбе тишелгәндәй, көтмәгәндә, өзлексез коя башлады. Уракның яртысы да төгәлләнмәгән иде әле. Басудагы эшләр бүленде. Бөтенләй юешләнеп беткән көлтәләрне киптерү дә, суктыру да мөмкин түгел иде. Күк йөзен тоташтан каплап алган кургашындай каракучкыл болытларның таралырга бөтенләй исәпләрендә юк кебек тоела башлаган иде инде. Сентябрьдә авырлык белән генә көннәр аязып, яңадан җылытып җибәрде. Басулар озак җилләде. Кичке җылы эңгердә алар өстендә җәй чилләсендәге кебек рәшә уйный башлады. Өлкәннәр дә үз гомерләрендә беренче тапкыр күргән мондый хәлне нәрсәгә юрарга да белмәделәр. Ходаем, сугыш китергән авырлыкларны тагын да озайтмасаңчы, дип теләделәр алар догаларында. Тоташтан койган яңгырдан мәлҗерәгән көлтәләрдәге ашлыкның үрергә өлгермәгәненә бөтенесе сөенде. Быел икмәк бик куандырмый. Җәй коры килеп, сабан игененең сабагы да, башагы да кыска булды. Барча халыкны күтәреп, көлтәләрне басуларда ук таратып салдылар да җиллэтеп алдылар. Таякка таянган әби-бабайлар да, сугыштан бер аякларын өздереп, гарипләнеп кайткан ирләр дә, укырга йөрүче бер генә бала да бу эштән читтә калмады. Мәктәпләрдә укуны туктатып тордылар. Көлтәләр җилли башлауга, атлар ындырга көн-төн көлтә ташый башлады. Арыш чәчү өчен җир тырмаларга сыерлар җигелде.

---

Вәрис ГАЛИ (Минневәрис Мингалиев) (1959) – *язучы, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш районы хакимиятенең Ш.Маннур исемендәге премиясе лауреаты. «Бәхет күпере», «Бөркет тау», «Матбугат аксакалы» һ.б. китаплар авторы. Мамадышта яши.*

Сентябрьдә инде яңгыр бүтән азапламады. Октябрь башында да көннәр әбиләр чуагындагы кебек җылы, сукаланган басу өсләрендә тоҗым җепләре уйнаклый иде. Дүрт елдан артыкка сузылган Бөек Ватан сугышыннан соң адәмнәрнең җаннары ял итсен, йөрәкләренә җылы йөгерсен, дигәндер Табигать-Ана. Өрлектәй ирләрне генә түгел, буыннары да ныгып җитмәгән бала-чагаларны, тал чыбыгыдай зифа кызларны, ак яулыклы әбиләрне дә аямады бу еллар. Берәр кешесе, туганы башын салмаган бер генә гаилә дә калмады Фатыйхаларның өч йөз йортлы, Кызыл Яр һәм Кала Тау итәкләренә сыенып утырган Урта Кирмән авылында. Үзенең дә тугыз баласының, тугыз йөрәк парәсенең берсе дә исән түгел бүген. Гөрнәдирдәй улларын каһәр төшкере сугыш ялмап алды. Тугызының җәсәде тугыз җирдә ята. Нинди гаепләре, гөнаһлары бар иде соң шушы җыйнак кына гәүдәле, сөякләре бүртеп чыккан, яше җитмешкә җитеп килүче Фатыйха карчыкның мондый югалту ачыларын күрерлек?!

Кичә оныгы – Ибраһим улының кызы Мәрзия төпчек улы Әгъмәлетдиннең дә Маньчжурия җирендә ятып калуы турындагы хәбәрне кайтып әйткәч, соңгы өметләре өзелде, йөрәгенең егәре китте. Әле август аенда да хатлары килеп торды. «Японнарны куа башладык, тиздән җиңеп кайтып җитәрбез», – дигән, җанын җылыта торган сүзләре белән өметләндергән, артына сагынуы турында җыр язылган фоторәсемен дә салган иде. Бүген инде анысы да бу якты дөньяларда юк микәнни?! Моңа һич тә ышанасы килми! Бу хәбәр ялгыш кына булгандыр, дип тибә йөрәге.

Җырларга ярата иде төпчек улы. Авылда бәйрәмнәрдә концерт куйганда, аны сәхнәгә чыгармыйча калдырмыйлар иде. Кечкенәдән моңлы бала булып үсте. Сузып җырлый торган халык җырларын бигрәк тә якын итә торган иде. Басуга уракка барганда җырлап бара, кайтканда җырлап кайта. Сузып җибәрсә, моңлы тавышы әллә кайларга кадәр ишетелә. Аның тавышын беркемнеке белән дә бутамыйсың. Бөтен нечкәлекләрен белеп җырлый иде. Сугышка китәргә кәгазь килгәч тә, сагышланып җырлап утырды. Инде ул бала да кайта алмады. Сары сагышларын басарга шул рәсеме белән, артына язган җыруы гына калды. Ачык йөзле, нәзек кашлы соңгы улы да бу якты дөньяда юк икән инде!

Күзеннән бары бер тамчы күз яше тәгәрәп төште аның шул кургашындай хәбәрдән соң. Юк, күзләреннән түгел, йөрәгеннән сытылып чыкты ул! Сул күзенең керфегенә эленеп торды да, яңагы буйлап аска тәгәрәде. Улларының һәлак булулары турында бер-бер артлы килгән хәбәрләрдән, кешедән яшереп елаган төннәреннән соң бәгыре таш булып каткан идеме, йөрәген тагын да бушатасы килсә дә, күз яшьләре бүтән күренмәде. Шул мәлдә бөтен түземлеген җыеп:

– Үз гомеремдәге соңгы яшь тамчысы булса иде! – дип теләде ул Ходайдан. – Бүтән минем башыма югалту ачыларын, кайгы-хәсрәт китермәсәң иде! – диде.

И дөнья! Ничек күтәрергә мондый авырлыкларны! Беренче улы Исмәгыйль гражданнар сугышында башын салды, алтысы – Бөек Ватан сугышында, сигезенчесе – японнар белән орышканда ятып калган, бердәнбер кызы – Сәлимәсе дә салкын тидереп, гүр иясе булды. Күңел кыры шыр ялангач бүген. Йөрәк җимеше, кырык елдан артык бөтен кайгы-

шатлыкларын бүлешкән ире, балаларының атасы – Фәттахы ярый әле сугыш чыгасы елның кышында вафат булды. Бу авырлыкларны – югалту ачыларын йөрәге күтәрә алмас иде. Ирләр йөрәге тизрәк таушала, тизрәк сына.

Аларның Урта Кирмәненә Чытырдан килен булып төшкән Миңсылуның Мәгъсүмҗан атлы энесе японнар белән сугыштан кайткан да, туган авылына шуны күрергә дип менгән булган икән. Юл ерак, Норма һәм Кирмән башы аша узасы бар, унбиш-уналты чакрым гына түгелдер. Үзенә иптәшкә үсмер кыз булып җиткән, хәзердән үк эшкә катылыгы белән аерылып торган Мәрзияне – Ибраһим улының кызын ияртkән булган. Бер урамда торалар. Гел бер-берләренә йөрешеп, авырлык килгәндә, бергә уртаклашып, хәзинәдә барын бүлешеп яшәгәч, олы кеше гозерләп үтенгәч, каршы килмәгән бала. Җәяүләп, Чытырга чыгып киткәннәр. Бригадир Әхмәтҗаннан ат та сорап тормаганнар. Хәер, сорасалар да бирмәс иде. Яңгырлар туктап, җир җилләгәннән соң, бөтен атлар Мамадышка, Чулман буендагы Вандовка глубинкасына икмәк ташый хәзер. Тракторлар гына өлгерми дип, җир сөрергә үгезләрне дә чыгардылар. Миңсылуның энесе сугышта күргәннәрен сөйләгәндә, аның төпчек улы Әгъмәлетдинне дә бик хөрмәтләп искә алган.

– Хайлар исемле шәһәрне алганда, каты бәрелешләр булды. Күп кеше һәлак булды. Безнең якташ – Урта Кирмәннән Фәттах абый малае Әгъмәлетдин шунда японнарның дзотын күкрәге белән каплады. Минем кулларымда җан бирде. Бигрәкләр дә кызганам шуны, түти. Яшь килеш әрәм булды, – дигән.

Бу җан өшеткеч хәбәрне ишеткәч, авылга йөгереп диярлек кайткан Мәрзия. Өйгә килеп кергәндә, сулышлары капкан, телен әйләндереп, сүзен әйтерлек тә түгел иде. Шул мәлдә үк аның йөрәге бик авыр кайгы килгәнен сизде.

– Әгъмәлетдин абый һәлак булган... – дип кенә әйтә алды бала, күз яшьләренә буылып.

Ул балалар да сугыш елларында кисәк олыгаеп киттеләр. Бер-бер артлы килеп торган үлем хәбәрләре аларның да җаннарын телгәләде, җилкәләренә авыр йөк булып ятты. Ашау җитмәү, чирләр аларның Урта Кирмәненнән дә әллә ничә кешенең гомерен алып китте. Ибраһимының Мәрзиядән кечерәк, әле ун яшенә генә җиткән Маһинур исемле кызы да чирләп гүр иясе булды.

Әгъмәлетдиннең үлем хәбәре бөтен дөньясын челпәрәмә китерде аның. Бәлки анысы кайтыр, бәлки ул исән калыр, дип өметләнеп көткән иде.

Хәле киткәнен, башы әйләнә башлавын сизеп, урынына барып ятты. Агач сәкенең такталары да аның йөрәгендәге кайгы авырлыгыннан ыңгырашып куйдылар. Баш астындагы, каз мамыгыннан тутырылган олы түшәк кенә гәүдәсенә җылылык бирә алмады. Мәрзиянең аны калдырып, өйләренә кайтып китәсе килмәде. Ибраһимы өйләнгәч, башка чыгарганнар иде. Гаиләсе икенче урамда яши. Әгъмәлетдиннең японнар белән сугышта һәлак булуы турындагы хәбәр авылга таралган иде инде. Хәбибулла белән Хәлимә кереп җитте. Хәлимә ишектән керүгә үк күз яшьләренә күмелде.

– И-и-и... Фатыйха апа, Әгъмәлетдинне ишеткәч, йөрәгем киселеп төште... – дип тезде. Монда кергәнче үк елаганы йөзенә дә чыккан – күз алмалары кызарып торалар.

Ана йөрәгендәге кайгының олылыгын алар да аңлый. Сигез бала бер бала гына түгел. Берсен югалту да бик авыр. Балаң сугышта һәлак булу абзарыңдагы сыерың егылып үлү генә түгел. Әле ярый һаман үз акылында карчык. Иренең һәлак булуы турында хат килгәч, Мамадышка бара торган юл өстендәге Кала Тау авылы Степанидасының акылы зәгыйфьләнеп калды әнә. Узган җәйдә алар авылына да килеп чыккан иде. Өй аралаш кереп, эчәренә су сорап йөрде.

– Апаем, йөрәгем яна. Һич баса алмыйм. Ярты чүмеч су бир әле, – дип сөйләнә үзе.

Артына бер төркем бала-чага ияргән. Үзләре дә кайсының әтисе, кайсының абыйсы сугышта һәлак булган балалар. Алар да хатынның кайгыдан түбәсе киткәнен белеп алганнар иде инде. Ничек җыелышкан булсалар, шулай тиз генә таралышып беттеләр.

Нәгыймә, Дөрия, Шәмсиямаллар да йөгереп кереп җитте Фатыйхаларга. Нинди генә хәбәр килсә дә, шатлыгын да, кайгысын да уртак итү – авылда электән яши торган гадәт.

– Фатыйха апа, торып ашап алмыйсыңмы? Умачлы бәрәңге алып кергән идек. Гәүдәң җиңеләеп китәр иде, – диде Хәбибулла.

Бик игелекле кешеләр алар. Иртә белән малларны көтүгә куарга чыкканда да:

– Берәр нәрсә кирәк түгелме, Фатыйха апа? – дип, әллә ничә тапкыр сораганнары булды.

Миңсылу олы тәлинкә белән пешкән бәрәңге күтәреп кереп җитте. Ул да кайтып җиткән икән.

– Мәрзияне азаплап, Чытырга кадәр алып менгәнгә ачуланма инде, апа. Юлдаш булыр, дигән идем. Әйдә, бераз күтәрелеп, капкалап алыйк әле, – дип, аның түшәген күтәреп куймакчы булган иде:

– Кирәкми, Миңсылу. Кисәк хәлем китте. Бераз ятып торыйм, дигән идем. Сез берегез дә борчылмагыз. Үз җаем белән торып капкалармын, – дип туктатты аны Фатыйха.

Беркем белән дә сөйләшәсе килми иде аның. Күршеләре аны ташлап чыгып китмәделәр. Авыл хәлләрен сөйләшә башладылар. Кырык өченче елны аларның Урта Кирмән авылын бүлеп, ике колхоз оештырганнар иде. Атау ягы күмәк хуҗалыкка утызынчы елны бирелгән исеме белән – «Алга» булып калды. Норма ягындагы урамнар кергәнен, авыл башындагы чишмә исеме белән – «Татлы су» дип атадылар. Халык та хәзер «Татлы су» ягындагылар, «алганыкылар» дип кенә сөйләшә. Фатыйхалар ягы «Татлы су»га керде. Ике хатын теленә кергәнне – бөтенесе белә, өч хатын җыелышса – базар, диләр бит! Нәгыймәләр, Дөрияләр дә, Урта Кирмәннең бер башыннан кереп, икенче башыннан чыктылар, Арташка да менеп төштеләр.

– Вагыйз абыйның Ушмы халкын Арташка йөгерткәнен ишеттегезме әле? – диде Миңсылу.

Фатыйха да, бу тагын нәрсә ишетеп кайткан дип, колакларын торгызды.

– Ушмы кибете янындагы ташка утырып, ипи ашап тора икән бу, янына бер әби килеп туктаган. Сезнең якларда нинди хәлләр бар, Вагыйз улым, дип сораган. Тегесе Арташка тоз белән парахут килеп калды, бушатырга кеше җыялар; менә, сезнең селсәвиткә әйтергә йөгерттеләр, ди икән. Әби салмак кына китеп барган. Чат башына җиткәнче, тизрәк тыркылдарга керешкән. Әйткән сүзләрен шунда ук онытткан да Вагыйз абый. Ипиен йотып бетереп, күмәч кебек иреннәрен сыпырып утырганда карый, авыл буенча олысы-кечесе йөгерешә.

– Кая чабасыз? Янгын чыккан мәллә? – дип сорый икән.

– Арташка баржа килгән. Тоз белән керәчин өләшәләр, – дигәннәр.

– Әнинең керәчине беткән иде, – дип, бу да артларыннан йөгергән...

Хатыннар рәхәтләнеп көлештеләр. Фатыйха да аларга кушылды. Вагыйз – бер бахыр инде. Буталып йөри. Бер кешегә дә зыяны тигәне юк үзенең.

– Вагыйз абый, бие әле, – дип бер әйтү дә житә, сәгатьләр буе биергә риза. Ут эченнән кара пичәтле хатлар килеп торганда, кибеткә җыелган халыкның йөрәгендәге яраларны үзенең риясыз биюләре белән аз юмады, таштай каткан йөзләрне аз елмайтмады ул.

Хатыннарның гайбәтләрен тыңлап ята-ята йөрәген баскан авырлык кимегән иде инде. Бераздан торып, тамак ялгап алды Фатыйха. Аның белән өстәл янына башка хатыннар да утырышты.

– Үзегезнең күчтәнәчләрегез белән сыйлыйм әле үзегезне. Оялып тормагыз, тизрәк җитешегез, – дип көлдереп алды аларны.

Басудагы игеннәрне урып, көлтә итеп бәйләп, әвеннәргә өеп бетерсәләр дә, аларны ташыйсылары, суктырасылары бар иде әле. Бөтенесенә дә иртәгә эшкә. Кузгалыштылар. Аларны өйалдына чыгып озатып калды Фатыйха.

Ул төнне йокысы йокы булмады аның. Бөтен тормышын уйлап чыкты.

Гомер тиз дә уза инде. Юкка гына фани дөнья ике күз арасы кебек, димәгәннәр. Әле генә буй җиткереп килә торган кыз иде, бүген инде – җитмешенә якынлашкан карчык! Унҗиде яше тулар-тулмас, Арт урамдагы Әхмәди Фәттахына димләп кияүгә бирделәр. Булачак хәләл җефете аннан сигез яшькә олырак иде. Ул елларда кыз белән егетнең очрашып йөрүләре, вәгъдәләр бирешүләре бик сирәк хәл бит. Яшь җилкенчәкләрне генә түгел, җиткән кызларны да әти-әниләре аулак өйләргә сирәк йөртте. Кеше арасында сүз таралудан котлары чыгып торды. Әхмәдинекеләрдән яучы килгәч, әти-әнисеннән, туганнарыннан аерылып, чит йортта яшисен күз алдына китереп, коелып иңгән иде. Фәттахның сөйкемле калын кара кашлары, Татлы су чишмәсеннән судан кайтканда көтеп торып әйткән матур сүзләре, мөлаем карашлары күз алдына килеп, сөенеп тә куйды. Арт урамның ике башында яшәсәләр дә, егет аны күзәтеп йөргән икән. Нәрсәсе белән йөрәген биләгән булгандыр? Буйга да артык күтәрелмәгән, гәүдәгә дә калын түгел югыйсә. Яңаклары аның кебек алмадай калкып торучы мөлаем кызлар авылда бер ул гына түгел. Аларның нәселендәге хатын-кызлар элек-электән туку эшенә оста булган. Киндердән җеп эрләп, кием-салым тегәрлек тукымалар да, бизәкле сөлгеләр дә сукканнар. Ирләре аларны Чөйле, Кирмән башы, Мамадыш базарларында сатып, акча юнәткәннәр. Фатыйханың да киндер сугу осталыгы телгә менә башлаган иде инде.

Әхмәдинекеләрнең дә куллары эш белә. Фәттах гаиләдә олы бала иде. Аннан соң Мәхмүт һәм Мөшәрәп исемле энеләре, Фатыйма исемле сеңлесе бар. Фәттах балта эшенә оста булды. Гәүдәгә аннан күпкә калынрак, олы, мәһабәт буй-сынлы кеше иде ул. Берәрсе каралты-кура, йорт-җир җиткерәсе булса, кулдаш итеп аны чакырдылар. Тирә-юньдәге авылларга чыгып эшләп кайткалады. Үзләренә дә аерым йорт салып чыгу турында хыялландылар. Еллар узгач, бу хыяллары да тормышка ашты. Урта Кирмәннең Арт урамында нараттан күп тәрәзәле, такта түбәле, алты почмаклы, байлар да тел шартлатырлык, шыңгырдап торган өй калыкты. Каралты-кураларны яңадан җиткерделәр.

Беренче уллары Исмәгыйль туганда, аңа унҗиде яшь кенә иде әле. Тагын бер елдан Ибраһим дөньяга килде. Мөгътәсим, Мөхлисулла, Мәгъсүмҗан, Габделбарый, ниһаять, көткән кызлары Сәлимә, Мисбахетдин һәм Әгъмәлетдин. Ир балалары ишле булгач, имана җирләре дә күп тиде. Унҗиденче елгы революциягә кадәр авыл халкына җирләрне гаиләдәге ир балалар санына карап бүләләр иде. Хатын-кызга имана җире эләкмәде. Балалар олысы-кечесе бергәләшеп, дус булып эшләделәр. Барысы да олы гәүдәле, нык бәдәнле булып үсте. Келәтләренә олау-олау ашлык кайта иде. Ашау ягына мохтаҗлык кичермәделәр. Урта Кирмәннең нык хәлле крестьяннарыннан исәпләнде Фатыйха белән Фәттах гаиләсе. Җирләрне элек унбер-унике ел саен бүлеп тордылар. Бүлгән саен төрле урыннан эләгә иде. Норма белән ике арадагы Имән күпер елгасы ягында да, руслар Кирмәненә таба – Тәкәрлек үзәне, Шуайт чокыры якларында туры килгәне дә булды. Шуайт чокырыннан арырак Сакаллы елгасы бар. Аның янында – Ханнар зираты. Андагы унлап борынгы кабер ташын үзенең дә күргәне булды. Чәчүгә төшкәч, Фәттах белән бер тапкыр барып килгәннәр иде. Зират бит, шикләнеп кенә карап йөрделәр. Ташлар төрлесе төрле җирдә ята. Өске якларында көнбагыш рәсеменә охшаган кояш сурәтен чокып ясаганнар. Бик тырышсаң, кайбер хәрефләрен танырга була икән. Берничә кабер ташының ватылгалаган кисәкләре генә калган. Бер ауганын торгыздылар да әле. Әллә ничә потлы шул ташны Фәттах кочагына алды да казык кебек утыртты да куйды. Иренең егәренә исе китеп, сокланып карап торган иде.

Ул тирәләрдә җилләр дә шомлырак исә кебек. Зират урыны гына түгел, каннар коелган җирләр. Болгар дәүләте, Казан ханлыгы заманнарында ук яшәгән борынгы Кирмәнчек шәһәрчегенә күп тапкырлар яу белән килгәннәр. Сугышлар булган, гомерләр өзелгән. Хатыннар, балалар тол калган. Аналар улларын югалткан. Уллары яу кырларында башларын салган аналарның йөрәгендәге кайгыны һәм югалту ачыларын аңлатып бетерә торган гынамы соң?! Шәһәрчек алынгач, халкы урманнарга качкан. Илбасарлар киткәч, яңадан җыелышып тормыш башлаганнар. Нинди генә яулар булмагандыр, әмма халыкны бу җирләрдән берсе дә биздерә алмаган.

Өлкәннәр:

– Ул зиратка безнең борынгы ханнар күмелгән. Рухларына дога багышларга онытмагыз, балалар, – ди торганнар иде.

Алар да әрвахларга атап, дога кылдылар. Бу җирләрдә икесенең дә бабалары каннарын койган, шәһит киткән.

Ханнар зираты каршындагы тау өстендә борынгы шәһәрчек булган, дип тә сөйлиләр. Атауның Сабиры Алтын базы дип йөртелгән тау куышы тирәсеннән яртылаш сынган көмеш хәнҗәр тапкан булган. Авылда аны кулларына тотып карамаган кеше калмагандыр. Кала Тау авылы руслары да ишетеп килеп җиткәннәр иде. Үзләренә сатып алмакчы булып, үгетләп тә караганнар Сабирны. Тик тегесе генә әйткән бәяләрен азсынган.

Ханнар зиратыннан соң, кул сузымында гына – текә ярның уртасыннан агып чыккан Изгеләр чишмәсенә барып килделәр. Әллә ничә тармак чыга анда кыядан. Теш сындырырлык салкын, шифалы суларын эчтеләр, бит-кулларын юдылар. Ул чишмәләрдән суны кабат та алып кайтканнары булды. Авыл халкы дәвага тота аларның суларын. Ә шифалары, дөрестән дә, тия. Тәндәге төзәлмәс яраларны да дәваладылар, күзләрне дә ачтылар, кан косуны да бетерделәр.

Беренче Герман сугышы чыгасы елның язында Фәттах Мамадышка өй салырга барган җиреннән биш алмагач үсентесе күтәреп кайткан иде. Аларны Шуайт чокырының Яке урманы ягындагы башына – үз печәнлекләренә утырттылар. Кеше бакчасында булса, салым түләтәләр икән. Ә болай – басуда, җиде җил чатында. Хуҗаларының исемнәре кәүсәләренә язылмаган.

– Килеп тикшерсәләр, үзләре тишелгән, диярбез, – диде Фәттахы.

Бик үҗәт булып чыктылар алмагачлар – барысы да үсеп китте. Берничә елдан алма да бирделәр. И, сөенгән иде малайлары алмаларын җыеп алып кайтканда. Ничә ел рәттән как койдылар. Быел да август ахырларында барып килгән иде. Картайганнар, кайрылары кытыршыланган инде, барыбер һаман үсеп утыралар әле. Алмалары кызарып пешкән. Бер яулык җыеп төйнәде. Ай буе рәхәтләнеп, күрше-күлән белән чәй эчтеләр.

Октябрь революциясеннән соң байларның җирләре ярлыларга өләшенде, аларның имана җирләре тагын артты. Яңа тормыш халыкка яңа сулыш өргән кебек булган иде, илдә бик тиз мәхшәр купты. Бөтен Рәсәе акларга һәм кызылларга бүленде. Унсигезнең көзендә байларның Халык армиясе авылларны талап узды. Атларны, сыерларны алып чыгып киттеләр. Алар да атсыз калды. Ашлык әле кырда – көлтәләр сугарга алып кайтылмаган иде. Ярты елдан яңа афәт – акларның Колчак явы Нократ, Чулман буйларына кадәр килеп җитте. Исмәгыйль белән Ибраһимны Мамадышка кызыллар отрядына язылырга алып киттеләр.

– Бер-берегездән аерылмагыз, – дип калды аталары аерылышканда. – Бер-берегезгә күз-колак булып, сакланып йөрегез.

– Ярар, әти, – дип киткәннәр иде, сугышта үзең теләгәнчә йөреп булмый шул.

Ике елдан калын кара мыек җибәргән, чын ирләргә әйләнгән Ибраһим гына әйләнеп кайтты. Абыйсын чит җирләрдә җирләп калдырган икән. Үзе дә яраланган. Җыйнак кына сандыгы төбеннән чүпрәк тышлы Коръән алып:

– Шушы изге китап исән алып кайтты мине. Моннан соң нәселебез ядкаре булып саклансын, – дип, әнисенең кулларына бирде.

Аклар ташлап калдырган олауларның берсеннән табып алган икән. Бүген дә исән әле ул китап. Кеше күзеннән еракта – сандык төбендә җиде кат чүпрәккә төрелгән килеш тора.

Имән кебек нык, таза, эшкә булган иде уллары. Егерме беренче елгы ачлыкта да табыннарыннан ипи өзелмәде. Берсе дә ачтан үлмәде. Фатыйхалар нәселендә дә, Фәттахныкыларда да хәер сорашуның нәрсә икәнен белмәделәр. Үз көннәрен үзләре күрделәр. Хәер сорашырга керүчеләргә ашарларына биреп чыгаралар иде. Утызынчы елны барысын да колхозга сөреп керткәч, Фәттах үз куллары белән җиткергән алты почмаклы нарат өйләрен тартып алдылар да аны ындыр табагына көлтә киптерү амбары итеп күчереп салдылар. Олы уллары Исмәгыйль гражданнар сугышында һәлак булмаса, Ибраһим Совет власте өчен канын коеп кайтмаса, аякларына нык басып яшәгәннәре өчен аларны да кулак тамгасы белән Себергә озаткан булырлар иде.

Барысын да колхозга керергә кыстаган җыелышны хәтерли әле ул. Егерме тугызынчы-утызынчы елның кышы иде. Барысын да клуб итеп үзгәртелгән, манарасы киселгән мәчеткә җыйдылар. Мамадыштан ике кеше килгән. Исемнәре онытылган инде хәзер. Билләрен буган каешларына наган кыстырганнар.

– Юлбашчыбыз Ленин барыбызны да күмәк тормыш белән яшәргә чакырды. Завод-фабрикалар эшчеләр карамагына бирелде. Җирне тулысынча сезгә – крәстиәннәргә өләштек. Һәркайсыгыз аерым гына эшләп, тормышыгызны яхшырта алмадыгыз. Үстергән ипиен язга кадәр ашап бетерүчеләр дә бар. Көзгә кадәр яңадан бурычка керәсез. Патша заманнары түгел хәзер. Моңа тыныч кына карап тора алмыйбыз. Батраклар тотучыларга чик куелачак. Партиябез һәм Совет хөкүмәте сезне күмәкләшеп эшләргә чакыра, – дип сөйли башлады озын буйлы, сары чәчлесе көр тавышы белән.

Аны калтыравык тавышы белән Гыйниятулла бүлде:

– Бу ничек була соң? Башта минем җирне чәчеп чыгалар, аннан Сәләхинекен, кабат Хашыймныкынмы? Әхмәтшаныкын чәчкәнче җәй уртасы җитәчәк бит.

Ирләр-хатыннар дәррәү көлеп куйдылар.

– Минем ике ат бар. Башта үземнекен чәчәмме, әллә атсыз Сабираныкынмы? – Сәләхетдин Гасыймы соравыннан өстәлдәге лампа ялкыны сискәнеп куйды кебек.

– Сез мине аңлап бетермисез икән, – дип, сүзен ялгап китте упалнамуч ир. – Күмәк хуҗалыкка берләшкәч, сезнең берегезнең дә җире калмый. Җирләрегезне дә, атларыгызны да, сыерларыгызны да, бөтен әйберләрегезне дә берләштерәсез. Бергәләшеп эшлисез. Җирегез дә, эш коралларыгыз да, малларыгыз да уртак була. Күмәк хуҗалык дип атыйлар аны. Юлбашчыбыз эшен дәвам итүче Сталин барыбызны да колхозларга керергә чакыра.

– Аның безгә нинди файдасы булыр икән? – Бу сорауны арткы рәтләрдә утыручы Зариф кычкырды.

– Колхозга тракторлар, машиналар, атлы молотилкалар, чәчкечләр кайта башлаячак. Тракторлар, машиналар эшли башлагач, сезнең эш бөтенләй җиңеләячәк! – дип җавап бирде аңа каршы төптән юан чыккан икенче вәкил.

– Ул тракторларны колхозга гына бирәчәкләрмени? Безгә эләкмәячәкмени алар? – дип сорады Фәттах.

– Аерым хуҗалыкларга бернәрсә дә булмаячак. Бөтенесе – колхозларга

гына. Иптәш Сталин барыгызны да күмәк хуҗалыкка берләшергә чакыра, – дип кырт кисте беренче булып сөйли башлаган вәкил.

Ике көн барды җыелыш. Берәм-берәм үгетләп, бөтен кешедән диярлек колхозга керергә гариза яздырдылар. Күмәк хуҗалыкка «Алга» дигән исем дә бирделәр.

– Эшләребез гел алга барсын, үзебез гел алда булыйк, – диделәр сәвит җырын җырлап йөрүче куштаннар.

Утызынчы елның язында хәллерәк яшәүче авылдашларны Себергә сөрү башланды. Дистәдән артык гаиләгә кулак тамгасы сугылды. Алар арасында җыелышта беренче булып кычкырган Сәләхетдин Гасыймы да бар иде. Һәркайсына берәр кат кием дә, берничә көн ашарлык ризык кына алдырттылар. Гомерләре буе җыйган маллары, байлыклары колхозга калды. Каргап, күз яшьләре белән елап саубуллаштылар китүчеләр авыл белән. Күрше-күләннәре, авылда калучы туганнары аларны кызганып елашырга да курыктылар. Бөтенесенә үз язмышы кадерле иде. Ата-аналары белән балалары да озатылды.

– Тамырлары да калмасын! – дип төкерек чәчте куштаннар.

Алар Себергә сөрелгәннәрнең йорт җиһазларын бүлештеләр. Җәйгә чыккач, бала-чага затлы чынаяк-тәлинкә ватыклары белән уйнап кинәнде. Хәләл көчең белән тапмаган малның кадере булмый шул.

Фатыйхаларның хан сарае кебек, бүрәнәләре шыңгырдап торган олы тәрәзәле, алты почмаклы өйләрен тартып алдылар.

«Урамда йортларының эзе дә калмасын!» – дип, авыл башындагы ындыр табагына көлтәләр киптерү амбары итеп күчереп салдылар.

Бер тамаша итеп, Сабан туена җыелган кебек, дәррәү килеп, сүтеп алганнар иде. Күзләре генә түгел, йөрәге елаган иде шул вакытларда Фатыйханың. Уллары белән бергә, хәләл көчләренә эшләп тапкан малларына җиткергән өй иде ул. Аларның йортларын тартып алгач, бар җирләре дә бөтен булганга көнләшеп, теш кайраучылар:

– Фәттахныкыларның тамырларын корыттык! – дип мактанып йөргәннәр.

Атауның Чулак Һадиулла хатынына нинди зыяннары тигән булды икән?! Ачлык елны атасына пот ярым икмәк биреп чыгардылар. Аннан соң да әҗәткә сорап килгән еллары булды. Әллә соң кияүгә чыкканчы Фатыйханың берәр малаена күзләре төшеп йөргән булды микән?! Кайбер хатын-кызлар гомерләре буе куенында елан йөртә.

– Шул кирәк аларга! Моннан соң артык сикерә алмаслар, – дип кычкырган.

Фәттахныкыларны алай гына бетерә торган түгел әле.

Колхозда да балта остасы булып эшләде аталары. Үз тегермәнен тоткан кеше, бөтен эшнең рәтен белә дип, күмәк хуҗалыкка тегермән җиткергәч, анда эшләргә куйдылар. Алтмышка җиткәндә дә, капчыкларны ансат кына үзе күтәреп ташый иде. Үз өйләрен җиткергәндә, иренең озын-озын нарат бүрәнәләрне ансат кына күчереп йөртүен хәтерли әле Фатыйха. Тимердәй бәдәнле, бик нык кеше иде. Сүзен өздереп әйтә белде, авыз эчендә ботка бутамады. Ул өйләрендә картаерга гына язмады шул үзләренә.

Ул да, олыгайгач, туку эшен ташлап бетермәде. Кышкы озып төннәрне бушка уздыра торган кеше түгел иде Фатыйха. Сөлгеләр тукыды. Икесе

– сигез улының төсе итеп суккан сөлгеләр бүген дә сандыгында саклана әле.

Колхоз дигәннәре кешене баетмады. Хезмәт көненә эшләттеләр. Салымнарны түләргә акча юнәтү өчен, Мамадыш базарына май, йомырка сатарга йөрделәр. Никадәр авыр булса да, сугыш елларында сыерларын бетертмәделәр. Балалар авызыннан сөт өзелмәде. Сөтле кешенең тамагы ач булмый инде.

Бик озак яткач кына, күзләренә йокы керде аның. Бүген ул төш күрмәде. Израэп йоклаган.

Таң беленүгә торып, намазына басты, сандыгы төбеннән Коръәнен алып, барлык балаларына атап, «Йасин» сүрәсен багышлады. Изге китапны яңадан кадерләп, иң аска салганнан соң, улларының яу кырыннан кайтуларына дип саклаган чикләвекләрен алып куйды. Келәттән он алып кереп, пешеренергә кереште. Йөрәге белән сизә: Чытырның Юныс Мәгъсүмҗанын бүген менеп күрмәсә, башка бер вакытта да моны эшли алмаячак. Соңгы улын, соңгы йөрәк парәсен җир куенына иңдергән кешене үз баласы кебек хөрмәтләргә, сыйларга теләде ул. Бөтен җаны тарта аны әле армиядән генә кайтып төшкән шул солдат янына. Бәлки, башка кеше белән буталгандыр, бәлки, төпчек улы исәндер әле, дигән кечкенә генә өмет чаткысы да сүнеп бетмәгән иде күңел түрендә.

– Тор, кызым, бүген Су Елгага менеп төшәбез, – дип, йомшак кына Мәрзиягә эндәште Фатыйха.

Оныгы әллә кайчан уянса да, йоклаганга сабышып аны тын гына күзәтеп ята иде. Өйгә таралган тәмле исләр дә борынны кытыклый. Тик бу юлы табын янына утырырга ашыкмады Мәрзия. Ул сыйларны кунакка алып барасын белә бит.

Фатыйха яңадан сандыгын ачып, рәешкә генә кия торган, вак бөрчекләр төшерелгән ак күлмәген алды, ак шәлъяулыгын бөркәнде.

– Әйдә, кызым, – диде Мәрзиягә.

Бер кулына – өрәңге таягын, икенчесенә күчтәнәчләре бәйләнгән төенчеген тотып, сәфәргә кузгалдылар. Гомере буе җәяүләп йөрсәләр дә, җитмешкә җитеп килүче карчык өчен кыска юл түгел унбиш чакрым. Әле ярый көннәр җылы тора, аяк асты коры. Үз уйларына чумып атлады да атлады ул. Мәрзия дә сөйләштереп азапламады.

Имән күпергә җиткәч, сөрелгән җир кырыена басып, хәл җыеп алды. Карале син, моннан Зур Тау үзәненә кадәр сузылган өч чакрымлы арада гаҗәеп манзара икән бит! Кирмән инеше бормаланып-бормаланып шуыша аларның Урта Кирмәне тарафына. Арт урамның Тәмле су очы малайлары андагы тугайларга балык чирттерергә менеп йөриләр. Аныкылар да үсмер чакларында, кая китте соң болар дисәң, шунда йөгергән булалар иде. Уналты-унҗиде яшьлек чаклары иде бугай, Исмәгыйль белән Ибраһим сулышлары кабып йөгереп кайтканнар.

– Андагы Таллы яр тугаенда су бозавы күрдек. Бүрәнә юанлыгы үзе, кап-кара, – ди Исмәгыйле.

– Озынлыгы минем кадәр,– дип өстәде Ибраһим.

– Кеше-кара күргәнче, менеп эләктерик әле, эти, – дип, атасын үгетли башлады Исмәгыйль.

– Су бозавын тоту ансат түгел ул, балалар. Кеше эләктерә алмаганга шулай зур булып үсәләр, – дип аңлата башлаган иде аталары, тыңлыйсылары да килми, тәмам кызганнар.

Үгетли торгач, күндерделәр тагын. Дүрт почмаклы сөкәсен күтәреп китте Фәттахы да. Бер йомарлам ит кисәге алдылар. Җәен балыгы ит имәргә ярата икән. Авылларында аны тотып алып кайткалаганнарын ишеткәне дә, күргәне дә бар. Җыйнаулашып, ярга сөйрәп чыгаргач, ат арбасына салып алып кайталар. Язгы ташу белән Чулман елгасыннан кереп кала, диләр. Кояш баеганда, Фәттах белән малайлары да кайтып җитте. Эләктерә алганнар су бозавын. Буе ике метр бар иде. Эшкәртеп, бүлгәләп кар базына төшереп куйдылар...

Хатирәләрдән яшьләнгән күзләрен Фатыйха яулык чите белән сөртеп куйды.

– Күзеңә чүп керде мәллә, әби? Алыйммы? – диде Мәрзия, моны үзенчә аңлап.

– Юк, балам, озаграк текәлеп торганга күзләрем яшьләнде, – дип, аны юатырга ашыкты ул.

Яңадан кузгалдылар. Имән күпер белән Норма межасы арасындагы басуны Җенле җир дип йөриләр. Басу уртасындагы юлдан китсәң, бер чакрым араны узганчы хәлең китә. Шуңа җәяүле халык аны инеш буеннан әйләнеп уза. Ни гаҗәп, басуның аргы башына туры юлдан киткәннәргә караганда, тизрәк барып чыгалар. Бу тирәләрдә Казан ханбикәсе Сөембикәнең елкы җәйләве булган дип сөйлиләр иде авыл карчыклары. Норма ягындагы Зур Тау елгасында Сафа Гәрәй сөекле ханбикәсенә җәйге утар да җиткергән булган, диләр. Ул елгага җитәрәк буе илле, иңе йөз метрлап булган матур гына түгәрәк күл дә бар әле. Ярларында камыш үсеп утыра. Анда кыр үрдәкләре бала чыгара. Авыл сунарчылары, көз җиткәч, үрдәк ауларга барып кайткалыйлар иде. Гаҗәеп гүзәл урыннар монда.

– Безнең әбиләр бу тирәләргә Казаннан Сөембикә ханбикә кайтып йөргән, дип сөйлиләр иде. Казанны руслар алгач, татар иле башкаласын монда оештырмакчы булганнар. Явыз Иван белеп алып, җир белән тигезләргә әмер биргән. Кирмәнне саклаучылар бик каты сугышканнар. Берсе дә исән калмаган. Басулардан гел борынгы акчалар, төрле әйберләр табалар. Төнлә Зур Тау янына берәр кеше адашып барып чыкса, акылдан яза икән. Ул тирәләрне җенле урын, диләр, – дип сөйләп алды оныгына, күл яныннан узганда.

Сул кул якта – инеш буендарак тирән генә чокырлар күренә иде.

– Ә болары элекке баз урыннары булганмы? – дип кызыксынып сорады Мәрзия.

– Булырга мөмкин, – дип куйды ул, үзе дә аларга игътибар итеп. Нindидер йортлар торган инде анда, димәк.

Зур Тау елгасы дип юкка гына әйтмиләр икән. Тавының дөрестән дә кисәктән биегәеп киткән урыны бар. Өстәвенә, текә дә әле. Аскы ягыннан үрмәләп менә торган түгел. Кирмән кору өчен бик җайлы җир булган шул монда. Бер ягыннан урман саклый, икенче ягыннан – текә яр. Тирә-юнь, уч төбендәге кебек, ап-ачык күренеп тора.

Норма авылын узгач, Кирмән башына кереп тормыйча, басу читләрендәге

ат юллары буйлап кына бармакчы булган иде. Халыкның көтүләре йөри торган Казыган тау елгасы буйлап китсәң, Чытырга турырак, юлның кыскарак икәнен белә. Ул киң үзәнне Сулы Елга дип йөртәләр. Бик күп чишмәләр тибеп чыга анда тау итәкләреннән. Үзләре мул сулы. Урта Кирмәннең дә чишмәләре элек бик каты кайнап чыга иде, дип сөйлиләр. Суы тирән булгандыр хәзер тезгә дә җитмәгән инешләренең. Бик борынгы заманнарда Чулманнан кечкенә көймәләрдә менеп йөргәннәр, дип сөйлиләр иде.

Кирмән башында элек волость үзәге иде. Андагы кантурга менгәне булды аның. Ә авыл галәмәт зур – мең йортлы дип сөйләшәләр иде. Тау башларында, су буйларында ындырлары тезелеп киткән. Авылга сыеша алмыйча, тау башына да берничә йорт җиткереп чыкканнар. Шуның кадәр күп кеше яшәгәч, җирләре җитмәгәндер инде. Арташ өстендәге олы басуны сугышып алганнарын хәтерли әле. Арташларны якларга Урта Кирмәннең ирләре дә күтәрелеп менгән иде. Кирмән башлары усал бит: барысын кыйнап кайтарганнар.

Егерме беренче елгы ачлыктан соң, Кирмән башының өч йөз гаиләсе Донбасс һәм Кузбасс якларына чыгып китте. Алкин байларының җирләрен бүлеп биреп, өч авыл оештырдылар: Хәсәнша, Чытыр һәм Игенче. Соңгысы халык телендә Ләүкә дип атала. Беренче күченгән кешесе, эш коралларын куеп торырга җайлы булсын дип, иң башта мунча ләүкәсе ясап куйган, диләр. Утыз дүртенче елгы урак вакытында Кирмән башы бөтенләй янып бетте. Себергә сөрелгән кулак малае кайтып ут төрткән, дип сөйләделәр. Кирмән башыннан бик күп кешене озаттылар шул. Утызынчы елның язында колхозга каршы хатын-кызлар да бунт күтәргәннәр иде. Алабуга милициясен китертеп, атаманнарын ирләре белән җыеп киттеләр. Бер гаепсез алып кителгән Югары оч мулласын Казанның Пләтән төрмәсендә кылыч белән тураклаганнар, дип сөйләделәр. Утыз дүртенче елны август бик коры килгән иде шул. Бөтен кеше уракта булган. Бернәрсәләрен алып чыга алмаганнар. Авыл бөтенләй янып беткән. Шундый хәлләрдән соң Кирмән башы кечерәеп калды. Хәзер өч йөзләп кенә хуҗалык, ди.

Талчыккан иде инде. Мәрзия дә аргандыр. Кирмән башы аша китеп, берәр танышларында чәйләп чыкмыйча булмастыр, дигән карарга килде Фатыйха. Югары очта Миңсылуның Салих атлы энесе яши. Хатыны Шәмсенур исемле. Аларга бер кереп чыкканы бар иде инде. Өйләре югары очның аргы башындарак, тыкрык буенда. Бакча башларында ук текә яр.

Хәл алырга Салихларга сугылдылар. Шәмсенур Мәрзияне дә, аны да тиз таныды. Өйгә узгач, утырып дога кылдылар. Совет куштаннары указлы муллаларны куып бетерсәләр дә, догасын ташламый халык. Яңа туган балага, авыл Советына алып барганчы, дога укып, исем кушалар; берәрсе вафат булса, зиратка җеназа белән җирлиләр.

– Самат әби күп итеп сәламнәр әйтергә кушты, – диде Мәрзия.

Миңсылуның Самат исемле малае бар иде. Сугышта һәлак булды. Бала-чага «Саматның әнисе» дигән сүзне әйтергә җиңелләштереп: «Самат әби», – дип кенә йөри башлады.

Үзләренең нинди йомыш белән Чытырга менәргә чыгуларын әйткәч, Шәмсенурның да күзләренә яшьләр килде. Самавырын куеп җибәрде. Аның янында сүз озак бармады. Фатыйханың тизрәк Мәгъсүмҗанны күрәсе килә иде. Юлдагының юлда булуы хәерле дип, тиз кузгалдылар.

**2**

Мәгъсүмҗан солдатларның өе авыл башыннан ерак түгел икән. Хәер, бер генә урамлы авыл ул Чытыр. Егерме беренче елгы ачлыктан соң халыкны Кирмән башыннан күчергәннәр монда. Авыл урынында куе чытырманлык булган, халык шуларны төпләп урнашкан. Кешеләре нык яши. Барысында да диярлек такта түбәле йортлар. Күбесе урманда эшли икән бу авыл халкының. Урман эшчеләренә ай саен акча түләп баралар шул.

Мәгъсүмҗан солдат өйдә туры килде. Ишегалларында нәрсәдер эшләп йөри иде. Озын буйлы, киң җилкәле, нык гәүдәле егет икән. Әле утызга җитмәсә дә, йөзе җитди. Мәрзия белән Фатыйханы күргәч, барысын да сүзсез аңлады. Чөнки Миңсылу апасы белән менгән уртача буйлы, киң җилкәле, толымнарын җилкәсенә үреп салган үсмер кызны тиз таныды ул. Алар белән каршыларына килеп күреште. Сугыштан кайткан гимнастёркасын гади күлмәккә алыштырырга өлгермәгән иде әле егет. Аңа карагач, кайсы ягы беләндер Әгъмәлетдиненә охшатып, ананың йөрәге сыкрап куйды.

Өйгә керделәр. Егетнең әнисе дә шунда иде.

– Кунаклар бар икән, мактап йөрисез, самавырым кайнап утыра, – дип, өстәл янына чакырды.

Фатыйха карчык кулындагы төенчеген чишеп, күчтәнәчләрен чыгарды. Аларны күргәч, солдат егет белән анасы уңайсызланып куйдылар.

– Мәгъсүмҗан балам, син миңа үземнең улым кебек. Сугыштан кайткан Әгъмәлетдинемне сыйлаган кебек сыйлыйсым килә. Бер дә тартынма. Менә бу пәрәмәчләремнән, чикләвекләремнән авыз ит әле, – дип, барысын аның алдына тезә башлады.

– Үзегез дә озын юл менеп аргансыздыр. Чәйне сөтләп ясыйм, – диде хуҗабикә.

Ашыкмыйча гына тамак ялгап алдылар. Табын янында авыл хәлләре дә сөйләшенде. Мәгъсүмҗан бераз ял итүгә урман эшенә урнашырга җыена икән.

– Мин инде хәзер күрәсен күргән, картайдым. Берсен дә яшермичә сөйлә миңа. Син – баламны соңгы тапкыр күргән кеше. Йөрәгемдә калмасын, – диде Фатыйха солдатка.

Утны-суны кичеп, дусларын югалту ачыларын татып кайткан кеше ана йөрәген аңламыймы соң! Бер мәлгә көрсенеп алды да:

– Бөтенесен сөйлим, – дип, сугыш елларында Ерак Көнчыгышта бергә ничек хезмәт иткәннәреннән башлап китте.

Байкал артында булганнар икән. Җиргә землянкалар казып яшәгәннәр. Менә-менә фронтка җибәрүләре бар дип, хәрби өйрәнүләрне үткәреп кенә торганнар.

– Тәртипләр бик каты иде. Офицерларның да, сугышчыларның да тизрәк фронтка китәсе килә. Күбесенең туганнары һәлак булган. Әгъмәлетдин дә

әллә ничә тапкыр рапорт язды. Барыбер җибәрмәделәр. Японнар илебезгә сугыш башлар, дип көттеләр. Алар ягыннан безнең чик сакчыларына карата провокацияләр күп булды. Автоматлардан да аттылар. Безне төнлә тревога белән күтәрәләр иде. Әгъмәлетдин якташ өйрәнүләрдә гел алдынгы булды. Командирлар мактап кына торды, – дип сөйләп китте ул.

Аның русча кыстырган сүзләрен аңлап бетермәсә дә, бүлдермәде Фатыйха. Барысын да күз алдына китерергә тырышты. Улы иптәшләре белән яшәгән землянка күз алдына килде. Җәй көннәрендә бик тынчудыр анда, яңгырлар яуганда, стеналары җебеп ишеләме икән? Кыш көне ягып җылыну өчен мичләре булдымы икән? Берничә караватт сыярлык итеп ясалгандыр инде ул землянкалары. Менә Әгъмәлетдингә каравылга чыгарга кушалар. Улы олы гәүдәле аның. Җәһәт кенә күтәрелеп, автоматын ала да тышка чыгып китә. Ә анда – үзәкләргә үтә торган ачы җил сызгыра. Әгъмәлетдин өстенә сарык йонынннан тегелгән толып элгән. Туңуны белми дә. Күзләре үткен. Карашларын дошман ягыннан алмый. Алар килә башласа, атып, барысын да уятачак ул...

Мәгъсүмҗан салмак, көр тавышы белән дәвам итте:

– Быел июнь аенда тревога белән күтәреп, Маньчжурия чигенә алып киттеләр. Японнар сизмәсен өчен төнлә генә барып, көндез ял итә идек. Июль урталарында ил чигенә барып җиттек. Бер айга якын сузылган хәрби өйрәнүләр башланды. Яңадан автоматлардан, пулемётлардан төз атарга, граната ыргытырга, кул сугышына өйрәндек...

* * *

Сугыш елларында Урта Кирмәндә дә үсмер кызларны, егетләрне җыеп, мылтык тотарга, шуышып барырга, штык белән кадарга өйрәтә башлаганнар иде. Авыл каршындагы биек, текә Кызыл Ярга йөгереп менәргә кушып азапладылар яшьләрне. Үзен командирлары дип йөрүче укытучылары кушкач, кая барсыннар. Йөгерәләр иде. Берсендә шулай төнлә күрше кызы тәрәзә шакыды. Нәрсә булды икән тагын дип чыккан иде. Сулышлары капкан.

– Фатыйха апа, безнең бөтенебезне дә клубтан кайтарып җибәрделәр. Казан ягыннан Мамадышка таба бик күп немец самолётлары очып килә икән. Бөтен утларны сүндерергә, тәрәзәләрне каплап бетерергә куштылар, – ди.

Аның да йөрәге төшеп киткәндәй булды. Ышанып, төне буе тәрәзәләрен капчыклар белән томалап йөргән иде. Ике-өч тапкыр очкан тавышлары ишетелмиме икән дип чыгып тыңлап та керде. Кая ул, төнлә күктә түгел, авыл өстендә дә шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Этләргә кадәр йоклап беткәннәр иде бугай. Икенче көнне барысын да клубка җыеп:

– Хәрби өйрәнүләр үткәрдек. Барыгыз да тырышты. Бөтенегезгә рәхмәт! – диде Мамадыштан килгән юан гәүдәле, хәрби киемле кеше. Күзләре бик канәгать ялтырый иде үзенең.

Моннан соң төнлә лампа яндырып утырмаска, кояш баюга тәрәзәләрне кара пәрдәләр белән каплап бетерергә куштылар. Пәрдәләре булмаганнарга кәгазь ябыштырырга боерылды. Ул гәҗитен дә бөтен кеше дә алдырмый бит әле. Укытучылардагы иске гәҗитләрне җыеп тараттылар.

* * *

– Август башында дивизиябезне тревога белән күтәрделәр. Политбүлек начальнигы Япония белән сугыш башлануын әйтте. Чикне узып, Маньчжурия территориясенә кереп киттек. Бик олы Гоби чүле башланды. Һава температурасы анда көндез кырык градуска кадәр күтәрелә икән. Йомшак кына җил чыкса да, тозлы комны очырта башлый. Ул сулышларны каплый. Кайнар комда күн итекләр бөрешеп кибә. Бик күп солдатлар юлда барганда, кызу тиеп, аңнарын югалттылар. Котелокларга иртән тутырган су өйлә турына эчелеп бетә иде. Әлсерәүдән телләр аңкауга ябышты. Бер тапкыр карыйбыз, алда зәп-зәңгәр күл күренә. Барыбыз да тизрәк шунда барып җитү өчен йөгерә башладык. Ә ул мираж – сурәт кенә булган икән. Безнең белгән нәрсәмени! Бик кызу көннәрдә чүлдә күзгә әллә нәрсәләр күренә башлый, диләр.

* * *

– Уразаның урак вакытына туры килгәне булды. Көн озын. Сәхәргә иртә торасың. Кояш соң гына байый. Көн чилләсендә бик каты кыздыра. Башка кызу бәрмәсен өчен, сүрән вакытта – иртә-кич кенә уракка чыга идек. Көн буе авызга тамчы да су капмаганга, кичкә бөтен хәл бетә. Егерме беренче елның җәендә монда да чүлдәгедән ким булмады. Кызудан көне буе һавада зәңгәрсу рәшә уйнады. Басудагы игеннәр корыды. Чишмәләр кипте, – дип искә алып утырды Фатыйха, чүл кызулыгын үзенчә күз алдына китереп.

* * *

– Чүлне чыккач, яңгыр коярга кереште. Башта суга тиенгәнгә сөенгән идек, ул тоташтан яуды да яуды. Олы Хинган таулары башланган икән. Аяк асты сазга әйләнеп бетте. Елгалар ярларыннан чыкты. Тауларны үткелләр аша гына кичеп чыгып була анда. Җитмәсә, алар тар. Урыны-урыны белән кыялар читеннән барасы. Шул үткелләрдә японнар аяусыз каршылык күрсәттеләр. Машиналар, танклар, туплар упкынга очты. Күп солдатлар кырылды. Зур югалтулар белән алга бардык. Ул тауларга менәргә безнең машиналарның көче җитми иде. Олы-олы әрҗәләр төягәннәр. Җайсыз урыннарда этеп алып мендек. Тауларны исән-имин узгач, тигез җирләргә килеп чыктык. Яңгырлар һаман туктамаган иде әле. Юлсыз җирдән саз ерып барырга туры килде...

* * *

Август уртасы монда да бик яңгырлы булды. Чиләкләп койды. Халык әллә ничә көн уракка чыга алмады. Яңгырлар туктагач, җир кипшергәч, аягында йөри алырлык бөтен кешене басуга алып чыктылар. Карт-корылар да калмады.

– Фатыйха апа, син дә уракка бар инде. Бала-чагаларны көлтә бәйләргә, әвен куярга өйрәтеп торырсың. Сыйфат инспекторы булырсың, – дип, бригадир Әхмәтҗан килеп әйткәч, соңгы елларда аерылмас иптәшенә әйләнгән өрәңге таягына таянып, ул да басуга китте.

* * *

– ...Тоташ фронт булмады анда. Японнар ныгытылган районнар әзерләгәннәр, аларга бетоннан дзотлар ясап, пулемётлар, туплар урнаштырып бетергәннәр. Алар җир асты юллары белән тоташкан, дип аңлаттылар. Сугышка бик каты әзерләнгәннәр икән. Андый ныгытмаларда канкойгыч сугышлар булды. Дошман билләренә гранаталар бәйләгән солдатларын күп калдырган. Безнекеләр туктаган җиргә кулларын күтәреп киләләр дә үз-үзләрен шартлаталар. Без бит башта аларның ниятләрен белмәдек, пленга бирелергә телиләр, дип уйладык. Ә аларны төрмәләреннән җыйганнар икән. Гаиләләренә акча вәгъдә иткән булганнар. Әгъмәлетдин белән икебез дә таш артында качып ятучы бер японны кулга алмакчы идек. Икебез ике яктан килеп, автоматларны төбәгәч, кулларын күтәреп, миңа таба килә башлады бу. Күп калмаган иде инде, шул вакыт взвод командиры, чуваш егете Григорий атып екты моны. Үзе яныма йөгереп килеп тә җитте.

– Шушында бетәсегез килде мәллә? Менә карагыз, нинди солдат ул, – дип, гимнастёркасын күтәреп күрсәтте. Биленә гранаталар бәйләнгән. Исән калуыбызга сөенеп, иптәшләр артыннан йөгердек.

Аргунь елгасын кичеп чыккан идек, дивизияне Хайлар дигән шәһәргә бордылар. Андагы ныгытылган районны ала алмаганнар. Август уртасында төнлә барып җитеп, андагы дивизия солдатларын алыштырдык. Бик күп кырылганнар икән. Атакага күтәрелгән саен, японнар яшеренгән җирләреннән чүкеп кенә торганнар. Ә безнекеләр – тау битендә, уч төбендәгедәй күз алдында. Икенче көнне иртән безне дә атакага күтәрделәр. Артиллеристлар дзотларны башта бик озак тупка тоттылар. Алар тау битләренә берничә рәт итеп урнаштырылган иде. Байтак ут нокталары җимерелсә дә, берничәсе исән калган. Кабат күрдек: стеналары икешәр метр калынлыкта итеп эшләнгән иде. Аларны ансат кына җимереп булмый шул! Командирлар һаман атакага күтәрелергә чакыра, ә без аларның пулемётларыннан башны да күтәрә алмыйбыз. Шул вакыт Әгъмәлетдин безнең юлны бикләп торучы дзотка таба шуышып китте. Әле бер, әле икенче таш артына ышыкланып барып, шактый якынлашты ул аңа. Егерме метрлап ара калгач, күтәрелеп, кулындагы гранаталар бәйләмен томырды. Дошман пулясы тиде бугай, үзе дә йөзтүбән җиргә капланды. Көчле шартлау яңгырагач, пулемёт юк ителде, дип уйлап, атакага күтәрелдек. Күп тә үтмәде, яңадан телгә килде бу. Минем ике яктагы егетләр дә, киселгәндәй, җиргә капландылар. Кире ятарга мәҗбүр булдык. Якташ бетте, дип уйлаган идем, карыйм, тагын шуыша Әгъмәлетдин! Егетнең исән булуын күреп, бөтенебез сөендек. Дзотка кадәр шуышып барып җитте дә, берничә метр гына калгач, торып автоматыннан ата-ата йөгереп, ут ноктасын күкрәге белән каплады. Моны күрүгә, башыма органдай булды. Ничә ел бер котелоктан ашаган, якын туганыма әйләнеп беткән бөркеттәй егетнең һәлак булуы иде бу! Иң беренче булып, мин сикереп торганмындыр. Ур-ра кычкырып, автоматтан сиптереп, аның янына ташландым. Тегеләр һаман дөмекмәгәннәр икән әле. Әгъмәлетдиннең гәүдәсен кырыйга этеп төшерделәр дә, яңадан ут ачтылар. Шул вакытта җир астыннан барып буып үтерерлек булдым. Барып кына булмый иде. Чернигов өлкәсеннән алынган Владимир Бульба дигән егетебез пулемётка иң якыны иде. Ул

да шуыша башлады. Башта гранатасын томырды, аннары дзотны кабат күкрәге белән каплады. Без дә шуышып барып җиткән идек инде. Әллә ничә кеше эчкә гранаталарыбызны аттык. Әгъмәлетдинне кулыма алдым. Күкрәге пулялар белән тишкәләнгән, кап-кара кан эчендә. Йөрәген тыңлап караган идем, җаны бар. Шатлыгымнан күзләремә яшьләр тулды. Тизрәк санитар кызга кычкырдым. Күп кеше кырылды анда. Әллә ничәсе яраланды. Санитар килеп җиткәнче, кулларымда җан бирде. Ул көнне бер генә япон солдатын да пленга алмадык. Күпме егетләр башын салды бит шул биеклектә. Төнлә дә ике арада атыш барды. Алар безне миномётлардан утка тоттылар. Икенче көнне яңадан безнең тупчылар эшкә керeште. Ярты сәгать буе аттылар. Атакага күтәрелергә әзерләнгән идек, тегеләр ак флаг күтәреп, капитуляция ясадылар. Биш мең кешелек гарнизоннары саклаган икән шәһәрне. Безнең барыбер сытып узасыбызны белеп, исән каласылары килгәндер. Дусларыбызны хөрмәтләп, салютлар биреп күмдек. Әгъмәлетдинне бөркәнчегенә үзем әйбәтләп төрдем, белгән догаларымны укыдым. Һәлак булганнан соң да йөзе бер дә үзгәрмәде. Ирен читләренә кадәр елмайган килеш иде. Бик авыр булды якташыбызны гүргә иңдерү. Ир-егетләр булсак та, барыбызның да күзләр яшьләнде. Батырлыгы өчен орденга тәкъдим итәбез, диде командирлар. – Мәгъсүмҗан ашыкмыйча, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде.

Авыр, бик тә авыр иде Фатыйхага боларны тыңлавы. Барысын да күз алдына китереп барды. Улының ничек итеп тауга каршы шуышуын, гранаталарын атуын, кабат күкрәге белән үлем сибүче тишеккә каплануын үзе күргәндәй булды. Мәгъсүмҗан туктагач та, тагын бер ишетәсе килеп, аңлап бетермәгән җирләрен кайта-кайта сораштырды.

Солдат ашыкмыйча гына барысын да аңлатты. Ананың соңгы өметләре чәлпәрәмә килгәнен белә иде ул.

– Без бертуганнар кебек идек. Бер-беребезгә килгән хатларны кычкырып укыдык. Әгъмәлетдин абыйлары һәлак булганга бик өзгәләнде. Фронтка китеп, алар өчен үч аласы килде. Сез илгә монда да кирәк, диделәр. Японнар белән дә сугыш менә-менә башланып китәр кебек иде. Шуңа күрә анда әллә ничә дивизияне тотканнардыр да инде. Бер дә тыныч булмады анда. Сакта торган солдатларны урлап китәләр иде. Кабат аларның үле гәүдәләрен китереп ташлыйлар. Берничә тапкыр шулай кабатлангач, командирлар каравылда торучылар санын арттырдылар. Әгъмәлетдин белән икәүләшеп, әллә ничә тапкыр бергә сакта торган булды. Күзләре үткен иде аның. Гел уяу булды. Шылт иткән тавышны да әллә кайдан ишетә иде. Стройда йөрергә дә оста булды. Командирлар гел мактап тордылар үзен.

Ана өчен улын мактаудан да олы сөенеч юк. Йөзләренә кызыллык китермәгән икән төпчек улы да. Рәхмәт аңа! Авыр туфрагың җиңел булсын инде, бала.

Мәгъсүмҗан такта чемоданын ачып, кызыл йолдызлы солдат пилоткасын алды.

– Бу – Әгъмәлетдиннеке. Истәлеге булып калсын, дип алып кайттым, – дип, анасының кулларына бирде.

Улының баш җылыларын тойгандай булды Фатыйха әлеге саргылт-яшел тукымада. Әйтерсең, ул җылылык, пилоткадан кулларына күчеп, гәүдәсенә

тарала бара, йөрәген җылытмакчы була. Аны бит Әгъмәлетдине берничә ел киеп йөргән. Шуның белән атакаларга барган, үлем белән күзгә-күз очрашкан. Җан биргәндә башында булгандыр. Күзләрен йомып, улының соңгы минутларын күз алдына китерергә тырышты. Менә аның күкрәге ядрәләр белән тишкәләнгән. Шинеле кап-кара кан гына. Үзенең дә бөтен гәүдәсе әҗәл ачылары белән сызлый башлавын тойгандай булды Фатыйха. Күкрәге таштай катты. Шул вакытта:

– Түти, Фатыйха апа, чәеңне җылытып биримме? – дип, Мәгъсүмҗан эндәшмәсә, үзе дә якты дөньяга әйләнеп кайта алмаган булыр иде.

Соңгы йөрәк җимешенең саргылт-яшел пилоткасын күкрәгенә кысты. Бүген ул – бу дөньядагы иң кадерле ядкаре. Күңеле мөлдерәмә тулса да, бәгыре каткан иде. Әйтерсең күкрәген юан кыршау кыскан. Күзләренә яшь тамчылары тулса да, яңаклары буйлап түгелмәделәр.

Әбисенең өстәл яныннан торганын күреп, Мәрзия дә күтәрелде.

– Исән-сау гына йөр, балам, – дип, Мәгъсүмҗанның чәчләрен сыйпады да, кайтыр юлга кузгалдылар.

**3**

Чытырга менгәндә, адымнары кызу иде, кайтканда ашыкмадылар, салмак кына атладылар. Фатыйханың аяклары да авырайды. Мәрзия сүзсез генә яныннан бара. Ул да уйчанланды. Йөзе җитди. Башка вакытлардагы кебек сораулар яудырмый. Ул да бит ятим. Бу дүрт ел эчендә балалар да кайгы коесыннан күп эчте. Кара көзгә кермичә, уку күргәннәре юк. Тырыс күтәртеп, коелган башакларны җыярга йөртәләр. Көзге салкында күшексәләр күшегәләр, җылы мәктәпләрендә укырга тиешле сәгатьләре чыкмыйча, басудан кайтып китмиләр. Әле ярый, колхоз эшенә йөрүчеләр дип, умачлы аш пешереп алып баралар үзләренә. Бригадир Әхмәтҗан ул ашны көн саен кызганмыйча пешерергә куша.

– Әниләре – эштә. Ашарларына пешереп көтеп торучы юк. Күбрәк пешерегез, – дигән.

Кайсыдыр аның өстеннән дә: «Колхоз малын таратып ята!» – дип, прокурорга шикаять язып җибәргән булган. Килде бер күзлекле ир. Амбарларны, бөтен кенәгәләрен тикшереп чыкты. Кәнсәләрдә өч көн утырды. Ахырдан:

– Барысы да тәртиптә. Үзең ашап бетермәгәнсең. Яшь буын сәламәт үссен өчен барыбыз да кайгыртырга тиеш, – дип китеп барды.

Кырык икенче елны колхоз рәисе Ләйләбәдәрне, ашлыкны таратып бетергән дип, төрмәгә озатмадылармыни?! Колхозчының ашарына калмагач, өстәгеләр кушканчы, хезмәт көненә бераз гына икмәк өләшкән иде. Анда да шул ук үзебезнең авыл хатыннары чакты! Бик зурлап, суд ясадылар. Фронтта кан коючы ирләрне ашатырга китәргә тиешле икмәкне яшереп калдырган, корткыч, дигән исем тактылар. Төрмәдән чыккач та, авылына кире әйләнеп кайта алмасын, дигәннәрдер. Авылдашларын кызганып эшләгән гамәле иде югыйсә. Кулларына богау салып озаттылар баланы авылдан. Халыкның:

– Төрмәгә утыртмагыз инде, – дип ялынуларын да тыңламадылар.

Фатыйха үз уйларына чумып, ат арбасы тәгәрмәчләре белән чуарланган

басу юлыннан акрын гына атлады да атлады. Көн дә сүрәнләнә төшкән, кичкә таба авышкан икән. Көз көзлеген итә: көн челләсе узуга, салмак кына салкынайта башлый, һава авырая. Игеннәрдән бушап калган басуларны тракторлар сөреп йөри. Сап-сары басулар акрынлап, яңадан кап-кара төскә керә баралар. Ара-тирә ямь-яшел уҗым кырлары да күренә. Ә урманнарга алтынсу төсләр кергән инде. Табигатьнең төсләргә иң бай, юмарт чагы. Бер атна элек үзе дә «уфалла» арбасын тартып, коры куакка менгән иде. Быел чикләвек бик мактанырлык түгел икән. Ә имәннеке ишелеп уңган.

– И дөньясы-ы! Имән кебек ирләр, егетләр иде бит улларым!.. Кайларда ятасыз икән, газиз балаларым?.. Каберләрегез кайларда икән сезнең?.. Гәүдәләрегезне гүрләргә иңдерүчеләр булдымы икән?..

Беренче улы Исмәгыйль гражданнар сугышында ук һәлак булган иде. Ибраһим аны үзем гүргә иңдердем, диде. Йоласын китереп, каберен казырга, ләхетен алырга, Йасинын чыгарга вакыты булдымы икән соң баланың? Иптәшләре булыштымы икән? Анда да бит ут эчендә. Ул вакытларда яу кырында шәһит киткәннәргә Йасин чыгу гаеп саналмагандыр әле. Хәзер генә ул Ураза тоту, Корбан чалу, намаз уку – зур гаепкә әйләнде. Урта Кирмән зиратына сибәргә Исмәгыйльнең кабереннән бер уч туфрак алып кайткан иде Ибраһим. Тугыз балалары арасыннан бер Сәлимәнең генә җәсәде авыллары зиратында ята. Ул бала да озын гомерле булмады, җиләктәй чагында салкын тидереп, үпкәсе кабарып китеп барды. Кияүгә чыгарга да өлгермәде ичмасам. Ул да иркәдә үсмәде, абыйлары кебек эшкә черәш иде. Җәй челләсендә дә тирләп эшләгән килеш салкын су эчсәң, бик тиз салкын тидерергә мөмкин шул. Авырып ятканда, Мәрзияне ияртеп, сеңлесенең хәлен белергә менгән иде Ибраһим. Озаклап, аның чәчләрен тарап утырган иде. И яраткан иде Сәлимә абыйсының чәчләрен таравын. Һаман күз алдында тора әле шул вакыт. Үпкәсенә салкын нык тигән булган икән. Хәле авырайганнан-авырая барды. Ике көн ут кебек ятты да, гомере киселде. Үз балаңны салкын гүрләргә илтеп салудан да авыррак әйбер юк икән ата-ана өчен. Тугыз баладан Ибраһим белән Мөгътәсим генә башлы-күзле булып өлгерделәр. Ибраһим авылларыннан өйләнгән иде. Башта алар белән бер йортта гомер иттеләр. Аннан соң башка чыктылар. Ә Мөгътәсим шахталарга чыгып китте. Башта Пермь өлкәсендә күмер чапты. Ул якларга Кирмән-Уразбахты төбәкләреннән күпләп китәләр иде. Гомер-гомергә кеше күп йөрде анда. Йорт җиткерү, сыер алу өчен акча эшләде ирләр. Кайберләре күмер басып, шунда мәңгелеккә калдылар. Дон буендагы Ростов каласына китте Мөгътәсим. Эштә бик алдынгы булган. Хатларында: «Стахановчы мин хәзер. Смена саен өчәр-дүртәр норма эшлим. Җыелышларда мактап сөйлиләр, премияләр, Мактау кәгазьләре бирәләр», – дип яза иде. Өйләнеп, бер малай, өч кыз үстерәләр иде, бәхетләре озын гомерле булмады. Хатыны Гамилә авырып үлгәч, балаларын туган нигезенә алып кайтты. Олы абыйсы истәлегенә улына Исмәгыйль дип исем кушты. Киноларда күреп, борын астында гына тар мыек йөртә башлады.

Аларның Урта Кирмәненә дә сугыш алдыннан кино куярга киләләр иде. Тавышсыз кинолар да күрсәттеләр, тавышлыларын да. Клубта аяк басарлык та урын булмый торган иде. Кино куючы ишек төбенән китеп,

утны сүндерүгә, эскәмия асларына бала-чагалар да кереп тула. Эчкә узарга кыюлыклары җитмәгәннәре тәрәзәләрне сырып ала. Аларның да кино карыйсылары килә. Совет иленең башка почмакларындагы халыкның ничек яшәгәнен дә күрсәтәләр. Авыл халкының күбесе Мамадыштан ерак китмәгән бит. Барысына да кызык. Дөньяда мондый җирләр дә бар икән дип, гаҗәпләнеп карап утырдылар. Сугыш башлангач, күбрәк тә килә башладылар бугай. Алдынгы уракчыларга бушлай күрсәтәләр иде.

– Фатыйха апа, син – безнең стахановчы. Җитмешкә җитеп килсәң дә, басуга эшкә чыгасың. Батыр уллар үстердең. Алар илне фашистлардан саклап, каннарын коялар. Синең урын түрдә булырга тиеш, – дип, аны гел беренче рәткә кертеп утырталар иде.

Сугыш чыккач, Мамадыштан бронь биреп кайтардылар Мөгътәсимгә. Башта үзе әйтмәгән иде, энеләре фронтта башларын сала, хәбәрсез югала башлагач, хәрби комиссариатка бер-бер артлы барган. Өч тапкыр борганнар. Дүртенчесендә повестка биргәннәр. Яу кырында ул да һәлак булды.

Көннәрдән бер көнне Фатыйхаларга бер төркем таныш түгел хатын-кыз килеп керде. Култык асларына кәгазь папка кыстырганнар. Йөзләре бик җитди. Ишегалдында ят кешеләр күреп, өйдән чыгып җиткән Фатыйхага бер кәлимә сүз әйтмичә, ишегалдын, бәрәңге бакчасы ягын, лапасны карап йөриләр.

– Син, апа, сыер да тотасың мәллә? – ди берсе.

– Әйе, кызым, үзем исән чакта сыерны бетермим. Авыз гел майда булмаса да, сыер тоткан кеше ачтан үлми ул, – диде, бер дә аптырап тормыйча.

– Аңа печән әзерләргә кирәктер бит. Бер үзеңә авыр түгелме?

– Үз йөгенең кемгә авыр булганы бар, балам.

– Туганнарың булышамы соң? Печән, утын әзерләргә ярдәм итәләрме диюем? – дип сүзгә кушылды арадан бик җитди күренгәне.

– Малайларым сугышта. Оныкларым бар минем. Ибраһимымның малае белән кызы гел килеп, хәлемне белеп торалар. Бөтен эшләремне алар эшләшә. Янымда иптәшкә Мөгътәсимнең балалары бар...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады. Хатыннарның өченчесе – озын буйлысы:

– Без шул балалар хакына килгән идек тә инде. Әниләре сугышка кадәр үк вафат булган икән. Әтиләре дә илебез иминлеге өчен һәлак булган. Хөкүмәтебез андый кешеләрнең балаларын ташламый. Казаннан ул ятимнәрне балалар йортына урнаштыру турында хат килде. Без аларны үзебез белән алып китәбез, апа, – диде.

Фатыйха коелып иңде. Яннарында бер юаныч булып йөриләр иде әле.

– Юк, җибәрмим. Тугыз бала үстергәнне аларны гына аякка бастырырмын, – диде ул, кыюлыгын җыеп.

– Без бит, апа, сезгә начарлык эшләргә килмәдек. Ярдәм итәргә телибез. Солдат балаларына хөкүмәтебез булышып тора. Хат язышырсыз. Үскәч, кунакка кайтып җитәрләр, – дип дәвам итте иң беренче булып сүз башлаган мөлаем йөзле, кара чәчлесе.

Хатыннар берсен-берсе уздырып, аны үгетләргә керештеләр. Фатыйха да аларның сүзләрендә хаклык барлыгын аңлый иде. Ул ике кыз баланы кеше арасында ким-хур булмаслык итеп киендерергә, ашатырга, тәрбия кылырга да кирәк бит. Яше җитмешкә җитеп килгән карчыкка җиңел түгел бу.

Ахырдан барыбер Мәрьямбикә һәм Рәхиләне балалар йортына алып китүләренә күнде. Җибәрәсе килмәгән иде дә бит, ни хәл итәсең. Мамадыштан килгән хатыннар хаклы: «Анда тамаклары тук, өсләре бөтен булачак». Шул китүләреннән бер хәбәрләре дә юк әле. Хат язарсыз дип, адресларын кесәләренә язып тыккан иде. Балалар йортында киемнәрен алыштырганда, үзләре белән ала белмәгәннәрдер инде сабыйлар.

Фатыйха күңеленнән улларын, оныкларын барлап, аларны күз алдына китереп кайта иде.

– Беренче булып, сугышка кайсыгыз китте соң әле, балалар?.. Очучы булып хезмәт иткән Мисбахетдин ут эченә беренче кергәндер. Шулайдыр әле ул!

Әбисе очучы улының исемен әйткәч, Мәрзия дә һавага карап алды.

Араларыннан иң зиһенлесе һәм башлысы шул баласы – Мисбахетдине булгандыр. Авылларындагы мәктәптә бик яхшы укыды. Укытучылары:

– Бу балага урта мәктәп бетерергә, институтка керергә кирәк, – диләр иде.

Кемнәр Казанга алып барып йөрсен соң аны. Колхозда эшли башлагач, яшьләр комсомол секретаре итеп сайлап куйдылар. Авыл советына сәркатип итеп алдылар. Яшьләрне үз янына туплап, концертлар, спектакльләр куеп йөрде. Басуларда алдынгы уракчыларны мактап җырлыйлар иде. Габделбарый, Мәгъсүмҗан, Мөхлисулла абыйларын, Сәлимә сеңлесен дә үзе белән ияртеп йөрде. Кеше белән сөйләшергә оста булды. Җитди, үткен карашлы, ачык йөзле, нәзек борынлы, калын иренле иде. Андыйларны кызлар яраталар. Мисбахетдиннең дә дуслашып йөргән, яшереп кенә, хатлар язган кызы бар иде. Гаилә корып өлгермәде шул бала.

Газеталарда очучылар турында яза башлагач, ул да укырга китәргә ашкынды.

– Авылыбыз өстеннән аэроплан белән очып әйләнәсем килә, – ди торган иде.

Мамадышка Водопьянов исемле очучы төшкәч, аның белән очрашуга да барып кайтты. Кәнсәләргә кичтән шалтыраткан булганнар. Төне буе күзенә йокы кермәгән иде баланың. Таң әтәчләре аваз салуга торып чыгып китте. Авыл Советының атын җигеп, бер төркем яшьләр җыелып барганнар. Митингтан соң янына барып сөйләшергә дә курыкмаган. Шул вакытта Мисбахетдингә:

– Очучылыкка укырга кирәк сиңа, егет. Бик кыю күренәсең. Яхшы очучы чыгачак синнән, – дигән.

Бала да, ныклы карарга килеп:

– Очучылыкка укырга китәм, – диде.

Анда да бик яхшы укыды. «Командирлардан рәхмәт алдым. Ялга шәһәргә чыгаралар», – дигән хатлары килеп торды. Сугыш алдыннан: «Бомба ташлый торган очкычта хезмәт итәм», – дип язды. Кайсы шәһәрдә укыганнары, кайда хезмәт итә башлаганнары гына исендә түгел. Ул шәһәрләр шул кадәр күп, үз гомерендә Мамадыш каласыннан да ерак китмәгән карчык кешенең хәтерендә калырлык түгел шул. Авыл өстеннән самолёт очып узганда:

– Әнә, Мисбахетдин абыегыз китте, – дип карап кала торган иде.

Балалар сөенешәләр. Мисбахетдиннең бөтен самолётта да очмаганын

үзе дә белә. Әмма аның исемен әйтү барыбер күңеленә рәхәт. Йөрәгенә горурлык тула.

Сугыш башлангач та, ут эченә беренчеләр булып алар кергәндер. «Дошманны бомбага тотарга очабыз. Бик каты сугышлар бара. Күп кеше кырыла... Бу сугыштан исән кайтсак, бер могҗиза булыр...» – дигән хатлары килә торган иде. Кырык икенче елның февралендә, аның исән кайтуына өметләрен чәлпәрәмә китереп, командирларыннан кара мөһерле хат килде. Андый конвертлы хатлар килә башлаган иде инде авылга. Исәннәрдән килгәннәре өчпочмаклы була.

«Каһарман егет үстергән хөрмәтле ана, Фатыйха Әхмәдиева! Улыгыз, офицер Фәттахов Мисбах безнең батыр очучыбыз, Сталин лачыны иде. Дошманның техникасын һәм тере көчләрен юк итү өчен каһарманнарча сугышты. Ул идарә иткән самолёт фашист илбасарларның күп эшелоннары тупланган тимер юл станцияләрен бомбага тотты. Улыгыз үзен чын батыр итеп күрсәтте. Ул бөтен иптәшләренә үрнәк күрсәтә иде. Чираттагы сугышчан заданиене үтәгәндә, самолётына дошман снаряды тиеп яна башлады. Чын каһарман Фәттахов Мисбах очкычын фашистларның техникасы өстенә юнәлтте һәм батырларча һәлак булды. Улыгыз командованиебез тарафыннан хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителде», – дип язганнар иде анда. Бүген дә матчага кыстырган җирендә торадыр әле ул хат.

– Каберләрең юктыр инде, Мисбахетдин улым... Самолётың белән шартлап өзгәләнгән, күмергә әйләнгән гәүдәңне кемнәр җыеп, җирләп йөрсен соң!..

– Дошманны җиңәрбез дә, бик тиз әйләнеп кайтырбыз! – дип киткәннәр иде Урта Кирмәннең ирләре дә. Дүрт елга сузылды бу яу. Әле һаман илнең тынычлык күргәне юк.

Сугыш чыккан көн һаман күз алдында тора әле.

**4**

Ял көне иде. Иртәдән көн аяз булды. Күк йөзендә бер каурый болытсыз атты таң. Басуда арыш серкә очырган көннәрдә генә була торган җылы рәхәтлек тутырган тирә-юньне. Һавадагы җылылык тәнгә сеңеп, буыннарга тарала. Кояш ныграк күтәрелгән саен, болытлары да күренә башлады. Көн акрын гына сүрәнләнеп китте. Өйлә вакыты җитә иде инде, Фатыйха кече казан астына ягып, өйдә уллары әбәткә кайтуына аш әзерләп йөри. Бер заман урамда чыр-чу килеп, бала-чага йөгерешкәне колагына чалынды. Матур, рәхәт вакытлар. Җәй чилләсендәге кояш ел буена җитәрлек сихәт бирә тәнгә. Аларның Арт урамнары тулы бала-чага. Капка саен биш-алты чыкса да, байтакка җыела шул. Сигезәр-тугызар бала үстергәннәре дә бар. Бер чирек күтәрелергә өлгергән яшел чирәм өстендә рәхәтләнеп йөгерешәләр, тәгәрәшәләрдер. Оныгы Мәрзия дә еш килеп җитә аларның урамнарындагы кызлар белән уйнарга.

Чү! Кайсыларыдыр елаша да түгелме?! Аларның шыңшымаган чаклары аз инде дип, бәрәңге әрчергә керешкән иде, кызыксынуы җиңде, Мәрьямбикә белән Рәхилә түгелме икән дип, урамга чыгып карап керергә булды. Өйалды ишегеннән чыгуга:

– Су-уг-ы-ыш... башла-а-нг-а-ан!!! – дип кычкырганнары колагына килеп керде.

Кулында калай тәлинкә иде. Шалтырап баскычка төшеп китте. Бөтен тәне эсселе-суыклы булды. Сугыш – бәйрәм табыны түгел, корбаннарсыз тынмый. Гражданнар сугышында аларның да олы уллары Исмәгыйль дә шәһит китте. Олы гәүдәле, тимердәй беләкле егет иде югыйсә. Соңгы елларда тагын сугышлар чыгып кына тора. Ике ел элек Амур буенда японнар илгә ябырылып карадылар. Фин сугышы башланды. Анысына Урта Кирмәннән дә берничә егетне алып җибәргәннәр иде. Кайберләре сугыш төгәлләнүгә әйләнеп кайтты. Кызыл Армиядә хезмәт итәргә калганнары да булды. Монысы тагын кемнәр белән икән инде, Ходаем?!

Урамга йөгереп чыкты. Бер кызны туктатып:

– Кайдан ишеттегез? Кем әйтте сугыш чыкканын? – дип сорады.

– Кәнсәләр янында... радиодан... Ярман сугыш башлаганын сөйләделәр... Бөтен кеше җыелып тыңлап торды, – диде ул, сулышы кабып.

Йөрәге өзелеп төшкәндәй булды Фатыйханың. Ундүртенче елны да:

– Ярман белән сугыш тиз генә бетә торган булмый, – дигәннәр иде ирләр, сүзләре рас килде. Бөтен Рәсәе буталып бетте. Пайтәхеттә патшаны төшерделәр. Кабат илгә байгуралар ябырылды. Унтугызынчы елның язында егерме чакрымдагы Мамадышта кызыллар белән акларның туптан атышуы дөңгердәп, Урта Кирмәнгә кадәр ишетелеп торды.

Дүрт елга сузылачак бу соңгы сугышта Газраилнең бөтен балаларын чүпләп бетерәсен алдан сизенгән булган икән. Ул вакытта сугышларны узып кайтучылар да монысының болай озакка барасын һәм бик күп корбаннар аласын уйларына да кертеп карамаганнардыр.

Төштән соң Мамадыштан митинг уздырырга килеп җиткән уполномуч ир дә:

– Кызыл Армиябез дошманның умырткасын тиз сындырыр. Ирләрегез күкрәк тулы орден-медальләр белән кайтырлар , – диган иде.

Күршедәге Кирмән башы авылы тумасы, армиягә алынганчы «Пятилетка» совхозында комсомол секретаре булып эшләгән, фин сугышында Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булган Гафият Нигъмәтуллинны искә алдылар.

– Әнә бит, нинди яшь кенә кеше. Ә сугыштан Алтын Йолдыз белән Ленин ордены тагып кайтты! Бүген Мәскәүдә укый. Безнең егетләр дә аларны алырлык, – дип сөйләделәр.

Гафият исемле ул каһарманны хәтерли Фатыйха. Күкрәгенә Алтын Йолдызын тагып, Урта Кирмәнгә дә килгән иде. Күзләре елмаеп торучы, түгәрәк ачык йөзле, уртача буйлы, киң җилкәле. Телгә кеше кесәсенә керә торганнардан түгел. Үзләренең ничек сугышканнарын, финнарны тукмауларын мавыктыргыч итеп сөйләде.

Митингта аның Ибраһим улына да:

– Син – гражданнар сугышы герое. Яшьләргә үз сүзеңне, киңәшләреңне әйт. Әти-әниләре, авылдашлары йөзенә тап төшермәсеннәр. Каты сугышсыннар, – дип, сүз биргәннәр иде.

Куркып, оялып тормады.

– Сугышта туган җир азатлыгы өчен башыңны салу – изге эш.

Крестьяннар һәм эшчеләр дәүләте өчен абыем Исмәгыйль шәһит китте. Мин дә канымны койдым – яраланып, госпитальдә дәваланып чыктым. Дошманнарны илебездән сebереп түктек. Җиребезне илбасарлар итекләре таптарга тиеш түгел. Илебезне саклаучылар сафына мин дә басам, – дип өздереп әйткән иде.

Авылларыннан беренче булып, сугышка китүчеләр кемнәр иде соң әле? Ибраһим Искәндәре, Дәүләтша Хөсәене, Гыйниятулла Һадиулласы, Вәли Мәүләвие, Имаметдин Хисаметдине, Зарыйф Салихы... Барысын да күз алдыннан уздырды ул аларның. Асыл кешеләр иде. Кайсы өйләнгән, балалар үстерәләр; кайсы – өлгереп җиткән егет иде. Кемнәр уйлаган берсе дә кире әйләнеп кайтмас дип? Аларның да кайсының һәлак булуы, кайсының хәбәрсез югалуы турындагы хәбәрләре генә килде. Кайгыларын йөрәкләренә төйнәгән аналарының, хатыннарының, нарасыйларының бүген дә аларның исән булмауларына ышанып бетәселәре килми әле. Ялгыш кына хәбәр булгандыр дип, могҗиза көтәләр.

Баштарак сугышка китүчеләрне күмәкләшеп – туган-тумача, күрше-күлән, бөтен урам җыелышып озаттылар. Мәгъсүмҗаны – алтынчы улы кырык бернең июлендә киткән иде. Нәкъ шулай! Авыл Советында йомышка йөрүче кыз повестканы эшли торган җиренә илтеп биргән. Анда Мәгъсүмҗан Фәттаховның Мамадыш хәрби комиссариатына иртәгә иртәнге 6 да килеп җитәргә тиешлеге язылган иде. Кайтып җитте бала. Мунча ягып керттеләр. Өч көнгә җитәрлек юллык ризык әзерләделәр. Туган-тумачалар бер-бер артлы килеп җиттеләр. Бригадир хатын:

– Колхоз председателе Мәгъсүм абыйны комиссариатка кадәр озату өчен ат бирде, – дип килеп әйтте.

– Алдынгы колхозчыбызга безнең рәхмәтебез бик зур, дошманны тизрәк җиңеп кайтсын, – дигән.

Ул хатынның кем булуын хәтерләми инде хәзер. Ирләрне сугышка ала башлагач эшләп торган иде.

Авыл җәй көне иртә уяна. Алар өе ул көнне таң сызылуга ук торып утырды. Ат белән барасы булса да, Мамадыш белән Урта Кирмән арасы егерме чакрымга тула. Иртәнге 6 да килеп җитәргә боерганнар икән, соңга калырга ярамый. Сәгать өч тулганчы ук юлга кузгалдылар.

Мәгъсүмҗан, ат арбасының арт ягына утырган килеш, авыл каршындагы Кала Тауны менеп, күздән күмелгәнче кулын болгап барды. Тавы да озын һәм биек бит. Өстенә менеп җиткәч, беразга гына туктап тордылар. Бөтен кеше белән соңгы тапкыр саубуллашуы булган икән. Газиз туган туфрагына башка әйләнеп кайтмасын йөрәге сизгән булгандыр.

Аннан хатлар сирәк булса да килгәләп тордылар. Соңгысын былтыр мартта язды. Башка хәбәр алмадылар. Май аенда хәбәрсез югалуы турында командирлары гына кара пичәтле хат салды.

– Мәгъсүмҗан балам, син кайларда ятасың икән?

Дүртенче улы Мөхлисуллага Мамадыштан бронь биреп кайтарганнар иде. Әнисенә, туганнарына әйтмичә, берничә тапкыр үзен фронтка җибәрүләрен сорап барган.

– Һәлак булган туганнарым өчен үч аласым килә, – дигән.

Кырык өченең апрель башында армиягә чакырдылар. Казаннан Яшел

Үзәндәге кораблар ясый торган хәрби заводка алып киткәннәр. «Анда Түбән Соннан Шәрифуллин Гаян, Ушмыдан Ногоманов Харис, Иске Заводтан Гыймазов Низам, Көектән Фәршатов Сафа исемле кешеләр белән бергә җибәрделәр», – дигән хаты килгән иде. Сафа Мәскәү янындагы сугышларда катнашып, яраланып кайткан булган. Яралары төзәлә башлагач, яңадан фронтка китәргә сораган. «Син хезмәт армиясенә дә кирәк», – дип, хәрби заводта калдырганнар. «Сафа төнлә сугышта күргәннәрен сөйләп чыга. Анда исән калу үзе могҗиза икән», – дип язган иде бер хатында. Ул бала да суга төшкәндәй юк булды.

– Исемеңне синә атаң тапкан иде. Мөхлис – ихлас күңелле, чын, тугрылыклы дус дигәнне аңлата, Мөхлисулла кушабыз, дигән иде. Каберләрең бар микән соң, балам?! Су төпләрендә ятасың микән?!

Иллегә җитеп килсә дә, олыгайган инде, дип тормадылар, Ибраһимын да фронтка алдылар. Атасына охшап, киң маңгайлы, калын кара кашлы, калын иренле, какча йөзле, җитди карашлы иде ул, калын кара мыек та йөртте.

– Ибраһим улым, синең каберең дә юктыр инде? И бала-а-ам...

Бер Комазан кешесе урман эшчеләре әбәткә туктаган җирдә Ибраһимның лесник булып эшләүче малае Гаптенур белән очрашкач, текәлеп карап торган да:

– Кайсы авылныкы син? – дип сораган.

– Урта Кирмәннеке, – дигән Гаптенур.

– Кем малае? – дип төпченә башлаган теге ир.

– Фаттах Ибраһимыныкы, – дигән.

– Ала-ай икә-ән... Башта ук Ибраһим малае түгел микән, дип уйлаган идем. Әтиеңә бик охшагансың. Йөз кыяфәтләрең коеп куйган Ибраһим инде. Әтиеңне яхшы беләм мин синең. Кырык бердә Мәскәү янындагы сугышларда бергә булдык. Бик кыю солдат иде. Әллә ничә фрицны юк итте. Граната атып, дошман танкларын да сафтан чыгарганы булды. «Сугыш тынган чагында окоптан башыгызны чыгарып карап тормагыз, немецларның снайперлары күп. Башыгызны күтәргәнегезне карап кына торалар», – ди торган иде яшьләргә. Аның киңәшләрен тотарга тырыштык. Ноябрь аенда кар бик иртә ятты. Немецлар Мәскәүне алу өчен гайрәт каты сугыштылар. Бер атакаларын кире кайтарабыз, икенче кат яңадан күтәреләләр. Алардан да, бездән дә кеше галәмәт кырылды. Һәлак булган егетләрне санитарлар җирләргә алып китеп өлгерә алмыйлар иде. Нык каршы тордык. Чигенмәдек. Каты салкыннар башлангач, сугышлар сүлпәнләнде. Фрицларның киемнәре юка икән. Кырык градуслы зәмһәрир салкында землянкаларыннан чыгасылары килми. Бер төнне Ибраһим абый рота командирына үзен дошман ягына разведкага җибәрүләрен сорады. Безгә әйтмәгән иде, уйларын командирларга гына сөйләгән икән. Берничә егетне немецлар тылына җибәрделәр болар. Берзаман дошман окоплары ягында көчле шартлаулар, ату тавышлары ишетелә башлады. Озак та тормыйча, үзләре дә кайтып җиттеләр. Барысы да исән иде. Шуышып барганнар да, башта салкыннан бөрешкән исерек сакчыларын юк иткәннәр. Аннан төтен чыга торган торбаларыннан гына землянкалары эченә гранаталар ташлаганнар. Шулай итеп, биш землянкаларын шартлатканнар. Моны

Ибраһим абый уйлап тапкан булган икән. Планнары барып чыккач, рота командиры полкка җиткергән. Ә полк комиссары башка командирларга да фашист илбасарларын шулай юк итәргә боерган. Иртәгесен һөҗүмгә күчтек, – дип сөйләгән Комазан ире.

Яраланып, госпитальләрдә яткан икән. Дәваланып бетү өчен авылына кайтарып җибәргәннәр.

– Атакага барганда, Ибраһим абыйның аяк астында мина шартлады. Гәүдәсен өзгәләп, чөеп атты. Өстән аяклары гына килеп төште, – дигән җан өшеткеч хәбәр дә җиткергән. Оныгы бу сүзләрне башта аңа әйтмәде. Мәрзиягә генә сөйләгән. Әтиләренең үлеме турындагы хәбәрне бик озак яшереп йөргәннәр. Хәрби комиссариаттан хат килмәсә, әле исәндер дип, өметләнеп йөргән булыр иде. Инде беренче улын гына югалтуы булмаса да, һәр үлем хәбәре кешене миңгерәүләтә. Бөтен җанны ашый, таштай баса. Үлемгә күнегеп булмый икән!..

Ул Комазан кешесе Урта Кирмәнгә дә килеп киткән иде. Капкадан солдат киемендәге кеше килеп кергәч, әллә үзенең берәр улы кайтканмы, дип сөенеп тә куйган иде. Ә ул бөтенләй күз күрмәгән кеше булып чыкты. Башта Ибраһимның гаиләсенә сугылган. Үзенең кем булуын, сугышта Ибраһим белән булуын сөйләгән. Аннан:

– Әнисен күрмичә китмим, – дип, аңа килгән.

Үз улы кебек кунак иткән иде аны Фатыйха. Ни генә әйтсәң дә, Ибраһим улы белән ут эчендә бергә булган кеше бит. Ничек сугышуларын, дошман солдатларын юк итүләрен, танкларын яндыруларын, Мәскәү янына кадәр чигенүләрен, үзенең яралануын, госпитальдә ятып чыгуын озаклап сөйләп утырган иде. Төн кунып китте. Ибраһимның һәлак булуы турында гына гаиләсендә булганда да, аңа килгәч тә, бер сүз дә әйтмәгән иде. Өметләре киселмәсен, дигәндер. Урман эшчеләре янында улын очраткач кына чишелгән.

Сәлимә авырып, түшәктә ятканда, Ибраһимының Мәрзия белән хәлен белергә менүе, озаклап сеңлесенең чәчләрен тарап утыруы исенә төште. Бик дус яшәделәр балалары. Бер-берсенең кадерен белә торганнар иде. Туган җанлыклы булдылар. Әтиләре дә гел: «Бер-берегезгә иңнәрегезне куеп яшәгез», – дип әйтеп кенә торды.

– Габделбарый улым, син дә әйләнеп кайта алмадың туган нигезеңә! Синнән бер хәбәр дә юк, балам!..

Ана улларын берәм-берәм искә төшереп, акрын гына атлады да атлады. Аларның исемнәрен кабатлады. Көннең кичкә авыша баруына да, оныгы Мәрзиянең ашыктырырга теләвенә дә игътибар итмәде ул. Тукталып, өрәңге таягына таянган килеш ял иткәләп тә алды. Җиргә утырсам, тиз генә торып китә алмам, дип уйлагандыр инде. Кулларына бер учлам кыр чәчәкләре җыеп алды. Соңгы улының пилоткасы белән аларны күкрәгенә кысып кайтты.

Нәзек иреннәре акрын гына:

–...Улларымның берсен булса да күрермен, дип өметләнгән идем... Кайтмадылар инде... Кайтмаслардыр... Чәчләре вакытсыз агарган аналарның, толларның, ятим калган балаларның ләгънәте төшсен бу сугышны башлаучыларга... – дип пышылдыйлар иде.

Өенә кайтып җитүгә хәлсезләнеп, тупса алдына утырды ул. Мәрзия оныгы аны күтәреп караган иде дә, булдыра алмады. Көне буена утыз чакрымнан артык юл узган, болай да рәтле-башлы ашау эләкмәгән үсмер кызның ничек хәле җитсен соң әбисен күтәреп өйгә кертеп салырга? Җыйнак гәүдәле булса да, олы кешенең сөякләре дә авыр була. Тартып та караган иде, кая ул! Күршеләренә йөгереп кереп китте. Ярый әле, ул игелекле җаннар кереп булыштылар.

Башка инде Фатыйха аягына баса алмады.

Яхшырак тәрбия кылсак, рәтләнеп китмәсме дип, күршеләрендәге Хәбибулла белән Хәлимә үзләренә күчереп караганнар иде дә, соңгы өметләре өзелгәннән соң яшәү ялкыны сүнгән иде шул инде.

Шул ук елның декабрь башында оныкларына, миһербанлы күршеләренә, авылдашларына хәер-фатыйхасын биреп, ана мәңгелеккә күзләрен йомды.

## Эпилог

Еллар узды. Мамадышның үзәгендәге Батырлар аллеясында яу кырында сигез улын югалткан Фатыйха Әхмәдиевага һәйкәл куелды. Нәкъ Чытыр авылыннан кайткан көндәге кебек – ак күлмәгеннән, күкрәгенә соңгы улы Әгъмәлетдиненең пилоткасын һәм кыр чәчәкләрен кыскан килеш гәүдәләндерелгән ул анда. Ә күзләре ул ятып калган көнчыгышка төбәлгәннәр. Әйтерсең, Ана соңгы өметенең дә челпәрәмә килүенә һаман ышанып җитми әле. Иреннәре:

– Юктыр, бу – дөрес хәбәр булмагандыр. Улым менә-менә кайтып керер. Берсе генә булса да исән калырга тиеш иде бит инде. Ана өчен бер балаңны югалту да иң авыр кайгы. Улларымны алган сугышны башлаучыларга барыбызның да ләгънәте төшсен, – дип пышылдый кебек.

Бу Олы Йөрәкле Ана һәйкәле яныннан узганда, һәркем тукталып уйга кала, йөзенә төбәлә. Күзләрендәге сагышны Мамадышны каймалап узучы Нократ суына салсаң, ул да кибеп бетәр кебек.

Һәйкәл эргәсеннән ел буе чәчәкләр өзелми. Аларны шәһәр кунаклары да, яңа өйләнешүчеләр дә калдырып китә.

Фәттаховлар нәселе өзелмәде. Бүген нәселне Ибраһим белән Мөгътәсимнең балалары, оныклары һәм оныкчыклары дәвам итә. Ә Ибраһим алып кайткан Коръән бүген дә исән әле. Ул нәсел ядкаре булып Мәрзия апада саклана.

Фатыйха Әхмәдиеваның оныгы Мәрзия апаның сигез оныгы илебез алдындагы гражданлык бурычларын үтәп – армиядә хезмәт итеп кайттылар инде.



Шәмсия
Җиһангирова

# ҮЗ БАЛАҢА МИРАС ИТЕП КАЛДЫР ТЕЛЕҢ...

## Нәсыйхәт

Без бу җиргә татар булып яралганбыз,
Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз...
Нинди кыйтга, ни илләрдә яшәсәк тә,
Телне саклап, милләт булып калалганбыз.

Хурланганбыз, таланганбыз әллә ничә...
Һәр тарафтан усал тарих җиле исә...
Аллаһ шаһит: аягүрә һаман татар,
Тик иелгән башны гына кылыч кисә.

Бердәм булсак, усал җилләр безгә тимәс,
Кемдер килеп, милләтеңне сакла, димәс.
Анаң карынында сиңа иңгән тел ул –
И татарым, үз телеңне сөеп сөйләш.

Кемдер мәҗлес-җыелышларда сүзен таба,
«Бетәбез!» дип, мөнбәрләрдән сөрән сала.
Җыелыш беткәч, башка телдә «сайрый» башлый,
Шулмы инде милләтпәрвәр, уйлап кара?!

И, мактана, минем диеп, улым-кызым
Алты-җиде башка милләт телен белә...
Акылың булса, сорау бир үзеңә көн дә –
Сөйләшәме алар бүген туган телдә?!

Һәр бирмеш көн шөкер димен мин үземә:
Балаларым, оныкларым телне белә,
Ата-баба васыятенә тугры алар... –
Ләкин никтер тыныч түгел күңел генә.

---

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА (1951) – *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты; «Төсле моң», «Якты сагыш», «Илаһият» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Көн-төн эшләп, мал җыябыз, акча, дибез,
Яхшы булыр балаларга калса, дибез.
Иң зур байлык ана теле – аңламыйбыз, –
Хайван белән бер үк акыл-сандамы без?!

Бездән соңра яшьләр шуны аңларлармы,
Борынгыдан мирас телне санларлармы?!
Үз телендә сөйләшкәннән «каһ-каһ» көлеп,
Маңкортлыкны дөрес юл дип сайларлармы?!

Ни-нәрсә ул иң бәһасез байлык бүген?
Акыл белән уйлаганың бармы синең?!
Мәгънә булсын дисәң җирдә яшәвеңнән –
Үз балаңа мирас итеп калдыр телең!

## Мин борылып китәм Мөслимнән...

...Аңламаслар мине! Аңлар бары
Үзе бу хәлләрне кичергән.
Ничә тапкыр, Баегыма керми,
Мин борылып киттем Мөслимнән.

Элек булса, әнкәм исән чакта!
Шундый гамәл эшләр идемме?
Баегыма кайтып тормый гына,
Кире борылып китәр идемме?!

Туган нигез дә бар, йорт та исән,
Каралты-куралар, абзары...
Бәрәңге бакчасы, су буйлары...
Газиз әнкәм генә юк бары...

Намазлыгы, тәсбихы, Коръәне… –
Әнкәмне юксына һәммәсе...
Тик бер генә тапкыр урамнарда
Чалынып китсә иде гәүдәсе...

Их! Исән булсамы? Җиде төндә
Юллар сабып кайтыр идем лә...
Һава ярып килгәнемнән тоеп,
Йөгереп чыгар иде үзе дә...

Сарылыр иде килеп иңнәремә,
«Бәбекәем, кайттыңмы?! – дип. –
Синең өчен генә сакладым...» – дип,
Куяр иде тәм-томын өеп...

Ул бит фанидагы бар гомерен
Балаларым диеп яшәде.
Күпме ялварсам да, кайтмас әнкәм,
Зиратларда ята – җәсәде.

...Кичерегез мине, авылдашлар!
Җаным бизмәсә дә һич сездән –
Бүген тагын Баегыма керми,
Мин борылып китәм Мөслимнән...

## Гамәл китабы

Әнкәм намазлыкта. Һәр бирмеш көн
Калдырмыйча укый намазларын.
Мин бик сабый әле. Аңламыйм да
Кылган гамәлләрен, догаларын.

Аңлашылмаса да чит-ят сүзләр,
Әнкәм намазлыкка иелүгә,
Сөйләшергә ярамавын аңлап,
Беркем белән керешми һич сүзгә,

Тын утырам бер почмакка посып.
Кайчак йокыга да оеп китәм.
Ә әнкәем, бөтен эшен ташлап,
Намаз укымакта кичен-иртән...

Намаз тәмам. Әнкәм намазлыктан
Күтәрелеп миңа башын бора...
«Сөбханаллаһ! Тәүфыйк, сабыр биргән,
Бәхетне дә өеп бирсен сиңа...»

Ни ул тәүфыйк, ни-нәрсә ул сабыр? –
Барып җитми бала акылыма.
Тик сизенәм: әнкәм илереп-илереп,
Бары яхшы теләк тели миңа:

«Фани дөньяларда ни кыласын
Язып куйган Гамәл китабына...
Бәрәкәтле, сөю-сәгадәтле
Гомеркәйләр насыйп итсен сиңа...»

Бар гамәлем: әнкәм өйрәткәнчә,
Һаман: «Амин! Амин!» – диеп торам.
Әлхәмделиллаһи, әнкәемнең
Бөтен теләкләре кабул булган.

Инде мин дә олыгаеп барам...
Газиз әнкәм күптән бакыйлыкта...
Бала чагым искә төшкән саен
Әнкәемне күрәм намазлыкта...

* * *

Баш очымнан кошлар күтәрелде...
Тоям, безнең якка очтылар...
Әнкәемә сәламнәрем әйткәч,
«Үзең тизрәк кайт!..» дип куштылар.

Кошлар: «Кызың сәлам әйтте...» – диеп,
Әллә кайчан хәбәр салгандыр.
Тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп,
Көтә-көтә күзе талгандыр...

Тукта! Ни сөйлим мин?! Саташаммы?!
Әнкәм юк бит инде... Ул китте...
Кайталмаган чакта, кошлар аша
Сәлам әйтер кешем дә бетте.

Ә нигә соң очар кошлар мине
Алдадылар: «Әнкәң көтә... – дип, –
Тынгы таба алмый җаннарына,
Сагына сине кич вә иртә...» – дип.

...Рәнҗемәгез миңа, очар кошлар,
Сез, чыннан да, хаклы булгансыз. –
Сәламемне әнкәм ишетсен дип,
Зират коймасына кунгансыз...

## Кыйбла һаман шунда

Үзем булып яшәү әйбәт тә бит!
Яңа заман үзгәрүне сорый.
Монда нәселдәнлек гаепледер... –
Юк! Булмагач, булмый инде, булмый!

«Җитте, диләр, йөрмә туры сөйләп,
Бераз гына як-ягыңа кара...»
Күпме карасаң да, файдасы юк!
Бары уфтанырга гына кала.

«Үзгәр!» диеп әйтеп тә тормагыз! –
Дөрес яшәмәвем яхшы беләм.

Сүзегез хак! Үзгәрергә кирәк! –
Яңа тормыш башлыйм дүшәмбедән.

Мин гел шулай, һәр якшәмбе саен,
«Дүшәмбедән» диеп, тынычланам.
Ә дүшәмбе көнне... уянам да...
Элеккечә үзем булып калам.

Һәр көнемдә, карап кыйбла якка,
Бетмәс шөкер итәм бер Аллага. –
Таулар күчә, илләр юкка чыга...
Кыйбла һаман үз урынында кала.

## Кошлар очкан биеклектән кара

Менә тагын быел, менә тагын
Җылы якка кошлар китеп бара...
«Кыйгак... кыйгак...» Канат җилләреннән
Күз яшьләре гүя тамып кала...

Нинди сагыш соң бу?! Нинди сыктау?!
Бар җанымны кинәт чорнап ала...
Аңлар өчен минем халәтемне
Кошлар очкан биеклектән кара.

Кошлар очкан биеклектән кара –
Хисләр үзгә анда, акыл башка.
Безгә андый халәт бирмәгән дип,
Күккә карап, җирдә чалкан ятма.

Хыялыңда күтәрелеп кара
Кошлар гына очкан биеклеккә...
Аягыңда басып торып кына
Бу җиһанны аңламассың һич тә.

Очар өчен канат бирмәсә дә,
Ходай безгә сагыш, хыял биргән...
Хыял канатыңда күтәрел дә
Тик беразга аерыл син җирдән.

Шул чагында, бәлкем, аңларсың син
Канат җилениләр сөйләгәнен...
Кошлар очкан биеклектән генә
Күреп була җанның көйрәгәнен.

Зәңгәр күккә күтәрелеп кара –
(Булдыралмый моны күпләр, беләм!)
Аңларсыңдыр шул чак минем җанның
Тоташканын җиде күкләр белән...



Зәбир
Гыймаев

# КӨРӘШЧЕ

ХИКӘЯ

**1**

– Синең сүзне көтәбез, Данияр!

Нигә икеләнеп калды соң әле ул? «Юк, егетләр, мин риза түгел» дияргә дә торып китәргә! Беркем гаеп итмәячәк.

Данияр башын күтәрде. Тау башыннан тирә-як уч төбендәге кебек күренә. Әнә Якты Күл авылы. Тау итәгенә сыенып утырган ике урамлы гап-гади бер авыл. Халкы эшкә уңган, җыр-моңга һәвәс...

Таллы Бүләк инешенең бу як ярында аның туган авылы Акташ. Тирә-юньгә нур чәчеп утыруын күр! Көрәшчеләре белән данлыклы авыл!

Ике авыл. Бер күмәк хуҗалык. Сабан туен бергә бәйрәм итәләр.

Гомер бакый яктыкүллеләр сәхнә тоткан, акташлар – мәйдан. Тәртип булган.

Тәртипне Якты Күлдән Кара Чутыр Хөснул малае Кәрим бозды. Кай арада үсеп җиткән дә, бил нығытып, кулына сөлге алган диген!..

Ике ел рәттән Чутыр Хөснул (Карасы каядыр төшеп калган) малае Сабан туенда батыр калды. Акташ егетләрен чистага салып! Менә шулай... Картлар алдында оят. «Хәзерге яшьләрнең буыннары сыек, име, кордаш? Менә без яшь чагында!..» – дип, сүз сөйләргә генә торалар. Авызлары килешкән.

Болай каршылыклы уйлар өермәсендә калмас та иде... Зарима бар бит. Зарима... Акташ авылы егете Даниярның йөрәген яндырыр өчен генә туган бала икәнсең! Кырык тапкыр яныннан: «Синең якка бүтән борылып та карамам!» – дип китте. Кырык тапкыр борылып килде.

Быел Сабан туе алдыннан кызның күңел кылларын тибрәтеп, үзенең дә ут йотып йөргүен сиздереп кую иде егетнең уе. Кыскасы, алда бик тә җитди, үтә дә әһәмиятле сөйләшү көтә иде.

Кичә Зариманы озатып куйды. Батырлыгын җыеп, сүзен әйтте:

– Зарима!.. Сөйләшәсе иде...

Кыз ялт итеп, егеткә күтәрелеп карады. Шуклык та, мутлык та бар

иде сылукайның күз карашында. Егет йөрәге янып бетсен дә кара күмере калсын дигәндер, кыз шаяртты:

– Мин Сабан туе батырлары белән генә сөйләшәм!

Шапылдап, җилкапка ябылды. Җиңел-җитез адымнар ерагая барып тынды. Ишегалды түрендә егетне мыскыл итеп, көчек чәңгелдәде...

Кыз шаяртты, егет аңламады.

Бүген сөрән җыйганда, Якты Күлдән хәбәр килеп иреште: «Көрәштә акташларны җиңү безнең авылда матур традициягә кереп бара инде ул!» Гарьлегеңнән егылып үләрсең!

Кичкә таба тау башына авылның җиде көрәшче егете җыелды. Көн кадагында бер мәсьәлә: Чутырның җиңүләренә чик куярга вакыт! Кәрим – бик көчле көрәшче. Шуңа күрә хыял диңгезендә йөзмичә, аек фикер йөртү кирәк.

Бәхәсләштеләр. Кайсылары кызып ук китте. Ахырда уртак фикергә килделәр:

– Кәримгә каршы авыл белән чыгабыз. Бу ни дигән сүз? Моны ничек аңларга?!

– Беренче. Көрәштә «син – Якты Күл авылы егете», «син – Акташныкы» дип бүлү юк. Кем кемгә туры килә. Акташ егетләре бер-берсе белән бил алышалар икән, Кәримгә чыгасы көрәшчене бик алҗытмый гына егылырга туры киләчәк. Бу – бик авыр. Бу – мин-минлеккә күсәк белән оруга тиң. «Шуңа да ачыктан-ачык сөйләшергә җыелдык, егетләр. Бер-беребездән тел яшермик», – диде Салават.

– Икенче. Кәрим белән бил алышкан көрәшче мөмкин кадәр көндәшенең хәлен бетерә. Бу гына да аз: Кәримгә каршы барлык алымнар рөхсәт ителә. Барлык алымнар! Моның нәрсә икәнен тәфсилләп аңлату кирәк түгелдер. Якты Күл көрәшчесе финалга барып җитмәсә, бигрәк тә яхшы.

Көн тәртибендә соңгы сорау калды: Кәримгә кемне чыгарабыз?

Салаватны сайладылар. Салават кисәтте:

– Судья Минсәгыйть абзыйның күзе очлы: аны-моны сизсә, мәйданнан куып чыгарырга да күп сорамас. Тамашачылар арасында да көрәшнең бөтен нечкәлекләрен белгән картлар җитәрлек. Кыскасы, уяу булыгыз!

– Данияр, телеңне йоттыңмы әллә?

Ник җебеп төште соң әле ул?! Синең җавабыңны дусларың көтә! Бетмәс монда кыз-кыркын капризы!

– Мин риза, егетләр.

– Әйткән сүз – аткан ук! – диде Салават.

– Вәгъдә – иман, – диештеләр егетләр.

Таралыштылар... Иртәгә Сабан туе! Бүген исә сәер халәт кичерәләр: күңел талпына, очар кош булып, канат кагына, тик очып китә алмый интегә мескенкәй, әйтерсең лә, чылбыр белән кыяга богаулап куйганнар үзен...

**2**

Кем уйлаган?! Алдагысын бер Алла белә, димәсләр иде аны... Өчәү калдылар: Кәрим, Салават, Данияр. Әүвәл Данияр белән Салават көрәшәләр. Җиңүче Кәрим белән бил алышачак. Кәримне җиңсәң – син Сабан туе батыры.

– Йәгез, егетләр! – Минсәгыйть абзый мәйдан уртасына чакырды.

Кемдер ризасыз тавыш белән кычкырды:

– Нигә бер авыл егетләрен көрәштерәсез? Якты Күлдән чыгарыгыз!

– Бер дә юкка тамак ертасың, агай. Жирәбә.

Кулларына сөлге алып, кара-каршы бастылар. Бер мизгелдән соң булачак. Соң булачак!..

Салават:

– Мин... – дип тотлыгып калды.

– Син тиз генә егылма. Көрәшкән атлы булып йөр. Сизә күрмәсеннәр. Ә Кәримне алам мин!

Салават дустанә елмайды. Сүзен өздереп әйтә алмавына ачуы чыкты. Ниһаять:

– Әйдә чынлап торып алышабыз... Син гаеп итмә... – диде.

– Ничек?!

Салават нидер әйтергә теләде. Тыелып калды. Икенче мизгелдә үзен кулга алды:

– Ярый. Синеңчә булсын. Мин сине аңлыйм, – дип, артык сүз озайтмады.

Бабасы сөйли торган иде: борын заманда Акташ авылында Зарифулла атлы батыр яшәгән. Бер сәер ягы булган Зарифулла батырның: арбасына йөкне чамаламыйчарак төйи икән бу. Аты йөген тарта алмый туктап калса, бахбаен тугарып, үзе җигелгән. Соңыннан: «И малкай, син түгел, үзем чак тартып кайттым!» – дип, атын кызганып басып тора икән.

Бәләкәй Данияр шакката. Бабасы мыек астыннан елмая. Әбисе: «Бер дә ушың китмәсен, улым. Җеннәре көч биргәндер Зарифуллага», – дип, кет-кет көлә.

Әллә чынлап та җеннәре көч бирде инде? Чистага салырмын дип, башына да китермәгән иде. Салды. Салават сөлгесен Минсәгыйть абзыйның җилкәсенә ташлады да мәйданнан чыгып китте.

– Син сүз бирдең!

– Вәгъдә – иман!

– Егетләр сине түгел, мине сайладылар!

Данияр берсеннән-берсе авыр гаепләү сүзләре ишетермен дип уйлаган иде. Салават:

– Мин сине аңлыйм, – диде...

Икәү калдылар. Җиңүче – Сабан туе батыры. Аның, Данияр Дамир малаеның, җиңелергә хакы юк.

Хөкемдар Минсәгыйть абзый биш минут ял бирде. Данияр маңгаена бәреп ватып, чи күкәй эчте. Хәл кереп киткәндәй тоелды. Астыртын гына көндәшен күзәтте. Бер дә алҗыганга охшамаган Чутыр!

– Мәйдан уртасына, егетләр!

Минсәгыйть абзый ашыктыра.

Чыктылар. Беренче күргәндәй, бер-берсенә сынап-тикшереп, күз ташладылар.

– Бүген кич Якты Күлгә тәкә ите ашарга килегез. Күл буенда җыелышабыз. Егетләреңә әйтерсең. Чакыруым шушы! – Мыскыллы караш. Шат чырай. Ихлас тавыш. Вәт артист! Максаты ачык: чак кына булса да, көндәшенең җиңүгә ышанычын какшату. Бер какшаган таш тиз куба...

– Кем кемгә кунакка килер бит әле! – Тавышын бөердән алып әйтмәкче иде Данияр. Мескенрәк яңгырады бугай... Их, авызың белән кош тота белмәгәч, шулай инде ул!

– Энем! Сине матур иттереп, сыртыңа салу минем өчен кыска вакытлы күңелле мәшәкать кенә булачак!

«Энем», ди. Авыз тутырып тәмләп әйтә. Ике яшькә генә өлкәнрәк югыйсә. Юк, хикмәт яшь аермасында түгел. Ул сине бер баш түбән төшерә, үзенчә малайсытып көлә.

– Башладык, егетләр!

Сөлгеләр күнегелгән хәрәкәт белән билләргә ятты. Зыңлап тартылды. Бөтен арулар артка чигеп, тәнгә башбирмәс үҗәт бер көч иңде.

Озакмы көрәшерләр алар? Ничә минут?.. Сәгать?.. Вакыт төшенчәсе югалды... Сөлгеләр ничек чыдыйдыр, сеңерләр шартлап өзелер, мөгаен: әле берсе, әле икенчесе көндәшен күтәрепләр алып чистага салмакчы!

Юк... Минсәгыйть абзый тавышы:

– Көрәшне дәвам итегез!

Янә билләрдә сөлгеләр тартыша, янә үҗәт бер көч бил бирмәскә, көрәшне дәвам итәргә өнди...

Мәйдан гүли. Картлар көрәштән канәгать түгел. Минсәгыйть абзый кырыс:

– Сөлгеләрне билләргә бәйләгез, егетләр! – ди.

Бәйлиләр. Кояш кыздыра. Хәзер күк күкрәп, яңгыр яусын иде.

– А-а!..

Үпкә-бавырлары суырылып чыкты бугай... Бар көчен бер мизгелгә туплап кычкырды Данияр, көндәшен күкрәккә алып, баш аркылы атмакчы булды.

– Тамыр җибәрмәгәнсеңдер, егет? Тор!

– Минсәгыйть абзый, нигә кешедән көләсең син?!

Торды. Нинди көч аны кат-кат кулына сөлге алырга мәҗбүр итә соң? Көч белән генә әллә ни майтара алмыйсың. Башыңны эшләт, егет! Нигә ул Кәримне җиңә алмый? Чөнки Кәрим аның көрәш алымнарын белә. Ул көндәше өчен ачык китап кебек. Менә кайда хикмәт! Хәер, ул да Кәримнең ничек көрәшкәнен бик җентекләп күзәтте. Алар бер-берсен бик яхшы беләләр шул.

Минсәгыйть абзый биш минут тәнәфес игълан итте. Һәр минутның кадерен белеп, көч җыярга кирәк.

Зәңгәр күктә тургай сайрый. Баш очында миләш чыпчыгы чыркылдый. Тәнгә рәхәт биреп, талгын җил исә... Кемдер, өздереп, гармун уйный; кемнәрдер җырлый, көлә, бәхәсләшә, яшьлеген сагына, дөньясын онытып көрәш карый.

Сабан туе бу!..

– Йәгез, егетләр!

И Туган җир! Билемә ныклык, беләгемә җегәр бир! Урман-кырларыңда тәгәрәп үскән малаең бит мин!..

– Ы-ых!..

Кәрим үкерде. Урталай өзеп чыгарырдай итеп, биленнән китереп кысты. Мәйдан зырылдап әйләнде. Дөньясы әйләнеп капланды...

– Торыгыз!.. Көрәшне дәвам итегез!

Минсәгыйть абзый, миһербансыз кеше син! Юк, ул тормаячак! Бик матур утыра әле...

Ул алтабан көрәшне дәвам итә алмый. Бу – кырыс чынбарлык. Ә без хакыйкатьнең күзенә туры карарга өйрәнгән егетләр. Алай дисәң, кайсыдыр журналда укыганы бар: кеше хәлдән таеп егылырга мөмкин, ә организм әле үзендәге көчнең чиреген дә сарыф итмәгән була, имеш. Юк сүз! Ялган! Ул йөз процент көчен сарыф итте! Артыграк булмаса әле... Җитте. Соңгы тукталыш. Көрәшмәде түгел – көрәште, тырышмады түгел – тырышты. Бүген кич Якты Күлгә кунакка барачак. Күл буенда Сабан туе тәкәсен пешереп көтеп торсыннар. Казанга салып пешерерләр микән, шашлык итеп кыздырырлармы? Әлегә колгага бәйләп куйганнар үзеңне, үлән чемченеп йөрисең, и бичара хайван!..

Кәрим майлырак калҗаларны аның алдына этеп-этеп куеп кыстар инде... Кунак сыйларга оста ул.

Хәзер күп җирдә баллар өстенлеге белән җиңәләр дә бит... Чутлап карасаң, аның баллары Кәримнекеннән күбрәктер дә әле. Акташ – Якты Күл Сабан туенда кануннар үзгә шул: син көндәшеңне бәхәскә урын калдырмаслык итеп җиң! Яисә... Бу хакта уйлыйсы да килми. Кырыс халык яши аның туган төбәгендә! Һай, кырыс...

– Башладык, егетләр!

Торды. Кара-каршы бастылар. Вакыт. Менә хәзер ике уйларга урын калдырмаслык итеп: «Кәрим! Синең кебек егеткә җиңелү хурлык түгел. Без матур көрәш күрсәттек!» – дияр... Әйе. Сүздән аркан ишеп тормас.

Шулчак көтелмәгән хәл булды.

Кәрим билендәге сөлгесен чиште.

Кәрим сөлгесен көндәшенең иңбашына ташлады:

– Син җиңдең! – диде.

Мәйдан тып-тын калды. Бу акыл күзе җитмәслек хәлнең асылына төшенү кирәк иде.

Бер минуттан мәйдан кайнап чыкты:

– Дөрес түгел!

– Алдан сөйләшеп куйганнар!

– Чистага салганчы көрәшсеннәр!

Бераздан тынычлана төштеләр. Якты Күл авылы көрәшчесе Кәрим Сәүбановны сөлгесен көндәшенең җилкәсенә ташлап, мәйданнан чыгып китәргә беркем дә мәҗбүр итмәде бит дип уйладылар. Булган хәлнең төбенә төшәргә тырышып, күпмедер вакыт фикер йөрткәч, күңелләре белән Акташ авылы егете Данияр Галимовны Сабан туе батыры итеп кабул иттеләр. Кемнәрдер батырны һавага чөйде. Җилкәсенә тәкә күтәреп салдылар. Ул мәйдан әйләнергә тиеш иде. Ул туп-туры АНЫҢ янына китте. Көрәшкәндә, үк АНЫҢ кайда басып торганын күргән иде. Каршысына килеп:

– Бүген кич клубка чыгарсың. Сиңа сүзем булыр! – диде. Кыз тирәсендә чуалган егет-җиләннең башларына сеңдереп, акылы өйдә булганнарга аңларлык итеп әйтте.

– Ярый, Данияр, – диде кыз йомшак күкрәк тавышы белән.

Бүтән авылларда ничектер – ул кадәресен белмим, Якты Күлдә кызлар Сабан туе батырына тел кайтарып, каршы сүз әйтмиләр.

## Эпилог

Күңелдә канәгатьсезлек хисе калды... Сәгатемә карадым. Бу вакытта кордаш Гаилә паркында булырга тиеш. Җыендым да киттем.

Ялгышмаганмын. Ул оныгы – елтыр күзле, дүрт-биш яшьлек шук, тиктормас малай белән футбол уйный иде. Олпат гәүдәле, яше җитмештән узган картның туп артыннан йөгерүенә елмаймый гына карап торып булмый – берара авыз ерып, боларны күзәттем.

Исәнләшеп, хәл-әхвәлләрне сорашкач, турыдан ярып:

– Көрәшеп, бер көтү тәкә алгансың! Биш тапкыр район, өч тапкыр республика Сабан туйлары батыры, бер тапкыр Җәлил призын откансың! Шул мәртәбәле ярышлардан бер хатирә ишетәсем килгән иде. Ә син миңа гап-гади бер авыл Сабан туенда көрәшкәнеңне сөйләдең, – дидем.

Кордаш рәхәтләнеп көлде.

– Менә көйсез кияү! Соң үзең «иң-иңен сөйлә» дидең түгелме?! Хәтеремдә уелып калганын! Мин сөйләдем. Син тыңладың. Ә болай... унбиш ел көрәшеп йөрдем мин. Һәр келәмгә чыгуым исемдә дисәм дә, ялгышмам кебек...

– Ә теге кыз белән аралар ничек булып бетте? – Алай да кызыксынмый булдыра алмадым.

– Зариманы әйтәсеңме? Быел март аенда алтын туебыз булды!

– Котлыйм! Ходай сәламәтлектән аермасын да, кайгы-хәсрәт читләтеп үтсен гаиләгезне.

– Рәхмәт. Иң кызыгы: туйда шул Сабан туен искә алдык. Елмаеп карады да әйтә бу миңа: «Җилкәңә тәкә салып, каршыма килеп басмасаң да, кияүгә чыгар идем инде мин сиңа! Синең кебек егетне кулдан ычкындырырга җүләрмени мин?!» – ди.

Ике ир-атның авыз күтәреп көлеп җибәрүеннән курка калыпмы, чәчәкле язда скандинавия йөреше белән үз көенә җай гына атлаучы әбекәй, чаңгы таякларын тиз-тиз селтәп, адымнарын кызулады.

– Син – көрәшче. Көрәш сиңа нәрсә бирде? Мин Сабан туе бүләкләрен күздә тотмыйм, – дип сорадым мин, язылып бетмәгән хикәям турында уйлап.

– Спорт, гомумән, үҗәт булырга, авырлыкларга баш бирми куйган максатыңа ирешергә ярдәм итә. Мине хәрәмләшмәскә өйрәтте. Беләсеңме, авыл егетләре белән алдан сөйләшеп куюыбыз хәрәмләшү кебек иде. Мин моны кулыма сөлге алгач аңладым, – диде ул, җитдиләнеп.

– Татар көрәшен киләчәктә ничек күзаллыйсың?

– Билбау көрәше Олимпия уеннары исемлегенә кертелер дип уйлыйм.

Эндәшмәдем. Кордашның йөзендә нур балкый; фикеремне әйтсәм, ул яктылык сүнәр-сүрелер кебек тоелды. Ничә тапкыр игътибар иткәнем бар: ир-атлар елмайганда, дөньяда игелек һәм иртәгәсе көнгә ышаныч арта.

Бәлки, ул хаклыдыр?..



Гөлнара
Сабирова

# МИН АКЛЫК ЭЗЛИМЕН ҖИҺАННАН...

***

Әллә соң дөньяда аклыкка,
Яктыга бер урын калмады?!
Көннәрне «сары сүз» буяган,
Карага буялган таңнары...

Кешенең гайбәте сатыла,
Хәсрәте (!) сатыла... лайкка.
Модада – җиңеллек һәм дә хайп,
Тик урын калмады лаекка.

Кайда җан? Кайда рух? Тирәнлек? –
Боларның барысы да – искелек.
Курчаклы уенга алданып,
Упкынга атыла кешелек.

«Бу – авыр, бу – озын, катлаулы,
Җиңелрәк булсын ул уйларга»...
Җиңеләйдең түгелме син, дөнья,
Җиңеллек артыннан куганда?!

...Бәгырьне айкарлык сүзләрнең
Бәһасе калмаган бу җирдә
Җылылык эзлимен (садә җан),
Һич югы бер мәгънә, кимендә..

Мин аклык эзлимен җиһаннан.
(Ә җанга каяндыр моң ява!)
...Сине бер кочаклап елыйсы,
Юасы кила бит, и дөнья!

Гөлнара САБИРОВА (1982) – *шагыйрә, журналист; Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре. Казанда яши.*

***

Рәхәт чакка җиттем.
Мин беркемгә
Бернәрсә дә бүген тиеш түгел.
Бер булганнан меңне күрә белә,
Булмастайны хыялланмый күңел.

Сөйләгәннәр... әйдә, сөйләсеннәр!
Миңа алар һич тә кызык түгел.
Үзем беләм: мин фәрештә булмам,
Әнкәй оялырдай бозык түгел.

Хисап тотасым юк уйларыма.
Кайсы чатта? Кайсы якка барам?
«Кыйблаң кайда?!» – диеп сорый ала
Ходай гына,
Җирдә – газиз Анам.

Рәхәт чакка җиттем!
Үз күңелемне
Бүген менә үзем аңлый алам!
...Яратыгыз – (башта үзегезне!) –
Дөнья шундый матур яратканда!

***

Мин.
Синең яныңда.
Яшәргә өйрәнәм.
Мәңгелек узыштан тукталып.
Бар нәрсә – шәмәхә. Чукынсын дөньясы.
Йөрәкне тыңлыймын таң калып.

Биш йозак артына бикләнгән йөрәкнең
Оныткан идем лә барлыгын.
Күкрәтер-тетрәтер давыллар көткәндә
Уятты... гап-гади тынлыгың.

Мин күпме йокладым? Айлармы, еллармы?
(Вакытның исәбе җуелган.)
Чаң булып кагылды исерткеч тынлыгың
Һәм тартып чыгарды чоңгылдан.

Планета ачкан күк йөрәгем тыңлыймын,
Таң калып, ишеткән сүзләрдән:
«Рөхсәт бир, бу гамьсез дөньяны җылытыйм!
Минме соң ярата белмәгән?!»

Мин. Синең яныңда. Яшәргә өйрәнәм...

***

Әйдә, без бәхетле булабыз!
Карамый бернигә,
Ис китми бер сүзгә!

Ә тормыш ул – шундый... Бик явыз.
Мең киртә әзерләр ул безгә.

Без икәү язмыштан көчлерәк!
Бәхетне... тудырган кеше без!
Һәм аны, яшәүнең асылын,
Тамырга тутырган кеше без.

Бәхетне көчлеләр төзиләр –
Җаннарны көйдергән ялкыннан.
Бу бәхет – сабырлык бәясе,
Бәхетле булырга хакым(ң) бар!

Хакым(ң) бар бәхетле итәргә!
Көттергән, көтелгән бу күкрәү.
...Әйдә! Без бәхетле булабыз!
Беркемгә әйтмичә. Тик икәү...

***

Мин – хатын-кыз. Минем белән авыр.
Миннән башка кыен меңәр кабат.
Йөз халәткә кереп төрләнсәм дә,
Бүген нинди булсам, шулай ярат.

Мин – хатын-кыз. Чык тамчысын күреп,
Яшь тамчысы балкыр битләремдә.
Елак та мин, нечкә күңелле дә.
Хатын-кызмын: сүзләр – хисләремдә...

Көчсезмен мин. Әмма яратканда
Күперләрне яндырырлык янам...
Таш диварлар авар, кыя таулар
Буйсынырлар шушы көчсез җанга.

Мин яратсам – бар барлыгым сөя,
Тугрылыгым – булат ныклыгында.
Бар дөньясы гаеп такканда да
Мин ышанам синең хаклыгыңа.

Мең кат үләм, мең терелəм көнгә,
Хисләремнән үзем тынсыз калам.
...Бүген нинди булсам – шулай ярат,
Мин барыбер син теләгән булам...

***

*Кулдагының кадерен белми торып,*
*Гел кояшка таба үрелдем...*

Мин генәме кояш ялкынынннан
Мең кат пешеп, мең кат сүрелгән?
Җирдә ничә буын яшәп киткән –
Барысы да күккә үрелгән.
Ничә меңнәр читтән бәхет көткән,
Куенында сөю ятканда.
Кеше өлешеннән телем кисеп,
Шул бәхеттән иткән тантана.
Мин генәме күзем томаланып,
Һаман чапкан, һаман ярышкан,
Үз көченә үзе бәя бирми,
Әллә кемнәр белән алышкан?!

Ярый әле минем кебекләрне
Сабак биреп, кояш пешерә.
Булганыңа шөкер итә бел дип,
Күктән кабат җиргә төшерә...
Мин генәме күкне урап төшеп,
Җирдәгедән көткән мәрхәмәт?!
Читләр салган яраларны бәйләр,
Якыннарым, сезгә мең рәхмәт!

*Саха (Якутия) Республикасының халык язучысы Николай Лугиновның «Ил чиге» дигән романын борынгы Кытай тарихының барлыкка килү чорын чагылдырган повестьлары тәшкил итә.*

*Укучыларыбыз игътибарына Фирүзә Җамалетдинова тәрҗемәсендә өч повестьтан торган шушы әсәрнең беренче өлешеннән өзек тәкъдим итәбез.*



Николай Лугинов

#ҺУННАР БӘЯНЫ

## САНЬГУАНЬ ЗАСТАВАСЫ

### 1. Онытылган үткәннәр, фаразланган киләчәк турында

Бу хәлләр күптән булган. Шулкадәр күптән ки, ул чактагы күп нәрсәләрне инде мүк баскан, ком астында калган, туфрак күмгән.

Әмма һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Борынгы Кытайның Чжоу чик буе провинциясендә бик күп гасырлар элек булып узган бу гадәттән тыш вакыйгалар турында искә төшерер вакыт җиткәндер.

Миңа мәңгегә югалган кешеләр һәм аларның гореф-гадәтләре турында якты хатирәләрне яңартырга туры килде. Әлбәттә, сез минем бу бәяннарыма үзегезчә аңлатма бирерсез.

Һәр кеше, чынлап та мондый хәлләр, гомумән, булды микән соң, дип шикләнергә мөмкин. Аеруча төпченергә яратучылар: «Булган очракта да, нәкъ шулай булды микән соң?» – дип тә сорар.

Әйтүе авыр, чөнки шулкадәр ерак гасырлар тирәнлегендәге бу вакыйгаларның ниндидер шаһитлары, аларны белгән кешеләр барлыгы хакында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Шушы округка хәрби хезмәткә билгеләнгәнче, үзем дә бу вакыйгаларга әһәмият бирмәгәнмен. Рәсми кәгазьләр дә сакланмаган. Шулай да кемнәрдер, төзүчеләр җир актарганда, борынгы каберлекләргә, баш сөякләренә юлыккандай, чыгарып ташланган архив «тауларыннан» данлыклы Чжоу дәверенең кульязмаларына да тап булырга мөмкиннәр. Әйе, без вакытның үзе кебек бераз йончыткан карт дөньяга күп тапкырлар әйләнеп кайттык.

Гүя, яңадан туып, яшәү бөҗрасында бөтенләй буталып беттек. Күп нәрсәләр үзгәрде һәм без дә чынбарлыгыбызга салынган «үзебез»дән ераклаштык. Йомшаграк холыклылар иске гөнаһларыннан арынмаган көенчә, яңаларына тиенде. Монысы, мөгаен, язмыштандыр. Вакыт синең янәшәңнән акканда, һәммәсе үзгәрә, теләсәң-теләмәсәң дә, шул агымга кушыласыңдыр.

Артка борылып карыйсың да уйга каласың: ул чакта күргәннәрең башка сыйфатта, башка чагылышта, хәтта башка яссылыкта булган икән бит... Яшь чакта боларның мәгънәсенә кем төшенгән? Берәү дә... Әгәр дә гыйлем җитмәүдән генә барысы белән дә ризалашсак, бер хәл әле. Юк шул. Берни белмәүче дә хәбәрдарлык кыяфәте чыгарырга тырыша. Ялгышучылар шулар. Үзе сукыр зат башка сукырларны җитәкләп йөреп адаштыргандай. Хәер, сукырлар җитәкләгән чорның кайчан башкача булганы бар?

Мин ул хәлләрне үзем күзаллаганча, үзем уйлаганча бәян итәргә телим. Кайдадыр хаталанып, хакыйкать сукмагыннан чыгып алуым да ихтимал, гаепләмәссез дип уйлыйм. Чөнки чорлар аръягында калган хәлләр бу.

Адәм баласының тормыш-яшәешкә сораулары гаҗәеп күп. Җаваплары гына юк. Табылган очракта да, шактый соңлап. Ул сораулар гасырлар буена җыела торгач, уйларны урман чытырманлыгыдай итә. Иң кызыгы: иске, әмма билгеле хакыйкатьнең юлын томалый. Хак чынбарлыкның юлын чистартыр вакыт җитте югыйсә... Ә бит төпченүчән затлар сорауны тезә генә: «Ни өчен?» «Ник алай?» «Нигә?» Аңа үзең дә төшенеп җитмәгән көенчә ничек җавап бирәсе? Чагыштырмача шулайрак, дию бер буталган җепләрне кабат чуалту гына булмасмы? Әмма җавап тотарга тырышу кирәктер. Аннан төпченеп сорау алучы заттан безнең буталчык уйгамәлләрне бер рәткә тезеп, тәртипкә салучы да үсеп чыгарга мөмкин бит дигән өмет тә юк түгел. Шушы өмет алга әйди, кайчандыр булган хәлләрне, үземчә күзаллап, бөртекләп җыярга, тоныклана төшкән хәтерне кузгатырга өнди. Ә анда сораулар... Сораулар...

Минем бер хезмәттәшем, бер ахмак ун акыллыбаш та җавап бирә алмаслык сорау томырырга мөмкин, диярга ярата иде...

* * *

– Беренче чик сакчылары кайчан барлыкка килгән?

– Беренче чикләр тәгаенләнгәчтер, мөгаен. Әйе, бик күптәндер, кешеләр борынгы, чикләрсез яшәгән чорларны хәтерләмиләр дә булыр. Ул заманнардан бирле җир өстеннән күп афәтләр узды, Янцзы һәм Хуанхэ елгалары буйлап күп сулар акты, чиксез бөек яшәештә исәпсез-хисапсыз гомерләр өзелде. Без шушы җавапсыз тормыш кайнаган җирләргә күп тапкырлар килеп китәрбез, ә чикләр калыр. Чикләр бит саклаучылары булмаса, үзенең әһәмиятен югалта.

– Ә беренче чик сакчысы кем? Аның вазифасы нидән гыйбарәт булды икән?

– Ахырдан башлыйсым килә, чөнки беренче ике сорауга минем җавабым юк, төгәл җавап таба да алмам төсле. Тукта әле, баштан ук башлап карыйм. Кем булган ул, дисеңме? Әлбәттә, сугышчы. Синең белән минем кебек үк. Кайда булганмы? Әлбәттә, чик буенда. Вазифасымы? Монысына төгәл җавап бирә алам, чөнки монысы үз башымнан кичкән.

Беренче һәм аннан соңгы барлык чик сакчыларына да изге бурыч йөкләнгән: илне читләр кул сузуыннан, басып керүеннән, үзенең дошманнарыннан саклау бурычы.

Без соңгысына якынрак икән, димәк, анысы беренчедер. Үзеннән-үзе сорау калкып чыга: соңгы чик сакчысы чиккә кайчан килер? Кайчан? Монысын уйларга да куркыныч: коточкыч чорлар булыр ул. Бөек Тәңребез безгә ул галәмәтләрне күрсәтмәс. Әйе, барлык чикләр беткәч, барыбыздан да бәхетсезрәк соңгы чик сакчысын да үз постыннан төшерер. «Үзеңнеке» һәм «читләрнеке» дигән төшенчәләр дә юкка чыгар. Элегрәк һич башка сыймаслык булып тоелса да, ни кызганыч, хәлләр шуңа таба бара.

Чик сакчыларыннан, дәүләтләрдән, хакимнәрдән азат, үзеңнеке һәм читләрнекенә бүленмәгән, туганлык һәм дошманлык төшенчәләре җуелган яңа эра туып килә. Әмма дөнья артык зур: кечкенә генә адәм заты анда нәрсәнедер үзенеке, җанга газиз дип саный алмаслык дәрәҗәдә киң һәм кырыс.

Әйтергә дә шомлы, кешедә үзенеке саналган кечкенә генә нәрсәләргә мәхәббәт урынына, колач җитмәслек зурларына карата битарафлык оялый. Ә битарафлар – куркыныч. Һәм бу изге затны иң түбән гөнаһ кылучы белән туганлашырга мәҗбүр иткән, аңлаешсыз, әхлаксыз, гомумән, коточкыч чор булачак.

Монысы инде башка тарих, дөресрәге аның азагы. Хәзерге карашлардан, аңлау куәсеннән бернинди мәгънә дә калмаячак. Безнең чор үткән, каршы торырлык көчебез беткән. Әйдә, шулай булсын. Иң мөһиме: боларга безнең катнашыбыз юк.

Үз илебез, үз Ватаныбыз юкка чыккач, миңа – өлкән чик сакчысына чиксез дөньяның ни кызыгы?!

Тарихның юл чатында шушы яңарышка катнашмыйча, без өнсез ташларга яки аның чакрым баганаларына әверелергә дә ризабыз. Һәм «Кем өчен?» дип сорау бирергә дә...

Шулай да катнашмыйчамы икән?..

* * *

Хәер, ниләр хәтерлим соң әле мин? Җир өстендә шактый үзгәреш кичерүем сәбәпле, күп нәрсәләрне онытырга да өлгергәнмен ләбаса. Шулай да чик сакчысы булуымны яхшы беләм. Төрле чорларда төрле ил чикләрендә хезмәт итүемне дә. Дөрес, чикләр еш кына кешеләрсез җирләрдән узганга, мин башкала яки илнең эре шәһәрләрендә ниләр кылынганыннан хәбәрдар булмадым.

Әйе, онытырга өлгергәнмен, ә Саньгуань заставасы янында хезмәт итүем яхшы ук истә. Бәлки төрле чорларда өч тапкыр язмышымның шуның белән бәйләнүе сәбәпчедер. Хәер, дүрт түгел микән әле...

Чорның кызыклы вакыйгалары нәкъ шушында булды да. Вакыйга дисәң дә инде, чөнки алар чик буйларының һәммәсендә дә бертөрлерәк. Иң мөһиме: ул заставада бөтен дөньяны уч төбендәгедәй күргән бик танылган затлар хезмәт итте.

Шуңа да мин сезгә Саньгуань заставасы хакында сөйләргә телим.

## 2. Саньгуань заставасы тарихы

Саньгуань заставасы тарихы, аңа кемнәр нигез салуы гасырлар төбендә калган. Шәрә тауларны саклауның кирәксезлеге, әйләнә-тирәдә кешеләр яшәмәве дә күпләрнең ачуын китергән. Барып җитә алмаслык еракта чикләр тоту да бик кыен һәм файдасыз булгандыр. Чынлап та, тигезлектәге Кытайның үз чикләрен еракка – биек тауларга күчерүен һич аңларлык түгел. Ни өчен? Әлбәттә, моңа дәлилләр дә бар: илгә тыштан гына түгел, чикнең аргы ягында да, шулай ук эчтән дә хәрби кыр (предполье) кирәк, ул дошман явын гөл-чәчкәле тигезлеккә үткәрмичә, каршы чыгып, юк итәрлек булсын. Күк астында һәрчак үзчикләүләргә омтылыш яшәгән.

Хәтта шул җирләргә бәйләнгән, әмма аны ташлап китәргә мәҗбүр ителгән, инде көтүлекләренә яңадан кайтырга теләгән күчмә халыкларга моны рөхсәт итмәслек чаралар күрелгән.

Саньгуань заставасы исә бик борынгы. Мөгаен, ул Чжоу династиясенә нигез салынганчы ук барлыкка килгәндер. Димәк, бүгенге көннән[1] исәпләгәндә, кимендә моннан җиде гасыр элек дигән сүз.

Шуннан бирле Янцзы һәм Хуанхэ елгаларыннан күп сулар аккан, тигезлектә яшәүче династияләр алмашынган, ә застава беркайчан да, берничек тә үзгәрмәгәндәй, какшамас хәлдә тора биргән. Әйтерсең лә, бердәм Кытай беркайчан да эчке чикләрен булдырып, үзара дошманлашучы дәүләтләргә бүленмәгән.

Чынлап та, элеккеге бөек империянең һәм аның җирлегендә барлыкка килгән вак дәүләтләрнең бу юнәлештәге мәнфәгатьләре элеккечә калган; ә застава күпгасырлык, тарихи яктан сыналган, көньяктан – Янцзы, төньяктан Хуанхэ елгалары башында, алардан өч йөз ли[2] ераклыгындагы мөһим стратегик пункт булып саналган.

Бу җирләрдән, Тибет белән Кытай арасыннан, хәрбиләр һәм сәүдәгәрләр өчен олы юл үтә. Һәрчак тикшерү һәм саклау таләп ителгән иксез-чиксез товар уза. Мондый җирләрдә чик аша таулардагы казылма байлыклар – алтын, алмаз яки кыйммәтле ташлар алып чыгучы контрабандистлар да очрый. Хәер, алар һәр чорда булган. Шуларга бәйле рәвештә, тарихи вакыйгалар да куерып торган.

Күп кенә чит гаскәрләр – тибет, һун һәм дилиннәр, күчмә төрки кабиләләр Кытайга басып керәләр. Ә талаучы төркемнәрне санап та бетерерлек булмый.

Чикне саклау – заставаның төп вазифасы, ул җентекле эш таләп итә: көндезен дә, төнен дә берни дә күз уңыннан ычкынмаска тиеш.

Каршы якның уй-исәбен вакытында чамалау өчен тауларда һәм далаларда яшерен төркемнәр, отрядлар оеша, махсус күзәтүче, тыңлаучылар куела.

Дошман бәреп кергәндә, һәр минут исәптә була. Тау тарлавыкларында чик бозучыны тотып алып, аста – тигезлектә урнашкан армия часте килеп җиткәнче тоткарлап тору сорала. Эш шунда ки: тауларда һәрчак салкын. Зур гаскәрләр тоту аеруча чыгымлы. Гомумән, застава кайда булуга карамастан, чик сакчылары хезмәте дә чыдамаслык, гаҗәп авыр. Шуңа үз теләге белән чик буенда хезмәт итәргә җыенучылар бик аз. Нигездә, җитәкчелек

[1] Б.э.к. 570нче еллар күздә тотыла.
[2] 150 км.

мондагы хезмәткә хәрбиләрне үзе билгели, күпчелек очракта ул кылынган гөнаһлар өчен җәза урыны кебегрәк кабул ителә. Әйтергә кирәк, Чжоуда бик күпләрнең нәселе төрки тамырларга, дилин, һуннарга барып тоташа. Шулардан чик сакчылары отрядлары туплана. Алар кырыс шартларга, төрле афәтләргә нәселдән килгән чыдамлылык һәм биргән антларына, хәрби бурычларына һичкарусыз тугрылыклары белән аерылып торалар. Юкка гына гасырдан-гасырга күчеп, киребеткән бер төрки хакында мәзәк йөрмидер. Имеш, аны сакка бастырып куеп, хезмәт вакыты чыкканны онытып җибәрәсең икән, ул үлем якасыннан алганчы шунда басып торырга мөмкин. Үзе җан тәслим кылса да, рухы барыбер беркемне дә үткәрмәячәк... Икенче яктан үзсүзле төрки канының әйләнә-тирәдәгеләргә начар йогынтысы да исәптә: ул теләсә кайчан астарак, фәкыйрьләр тирәсендәрәк кайнап алырга, протест булып бәреп чыгарга, бунт яки өстәгеләр белән каршылык тудырырга мөмкин. Шуңа аларны читкәрәк, уңдырышсызрак җирләргә күчерәләр дә. Элеккеге кыргый туганнары бәреп кергәндә, үз ырудашлары ярдәме белән юлларын да кисәләр.

Төньяк-Көнчыгыш чик сакчылары округын җитәкләүче Дин Хунның озакка сузылган хәрби хезмәте чорында чик аша товарларга яшерен юл салучы билгеле контрабандист – Чжан Чжень дигән кеше яшәгән. Бала чактан ук таныш булуга карамастан, аларга чик буенда кат-кат очрашырга туры килгән. Дин Хун карт бүрене күп тапкырлар хөкем чыгаручылар кулына тапшырган. Хөкемдарлар нинди үлчәүгә салгандыр, беркем дә белми. Хөкем итәләр итүен, әмма танышларның дүрт-биш елдан тагын шунда ук юллары кисешә. Һәм тагын шул ук хәл кабатлана. «Ике аерылмас дус» бер-берсенең күзләренә карап, картлыккача шулай яши бирә.

Дин Хун күзәтчеләр отрядыннан – дозордан генералгача күтәрелә, округ командующие була, үзенең тырыш хезмәте белән дан яулый. Үз вакытында Чжан Чжень да «карьера» ясый, әлбәттә, капма-каршы юнәлештә. Гади бер малайдан – тотып алучыга, товар ташучыдан оештыручыга әверелә, күптармаклы яшерен контрабанда кәсебенең җитәкчесенә әйләнә. Һәм үзенең мәңгелек дошманыннан аермалы рәвештә, иксез-чиксез мөлкәткә, дәүләткә ирешә. Чжоуда да, һуннар даласында да артында ныклы элемтәләр, зур кешеләр тора.

Хәвефле һәм тоташ эш белән бәйле чорлар үтә, икесе дә үз хезмәтендә дәрәҗә яулый, икесе дә үзенчә мактаулы затка әйләнә, әмма икесенә дә эштән читләшер вакыт җитә.

Болар киткәнче, елга буенда яңа застава төзелә, ә искесе, каравыл тавындагысы, берничә ел эчендә ташландык хәлгә килә.

Отставкага чыкканда, Дин Хунның авылда туган-тумачасы да калмый, кайсылары бакыйлыкка, кайсылары шәһәргә күченә. Шунлыктан ул икенче туган йортына, җир өстендәге бердәнбер газиз урын дип саналган иске застава янында төпләнә. Югары командование аңа тузган заставаның әле файдаланырга яраклырак корылмасы белән бергә денщик, сакчы, бер ат һәм ишәк тә бирә. Шулай ул элеккеге контора бинасын үзенә торак итеп көйли, хезмәтчеләре белән бергә әкрен генә күкләрдә тәгаенләнгән гомерен айларга, көннәргә ваклый.

Әмма тыныч тормышы озакка бармый. Бик сәер килеп чыга: Чжан Чжень

дә давыллы, ярсулы, үзгәрүчән тормышыннан туеп, калган гомерендә рәхәткә тиенерлек, җанына шифа булырлык урын эзли башлый. Баштарак җылы диңгез ярына урнашу теләге җиңсә дә, дымлы һавасы ошап бетми, аннан, диңгез холкына да күнегелмәгәнгәме, һәммәсе чит төсле тоела. Тигезлектәге елга буенда гөл бакчага күмелеп утыручы киңлекләргә дә ияләшә алмый: артык кызу, җитмәсә, монда барысына да җиде ят ул. Хәтта чикнең аргы ягында – Тибетта яшәп карый, анда исә салкын: йә җил дә җил, йә һаман кыш та кыш.

Һәм ниһаять, үзе ияләнгән урында төпләнергә уйлый: хәрби идарәдән иске заставаның буш корылмасын сатып ала. Аңа гомеренең күп елларын сак астында уздырган элеккеге төрмә бинасы аеруча ошый: нык, эре таш блоклардан салынган, диварлары да калын. Матди көче җитәрлек: ул бинаны өр-яңадан ремонтлап, яңа тәрәзәләр, ишекләр куя. Бары тик тәрәзәдәге рәшәткәләрне элеккеге көенчә калдыра, хәтта аларга алтын йөгерттерә; монысы кем беләндер бәхәскә керергә теләве, тәкәбберлеге, кемгәдер үч итеп яки мәсхәрәләп көләсе килүе сәбәпчедер.

Әлбәттә, ул хан сарае да салдырыр һәм аны төзеп тә бирерләр иде. Ләкин уй-теләкләре караңгылыкка гына тоташкан шул.

Ниһаять...

Аңа югары хезмәт вазифасы билгән дәрәҗәле кешеләр, зур түрәләр килә башлады. Араларында элеккеге гамәлләренә бәйле затлар да, вакытында үз канаты астына алучылар да бар иде. Барысы да бүгенгеләр, хәер, каракның кичәгесе булмый... Очраштыра икән – бу бик сирәк хәл. Дин Хун шулай уйлады һәм аның бөтен вөҗүден биләгән тынычлыгы бетте. Баштарак, эшсезлектән күңелендә туган картлык моңсулыгын, ташланганлыкны, беркемгә дә кирәксезлеген сизүдән көенүләре бик тиз юкка чыкты. Яшьлек дусты Лао Цзы әйткәнчә, бушлыкның эчтәлеге мәгънә белән тулды. Яңадан ул хәрби хезмәттәге кебек застава каланчасына чыгып басты. Камыш яфраклары белән төпләнгән калын журналга Чжан Чженьнең шиклерәк тоелган барча гамәлләрен теркәп барды. Исәпсез-хисапсыз кунакларын җентекләп күзәтте, хезмәтчесен алар ягына юллады.

Ә Чжан Чжень инде эшеннән киткән булуга карамастан, элеккеге кәсебенә бәйле яшьләр һаман аңа әле киңәш, әле ярдәм сорап килде; карт бүренең укучылары аңа тирән ихтирам, олылауларын белдерү өчен дә капкасына кагылып үтте.

Шунысы гаҗәп, чиктән ашкан караклар да кайчак үзара кешечә мөнәсәбәт күрсәтте, аеруча бер-берсенә бәйләнгәнлек һәм рәхмәтле була белүләре белән күзгә ташландылар.

Карт кайчак зурлап, аш уздыра, анда җирле крестьяннарны да дәшә, алар исә бу чакыруны дәрәҗәгә санап, бик теләп кабул итәләр. Мөгаен, болар арасында да Чжан Чженьнең дәвамлы эшләренә бәйле затлар булгандыр, кемдер товарын яшерергә, кайсыдыр кемгәдер тапшырырга булышкандыр.

Дин Хуннан исә крестьяннар бераз шүрли. Аларга ул һәрчак кырыс, дәүләт мәнфәгатьләренең тәкәббер сакчысы, күпсанлы вак-төяк тәртип бозулар өчен җәза бирүче башлык булып күренә. Хәер, шулай фикер йөртүчеләр һәр чорда булган.

Еш кына Дин Хунда «тегe якка чыгу» – аучылык яки гөмбә, җиләк, һич булмаса, дару үләннәре җыю теләге уяна. Чынлап караганда, бернинди

чикләр дә кеше тормышы буйлап сузыла һәм аны чикли яки үзенә буйсындыра алмый. Яшәү шулай көйләнгән: җәмгыятьтә, дәүләттә булсын, адәм баласында рөхсәт ителгән чиктән чыгып карау теләге яши. Әлбәттә, тәртип бозуларның күпчелеге чагыштырмача аз зыян салучан һәм моңа еш кына дәүләт төзелешендәге җитешсез яклар сәбәпче була.

Дин Хун бу хәлне яхшы аңлый, вак-төяккә күз йомарга тырыша, әмма тәртип бозучыга кисәтү ясамый калмый.

Крестьяннар исә, күзаллаулары ягыннан әлләни ерак китмәсәләр дә, нечкә тоемлы халык, бөтенесен сизеп торалар. Шуңа карт генералга яратмыйча яки нәфрәт белән караудан бигрәк, аннан куркалар һәм намуслы, риясыз, гадел булганы өчен ихластан хөрмәт итәләр.

Әмма иң көендергәне шул: халыкка, нигәдер, дәүләтнең нигезен какшатучы контрабандист (үзләренә бер тиенлек файдасы тимәгән зат) дәүләт иминлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүче затка караганда күпкә аңлаешлырак, туганрак һәм якынрак тоела.

Ни өчен казнаның бушап калуында, шуның аркасында дәүләтнең ачлыкка, кырылуга каршы тора алмавында, дошман яуларын кире кагарлык көче калмавында кешеләрнең бер гаме дә юк.

Ә бит мондагы җирләргә дошман гаскәрләре һөҗүм итеп кенә тора, халык шунда ук застава крепостена күченә. Сугышчылар дошманны бәреп чыгаруга, барысы да куанышып, йортларына таралалар һәм үзләрен коткаручыларны шунда ук оныталар, болай гына да түгел, җае чыкканда хурларга, сүгәргә дә күп сорамыйлар.

## 3. Шомлы хатирәләр

Ул дымлы, яңгырлы салкын иртәне гомере буена хәтерендә саклады.

Тыныч, борчусыз балачак төшен әнисенең кычкырып, бүре улавына охшатып, такмаклап елавы бүлде. Күзен ачуга малай аның әтисе кулында бәргәләнеп иңрәвен күрде, нигәдер әтисе дә елый иде. Шунда ук ул әтисе кулыннан ычкынып, улына капланды, аның бөтен гәүдәсен, сөякләрен шыгырдатып калтыранган куллары белән кысты.

– Каһәр төшсен бу тормышка! Гаделсез дөнья череп таркалсын! Аһ, нинди хәсрәт! Ничек күтәрим мин аны? Улымнан башка ничек яшим?

Әнисен аның беркайчан да мондый хәлдә күргәне юк иде: күзе яшьле, билгесезлектән тетелгән коточкыч халәттә, кыскасы, гаиләгә килгән бәхетсезлекне аңлавы һич мөмкин түгел.

Узган ел иртә кырау төшү сәбәпле, гаилә уңышны җыеп алырга өлгермәгәнлектән, салымнарны да түли алмаган, ди. Шуңа улларыннан мәхрүм итмәкчеләр икән.

– Улкаем, гаепләмә безне! Бу каһәрле дөньяга тудырганым өчен кичер! Нигә болай килеп чыкты соң? Моның өчен кайчан да булса, безне гафу итәрсеңме, улым?

Әнисе тагын шашынып өзгәләнергә кереште һәм ул кинәт гүя ят, таныш булмаган куркыныч затка әверелде, хәтта Дин Хун шомлы билгесезлектән коты очып, үзе дә кычкырып елап җибәрде.

Шунда ук күршеләре йөгереп керде. Әнисен тынычландырырга

фәрештәләр. Арада гаепләгән күзләр белән караучылар да юк түгел иде. Нигәдер аларның сүзләре йөрәккә тирәнрәк уелып калды.

– Ярар, бетеренмә, бу рәвешле, чиктән тыш куәтле затларның һәммәсенә ачу саклавың бар...

– Менә бит... Кыргый, басып алучылар каны кайнаган затлардан тагын ни көтәргә мөмкин?! Зәңгәр күзле һуннар шундый алар, ярсулы чакларында бигрәк тә... Һәммәсен кырып ташларга да күп сорамаслар!

– Бу язмыштыр, күрәсең, Тәңредән узып булмый, кыраулар да тиккә генә төшмәгәндер, малайларны хәрби хезмәткә чакыру өчен бер сәбәптер. Анда барысы да алдан планлаштырылгандыр. Балам алдында гына гарьләнәм, берни эшләр хәл дә юк, язмыш белән килешергә генә кала...

– Бәлки улыгыз югалмас, яшәп китәр. Басып алучылар каны уянса, ул әле борынгы кыргый йолаларны торгызыр... Хәтта әле берәр начальник булыр. Каян беләсең? Тәңре – төркиләрнең Алласы бит. Ул аларның күп гөнаһларын кичерә һәм, күрәсең, ярдәм дә итә.

Озатканда, әтисенең, үз хәер-фатихасын биреп калырга ашыгып, кайнар пышылдавы аның хәтерендә саклана.

– Улым, исеңдә тот, безнең башка чарабыз юк. Сине биреп җибәрергә мәҗбүрбез. Солдатлар кирәк аларга, шуңа бездән йолкып алалар. Кечкенә әле ул, тимәгез, дидем. Ялындым. Ишетергә дә теләмиләр: укытырбыз, шунда үсәр, диләр. Улым, сиңа анда авыр булыр, бик авыр. Тик син түз, онытма, син бөек һуннар нәселеннән! Оятка калдырма! Шуны онытма – син безнең коткаручыбыз... Хәзер син гаиләбезне коткарасың, аны саклыйсың. Киләчәктә дә сакларсың, ул чакта инде сугышчы булып якларсың! Онытма шуны!..

Әнисе хушлашу мизгелендә, улын, сөякләрен шытырдатып, күкрәгенә кысты, әйтерсең, ул аны кире карынына яшерергә тели иде. Дин Хун чүт кенә тончыкмады, шул чакта аны кемдер аның кайнар кочагыннан йолкып алды. Әнисенең хәсрәткә баткан зәңгәр күзләре коточкыч, үзе бөкрәйгән, җирән чәчләре тузгыган, хәлсезлектән ул шыр ачык ишеккә сөялеп калды...

Ул салкын, кырыс иртә Дин Хунның элекке, күбрәк җитмәүчелектән, нужадан торса да, чагыштырмача гамьсез балачагын тимер көрәк белән кырып ташлагандай итте һәм аны күз алдына да китермәгән яман каты бәгырьле, чит дөньяга беректерде. Яңача, сәер, ят тормыш башланды. Аны үзе кебек үк борын асты кипмәгән, бәхетсез, шау-шулы малайлар төркеменә кушып җибәрделәр дә көнбатыштагы олы юлга таба ияртеп киттеләр.

Баштарак, һәммәсе дә бердәй бәхетсез, тигезләр иде. Тиздән җәмгыять аларны түбән, урта, югары дәрәҗәдәге төрле төркемнәргә бүлгәли башлады. Үзеннән-үзе шулай килеп чыккан кебек иде, әмма монда нindидер закончалык булуы да сизелде. Малайларның һәрберсе акыл ирешмәслек сайланыш аша үтеп, билгеле бер төркемгә керде.

Дин Хун тиз аңлады: ул үз яшьтәшләреннән күчмә бабаларыннан мирас итеп тапшырылган тышкы кыяфәте белән дә, гадәтләре белән дә аерылып тора. Бу бик үк яхшы хәл түгел, чөнки аны бүтәннәргә каршы куя, аерым шартларга, читләшеп яшәргә этәрә иде. Һәм шул сәбәпле, аңа үз-үзен якларга, дәрәҗәсен, аерымлыгын күрсәтергә туры килде. Шул ук вакытта, моңа кадәрле үк, башкаларны куркытырлык нидер булган, шуңа күпләр аңа юл бирергә тырыша кебек тоелды. Бары тик соңыннан, еллар узганнан

соң гына, рәхимсез, аяусыз сынаулар аша уза-уза, башкаларның анда нык ихтыяр, дошманны басу сәләте, кыюлык, куркусызлык, ачуы чыкканда, кешеләргә хас булмаган дуамаллык ташуына төшенде.

Беренче җитди сугышта тигезсез алышта ул биш кешене чабып үтерде. Аннан соң да, дошман күбрәк булуга карамастан, аны кысрыклап, чигенергә мәҗбүр итте. Дин Хун берүзе өметен җуйган көрәштәшләрен үз артыннан әйди белә, могҗизалы рәвештә җиңүгә ирешә иде.

Провинциядә яшәүчеләрнең байтагы төркиләр, төгәлрәге, дилин, һуннар тамырыннан, ә җирле кытайлар күпчелекне тәшкил иткәнгә, аларга түбәнсетебрәк карыйлар иде. Җәмгыятьтә күп кенә көйсезлекләр, бәла-казалар йөгәнләнмәгән, буйсынмаучан һәм көтелмәгән эшләр башкару сәләтенә ия дала каны тәэсире белән аңлатыла иде. Кемнәрнеңдер тышкы сыйфатлары күзгә дә ташланмаучан, ә Дин Хунның бөтен булмышы – төркиләрдән: зәңгәр күзләр, бөдрә салам чәчләр, бөкреле борын, зифа буй... Холкы белән исә, әтисенә охшаган: чыдам һәм басынкы. Намуслы хезмәте белән яулап алынган дан һәм дәрәҗәсе булуга карамастан, ул үзен һәрчак чит, аерым бер кеше итеп сизде.

### 4. Озату пунктында

Борынгы акыл ияләренең хикмәтле фикерләренә караганда, кешенең язмышы туганчы ук тәгаенләнгән, имеш, моны раслаучылар да бар.

Борынгы хакимнәр тормышны зирәклек, катгыйлык аша (катылык аша булмаса әле) төзегәннәр һәм табигый рәвештә бер кеше дә хөкем ителүчеләр эскәмиясенә утырмаслык тәртип, канун-кагыйдәләр булдырганнар. Кемдер эләгә икән, бу гайре табигый вакыйга саналган.

Әмма дәүләткә һәрчак крепость-кальгалар, саклану корылмалары, канаулар төзү өчен эшчеләр, армия һәм чик буе заставаларына солдатлар, флот өчен диңгезчеләр кирәк. Үз теләге белән катлаулы, кырыс хезмәткә барәү дә бармас иде. Шуңа салымын түли алмаган гаиләләр өчен канун кабул ителгән, алар хөкемгә тартылган. Ә хөкем карары гаиләнең бер әгъзасын бер елдан биш елгача ирегеннән мәхрүм иткән: яше буенча туры килгән улларының берсен разнарядка белән алып та киткәннәр.

Маймыл елы корылыгыннан соң Ли Эр, Дин Хун һәм аларның башка хезмәттәшләре иҗтимагый эшләргә тартылды. Иҗтимагый дигәндә, иң авыр хезмәт – саклану корылмалары, канаулар төзү күздә тотылды. Эш җәй челләсендә дә, кышкы суыкларда да ел әйләнәсе дәвам итте.

Эшчеләрнең яшәү шартлары коточкыч, арада түзалмыйча җан тәслим кылучылар да аз түгел иде, алар хакында авылда шомлы хәбәрләр таралды.

Хөкем ителгәннәр башта Озату пунктына эләгә, аннан төзелешкә җибәрелә, ә яше җиткәннәрне армия хезмәте көтә. Монысы исә хөкем ителгәннәр өчен котылу чарасы, киләчәккә якты өмет иде.

Армиядә хезмәт итәр өчен Озату пункты түрәләре ай буе аерым сынаулар үткәргәннәр, шундагы авыр шартларда һәрберсенең мөмкинлекләре, нәрсәгә һәвәслекләре ачыкланды. Адәм баласы үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен белеп бетермәскә дә мөмкин. Әмма Озату пункты хезмәткәрләренең тәҗрибәле, үткер күзенә барысы да яхшы күренә.

...Озату пункты, ким дигәндә, мең ел элек төзелгән, борынгы кальгада урнашкан бина. Вакытлар үтү белән каралып, ташларына мүкләр үскән биек диварлары аңа төксе, дәһшәтле төс биреп тора. Күпсанлы эчке ишегаллары, бүлмәләре яңа килгәннәрне төркемнәргә аеру өчен аеруча уңайлы. Бүлмәләр дә төрлечә җылытыла: кайсы салкын, кайсы түзәлмәслек кызу була. Андыйларындагы бөркүлек кешене нык йончыта.

Ниндидер күзгә ташланмаган билгеләр буенча, һәр кешене аерым өйрәнеп, илле кешелек төркем туплана. Караңгы чырайлы картлар аларның йөзләренә текәлә-текәлә, араларыннан йөреп чыкты. Ымлап кына, чираттагы корбанны әләктереп, олырак ярдәмче малайлар, аларны бүлмәдән алып чыгып китә тордылар. Калган бәхетсезләр, гадәттәгечә, шыңшырга, еларга, үзләренә тимәүләрен сорап ялынырга тотындылар. Болар чынлыкта, балалыктан да чыгарга өлгермәгән, башларына акыл кермәгән үсмерләр генә иде әле.

## 5. Караңгы бүлмә сере

Дүртенчеме, бишенчеме мәртәбә тикшерелүләрдән соң, Дин Хун яше дистәдән генә үткән яшүсмерләр ябылган чираттагы бүлмәгә эләкте. Күпсанлы күчерүләрдән соң, аның янына кечкенә буйлы, чандыр һәм аз сүзле Эр Ли исемле малайны керттеләр. Үз эченә бикләнгән: күрәсең, аны күп кыерсытканнар. Тик ни өчен? Башы зурга, колаклары тырпаеп торгангамы? Эр Линың колагыннан тарту яки маңгаена чиртү шаянракларының күңелен күтәргәндер. Әйе, нәкъ шулай булгандыр.

Кеше дигәнең сәеррәк зат шул, үзләре шактый кыен ашап, әле бу сазлыктан чыкмаган көенчә дә, мыскыллар өчен корбан эзләп табалар, шәхси көчсезлекләренә бәйле ачуны шушы гөнаһсызлардан алалар.

Дин Хун җавап бирә белми торган, килбәтсез, ихтыярсыз иптәшен рәнҗетүчеләрдән бер генә якламады. Җирбитләргә каршылык күрсәтеп, йодрык ашатырга да туры килгәләде. Бәйләнчекләрнең уңышсыз сугышын һәм елашкан тавышларын ишетеп, күзәтүче-надзиратель керде. Аның тәҗрибәле, алҗыган карашы шунда ук чүгәләп утырган горур сынлы, хезмәт итүчеләр арасында шактый билгеле Дин Хунда һәм аңа сыенган зур башлы малайда тукталды. Күзәтче аларны бармак белән генә чакырып, озын, тар коридор буйлап ияртеп китте. Ахырда ул, бер ишекне бәреп ачып, тегеләрне караңгы бүлмәгә этеп кертте. Караңгы дивар аша тәрәзәдән төшкән тонык ут яктысы бүлмәнең дүрттән берен дә яктыртырлык түгел, өстәвенә караңгыга күнекмәгән күзләр берни күрми иде.

Яшүсмерләр, нишләргә белмичә, күзләренең караңгыга ияләшкәнен көтеп, ишек төбендә таптандылар. Дин Хунга, нигәдер, бүлмәдә кемдер бар кебек тоелды, дөресрәге, берәүнең авыр карашын тойгандай булды. Ниһаять, өч шәүлә чалымлангандай булды.

– Ә, бу синмени, генерал? – диде өлкән кешенекенә охшаш карлыккан тавыш. Көтелмәгән хәлдән яшүсмерләр читкә тайпылып, ишеккә елышты, тик ул бикле иде.

– Йә, нигә дәшмисең, генерал? Исемең ничек?

– Дин Хун мин. Генерал түгелмен, шулай да...

– Күрәм, әлегә генерал түгелсең, әмма зур кеше булачаксың син. Тумышың

белән төркиләр нәселеннәнме? Ярар, түз. Алар арасыннан да сайланганнар бар. Сайланганнардан сайлап алырлыклар чыга. Синең юлың шушы.

– Мин бит әле... солдат та түгел. Сез миннән көләсез, хөрмәтлем.

– Көләргә уйлаганым да юк: солдат та булырсың, командир да, барысы да алда. Барысы да үз вакыты белән килер. Кыюлык һәм уңыш, аннан үз хезмәтеңә тугрылык юлдаш булсын! Ул чорга барып җитәргә, шуңача яшәргә һәм хезмәт итәргә генә кирәк. Син булдырасың. Син зур кеше, син көчле заттан!

– Ә синең артыңа качканы кем? – дип сорады ул башка чыелдык тавыш белән. – Яле, яктыгарак чык, нинди җитлекмәгән көзге чебеш икән ул анда? Озын колак, дәү баш, фу-у! Кыяфәтсез! Ничек аны чик сакчысына алганнар диген?

– Бу Ли Эр була, – дип, үз кешедәй кычкыра төшеп әйтте Дин Хун һәм арка ягыннан этәктереп, дустын алгарак этте.

Өч шәүлә сискәнгәндәй тибрәнеп куйды, аннан аңлаешсыз авазлар ишетелде. Аларның гаҗәпләнүме, сокланумы икәненә тиз генә төшенерлек тә түгел иде.

– Чынлап улмы? Юктыр... Нинди көн соң бу? Артык уңышлы...

– Күр инде, зур кеше артына бөек кеше яшеренгән...

Өчесе дә килешкәндәй, бер-бер артлы хөрмәт белән башларын иделәр.

– Әйе, бу ул! Бөек мөгаллим. Озак, бик озак көттек без аны!

– Тәңренең уңышыбыз өчен бүләкләведер бу.

Ли Эрны гүя алыштырып куйдылар. Әле генә алгарак чыгып басарга да оялган малай караңгы шәүләләргә тынычланып, текәлеп карап торды. Шуннан көлке тудырырлык тавыш белән сорады:

– Мин дә генерал булачакмынмы әллә? Бәлки полководецтыр? Шаккаткыч!

– Юк, юк, генерал да, полководец та түгел. Алары болай да күп, киләчәктә дә аз булмас.

– Император мәллә соң?.. Бер дә охшамаган...

– Императорлар да җитәрлек, моннан соң да бер-берсен алыштырып кына торырлар.

– Кызганыч, – дип куйды кан качкан иреннәрен кыймылдатып Ли Эр. Сөйләүчегә ышанып бетмәве аның күзләреннән күренә, барыбер сүзне өзмәскә тырышып:

– Мин сугышырга бөтенләй рөхсәт итмәс идем, солдатларны да өйләренә кайтарып җибәрер идем, – дип өстәде. – Алайса кем соң?

– Син бөекләрдән дә бөегрәк булачаксың.

Шулчак бүлмә караңгылыгы төпкеленнән кыл өзелгәнгә тартым зыңлаган тавыш ишетелде һәм тынлык урнашты.

– Әй, сез кайда? Ник дәшмисез? Җавап бирегез! – Малай боеру төсмере салып эндәште. Бүлмәдә тынлык хөкем сөрде. Алар икәүләп караңгылыкка озак текәлеп тордылар, элеккеге шәүләләр дә күренмәде. Аннан, курка-курка бүлмә уртасынарак уздылар, җиде-сигез адым санадылар, әмма анда да беркем дә юк иде. Диварны сыйпап чыктылар, нигәдер ишекне тапмадылар, җитмәсә, дивары да тоташ таштан икән. Малайлар аптырашка калды: алар белән сөйләшкән кешеләр кая китте соң? Үтә сәерлеге белән бу хәлләр һич башларына сыймады.

Ли Эр бөтенләй үз эченә бикләнде, каушауданмы, уйлары

тынгысызлагангамы, тәмам дәшмәс булды. Дин Хун, гадәттәгечә, тиз аңына килде. Ул озаклап уйларга бирелергә яратмый, хәер, уйлаудан ни файда: юкка чыкканнар икән – чыксыннар соң! Шулай да ирексездән дустына әверелгән, күңеле якын итә башлаган зат белән шаярып алырга булды.

– Әйт әле, Эр Ли, сиңа ябырылган баягы тинтәкләр башыңа суктылармы әллә?

– Яхшы ук тондырдылар. Син көчле дә, зур да, шуңа әйтүдән ни файда, ничек авыртканын барыбер аңлый алмассың, – диде малай уйларыннан бүленеп, хәйләле алдашуны һич күздә тотмыйча.

– Сизелә икән шул, каты бәргән болар... Әгәр дә...

– Нәрсә әгәр дә?

– Җыен юк-бар күзгә күренгәндәй булды лабаса...

– Син нәрсә? Берни дә күрмәдек, берни дә ишетмәдек, дияргә телисеңме?

– Юк инде... Ә нәрсә булды соң? Сөйлә әле, миңа бик кызык бу.

– Кит инде, икебез дә бергә ишеттек ләбаса, син алар белән сөйләштең дә әле, сорауларына да җавап бирдең.

– Юк, юк, берни дә булмады, – дип, Дин Хун чиксез гаҗәпләнүен сиздерде. – Син, егеткәй, артык күп сөйләшә башладың...

– Ничек инде, үзеңә генерал булачаксың, диделәр ләбаса...

– Мин... генерал? Үз акылыңдамы син? Нинди генерал чыксын миннән? Әле тиз генә гади солдат та итмәячәкләр...

– Димәк, берни дә ишетмәдек дип саныйк...

Эр Ли аңа чын-чынлап үпкәләде, бөтенләй сүзсез калды.

## 6. Хәрби хезмәткә омтылыш

Караңгы бүлмәдәге вакыйгалардан соң берничә көн үткәч, Дин Хун белән Эр Ли монда хезмәт итүчеләрнең тавышын ничек кенә тыңларга, эләктереп калырга тырышсалар да, тегеләрнекенә охшаш авазлар тоемланмады. Өлкән кешеләрнең тавышы үзенә бер төрле, аларны һичкем белән бутау мөмкин түгел иде.

Ә бер иртәдә, таң яктысы беленә башлауга, аларны уятып, иске кальганың төп мәйданына алып чыгып тезделәр һәм кызыктыргыч чик сакчылары исемлегенә эләккәннәрне кычкырып әйтә башладылар. Һәр бәхетле затны чиксез көнләшү тулы карашлар белән озата тордылар. Дин Хун шушы исемлеккә керәсенә тамчы да шикләнмәде, ә дәү башлы, нечкә муенлы дусты яңа рәттә артына килеп баскач, шатлыгының иге-чиге булмады. Күрәсең, сайлаучылар, көч, гайрәт, кыюлык, җитезлектән бигрәк, зирәклеккә, башы эшләгәннәргә күбрәк игътибар иткәннәрдер.

Аларны иске крепостьтан алып чыгып, көнбатышка таба алып киткәндә, көнчыгыштагы кояш сөңге буе күтәрелгән иде инде. Малайлар иске кальганың тончыктыргыч дымыннан соң, салкынча, кыр чәчкәләре һәм урман исе аңкыган саф һаваны күкрәк тутырып суладылар.

Шулай итеп, Җир буйлап сәфәр чыктылар, ул исә бик-бик озакка сузылды, чиксез авыр һәм бормалы-сырмалы булды. Юлларында төрле хәлләр, көтелмәгән сынаулар очрап кына торды. Ә алар үз сукмакларыннан читкә тайпылмыйча, аны намус белән үтәргә тырыштылар.

Дин Хун белән Эр Ли Саньгуань заставасында нибары биш ел бергә хезмәт иттеләр. Шунысы да мәгълүм: кеше язмышында яшьлекнең башлангыч юллары аеруча әһәмияткә ия, йөрәккә, хәтергә тирән уелучан, нәкъ шул чорда адәм баласы иң якын һәм ышанычлы дусларын таба. Ул нинди генә озынлыкта булмасын, күпмедер бергә яшәлгән, серләр сөйләшенгән, уй-хисләр кичерелгән.

Әйе, юллары аерылды, хәрби хезмәт сукмаклары буйлап төрле якка китсәләр дә, алдагы тормышта барыбер бергә калдылар: бер-берсенә уйлар аша ялгандылар, бәхәсләштеләр, ачуланыштылар, аннан яңадан дуслаштылар, кыскасы, бер-берсен янәшәдә тоттылар. Үзара якыная төшкән саен икесендә дә бер-берсенә хөрмәт артты. Һәр икесенең дә фикердәшләре, укучылары, хезмәти дәвамчылары күп булды, әмма казармада яшьлегендә очраган туганнан да якынрак дуслыкны алыштырырдай берәү дә табылмады.

Тормыш кайчакта адәм баласыннан мыскыллап көләдер сыман тоела, хәтта Дин Хун, Ли Эр кебек билгеле затлардан да... Үз гомерендә Ли Эр күпләргә белем бирде, алар арасыннан уртачаларны, акыллыларны, бигрәк тә үз мирасына хуҗа итәрлек, лаеклы затларны аерып алырга теләде, әмма бу эше нәтиҗәсез булды. Эшен дәвам иттерүчене аң-белемгә һич катнашы булмаган чик сакчысы Дин Хун табып бирде.

Ли Эр Саньгуань заставасында хезмәт иткән чорны, андагы шактый кыен ашаткан кырыс тормышны аерым бер җылылык аша искә төшерә. Ул шунда бер-берсеннән еракта калкынган тауларда кизү торганда, фикерен тупларга, аңа юнәлеш бирергә өйрәнде. Сырты гел карлы Куньлунь тавын аеруча яратты, картаймыш көнендә шунда әйләнеп кайтты.

Чик буендагы хезмәттән соң, Ли Эр җиде ел эчендә өч имтихан биреп, дәүләт хезмәте баскычларыннан әкрен генә, әмма гаделлек белән өскә күтәрелде. Чжоу патшалыгының баш архивчысына кадәр үсте, архив исә укуына бәйле күп кенә эшләрне башкарып чыгарга юл ачты.

Ни сәбәпледер, гаилә кормады, гомеренең күпчелек өлешен укучылары әйләнәсендә, хакиме бүләк иткән тау елгасы буендагы утарында уздырды. Шәкертләренә еш кына батыр йөрәкле, көчле рухлы, үтә намуслы дусты Дин Хун һәм кайда да «бүресе улый торган» дошманы – контрабандист Чжан Чжень турында сөйләде.

Ли Эр ничек кенә укытырга, өйрәтергә тырышмасын, укучыларының фәлсәфә юнәлешендәге уңышлары да уртача, остазларына карашлары да гадәти, гади иде. Гаҗәп хәл, ул тәрбияләгән укучыларның күбесе чик сакчылары заставасы башлыклары, саклау корабльләре капитаннары, гомумән, фәлсәфә дөреслеген табарга алынмаган, ә чик сакчысы кануны кебек дөньяви кыйммәтләргә бәйле гади хезмәт итүчеләр булып киттеләр. Нишләмәк кирәк, тормыш безнең теләк-омтылышларыбыздан мәсхәрәләп көләргә ярата шул.

## 7. Ике тантана

Куян елында[3] Дин Хун җитмеш яшьлеген бәйрәм итте. Юл өзелде, Янцзы һәм Хуанхэ елгалары ташыды, шул сәбәпле, кунаклар чагыштырмача азрак килде. Императорның «Озак еллар карусыз хезмәт итүе һәм чик буйларын

[3] Б.э.к. 509 ел.

ныгытудагы эшчәнлеге өчен» дигән зур бүләген башкомандующий урынбасары Хуан Ли тапшырды. Барлык хәрби идарәләрдә кабул ителгәнчә, Төньяк-Көнбатыш чик сакчылары округы командасы составы тантаналы сафка тезелде. Аннан күрше чик саклау округыннан, заставаларыннан, читтәге шәһәр һәм авыллардан килгән халык өчен хәрбиләрчә корырак табын корылды. Дин Хун канәгать калды: Император котлады, хезмәттәшләре олылады, йә, тагын ни кирәк инде? Ул язучы да, галим дә, китап күчерүче дә түгел, ә гади хезмәт итүче, югыйсә дәүләттә аның кебекләр күптер.

Көз җитте. Икенче тантана, шулай ук җитмеш еллык, монысы чик сакчысыныкы түгел, киресенчә, күпләрнең шаяртуына кушылып әйтсәк, «Төньяк-Көнбатышның баш контрабандисты» Чжан Чженьнеке. Бу сәер тантана колачлылыгы белән бөтен кешене гаҗәпкә калдырды. Төрле катламнан иксез-чиксез халык чакырылды. Хәтта «карт бүре»не дәүләт хезмәте түрәләре дә котлады. Кунаклар арасында Эчке элемтәләр, сәүдә, мануфактура министрлыгы вәкилләре дә бар иде. Диңгез ведомствосыннан да тәбрикләүчеләр күренде.

Ә кем соң ул Чжан Чжень? Әлбәттә, аны тулы бер Төньяк-Көнбатышның контрабандисты дип, берәү дә атамады, һәммәсе кызып-кызып, «яхшы кеше», «ярдәмчел, хәлгә керә белүче, илтифатлы» булуын ассызыклады. Хәтта «күрше халыклар белән дуслык элемтәләре урнаштыруда чиксез күп көч куючы» икәнен дә әйттеләр. «Юмарт, зирәк, риясыз» кебекләре гүя капчык авызыннан коелып торды. Бу чыгышларның күпчелеге оятсызлыкка, ялганга корылган иде, тантана хуҗасының законга сыймаган, күп мәртәбәләр судлар раслаган җинаятьчел эшләре имеш дәүләт өчен булган, имеш аны аңлап бетермәгәннәр дә бәяли белмәгәннәр, җитмәсә әле эзәрлекләгәннәр дә.

Таможня аша кыйммәтле әйберләрне кертү-чыгарудагы астыртын эшләре – һичзарарсыз товар таратуы белән ул халыкара элемтәләрне җәелдерүгә генә түгел, ә мәдәни багланышларны җәелдерүгә дә өлеш керткән икән. Гомумән алганда, дуслары Чжан Чженьнең җинаятьчел эшләренең бөтенесен дә акладылар, алай гына да түгел, моны батырлык итеп күрсәттеләр. Алар тантана хуҗасының гөнаһларын юар өчен кайчандыр гамәлдән төшерелгән законнарның искергән маддәләрен искә алдылар, алдан күрүчәнлегенә сокландылар. Болар янында һәр канунны шик астына куеп, иртәгә үк үзгәртеп яки гамәлдән чыгарып буладыр кебек тоелды.

Дин Хун үз бәйрәменә Чжан Чженьне күрше буларак чакырган иде: кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, аңа да тантана табынына керергә туры килде. Ә Чжан Чжень аны дәрәҗәле урынга утыртты, тормыштагы үсешен тәэмин иткән саф күңелле кеше, дип таныштырды.

«Хәлемнән килсә, мондый затны ирекккә чыгармас та идем, үлгәнче читлектә яшәтер идем. Хәер, үз теләге белән дә нәкъ шулай булды түгелме соң?!» дип, караңгылык аша уйлап алды Дин Хун элеккеге төрмәнең алтын рәшәткәләренә төбәлеп.

Гомерләре буена бер-берсе белән көрәшүдән туктамаган бу ике затка тагын янәшә, күрше булып яшәргә туры килде, карт чик сакчысы дусты Ли Эрны, хәзер инде Лао Цзыны еш искә ала башлады. Теге чакта, казармада, соңрак та, Дин Хун аның уйлары агышын аңлап бетермәде генә түгел, бөтенләй кабул итмәде. Ли Эрның зирәк, канатлы сүзләрен кире какты,

чөнки алар чик сакчысының һәрчак шулай булырга тиеш, дигән катгый, ачык һәм гади кыйммәтләр системасын җимерә иде. Мисал өчен «өмет баглау»га караган нигезсез фикерләре. Аларны турыдан-туры аңларга теләсәң, болайрак килеп чыга: чик буен саклау да, тәртип бозучыларны эләктерү дә һич кирәкле гамәл түгел. Барыбер һәрнәрсә үз божрасына әйләнеп кайта, ничек тиеш – шулай була. Имеш, сиңа, чик сакчысына, табигый әйләнешкә тыкшыну һич мәгънәсез нәрсә...

Яшьлегендә Дин Хун кискен, катгый фикерләрне сабырлык аша тыңлый белде. Кайчакта аңа дусты кешене башсызлыкка этәрә, яхшылык һәм явызлык, дөреслек һәм ялган, канун һәм җинаять шикелле төшенчәләрне юри бутый, адәм баласы кылган гамәлләрнең җеп очын чуалта кебек тоела иде. Күзгә күренеп торган гади нәрсәләрне авызыннан күбек килгәнче яклый, ачыклык кереп җитмәгән билгеләмә-аңлатмаларга ачуы чыга иде. Аның кайнарланып, картларча каршы торуын күреп, дусты серле елмая: «Вакыты җиткәч аңларсың, хәзер сиңа нәрсә исбат итеп булсын?» – ди.

Дустының башка постулатлары белән дә шулайрак килеп чыкты. Тулысынча түгел түгелен. Озын тормыш юлы чынлыкта да байтак күренешләрнең катлаулылыгын ачып салмаса, Дин Хун хәзер дә, бернинди шартларда да ул фикерләр белән килешмәс иде. Монысына ул атлап чыга алмаслык табу салынган, хәер, болай эшләргә теләмәс тә иде.

Җир өстендә бөтен нәрсәнең берсе беткәч, икенчесе башлана торган төгәл, ачык сызыгы – чиге бар. Башкача була да алмый, чөнки дөнья шулай яратылган. Хәтта ерткыч хайваннар да үз биләмәләрен билгели, аны читятлар керүеннән саклый. Ә кешеләргә чикләрсез яшәү килешми. Меңәр ел элек акыллы кануннар нигезендә барлыкка килгән чикләрне бозу яки аларны танымау һич тә ярамый. Югыйсә бәла-казага бер адым калыр. Бу үз тиресен кайгыртканнар өчен генә кулай.

Дөньяны тотып торган төшенчәләрне бутау яки бөтенләй күмеп кую дөрес түгел. Югыйсә ул сазлык кебек селкенеп, тетрәп торачак: яхшылык һәм яманлык, мәрхәмәт һәм явызлык, җир һәм диңгез кебек төшенчәләрдә тигезлек югалачак. Батырлык һәм җинаять арасында ачык күренүчән чикләрдән тыш, ерактан аерылып торсын өчен киң мәйдан да калырга тиеш. Болардан чыгып карасак, чик сакчысының контрабандист белән уртак тел табуы күзалларлык хәлме? Әйдә, алар мәңгелек каршылыкта калсын! Үзара якынаюга, уртак мәнфәгатьләргә, ниндидер элемтәләргә юл куярга ярамый, димәк, ике якның әхлагы да уртак була алмый. Шулай түгел икән, әхлак, әдәп дигәне бөтенләй юкка чыгачак. Ә бу бетүгә таба баруның башы булыр...

## 8. Кануннар һәм намус турында

Тантана табыны түрендә, «законсызлык бәйрәмендә» Дин Хун берүзе төмсә чырайлы текә таудай утырды. Күңелгә тиючән төче, төзек җөмләләрне тыңлап, сөйләүчеләрнең төп нәрсәләрне әйтмичә, шул ук вакытта эчен әйләндереп салып, караны – ак, акны – күк, чынбарлыкны бәхәсле дип күрсәтә алуларына сокланды. Көтмәгәндә, үзенә сүз бирелгәч, бермәлгә икеләнеп калды: шушы эчкечелек тамашасына, ялганга кискен каршы чыгу кирәк микән соң? Сайлап җыйгандай (чынлыкта, ниндидер сыйфатлары

буенча сайланган да), оятсыз вак адәми затларга каршы төшүдән ни мәгънә? Һәм ул картлык утырткан олы гәүдәсе белән торып басты: ялганчы, намуссыз, шәрабтан кызарган йөзләрне карашы белән сөзеп чыкты. Кинәт сулу алган да сизелерлек табигый булмаган киеренке тынлык урнашты.

– Тормыш шулкадәрле озын һәм катлаулы дип, яшьлектә һич тә уйламаганмын, – дип урабрак башлады ул сүзен. – Әгәр аны Чжан Чжень белән без яшәгән кадәр яшәсәң, баш җитмәслек хәлләргә кадәр барып чыккан буласың... Мәсәлән, гади һәм аңлаешлы төшенчәләрне, һич җимерелмәс, какшамас нигезебезне, чынбарлыкны көтелмәгәнчә аңлату шуңа кермиме? Менә мин гомеремне чик буен саклауга багышлаган зат, чик бозуны яшәешенең төп шөгыле, кәсебе иткән кешенең бәйрәм табынында утырам. Иренмичә санадым: аны утыз ике мәртәбә тотканмын икән...

– Әйе, синнән башка мине бер генә чик сакчысы да эләктерә алмады, – дип, горурлык аша әйтеп куйды Чжан Чжень. Аның сүзләре кунакларның тантаналы авазларына күмелде, ә кул чабып алкышлаулары һәр икесенә дә багышлангандай тоелды.

– Хәзер менә икебез дә бер өстәл янында утырабыз, күршеләрбез. Дөрес, тәртип бозучылардан ул берүзе генә түгел иде. Алар күп. Әмма бөтенесе дә төрмәдә череде, үлем җәзасы алдылар. Гаҗәп хәл, еш кына тантана хуҗасыныкына караганда күпкә кимрәк җинаятьләре өчен дә... Ник шулай? Кем аңлата ала? Ничек, ни өчен ул бүгенге көнгәчә килеп җитте соң, бөтен маддәләр буенча да болай булырга тиеш түгел иде бит?!. – Дин Хун тагын кунакларга күз йөгертеп алды, әмма җавап ишетелмәде.

– Ул ерткычлар сизгерлеге белән яшәде, чикнең кай төшендә палач кылычы ятканын алдан белде һәм ул якка башка адым атламады. Борчуга салырлык каршылык шунда ки, Канун кушканча һәм Намус кушканча яшәү беркайчан да диярлек тәңгәл килми. Кануннар һава торышы кебек даими үзгәрештә: кайчандыр катгый, кайчандыр йомшара төшә, ә Намус чикләре беркайчан да үзгәрми. Бу безнең яшәешебезнең катлаулы һәм бәхәсле өлеше. Күпләр бу каршылыкта сөртенә, күпләре шушы катлаулы бәрелешкәчә барып та җитми...

– Ә син соң үзең кайсысы өчен яшәдең? Закон өченме, әллә Намус хакынамы? – дип сорау ташлады Чжан Чжень, сакал астыннан гына тавышын чыгарып.

– Мин – чик сакчысы. Ә чик – закон ул. Чик буенда хезмәт итүнең бөтен тәртибе, нәрсә яравы, нәрсә ярамавы дәүләт кануннарында, боерыкларда, уставта язылган. Мин хезмәт итүче кеше буларак, боларны беркайчан да бозмадым. Дөресрәге, бозмаска тырыштым.

– Ә намус?

– Намус – һәркемнең шәхси эше, шуңа ул үтә күренмәле, – дип куйды кунакларның берсе. – Әйе, төгәл нәрсә түгел, уйдырма төшенчә дисә генә...

– Намус билгеләмәсендә кайсыгыз ул анда бәхәскә кермәкче? Сәер кешеләр сез, – дип кискен бүлдерде карт чик сакчысы монафикъларча сөйләшүчене. – Намус йә бар ул, йә юк. Кемнекедер йоклаган булырга, кемнекедер яшәү өчен кирәге чыкмаганга бөтенләй корып кибәргә мөмкин. Әмма Намустан башка, әдәпле, яхшы кешене күз алдына да китереп булмас. Синдә бар икән – ул сызлый башлый, кычыта, аннан йокыңны качыра, тынычлыгың югала, хәлне

ничек үзгәртим икән, дип бәргәләнәсең. Нәкъ менә Намус һәм аның тоемы таләбе сәбәпле, яхшы кануннар языла, кешеләр һәм дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр җайга салына. Аерым берәр төркем яки милли мәнфәгатьләр үзгәреш кертергә мөмкин, әлбәттә. Шул сәбәпле, дөньядагы тигезлекне, тынычлыкны җуюга китерүче дөрес булмаган кануннар да кабул ителә. Ә мәнфәгать нәрсә соң ул? Саранлык, комсызлыктыр, мөгаен.

Дин Хун кинәт үзен инде беркем дә тыңламавын тоеп алды. Хәер, монда шундыйлар гына җыелган ласа – бөкреләр, аларны кабер генә төзәтер. Туктап, елмая төшеп әйтте:

– Хәер, сезгә ни дип сөйләп торам соң? Намус мәсьәләсендә барыбер уртак тел таба алмаячакбыз бит...

Ул урыныннан кузгалып, бәйрәм табыныннан чыгып китте. Хәтта хуҗа да аны туктатырга җөрьәт итмәде. Чикне үтеп, юл аша чыкты да өенә кайтып та җитте.

Кунакта туган уйлары һич тынгылык бирмәде. Кеше фикере барда гына яши, әйтәсен әйтергә, сүзләр камалышында калдырырга кирәк иде дә бит... Үзенең дүрт хезмәтчесен чакырып китерде: ике денщик, кучер, аш пешерүчене каршысына утыртты. Табында «саңгыраулар» белән очрашканын әйтте. Һәм сорады:

– Ничек уйлыйсыз, безгә Намус дигән нәрсә кайдан килде икән? Һәркем үзендә үзе үстерә мәллә? Әллә аны Күкләрдән иңдерәләрме?

Бераз тоткарланып торганнан соң, чандыр, аз сүзле аш пешерүче сүз алды:

– Бер дә белмибез шул, әфәндем. Намус барында бөтен кешегә дә әйбәт бит: синең кебек зурларына да, кечкенәләргә дә. Барыбызга да яхшы икән – тагын нәрсә кирәк инде? Калганы безне кызыксындырмый да...

– Бөтенесе дә әйбәт микән соң? Күп нәрсә Намус белән эшләнми, шул сәбәпле, ызгыш-талашлар, ара бозылу, сугышлар килеп чыга. Кешеләр бөтенесе яхшы булуны теләми мәллә соң? Телиләр дә шикелле. Арада кемдер табыла: үзенә генә яхшы булсын дип тырыша. Башкаларга яманы да бик җиткән. Мондыйларга тарыганым бар. Тик бу ике теләкне ничек тигезлисе соң?

– Монысына Тәңребез үзе дә җавап бирә алмыйдыр, мөгаен, – дип, уйчан гына әйтеп куйды карт денщик. Ул генерал белән ачыктан-ачык сөйләшергә күнеккән, чөнки бергә хезмәт итүчеләрдән берүзе аның янында калган. – Белсәм дә әйтмим...

– Әгәр дә әйтәм икән, мине кем тыңлар соң? – диде кайнарланып, аш пешерүче. – Чып-чын кытай кешесе буларак сөйлим сезгә, без – эшлекле халык, үз дәрәҗәбезне яхшы чамалыйбыз, ни кызганыч, төркиләргә караганда алласызрак кына...

– Төркиләрнең үзләрен белмим, әмма Бөек Тәңрегә ышану безгә алардан килгән, – дип, караңгы йөзен ачмыйча гына әйтеп салды карт денщик. Әйтерсең, ул бу мәлдә ерак нәселен якларга алынган иде.

– Намус чикләр һәм кануннар урнаштырырга тиеш бит, әйеме? Мин дә шулай дидем, тик алар моны аңлыймы соң? Бөтен бәла-каза чикләр җуелудан түгелме? Намусның төсе тоныкланып китүе сәбәпле, әрәмтамаклар, контрабандистлар үрчи ласа. Әйтик, без намуска чикләр урнаштырдык, ди, ә аны кем сакларга тиеш соң? Миңа, гади чик сакчысына, өч тапкыр

генерал булсам да, кирәк түгел бу. Әйе, мин иң тупас эштә булдым, иң тупас, эшләнеп бетмәгән кануннарны сакладым. Ә монда тышкы чикләрне генә тәртиптә тоту җитми, кешеләр арасындагы – эчкесенә дә күз-колак кирәк... Хәтта һәр кешегә... Йә, моны кем башкарып чыга ала?

– Бер дә белмибез шул, әфәндем, Тәңренең дә көче җитмәстер, мөгаен...

Их, Ли Эр янәшәдә булсын иде ул! Бергә-бергә мәсьәләне чишәрләр дә иде. Әлбәттә, мошенник, харам капчыгының бай табынында тыгынучылар белән бәхәскә керүе җиңел түгел. Кайчакта фикердәшең белән дә уртак тел табып булмый. Зирәклеген эшкә җигеп, ул да гади, ап-ачык нәрсәләрдә юлыңны саташтыра.

## 9. Инь Си – ике укытучының укучысы

Дин Хунны ике зур тантанадан соң, авыр, катлаулы уй-тойгылар чолгап алды, бигрәк тә артыгын ачылуы, каршылыклы дәлилләре өчен борчылды. Әмма белә: чик сакчысы үз вакытында эшләп калырга тиеш, әз генә соңардыңмы, тәртип бозучыны күз уңыннан ычкындырып җибәрергә дә мөмкинсең.

Гомумән, Дин Хун озын-озак гомерендә яхшылык һәм явызлык, дөреслек һәм ялган, гаделлек һәм гаделсезлеккә карата ачык күзаллаулар белән яшәде. Төп бәла – бик теләсәң дә, һәр җирдә, һәрвакытта ике капма-каршы якны бүлеп торучы чик сызыклары юклыгы, аерымлануның башы – берсе бетүгә икенчесе – капма-каршысы башлануда иде.

Димәк, чик саклау зонасы кебек ике башлангычны да аерып торучы нидер кирәк. Ә тормышта ул юк һәм була да алмый... Юк икән, димәк, кешелек дөньясын аянычлы киләчәк көтә: һичшиксез, чикләрне дөрес билгеләмичә, аннан файдаланучылар, билгеләүче-аеручы казыкларны, маякларны, ягъни яхшылык-явызлык кебек төп кыйммәтләрне белгән көенчә бутаучылар табылачак. Ә аннары күз алдына китергесез хәлләр башланачак. Болары аерым исбатлауларсыз да билгеле, шуңа ул, үзе дә аңламастан, уйларыннан качарга тырыша, баш ватуның мәгънәсе юклыгын, хәтта кеше акылына зыян китерү ихтималы барлыгын чамалый. Әйе, ул алардан йотып алырга авызын ачкан чоңгыл кырыеннан киткәнчә китә, югыйсә һич тормышка ашмаслык нәрсәләргә кадәрле барып чыгуың да ихтимал...

Әле күтмәгәндә бер фикер башына сукты: бөтен тәне тартышып, чымырдап куйды. Ул Чжан Чжень белән үзе арасында аерым-ачык тоемланырлык элемтә булуын ачыклады. Бу берничек, беркайда да мөмкин хәл булмаса да, тормыш-яшәеш чикләре бик-бик еракта аерылса да... әмма ул элемтә бар. Бу – бүгенге чынбарлык һәм аңардан качып булмый.

Чып-чын чик сакчысы контрабандист белән үзара бәйләнеш эзләсен инде, йә, кыргыйлык шушы түгелме? Мифка тиң, башка яссылыкта тоелса да, бу элемтә – чынбарлыкта, рөхсәт ителмәсә дә, ул өзелмәслек түгелме?

Чик сакчысы өчен бу – хөкем ителүгә лаек җинаять. Аерым Җинаять кануннары җыелмасы нигезендә генә түгел, һәр чик сакчысы килеп басачак Күкләрдәге югары суд кодекслары таләп иткәнчә дә...

Дин Хун әлеге элемтәнең кодекс буенча нинди хөкемгә лаек икәнен тәгаен генә белми, тик шунысы ачык: гаепләячәкләр, гаебен дә табачаклар, алай булмаса, уйлары аны эзәрлекләмәс тә, лаеклы ялын шомга коендырмас та иде.

Кодексның ачыклау, раслау өчен үз тикшерүчеләре бар. Әйе, эш, шәхсән, үзендә генә түгел, башкалар да белсен, мондый бәйләнешкә керүдән курыксыннар.

Дин Хун озак еллар хезмәт итү дәверендә, зурдан кубып, махсус оештырылган чик бозуларны тамырыннан корытты. Шактый контрабандист-каракны иле өчен мөһим законлы сәүдә юнәлешенә борып җибәрде.

Яшерен хәрәкәт иткән дошман гаскәрен алдан белеп, төп заставаның аз көче белән дә каты яуга каршы торып, армия часте килеп җиткәнче кире чигендерә алды. Бөтен Чжоуны зур бәхетсезлектән коткарды. Баштан ук тончыктырып, талаучыларны ил чигеннән куып чыгарды.

Төньяк-көнбатыш округының чик сакчылары командованиесен ышандырып, Император аңа үзе дәүләтнең иң югары дәрәҗәсен – генерал исемен бирде. Шулай итеп, караңгы бүлмәдәге серле юраулар чынга ашты.

Дин Хунга кадәр күп еллар элек төп застава янында үз вакыты өчен зур китапханә булган. Аңа исеме күптән онытылган, шушында хезмәт иткән бер укытучы нигез салган, имеш. Һәм, күрәсең, бу сүзләрдә гаделлек тә бардыр. Чөнки шул чордан бирле, Саньгуань заставасыннан чыккан затлар армиядә генә түгел, ә дәүләтнең төрле өлкәләрендә дә уңышлы карьера ясый. Күпләре Император сарае каршында югары урыннарда утыра. Элеккеге чик сакчыларының берничәсе музыкантлар, рәссамнар булып китте. Икесе китап күчерү өлкәсендә дан казанып, Чжоуда гына түгел, Лу, Чу кебек читтәге илләргә дә билгеле затларга әверелделәр. Чынлап та, гыйлемгә тартылу, өйрәнү кешенең тормышын үзгәртми калмыйдыр.

Дин Хун хәрби вазифаларын башкарганда да, таләпчән, аз сүзле иде. Дөньяга солдат булып яралган зат хезмәтеннән тыш, тагын ни турында сөйләшсен соң ул? Сирәк кенә, күңеле кушканда, горурлык хисләре яки гаҗәпләнү аша бөек дусты хакында сөйләшештерә. Инь Си – Төньяк-Көнбатыш чик сакчылары округының булачак башлыгы, утыз яшеннән үк генерал дәрәҗәсенә ия, укучылары арасында аеруча тырышы. Әлегә ул капитан, гади застава белән җитәкчелек итә. Хезмәттәшләре дә «еракка китүен» алдан сизенделәр, аңа шелтәләп карадылар, күзләреннән исә көнләшү түгелде: «Нинди уңышлары хакына беркемгә тәтемәгән зур киләчәк юрыйлар соң моңа?» Мөгаен, алар, дәвамчылыкның ни икәнен чамаламыйлардыр, яшь капитаннан бигрәк, укытучы-остазының ни тапшырырга теләгәнен, төп тормыш, хезмәт һәм фикерләү принципларын тирәннән үзләштерүен дә. Хәрби хезмәт баскычлары буйлап, югарырак күтәрелгән саен Инь Си ныгый бара, чик сакчысы намусын бөтенесеннән дә өстенрәк куя. Чик саклау идарәсенең кадрлар белән эшләүче зирәк затлары аны өлкән генералның дәвамчысы итеп күрәләр икән – бу бер дә гаҗәп түгел.

Инь Си мәңгелек кыйммәтләргә басым ясаучан остазын үзе дә хәтер түрендә саклый. Иске дуслары бер үк вакыйганы төрлечә бәян итсәләр дә, капма-каршы нәтиҗә чыгарырга тырышалар, Дин Хун исә нindидер юллар белән элеккеге хезмәттәшләренең һәм иптәшенең авыр хәлен күпертебрәк күрсәтергә ярата. Нәкъ шушы хәл Инь Сине ике укытучының укучысы итте дә инде. Балачактан ук дөньяның яшәеше турында уйланудан туктамаган малай, аларның дәлилләрен, табигать турындагы каршылыклы фикерләрен, явызлык һәм яхшылыкның килеп чыгу сәбәпләрен, дөрес юлдан бару һәм адашуларның сәбәпләрен ачыклаган бәхәсләрен күбек мунчаладай сеңдерде.

Инь Си, кыюлыгы җитеп, Дин Хуннан дәү башлы дусты хакында сөйләвен үтенсә, генералның йөзе балкып китә, кырыслык чалымнары сеңгән күзләрендә тере очкыннар биешә, ул тәфсилләп, вак детальләр аша чираттагы бәхәснең асылын аңлатырга керешә, әлбәттә, бөтенләй килешмәгән очракта да иптәшенә хөрмәт саклый, җиңелчә генә ирониягә, ягъни үз-үзеннән көләргә урын калдыра. Беркайчан да фикерен күпертеп күрсәтми. Кirebетkән әңгәмәдәшенең дәлилләренә төшенергә тырыша, ерактан торып та, генерал белән фәнни бәхәсләр алып бара.

Ә каршылыклар бар. Бигрәк тә, алар бөек эшләр һәм өмет баглау мәсьәләсендә тирәнгә керделәр. Сәбәпләре төрле булып, заставада казарма җирлегенә хас тоелмаганча, монда тәрбияләнүчеләр арасында, кайберәүләр инкарь иткән яшәүнең мәгънәсен эзләүгә, укый-яза белүгә һәм гыйлемгә омтылышка ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләнде. Болар эзсез югалмады: Саньгуань казармасы диварлары арасыннан чыккан дәрәҗәле, исемле ир-егетләр санап бетергесез. Инь Си дә ике укытучының читтән торып еш бәхәсләшүләре, югары дәрәҗәдә сөйләшә белүләре җирлегендә шәхес буларак формалашты. Бу хакта башка вакытта, башка урында да сөйләшеп булыр иде, бигрәк тә беренчесенә бәйлесе – куенында яралганы турында, әмма монысы инде башка тарих.

## 10. Чжан Чженьнең җинаятьтә тотылуы

Гаделлек бинасының барча төшенчә һәм мәгънәләре халык тарафыннан күп гасырлар буена төзелә. Шушы аерата җитди эштә ярыклар хасил итәрлек, байтак кына тоташмаган, бәйләнешсез урыннар, фикер һәм карашлар төрлелеге чагыла, аларның әле каршылыклы мәлдә таралып, ишелеп төшү ихтималы да бар. Һәм моңа кем гаепле соң? Гаделлек исеменнән чыгыш ясаучы хөкемдарлар кайда ул? Алар бит үз җиренең, үз чорының балалары, ә Гаделлек боларга бәйле түгел, чөнки аның вакыты – чиксезлек, урыны да чикле түгел, үзе мәңге үзгәрешсез. Һәм закон үтәүгә бәйле мәсьәләне чишкәндә, аның какшамас шарт-таләпләрен төгәл башкарып кара... Әйе, ачыклык, билгелелек, Намус – патшабикәнең иң йомшак, иң нечкә урыны. Мисаллар артында гамәл тора, шуның берсен сезгә бәян итәм.

Ул чакта бөтенесе дә шик-шөбһә таратучы дәү башлы, ахырда Лао Цзы – Өлкән Укытучы исеме тагылган Ли Эрдан башланды. Илле еллар элек үк тормышның өч җебеннән торган төен бәйләнде: икенчесе – яшь хезмәт итүчеләр арасында Өлкән чик сакчысы кушаматы белән йөргән, вафатыннан соң Мәңгелек сакчы кушаматы алачак Дин Хун, ә өченчесе карт бүре – контрабандист Чжан Чжень тормышыннан гыйбарәт иде. Ә ул төен әлегәчә чишелмәгән...

Салкын, яңгырлы көзге иртә иде ул. Күзәтә торгач, ике яшь чик сакчысы чик бозучы малайны тотып алдылар. Ул ботаклары салынып-салынып төшкән агач төбенә ятып йоклаган иде. Төнге суыктан бөгәрләнеп җыерылган килеш, баш астына пычрак капчыгын салып изрәп киткән.

Ерактан, теге яктан, чик буена якынлашучының ялгыз булуын кичтән үк күрделәр. Эңгер-меңгердә йотылган агач ышыгында төнне үткәрергә һәм иртәнге якта засада урнаштырылган җирдән шыпырт кына таярга чамалаган иде ул. Әмма яшь чик сакчылары өлгерлек күрсәтте, сиздермичә генә аның

янына килеп тә җиттеләр. Чик бозучы янындагы агачта зур елан башын күтәреп ысылдап куйды. Дин Хун югалып калмады, җитезлеге җитеп, үткен кылычы белән аны чабып өзде.

Малай да башын күтәрде, шылу ягын карарга өлгергәнче, бердәм рәвештә аңа ташландылар һәм тиз генә кул-аякларын ныгытып бәйләп тә куйдылар.

Бу – Чжан Чжень иде.

Чарасызлыктан ул такмаклый-такмаклый елады. Малайлар шуны белде: аны өендә үлем хәлендәге авыру әнисе көтә, әлегә кечкенә сеңлесе генә карап тора, ә әтиләре дилиннарга каршы сугышта күптән һәлак булган, имеш... Әгәр дә ул тиз арада кайтып өлгермәсә, әнисе белән кечкенә сеңлесе дә ачлыктан җан тәслим кылачак...

Малайның капчыгын актарганда, яшь чик сакчылары аннан дәва үләннәре, женьшень тамыры һәм ниндидер авыр ташлар таптылар. Һәм бердәм фикергә килә алмыйча, сөйләшер өчен бераз читкәрәк киттеләр. Дин Хун тотылучыны заставага алып кайтып тапшырырга тәкъдим кертте. Башлыклар нишләтәсен безгә караганда яхшырак белә, үзләре хәл итсен, диде. Чөнки чик бозучыны бу тирәдә берничә кат күргәне бар, әлеге җирлектә адашмый йөри алуын да чамалый иде.

Ә Ли Эр малайны этә төшеп, дусты янына килде, әллә ни зур гаебе булмаган тәртипсез затны авыру әнисе янына кайтарып җибәрергә тәкъдим итте. Дару үләннәре дә, женьшень тамыры да чикнең аргы ягында үскәнгә ул гаепле түгел бит, диде. Әнкәсе алдында ул балалык бурычын үти, аны үлемнән йолып алу өчен үзен нинди куркыныч көткәнен дә аңламыйча, дәва үләне эзләп килгән ләбаса, диде.

«Балалык бурычы» дигән сүзне ишеткәч, Дин Хун бераз йомшый төште. Аның да, кайдадыр, еракта, тигезлекләр аръягында әнисе яши бит. Хәзер ни хәлләрдә икән ул?

– Ярар соң... Бу дәлил белән килешергә дә була. Алдашмаса, әлбәттә... Әгәр дә дөресен сөйләмәсә? Йә, ничек тикшерик?

– Ышаныйк та кайтарып җибәрик, шул гына... Алдаша икән – гөнаһысы үзенә. Киләчәк язмышына без тыкшынмыйбыз, – диде Ли Эр.

– Шулай да, әгәр алдашса?

– Намусы тынычлыкта калдырмас, барыбер бер җәзасын алачак. Монда булмаса, башка җирдә, хәзер булмаса, соңрак...

– Әмма безгә дәүләт чикләрен ышандырдылар бит. Без Император алдында ант иттек, чик бозучыларга карата рәхимсез булырбыз, дидек. – Дин Хун һаман икеләнә иде. – Үзебез генә шундый карарга килә алабызмы соң без? Хөкемдарлар түгелбез, болай ярамас...

– Сөйләп торасың тагын, дәүләт, чик буе, Император, имеш... алар һич какшамаслык, бу бәхетсез малайны хаста әнкәсе янына җибәргәннән колаклары да селкенмәячәк... Ә безнең киң күңеллелектән дәүләт рухи яктан ныгыр гына...

– Монысын кайдан өйрәнеп өлгердең тагын? Дәүләт кальгасына рухи әйберләрнең һич катнашы юк. Аның бөтен көче безнең чикләр ныклыгын тәэмин итүдә. Теләгән бер кеше аны боза башласа, ахыры ни белән бетәр соң? Дәүләт үзе калырмы аннары?..

Малайлар тоткынның кулларын чишеп, постка алып килделәр. Учак кабызып җибәрделәр, казанда елан ите пеште. Иртәнге таң нурлары җиргә

чәчелгәндә, өчәүләп утырып ашадылар. Чжан Чжень аларның яшьтәше булып чыкты, болар икесе дә аңардан хәрби киемнәре белән генә аерыла иде.

Дин Хун тоткынны кызганып куйды, тегесе дә тиз сизеп алды, әле генә үзен саклаучылар белән һич оялусыз елан ите сыпырткан малай янә үлем түшәгендә яткан әнисен һәм бәхетсез сеңлесен искә төшереп, такмаклап еларга кереште.

Дин Хунга күз яшьләре тәэсир иттеме, ул дустын читкәрәк чакырып, күзләренә туры карап, сорау бирде:

– Хәл итик, нишлибез? Тиздән безгә алмаш килә, тикшерүче дә...

– Минем фикерне беләсең... Син – постның өлкән сакчысы, үзең хәл ит, – диде Ли Эр.

– Хәйләкәр син! Игелекле зат булып калыргамы исәбең? Ә җаваплылыгы миңамы?

– Командир итеп сине куйдылар бит, шуңа үзең хәл ит инде...

Әле солдат булып та җитешмәгән, пост өчен генә җаваплы саналган яшүсмер Дин Хун кирәкле карарны кабул итүнең чиксез авырлыгын беренче мәртәбә тойды. Икеләнүләр, бигрәк тә кызгану хисен җиңә алмыйча, Дин Хун хезмәт бурычын үтәүдәге озын-озак гомерендә беренче һәм соңгы хатага юл куйды: чик бозучыны ирекқә җибәрде. Ике яшь чик сакчысы да бу мәлдә үзләренчә канәгатьлек хисләре кичерде: законга сыешмаса да, һич бәхәссез яхшы гамәл кылдылар, берәүне катгый җәзадан коткардылар, ә аның язмышын сындырырга да күп кирәкмәс иде бит...

Әмма бер айдан Чжан Чжень яңадан эләккәч, икесе дә тәмам аптырашта калды. Элеккеге акланулар кабатланды: әнкәсе терелмәгән, дару үләннәре беткән, инде яңаларын юллап килүе икән...

Ли Эр яңадан тәртип бозучы ягына авышты:

– Бер мәртәбә ышандык бит, икенчесенә дә ышанырга кирәк, – диде. – Намус кушканча эшлик...

Дин Хун бу юлы килешмәде.

– Мин хәл итмәм, тәртип бозучыны командирларыма тапшырам да, нишләргә кирәген үзләре белерләр, кызгансалар – җибәрерләр, кызганмасалар, закон үзе юл күрсәтер, – диде.

Кояш Куньлунь тавы сыртына күтәрелгәч, аларга алмаш килде һәм тикшерүче тоткынны билгесезлеккә таба алып китте.

Шуннан соң күп сулар акты, күп еллар үтте. Чик сакчыларына, тоткынны хөкемдарлар өч елга ирегеннән мәхрүм иткән, аны флотта юнга, ягъни сәүдә судносы өйрәнчеге хезмәте белән алыштырганнар икән, дигән хәбәр килеп иреште.

Дин Хун бу хәлне үкенеп искә алды: Чжан Чженьнең гаиләсе һәм үзенең язмышын бәләсе килде.

Вакытлар үтте, яшь чик сакчыларының да мәҗбүри хезмәт вакыты чыкты.

Ли Эр туган җиренә кайтып, катгый карарга килеп, дәүләт хезмәтенә керү өчен имтихан сынаулары үтә башлады.

Дин Хун исә, бераз икеләнүләрдән соң, әлбәттә, үз теләге белән, ирекле килешү нигезендә күңеленә хуш килгән чик саклау хезмәтен дәвам итте.

# БАКЧАЧЫ, ГАЛИМ ҺӘМ ЯЗУЧЫ

## ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Миңа бу язманы язу авыр булды. Әмма бу фәнни, публицистик мәкаләләр, китаплар язгандагы авырлык түгел, бәлки, психологик авырлык, күңел кыенлыгы. 60 елдан артык гомерне, якыннан аралашып, дус булып, авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне һәм шатлыкларны уртаклашып яшәгән, әле кайчан гына хәлләребезне белешеп, бер-беребезгә киңәшләр биреп, күңелләребезне күтәрешеп торган кеше турында үзе якты дөньядан китеп барганнан соң юксынып, сагынып язу авырлыгы бу.

Фарсель Зыятдинов белән беренче тапкыр 1960 елның август көненнән алып, 2021 елның август көненә кадәр булган йөзләрчә вакыйгалар, күренешләр бер-бер артлы күз алдыннан уза. 1960 елның августында без, бер төркем татар егетләре һәм кызлары, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты бинасында, шушы уку йортына керү өчен кабул итү имтиханы тапшырырга җыйналган идек. 2021 ел августы көнендә исә мин Республика больницасында инде айдан артык аңсыз (комада) яткан Фарсельнең хәлен белергә дип килгән көн иде. Ясалма сулыш алдыру аппараты куелган Фарсель дус тын гына йоклап ята сыман. Колагына якын килеп, әкрен генә дәшәм: «Фарсель, мин Рүзәл, ишетсәң, минем сүзләремә төшенгәнлегеңне сиздереп, керфекләреңне как. Без сине онытмыйбыз, синең өчен борчылабыз, сәламәтләнүеңне телибез». Сүзләремне тагын ике тапкыр кабатлыйм. Ләкин керфекләр селкенми. Берничә көннән Фарсель фани дөньядан китеп барды...

Хәзер, Фарсель Зыятдиновның тууына 85 ел, вафатына бер ел тулып килгән көннәрдә журнал укучыларны һәм алар аша башкаларны да бу күркәм кешенең биографиясендәге кайбер аеруча гыйбрәтле хәлләр белән кыскача гына таныштырып китү зарур. Бу язмабыз аның якты истәлеге булсын.

Фарсель Зыятдиновның, тынгысыз кеше буларак, үз гомерендә кылган игелекле гамәлләре күп төрле. Аның энергиясе һәркайчан һәм һәркайда ташып торды, ул эшләп өлгергән эшләрнең күплегенә һәм күп төрле булуына гаҗәпләнми мөмкин түгел.

Без, Фарсельнең университет буенча сабакташлары, аның үзенә бертөрле тиктормас, тынгысыз, төкәнмәс энергияле кеше икәнлеген вузда укыган чактан ук күрдек. Тик, соңыннан мәгълүм булганча, анда бу сыйфатлар элегрәк салынган булган икән инде. Университетта укыган чорда исә ул бу үзенчәлеге белән барыбыздан да аерылып торды. Хәлбуки, безнең группа егет-кызларының берсен дә уңмаган дип әйтерлек түгел иде.

Фарсель, тырыш студент булуы белән бергә, бик актив җәмәгать кешесе булды, факультет комсомол комитетының курс бюросы секретаре вазифаларын башкарды. Ул елларда исә комсомол, гомумән, В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында бигрәк тә, алдынгы иҗтимагый көч иде. Шул ук вакытта Фарсель газета-журналларда мәкаләләрен, шигырьләрен бастыра, факультеттагы әдәби түгәрәк эшендә, башка төрле чараларда катнаша. Шуның өстенә, ул университетта укуы белән бергә читтән торып, Казан авыл хуҗалыгы институтында да укып йөргән. Нәтиҗәдә Фарсель 1965 елны филолог дипломы, бер елдан икътисадчы дипломы алды. Армиягә алынганчы, ул, Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, агроном белгечлеге алган була инде. Һәм менә кызыклы хәл: бу өч белгечлеккә ия булу Фарсельнең тормышында өч төрле тармакта уңышлы хезмәт итү мөмкинлеге бирә. Университет белеме белән

күренекле журналист һәм язучы булып китә. Авыл хуҗалыгы институтында алган белеме аңа, икътисад фәннәре докторы һәм профессоры буларак, игелекле гамәлләр кылырга юл ача, агрономлык белеме исә аны республикабызның һәркемгә мәгълүм бакчачысы итеп таныта. Фарсель Зыятдинов бу өлкәләрнең өчесендә дә күңел биреп, җиренә җиткереп эшли, табигатьтән килгән рухи һәм физик көч аңа аларның һәркайсында да күркәм нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген бирә.

Бакча җене Фарсельгә кечкенә чагыннан ук кагылган була. Аның туган җире Актаныш районының Качкын авылына урыс авылларыннан марҗалар килеп, тозлаган кыяр, помидор сатып йөриләр. Бу хәлне күреп йөргән Фарсель: «Нишләп соң без тозлаган яшелчәне дә руслардан сатып алып яшибез әле, үзебез үстерә алмыйбыз микәнни?» – дип уйлана. Ул елларда һәм аннан элегрәк тә Актаныштa гына түгел, башка районнарда да татарлар, гомумән, яшелчә үстерү белән дә, җиләк-җимеш агачлары утырту белән дә шөгыльләнмәгән. Фарсель, кайдандыр кыяр орлыклары юнәтеп, аларны бакчаларына утыртып, су сибеп тәрбияләп үстерә. Тиздән сугыштан әтисе кайтасы хәбәрен ишетеп, кыярларын, ул кайтканны көтеп, саргаеп беткәнче саклап тора. Әтисе кайткач, улының бу шөгылен күреп, аның күңелен күтәреп җибәрә. Фарсель әтисе белән бакчаларында башка төрле яшелчәләр дә үстерә, аннары булачак бакчачы малай җиләк-җимеш агачлары үстерү белән шөгыльләнә башлый. Зыятдиновлар бакчасындагы нигъмәтләрне күреп, авыл халкы да, әкренләп, бу эшкә керешә.

Җиргә тартылу, бакча җимешләрен үрчетүгә күңелен салу Фарсельнең, мәктәпне тәмамлагач, Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумына кереп укуына сәбәпче була. Техникумнан соң берникадәр вакыт Арча районында агроном булып эшләү дәверендә ул андагы халыкка бакчачылык белән шөгыльләнү идеясен тарата башлый. Тиздән, армиягә алынып, топограф-геодезист сыйфатында Кавказ тауларындагы күкрәп үскән җиләк-җимеш, яшелчә бакчаларын күреп йөрү Фарсельнең күңелен тагын да ныграк иләсләндерә, һәм бу хисләр киләчәктә аның, Татарстан халкын бакча эшенә өйрәтүче төп белгеч буларак, игелекле гамәлләр кылуына китерә. Күп меңләгән радио тыңлаучылар эфирдан күп еллар буе бакчачы-галим Фарсель Зыятдиновның бакча нигъмәтләрен дөрес итеп үстерү, тәрбияләү, саклау турындагы әңгәмәләрен, киңәшләрен көтеп алып тыңлыйлар. Меңләгән, миллионлаган бакчачылар хәзер дә Фарсель абыйларының эфирдан салмак тавыш белән сөйләгән тапшыруларын сагынып искә алалардыр.

Фарсельнең фидакарьлек сәләте университетта укыганда ук күренә иде инде. Әйтелгәнчә, берьюлы ике вузда уңышлы укып бару, шуның өстенә, һәртөрле җәмәгать эшләрен башкару, журналистлык, иҗат эшләрендә дә үзен күрсәтү бик сирәк кешенең генә көченнән килергә мөмкин. Хәер, безнең студентлар группасында эленке-салынкы гына укып-эшләп йөрергә мөмкин дә түгел иде. Безнең ул вакыттагы егет-кызларыбыз хаклы рәвештә мактанырлык һәм горурланырлык булды. Бу хәл укуның беренче көннәреннән үк башланды. Үзенә бертөрле гаҗәеп яшьләр тупланган иде безнең группада. Егетләрнең барысы да диярлек армиядә хезмәт итеп кайткан, кайберләре хәтта кабул итү имтиханнарында да солдат киеменнән иде әле. Кызларның да күбесе ике-өч ел эшләп килгән. Димәк, Владимир Ульянов-Ленин укыган шөһрәтле уку йортына иң тырышлар, әзерлеклеләр генә кабул ителгән. Ул елларда татар яшьләрендә миллилек рухы, Ватанга, халыкка хезмәт итү, максатлы яшәү омтылышы көчле иде. Барыбыз да, теш-тырнагыбыз белән ябышып дигәндәй укыдык һәм һәртөрле җәмәгать эшләрен актив башкардык.

Берничә елдан бу группада укып чыккан егет-кызларның барысының да күренекле кешеләр булып, республикабыз мәдәниятенә, мәгарифенә һәм фәненә зур хезмәт күрсәтүе очраклы хәл түгел. Фирдәвес Гарипова, Флёра Баязитова – фән докторлары, күп гыйльми китаплар авторлары, Равил Фәйзуллин – халык шагыйре, Г.Тукай премиясе лауреаты, парламент депутаты, Фарсель Зыятдинов – фән докторы, язучы, Петров академиясе академигы, Ленар Җамалетдинов – өлкән гыйльми хезмәткәр, Г.Тукай

премиясе лауреаты, Әнвәр Шәрипов – фән докторы, язучы, Шәрифҗан Асылгәрәев – фән кандидаты, Тел, әдәбият, сәнгать институты директоры урынбасары, Шамил Маннапов – шагыйрь, журналист, Лениза Галиева – алдынгы педагог, Татарстанның атказанган укытучысы, Роза Ханнанова – Татарстанның китап палатасы директоры, Рүзәл Юсупов – Татарстан Фәннәр академиясе һәм башка академияләр академигы, Дәүләт премиясе лауреаты, парламент депутаты, Казан педагогика университеты ректоры. Бу исемлекне дәвам иттерергә мөмкин әле.

Безнең группа студентларының хәзерге буын студентларына үрнәк булырлык гамәлләре турында күп сөйләргә була. Мәсәлән, тагын бер күркәм күренеш. Безнең кайберләребезгә өченче курстан индивидуаль план дип аталган махсус план буенча уку һәм фән белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирелде. Өчебез – Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов һәм мин, шундый индивидуаль план буенча укып, биш еллык уку планын дүрт елда тәмамлап, өчебез дә бер вакытта Татарстан радиосында эшли башладык. Бу хәлнең инициаторы Фарсель булды. Ул беренче курстан ук нәшрият, матбугат, радио, телевидение кебек оешмаларга юлны яхшы белә иде. Бу очракта аның җитезлеге, белдеклелеге безнең өчебезгә дә бик ярап куйды. Башта ул үзе радионың авыл хуҗалыгы тапшырулары редакциясе хәбәрчесе булып урнашты. Ул арада, музыка тапшырулары редакциясендә редактор урыны бушаганлыгын белеп алып, шунда Ленар Җамалетдиновны чакырып китерде, һәм шагыйрьлек, җыр язу сәләтләренә ия булган Ленар музыка редакциясендә эшли башлады. Бер җай килсә килеп тора бит ул: шул көннәрдә радионың күп еллар эшләгән күренекле тәрҗемәчесе Абдулла абый Төхфәтуллин пенсиягә чыгарга әзерләнә башлаган. Бу хәлне белеп алган Фарсель Абдулла абыйдан бушаган урында эшләргә мине дә дәшеп алды. Мин, университетта индивидуаль план белән укып, тәрҗемә теориясеннән өстәмә белгечлек алган кеше буларак, тәвәккәлләп карарга булдым. Мине дә тәрҗемәче итеп алдылар. Шулай итеп, без бер группадан бер вакытта диярлек өчебез дә радио хезмәткәрләре булып киттек.

Фарсель өчен радионың авыл хуҗалыгы редакциясендә башта хәбәрче, аннары редактор булып эшләү – балык өчен су кебек иркен мәйдан булды. Ул авыл халкы өчен тапшырулар әзерләп эфирга бирү эшенә баш-аягы белән чума. «Авыл таңнары», «Авыл офыклары» дигән тапшыруларда җир кешеләрен файдалы, әһәмиятле мәгълүмат белән сугара, үзенең кечкенәдән үк күңелендә йөрткән Татарстан халкын бакчачылык шөгыленә күнектерү хыялын гамәлгә ашыра башлый. Аның бу өлкәгә караган тапшырулары радио тыңлаучыларда зур кызыксыну уята. Бу тема буенча тапшыруны алып баручы Фарсель Зыятдинов белән радио тыңлаучылар арасында җанлы элемтә урнаша. Фарсель авыл хуҗалыгы тапшырулары белән параллель рәвештә яшьләр өчен тапшырулар әзерләргә дә өлгерә. Ул эфирга «Яшьлек радиодулкынында» дигән яңа рубрикалы кызыклы тапшырулар әзерләп, тиз арада яшьләрнең ихтирамын казана.

Татарстанның авыл хуҗалыгы гыйльми тикшеренү институтында фәнни-техник информация һәм пропаганда бүлеге мөдире булып эшләгән 1970-1986 нчы еллар – Фарсель Зыятдинов гомеренең аеруча зур нәтиҗәле чоры. Аның бу дәвердә башкарган эшләрен саный башласаң, таң каласың. Ф.С.Зыятдинов җитәкчелегендәге бердәм коллектив бу елларда күп фәнни тикшеренүләр үткәргән, авыл хуҗалыгы өчен әһәмиятле ачышлар ясаган. Зур оештыру эшләре башкару белән бер үк вакытта, Фарсель авыл хуҗалыгы институтындагы аспирантурада укып, диссертация яклап, икътисад фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була. Аннары шушы институтның икътисад бүлеген җитәкләгәндә, монографияләр, авыл хуҗалыгына һәм икътисадка караган, күренекле шәхесләргә багышланган публицистик әсәрләр яза. Матди-техник, хезмәт ресурслары һәм алардан агропромышленность комплексларында нәтиҗәле файдалану турында 7 монография язу өчен аңа күпме тәҗрибәләр үткәрергә, эзләнүләр белән шөгыльләнергә туры килә!

«Агросәнәгать комплексының ресурс потенциалы: анализ, бәя һәм куллануның

эффектлылыгы» дигән фундаменталь монография күп белгечләрнең популяр әсбабына әверелә. Фарсельнең 230дан артык фәнни-икътисади мәкаләләре – шулай ук фидакарь хезмәте нәтиҗәсе. Моннан тыш, татар телендә «Икътисад һәм бизнес», «Дөньяның икътисади һәм социаль географиясе» дәреслекләрен әзерләү; гомуми белем бирү мәктәпләренең профильле сыйныфлары өчен «Экономика» китабын, соавтор буларак башта рус телендә, соңыннан тулаем татар теленә тәрҗемә итеп чыгару; дистанцион уку өчен «Оешмаларның экономикасы» дигән дәреслекнең электрон вариантын әзерләүдә катнашу, ул эшнең җитәкчесе булу; «Финанс-икътисади һәм юридик терминнар» аңлатмалы сүзлеген төзү... Фарсель Сәхаб улы Зыятдинов 1986 елда Казан финанс-икътисад институтының икътисад һәм оештыру кафедрасы доценты итеп сайлангач, халык хуҗалыгының төрле тармакларына икътисад белгечләре әзерләүгә зур өлеш кертә. Ул, диссертация яклау комиссиясе әгъзасы буларак, яшь галимнәргә ярдәм итә. Аның җитәкчелегендә дистәләгән аспирантлар кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклый.

Татар халкының лаеклы улы, милләт җанлы кеше буларак, Фарсель Зыятдинов укучыларының чын милли кадрлар булуын кайгыртты. Финанс-икътисад институтында, Ислам институтында студентларга лекцияләренең күбесен ул татар телендә укый, икътисад фәнендәге терминнарны аларга татар теленә тәрҗемә итеп өйрәтә. Балалар мондый терминнарны туган телләрендә күреп-ишетеп үссен өчен Фарсель, ул атамаларны кулланып, гади хикәяләр рәвешендәге язмалар әзерли. Финанс-икътисад институтының җитештерү икътисады кафедрасында профессор булып эшли башлаган көннәрендә, Фарсельне Татарстан Фәннәр академиясе президенты, Татар энциклопедия институты директоры Мансур Хәсәнович Хәсәнов үзенә эшкә чакыра.

– Фарсель Сәхабетдинович, син бит үзең – аяклы энциклопедия. Бүлек мөдире итеп эшкә чакырсак, каршы түгелме? – ди ул, аның әллә кайчангы хыялын белгәндәй.

Фарсель инде бик күптән, җитмешенче елларда ук, татар энциклопедиясен төзү кирәклеген белдереп, Мәскәүгә – КПСС Үзәк Комитетына хат язган була. «Андый энциклопедияләр союздаш республикаларда гына эшләнә, Татарстан – автономияле республика», – дигән кыска җавап алгач та, ул өметен өзеп бетерми. Фарсель Мансур Хәсәновичның тәкъдименә шатланып риза була.

Финанс институтында укытуын дәвам иттергән килеш, Энциклопедия институтында эшли башлагач, вакыт тагын да кадерлерәк булып китә. Монда эш шулкадәр күп: тавык чүпләп бетерерлек тә түгел. Фарсель, үзе җитәкләгән бүлек хезмәткәрләре белән берлектә, башта энциклопедик сүзлекнең караламасын эшләүне максат итеп куя. Сүзләр, терминнар, шәхесләр турында язу зур төгәллек сорый. Шәхесләр тормышына кагылышлысы аеруча җитди караш, көч һәм эзләнү таләп итә, чөнки кайчагында йә билгесезлеккә, йә төрлелеккә килеп төртеләсең дә чынбарлыкны ачыклау өчен әллә никадәр вакытыңны түгәргә мәҗбүр буласың.

Мәгълүматның дөреслеге, төгәллеге өчен көнне төнгә ялгап чапкан чаклар аз булмый. Юл йөрүләрнең, эзләнүләрнең, түгелгән көчнең куанычлы нәтиҗәсе башта терминнар сүзлеге, кыскача русча-татарча сүзлек, аннары том артыннан том булып дөнья күргән 6 томлык татар энциклопедик сүзлекләре булды.

Фарсель, аяусыз хезмәтенең җимеше буларак, 2002 елда «Агросәнәгать комплексы ресурс потенциалыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү» дигән темага докторлык диссертациясен яклый.

Ф.С.Зыятдинов белән якыннан аралашкан кешеләр беләләр: ул искиткеч эшчән, тырыш булуы белән бергә, ярдәмчел, игътибарлы, сабыр, намуслы, үзенә авырлык алып булса да, кеше гозеренә илтифатсыз кала алмый. Язмада санап кителгән күп рәсми эшләре белән мәшгуль булуына карамастан, ул халык өчен файдалы җәмәгать эшләреннән дә баш тартмады. Үзгәртеп коруның кырыс җилләре искән елларда социаль-икътисади кыенлыклар эчендә калган халыкка мораль ярдәм итү, аның чарасызлыктан гаҗиз булып калган башындагы аптыраулы сорауларына җавап бирү

нияте белән, «Татарстан яшьләре» газетасында «Авылга, Нәфисә апага» дигән рубрика ачып, укучыларның күпсанлы сорауларына җавап һәм файдалы киңәшләр биреп килде, Россиядәге проблемаларны, икътисадтагы буталчык хәлләрне гади кешеләр аңларлык телдә тасвирлап барды. Аның «Татарстан», «Тәртип», «Болгар» радиоканалларындагы бакчачылык турындагы тапшырулары, тыңлаучылар белән әңгәмәләре, аларга биргән киңәшләре мәгълүмат чаралары тарихының истәлекле матур сәхифәләрен тәшкил итә.

Халыкта булдыклы кеше бөтен яктан да сәләтле була, дигән гыйбарә бар. Бу сүзләр безнең язмабыз героена да туры килеп тора. Фарсельнең биографиясе аның монда сурәтләнгән игелекле гамәлләре, казанышлары, икътисадчы, педагог, бакчачы һәм башка рәсми эшләре белән генә чикләнми. Ул күренекле язучы да әле. Аның бу һөнәре дә бер яклы гына түгел: ул шагыйрь дә, прозаик та, балалар язучысы да, публицист та... Аның «Кызык уен» дигән шигырьләр, «Минем әни» исемле хикәяләр җыентыклары, «Гыйльми белән Белми», «Безнең гомер», «Изге йорт» дигән китаплары татар укучыларына яхшы таныш. «Читекле кәтүк» китабы өчен аңа Абдулла Алиш исемендәге премия бирелде, «Ата күңеле балада» дигән китабы «Ел китабы» бәйгесендә җиңүче булды. Фарсель китаплары, нәфис әдәбиятка караганнарын да, публицистик һәм фәнниләрен дә исәпләгәндә, өч дистәдән артып китә.

Күренекле шәхесләр турында язганда, укучыда табигый рәвештә, аларның кылган гамәлләре, казанышлары белән танышудан тыш, шәхси тормышларын беләсе килү теләге дә туа. Күп кешеләрнең тормышында шатлык-сөенечле күренешләр, уңышлар авырлыклар, драмалы һәм фаҗигале хәлләр белән үрелеп бара. Фарсельнең дә шулай булды: хезмәтендәге казанышларының, күркәм хәлләренең шатлыгын шәхси тормышындагы авыр сынаулар, кайгылы вакыйгаларның караңгы шәүләсе шактый нык каплады. Сабакташларына, шул исәптән миңа да, бу күренешләрнең шаһиты булырга һәм дустыбызның борчуларын күреп-белеп һәм уртаклашып торырга туры килде.

Фарсельнең гаилә тормышы матур башланып киткән иде. Ул университетта укуының соңгы елында татар филологиясе бүлегендә бездән ике курс түбәнрәк укучы уңган, чибәр студент кыз Фирая белән тормыш корып җибәрде. Бу Әтнә районы кызы, укуда һәм эштә өлгер булуы белән бергә, матур-матур шигырьләр яза торган шагыйрә булып китте. Бер-бер артлы китаплары басылып чыга торды, шигырьләренә күренекле композиторлар матур җырлар иҗат иттеләр. Аның җырларын халык хәзер дә бик яратып җырлый. Фирая, укуын тәмамлап, Татарстан китап нәшриятының редакторы булып эшли башлады. Тиздән Зыятдиновлар гаиләсенең шатлыгы Алсу дөньяга килә. Бәхетле, тигез тормыш гөрләп бара. Әмма бераздан бу гаиләгә кара кайгы канатын җәя: йөрәк җимешләре Алсуларын ике яше тулганда, салкын җир үз куенына ала...

Тормыш дәвам итә. Фарсель белән Фираяның бер-бер артлы өч улы – Айдар, Айваз, Айнур дөньяга килеп, аларның тормышларына ямь өсти. Әмма дөнья гаделлеккә, шатлыкка гына корылмаган шул, Зыятдиновлар гаиләсенә тормыш яңа сынаулар, хәсрәтле сынаулар китереп тора: 90 нчы еллар башында Россиядә күтәрелеп киткән тәртипсезлек, җинаятьчелек шаукымы Фарсельләрнең уллары Айвазга да зәхмәтен тидерә. Аны беркөнне кичен өйләренә кайтып барганда, хулиганнар, гаепсезгә бәйләнеп, бик каты кыйнап ташлыйлар. Сәламәтлегенә зур зыян килә. Бәла ялгызы гына йөрми, диләр. Берничә елдан кече уллары Айнур, мотоциклда зур авариягә эләгеп, нык зәгыйфьләнеп кала. Ата-ана чыдасын гына. Ул арада Фарсель тагын бер бик авыр сынауга дучар була. Аның иң кадерле кешесе – күркәм, сөйкемле хатыны, уңган хуҗабикә, күренекле шагыйрә Фирая вакытсыз вафат була. Килсә килә икән адәм баласына кыенлыклар. Берникадәр вакыттан чираттагы кайгы: икенче улы Айваз да фаҗигале төстә дөньядан китеп бара.

Түзә Фарсель, сынмый, сынатмый. Ул элеккечә тормыш арбасын җигелеп тарта: күп эшли, иҗат итә. Шушы актив яшәве, коллективта булуы аңа зур хәсрәтләрдән бөгелеп төшмәскә ярдәм иткәндер.

Бәхетенә, Фарсельгә, Фирая вафатыннан берничә ел узгач, бер хәерле очрак ярдәмгә килә. Ул яшь чакта ук таныш булган, хәзер шулай ук ялгызы калган Венера ханымны очрата. Сөйләшәләр, аңлашалар. Зур тормыш юлы узган, җаваплы эшләр башкарып килгән Венера Фарсельнең хәленә, язмышына битараф калмый, күп җәфалар чиккән, ат кебек эшли торган бу игелекле ир затына турылыклы иптәш булып, ярдәм кулы сузарга карар кыла: алар бергә яши башлыйлар. Фарсельнең дөньясы яктырып китә, аның яшәү көче арта. Ярдәмләшеп, аңлашып, бер-береңне ихтирам итеп яшәүгә ни җитә. Венера гаиләдә кайгыртучан хуҗабикә була, Айваз белән Айнур да игелекле хатын-кыз тәрбиясе күрәләр.

Венера ханымның безнең хөрмәтле сабакташыбызга ихтирамлы, җылы мөнәсәбәтен, Фарсельгә, каты авырып китеп, озак вакыт аңсыз (комада) яткан чагында тәрбия күрсәтүен, соңгы юлга озаткач та, төрле мәшәкатьләрне, авыруксынмыйча, үз өстенә алуын һәм аның исән чагында бастырып өлгерми калган китапларын, кулъязмаларын дөньяга чыгару өчен тырышып йөрүен лаеклы бәяләп, аңа ихтирамлы булуны бурычым дип саныйм.

Фарсель Зыятдинов шанлы тормыш юлы узды, аның башкаларга, шул исәптән безнең кайбер татар интеллигенциясе вәкилләренә дә үрнәк булырлык гамәлләре күп. Ул – мәдәниятнең, фәннең, иҗатның күп төрле тармакларында армый-талмый хезмәт итүе белән сокланырлык күркәм кеше, татар халкы өчен җан атып йөргән милләтпәрвәр буларак та зур хөрмәт белән искә алырлык олуг зат. Мин аның 1990 еллардан илебездә, республикабызда башланган социаль-сәяси күтәрелештә, халкыбызның үзаңы, иреге, милли үсешенә кагылышлы вакыйгаларда актив катнашуының шаһиты булдым. Без аның белән башка фикердәшләребез катнашуында республикабыз халкының һәм күп җирләрдә чәчелеп яшәгән татарларның бәхетле тормышы өчен хезмәт итәргә тиешле Татарстанның Республика партиясен оештырдык, аның программасын, уставын төзедек, «Татарстан Республикасы» исемендәге газетасын чыгарып, анда көн үзәгендәге әһәмиятле вакыйгаларга багышланган мәкаләләр, партия исеменнән җитди белдерүләр бастырып килдек.

Тынгысыз, бик эшлекле кеше булуына өстәп, аның сәяси активлыгын да күрсәтеп үтәргә кирәк: ул милләтебез, аның теле, мәдәнияте мәсьәләләренә багышланган чараларда катнашмый калмады, хәтта соңгы вакытларда, сәламәтлеге какшагач та, Хәтер көне митингларына килә иде.

Татар халкы Фарсель Сәхабетдин улы Зыятдиновны хаклы рәвештә үзе исән чагында яхшы белә һәм хөрмәт итә иде, хәзер дә онытмый. Аны бигрәк тә якташлары олылый, хатирәләрен кадерләп саклый. Туган авылында аның музеен оештыру – шушы хөрмәтнең матур мисалы.

Фарсель Зыятдинов халкына, җәмгыятькә файда китерерлек итеп, дәртләнеп, илһамланып эшләгән, иҗат иткән ялкынлы йөрәкле шәхес, мәгънәле яшәүнең матур үрнәге буларак, күпмеңләгән милләттәшләренең күңелендә озак сакланыр.

**Рүзәл ЮСУПОВ**

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,*
*Фарсель Зыятдиновның үзе укуында*
*шигырьләр тыңлый аласыз.*
*1990 елларга караган язма.*

Fən
Фән

# ТАТАР ТАРИХЫННАН ЭНҖЕ ЭЗЛӘҮЧЕ ГАЛИМӘ

Татар халкының күп кенә төркемнәре гасырлар дәвамында үз туган җирендә, асыл ватанында, әмма Казаннан, Татарстаннан читтә гомер итә. Без, мәркәздәгеләр, алар хакында күпмедер хәбәрдарбыз. Алар исә милли үзаңын, татар икәнлекләрен белеп, үз тарихын һәм мәдәниятен өйрәнеп, шулар белән горурланып яшәргә омтыла. Ерак тарихка реконструкция ясап, читтәге милләттәшләребездә милли-мәдәни үзаң булдыруны да, аларның яшәешен, үткәнен һәм киләчәген – безгә танытуны да, иң беренче чиратта, аларның галимнәре, шулай ук мөгаллимнәре, сәнгатькярләре кайгырта. Татарстаннан еракта яшәп тә, татар тематикасы белән шөгыльләнүче гыйлем ияләре – дәвамчанлык җепләре өзелмәүне тәэмин итүчеләр алар!

«Казан утлары» журналы укучыларына тәкъдим ителә торган бүгенге кунагыбыз – Вильнюс университетының филология факультетында эшләүче дөньякүләм танылган галимә, ачык йөзле гыйлем иясе Галина Мишкинене – шундый гаҗәеп затларның берсе. 600 елдан артык элеккеге Литва Бөек кенәзлеге җирләрендә яшәгән татарларның нәсел кыйпылчыгы, дәвамчысы ул[1]. Үзенең гомерен бабаларының язу тарихын өйрәнүгә багышлаган шәхес.

1966 елның 29 апрелендә литва татарлары гаиләсендә кыз бала туа, исем кушып азан әйткәндә, Галифә дип тәгаенлиләр. Үзенең гаиләсен Галифә-Галина Александрович гадәти, традицион татар гаиләсе дип атый: монда үзләренең тарихын, мәдәниятен яхшы беләләр, дини йола-гадәтләрне башкаралар. Әбисе Елена Полторжицкая ягына карасаң, аның әтисе Александр Полторжицкий – хәрбиләрдән (гомумән, Литва Бөек кенәзлегендә яшәгән татарлар – борынгыдан шәүкәтле сугышчылар!), әнисе Мәрьям Полторжицкая – гаилә учагын саклаучы, үзенең һәм башка балаларны Коръән укырга, дини йола-гадәтләргә өйрәтүче мөгаллим, аларны биредә «хуҗа» дип атыйлар. Бабасы Мостафа Александрович бала вакытта ук (6 яшендә) ятим кала, күп авырлыкларны җиңеп, күн эшенә керешеп китә, күн эшкәртүче иң мәшһүр татар осталарыннан була. Гаилә Литваның көнчыгышында урнашкан Игналино шәһәрендә яши. Татарларга хас булганча, балаларының гыйлемле булуын, югары белем алуын максат итеп куялар. Галинаның әнисе Тәнзилә Александрович (1945–1992), Вильнюс педагогика институтын биология һәм химия белгечлеге буенча тәмамлап, гомере буе Игналинодагы урта мәктәптә балалар укыта.

Галина Александрович 1983 елны мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Вильнюс университетына укырга керә. Гаиләдә кабул ителгәнчә, математик-техник юнәлешне сайлар дип уйласалар да, күрәсең, татар кызының язмышына үз милләтенең фәне белән

[1] Элеккеге Литва Бөек кенәзлеге җирләре хәзер өч дәүләткә: Беларусь, Литва һәм Польшага карый. Беларусь Республикасы Милли статистика комитеты сайтында соңгы тапкыр Халык санын алу (2009 ел) мәгълүматлары буенча, Беларусьта татарлар 7316 кеше (0,1 %), Литвада Халык санын алуга (2011 ел) нигезләнгәндә – 2793 кеше (0,09 %), Польшада исә (2011 ел), Милли статистика комитеты хәбәренә караганда, 1828 кеше исәпләнә.

Литва Статистика департаменты (2011 ел) аларның яшәү географиясен болай билгели: 1517 татар – Вильнюста һәм Вильнюс округында, 408 – Алитус округында, 249 – Каунас округында, 233 – Утенс округында (аларның 170-е – Висагинас шәһәрендә), 215 – Клайпедада һәм Клайпеда округында, 171 башка урыннарда яшиләр.

шөгыльләнү язып куелган була! Аның юлына фәннәр докторы, профессор, һабил[2] Валерий Николаевич Чекмонас очрый. Әлеге харизматик шәхес йогынтысында Галина һуманитар өлкәне, Вильнюс университетының филология факультетындагы рус теле һәм әдәбияты белгечлеген сайлый. Бер ел укып, инде математика факультетына күчәргә җыенган бер вакытта, шул ук профессор В.Н.Чекмонас аңа үз бабалары (татарлар) тарихын өйрәнү һәм литва татарлары язмачылыгы белән шөгыльләнү тәкъдимен ясый. Профессорның сүзләре өйнең иң түрендә дини китапларны (Коръән, хамаилләр) күз карасыдай кадерләп саклаган, әби-бабай үрнәгендә барлык мөселман йола-гадәтләрен үтәп яшәгән гаиләдә хуплау таба.

Гомумән алганда, литва татарларының беркемнекенә дә охшамаган гарәп язулы китаплары XIX гасырда фән даирәсендә кызыксыну уята. Үзләре ***«китаб»*** дип йөртә торган зур форматтагы, калын-күләмле, төрле мәгълүматларны үзенә туплаган, төрле телләр катыштырып, сәнгать әсәре дәрәҗәсендә матур-камил итеп язылган, халык тарафыннан яшәү кодексы кебек кабул ителә торган мондый китапларның серенә төшенергә теләп, алар хакында беренчел мәгълүматларны Генрих Флейшер (1838), Антон Мухлинский (1857) бирә.

Әмма шуннан соңгы вакыйгалар: Беренче Бөтендөнья сугышы, советлар килгәч, китаплар сакланган мәчетләрнең дә, диннең дә юкка чыгарылуы бу эшне өзә. Бары тик XX гасыр уртасында гына китаби тикшеренүләрне[3] этник беларусь, профессор, һабил-доктор Антон Константинович Антонович (1910–1980) Вильнюс университетында башлап җибәрә. «Хрущёв җепшеклеге» биргән ирektән файдаланып, университетның Сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә эшләүче яшь галим 1953 елдан литва татарларының гарәп графикасындагы кульъязмаларын барлауга, өйрәнүгә керешә, аларны уку өчен бүген дә кулланылышта булган транслитерация системасын төзи, мондый кульъязмаларның күчермәләрен (барлыгы 24 китаб) университетта туплый. 1968 елны аның «Гарәп язуындагы беларусь текстлары, аларның график-орфографик үзенчәлекләре» дип исемләнгән монографиясе басылып чыга. Бу хезмәт үзенең язмышын литва татарлары язмачылыгын өйрәнү белән бәйләгән шәхесләр өчен «өстәл китабына» әйләнә.

Профессор А.К. Антоновичның шәхси аралашу даирәсенең киңлеге, тикшеренүчеләр арасындагы үзара ярдәмләшү һәм багланышлар әлеге тема белән кызыксынган галимнәр, фәнни оешмалар һәм төбәкләр өчен дә бергәләп эшләү-эзләнүләргә юл ача. 1964 – 1974 еллар аралыгында ул тюрколог-галимнәр Ә.Халидов, М.Мамедалиев, Р.Мозаффаров, Ә.Нәҗип, Ш.Мөхәммәдьяров белән тыгыз аралаша. Әйтик, галимнең Альберт Фәтхи белән хат язышуы аркасында фәнни җәмәгатьчелеккә литва татарлары кульъязмаларының Казан университеты Фәнни китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклануы мәгълүм була. Болар, бер яктан, литва татарлары рухи мирасын фәнни өйрәнү кирәклеге хакында сөйлиләр. Икенче яктан, әлеге ядкәрләрнең татар язмачылыгында аерылып торуын, үзенчәлекле булуын, шуңа күрә аны өйрәнү-тикшерү өчен өр-яңа методика кирәклеген күрсәтәләр.

Менә шушы дулкында үзенә фәнни тема сайлаган Галина Александрович университетта профессор А.К.Антоновичны тере килеш очратмаса да, профессор В.Н.Чекмонасның остазлык ярдәме белән асылда Вильнюс университетында А.К.Антонович фәнни тикшеренүләрен дәвам итүче, олпат галим үз алдына куйган бурычларны акрынлап тормышка ашыра баручы булып чыга.

[2] Кайбер илләрдә философия буенча доктор-профессорлык дәрәҗәсе алганнан соң, югарырак академик баскыч – һабил дәрәҗәсе дә бирелә (Франция, Алмания, Швейцария, Австрия, Финляндия һ.б.).

[3] Китаб – литва татарларындагы кульъязмаларның бер жанры, төрле эчтәлектәге: ислам дине нигезләре, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы һәм эшчәнлеге, йолалар һәм гадәтләр, мөселманнарның гаилә-көнкүреш тәртибе турындагы – текстларны туплаган күләмле җыентыклар. Аларда еш кына Библия легендалары, үгет-нәсихәт бирүче хикәятләр, хәтта Шәрыкнең маҗаралы повестьлары да очрый. Димәк, китабистика – литва татарлары кульъязма мирасын өйрәнү юнәлеше ул. Шунысы да бар: литва татарларының әдәби-мәдәни мирасы – күптелле хәзинә, ул беларусь, поляк, гарәп һәм төрки телләрдәге мәдәни байлыкны өйрәнүгә юл ача. XVII–XX гасырларга карый торган мондый җыентыкларда славян текстлары (беларусь һәм поляк) да, шәркый (гарәп һәм төрки) текстлар да гарәп язуы-әлифбасында.

1998 елны, Вильнюс университетында докторантураны уңышлы тәгәлләп, Галина Александрович «Литва татарларының бик борынгы кульязмалары (Графика. Транслитерация. Тәрҗемә. Текстларның структурасы һәм эчтәлеге)» дигән темага диссертация яклый; ул 2001 елны монография булып басылып чыга. Бу урында мондый хезмәтне дөньяга китерү өчен гарәп язулы славян телле (иске беларусь һәм иске поляк) текстларны тикшерүчегә славян телләрен дә, гарәп һәм төрек, төрки телләрне дә белү таләп ителгәнлекне искәртергә кирәк.

Бүген инде бу өлкәдә күп кенә ачышлар ясалган икән, монда Галина Антоновнаның өлеше гаять зур. Ул кадерләп җыйнаган, барлаган, өйрәнгән кулъязма ядкарьләр халык хәтерендә сакланган мөһим тарихи фактларны тагын бер тапкыр раслый, шуның белән тарихи-мәдәни дөнья сурәтен тергезүгә дә ярдәм итә. Әйтик, мөселманнарның бу җирләргә кайчан күченүе билгеле булмаса да, аны Литваның Алтын Урда белән бәрелешләре көчәйгән, ул үзенә Смоленск һәм Чернигов тирәләрен буйсындырган XIII гасырның беренче яртысына (1238-1239) бәйлиләр. Кулъязмалар да шуны күрсәтә. Монда күченгән татарларның теле ике гасыр дәвамында җирле халык сөйләше һәм мәдәнияте белән катнаша. XVI гасырда инде халыкның зур күпчелеге татар телен югалтып, поляк, литва яки беларусь теленә күчә, әмма ислам динен саклый. XVI гасыр уртасында гарәп язуында беларусь кулъязмалалары, XVII-XX гасырларда – поляк текстлары язылу нәкъ менә лингвистик ассимиляция нәтиҗәсе була да инде.

Безнең көннәргә килеп җиткән кулъязма җыентыклар XVII-XIX гасырларга карый. ***Китаб*** дип аталган күләмлеләре ислам дине нигезләре, пәйгамбәрләр тарихы турында сөйләп, дини йола-гадәтләрне аңлата, араларында мондый җыентыкларның кыскарак вариантлары да очрый (аларын ***ярымкитаб*** дип тә исемлиләр). ***Хамаил*** дип йөртелгән гарәп һәм төрки телләрдәге дога китапчыкларында мөселман вакыт әйләнеше, дога укып авырулардан дәвалау, төшләрне юрау кебек мәгълүматлар китерелә. ***Тәҗвид*** китапларында Коръән уку кагыйдәләре, ***тәфсирләрдә*** изге китапны шәрехләү һәм сүзен-сүзгә беларусь һәм полякча тәрҗемәләр урын ала. Кыйммәтле, матур итеп язылган ***китаб***лар һәр торак урын мәчетендә, калганнары – өйләрдә-гаиләләрдә саклана торган була. Бу кулъязмаларның гасырлар дәвамында халык өчен ислам мәдәниятен һәм милли яшәү рәвешен киләсе буыннарга тапшыру чыганагы булуы бәхәссез.

Татар кулъязмаларын өйрәнү Галина Антоновнага өр-яңа юнәлешкә – текстологик тикшеренүләргә – нигез салырга мөмкинлек бирә, мондый эшчәнлек исә беренчел асыл текстны, архетип-текстны ачыклау омтылышын ясарга юл ача. Бүген дә литва татарларын өйрәнүче тикшеренүчеләр алдында авторлык мәсьәләсе, текстларның язылу урыннарын ачыклау, аларның яшәү, тел үзенчәлекләрен, Шәрыктагы башка традицияләр белән бәйләнешләрен барлау кебек бурычлар әһәмиятле булып калсалар да, Вильнюс китабистика мәктәбе язмачылык мәсьәләсендә ныклы нигез һәм күзаллау булдырган инде.

Аерым алганда, галимнәр тарафыннан литва татарларының 300 кулъязмасы табылган, дәүләти яки шәхси коллекцияләрдәге тупланмалар тасвирланып, каталоглар төзелгән. Шәхси коллекцияләр буенча Е.И.Титавец мәкалә әзерләгән булса, Беларусь, Литва һәм Польшадагы дәүләти оешмаларда саклана торган кулъязмаларга тасвирламаны Г.Мишкинене ясый: 2005 елны үзенең укучылары Сигита Нававичюте һәм Екатерина Покровская белән бергәләп, ул «Литва татарларының гарәп язуындагы кулъязмалары каталогы»н төзеп бастыра!

Әлбәттә, китаби кулъязмаларны комплекслы өйрәнү, бу эшкә төрле фәннәр галимнәрен тарту өчен, аларның транслитерация ясалган тулы текстларын бастырып чыгаруны башкарырга кирәк була. Озак еллар бу эш хыял булып кала. Бу хыял бары тик 2009 елны, Галина Мишкинене тарафыннан әзерләнгән «Иван Луцкевич китабы – Литва татарлары мәдәнияте истәлеге» дип исемләнгән хезмәт нәшер ителү белән

тормышка аша. Быел әлеге хезмәтнең тулыландырылган, текстлар тулысынча инглиз теленә тәрҗемә ителгән версиясе басылып чыгачак.

XVIII гасырның беренче яртысына караган әлеге кулъязма фәнни әдәбиятта тарихчы, археолог, библиофил Иван Луцкевич исемен йөртә, чөнки нәкъ менә ул әлеге кулъязманы XX гасыр башында Вильнюс өлкәсенең Кырык татар авылында тапкан булган. Китап күләмле, барлыгы 280 биттән тора, гарәп хәрефләре белән иске беларусь телендә язылган. Бу китапта ислам нигезләре, Рамазан ае, ураза вакытында ашарга тиешле ризыклар, намаз вакытлары турында бәян ителгән. Анда, шулай ук, әхлак нигезләре: мөселманнарның вазифалары, ятимнәрне кайгырту, ата-анага кадер-хөрмәт, кунакчыллык, яхшы һәм начар тәрбия, гаилә тормышы, эчкечелек турында да, Коръән һәм мөселманнарның гореф-гадәтләре хакында да анык язылган. Галина Антоновна бу юнәлештә беренче булып, факсимиле белән янәшә, һәм славян, һәм гарәп, һәм төрки телле текстларның транскрипциясен, иске беларусь теленнән литва һәм рус телләренә тәрҗемәләрен, кулланылган төшенчәләрнең мәгънәләре, исемнәрнең килеп чыгышы аңлатылган әтрафлы шәрех-комментарийлар әзерләгән. Бу хезмәт – татар язмачылыгы тарихын өйрәнү өчен гаять кыйммәтле чыганак булып чыккан, шушы статуста ул бүген бик күп яшь галимнәргә хезмәт итә.

Шушы башлангычның дәвамы төсендә, галимә кулъязмаларны чагыштырып, текстологик анализлауны дәвам итә. Якын киләчәктә без аның яңа ачышлар белән сөендерәчәгенә шикләнмибез.

Әлбәттә, һәр галим һәрвакыт үзенең эшен дәвам итәрлек кешеләр әзерләү хакында уйлана. 1998-1999 уку елында Анкара университетында стажировка узып, Галина Антоновна Вильнюс университетының филология факультетында «Литва филологиясе һәм чит (төрек) тел» дигән программа эшли. Ул 2001 елны ачыла һәм бүгенге көнгә кадәр уңышлы эшләп, бакалаврлар һәм магистрлар әзерләп килә. Шушы программа белән бәйлелектә, 2008 елны өр-яңа, «Азия тикшеренүләре (тюркология)» программасы мәйданга килә. Шулай итеп, Галина Мишкинене бүген Балтыйк буе илләрендә тюркология мәктәбе булдыру белән шөгыльләнә. Үзе исә университетта шушы программаларның нигезен тәшкил иткән предметларны: Ислам белеменә кереш; Ислам һәм христиан диннәре диалогы; Тюркологиягә кереш; Литвадагы төрки халыклар: татарлар һәм караимнар; Литва һәм Польша татарларының кулъязмалары: Төрек әдәбияты кебек курслар укый, төрек теленә өйрәтә. Остаз буларак, татар мәдәниятен тикшерүче галимнәр тәрбияли. Әйтик, Галина Антоновнаны фәнни консультант итеп сайлаган, әтисе Ибраһим Канапацкий юлын дәвам итүче тарих фәннәре кандидаты, Беларусь дәүләт университеты доценты Зорина Канапацкая – беларусь телле татар язмачылыгы буенча Казанда да билгеле яшь тикшеренүчеләрдән. Борынгы татар китапларының иң бай коллекциясе саклана торган Беларусьта ул, шулай ук, кулъязмаларны барлау, тикшерү, каталоглар төзү эшен җәелдерә. Тагын бер укучысы – Мария Коницкая докторлык диссертациясе әзерли. Галимә яздыра торган бакалавр һәм магистрлык хезмәтләре дә татар язмачылыгының төрле, моңа кадәр игътибар ителмәгән мәсьәләләренә карыйлар.

Галина Антоновна литва татарларының рухи мирасын өйрәнүгә күпьяклап өлеш кертә. 2002 елны ул әзерләгән литва-төрки телле сүзлек-сөйләүлек («Lietuviški – turkiški pasikalbėjimai. Turkų-lietuvių žodynas. Litvanca–Türkçe konuşma kılavuzu. Türkçe–Litvanca sözlük». Vilnius, 2002, 243 p.) дөнья күрә. Аерым бер кулъязмаларны тикшерүгә багышланган хезмәтләре Нью-Йорк, Вильнюс шәһәрләрендә нәшер ителә («Турэцка-беларускі размоўнік 1836 году з збораў Нацыянальнага Музэю Літоўскай Рэспублікі ў Вільні». New York, 1995, 62 с. (совм. с С. Шупа); «Türkçe-Lehçe konuşma kılavuzu (Yıl 1840)/Turkų–lenkų kalbų žodynėlis iš Lietuvos totorių rankraščio (1840)». Vilnius, 2008, 176 p. (совм. с Nesrin Güllüdağ); источников «Кітаб з фондаў Казанскага Ўнівэрсытэту

(№1446)», Запісы. Беларускі інстытут навукі й мастацтва 21. New York, 1994, 76–112; һ.б.). Г. Мишкинене – 100дән артык фәнни һәм фәнни-популяр хезмәт авторы.

Тәрҗемә белән дә шөгыльләнә ул. Орхан Памукның «Кара китаб»ы ((Orhan Pamuk Juodoji knyga/Kara kitap. Iš turkų kalbos vertė Galina Miškinienė. Vilnius, 2005, 502 p.); Айшә Кулинның «Севдалинка»сы (Aiše Kulin Sevdalinka. Iš turkų kalbos vertė Galina Miškinienė. Vilnius, 2006, 306 p.); Егленың «Су еланнары патшабикәсе» (Egle, Su Yılanlarının Kraliçesi // Avrupa‘dan Masallar. Antalya: AB Bilgi Bürosu Antalya Ticaret ve Sanayi Odası, 2007, s. 51–62) кебек әсәрләр белән Литвада Мишкинене тәрҗемәсендә танышалар.

Фән кешесе милли мәсьәләдә, бигрәк тә иҗтимагый фикер күтәрелеш кичергәндә, битараф кала алмый. 2004 елдан Галина Антоновна иҗтимагый эшчәнлеккә кушылып китә һәм «Вильнюс округының литва татарлары җәмгыяте» ассоциациясен җитәкли, 2012 елдан Литва Республикасы хөкүмәтендәге Милли азчылыклар эшләре департаментының Милли азчылыклар советында татарларның вәкиле булып торса, 2015 елны шушы Советның рәисе итеп сайлана. Иҗтимагый-сәяси эш, фән белән бергә, шулай ук татар милли үзаңын саклауга, ныгытуга юнәлтелгән бит.

Галимәнең фәндә, мәгарифтә, иҗтимагый-сәяси тормышта активлыгын аның матур гаиләсе хуплап, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булып яшиләр. Үзләренең нәсел тамырларын белеп, ике уллары үсеп килә. Ире Витаутас Мишкинис, һөнәре буенча җылылык эшләре инженеры булса да, шулай ук сәнгать, бигрәк тә борынгы мәдәниятнең суфичылык тармагы белән кызыксына. Галина Антоновна татарларның тарихы һәм мәдәнияте турында лекцияләр укыганда, ул шушы катлам турында сөйли, суфи-дәрвишләрнең бөтерелеп биюе – семаны биеп күрсәтә дә ала әле. Шул рәвешле, алар бергәләп, үз җирләрендә Шәрык мәдәниятенең тирәнлеген, гүзәллеген, фәлсәфи көчен пропагандалап яшиләр.

Литва татарларының тарихы турында сөйләгәндә, XIX гасырда аларның милли асылыннан баш тартуы күзәтелә дип, «Без татарлар түгел, мөселман шляхтасы[4], безне «татар» дип, гади крестьяннар гына атый» дигән шигарьне еш кына мисалга китерәләр.

Әмма вакыт үзенекен итә – бүген инде кавемдәшләребез яшәгән җирләрдә аның бөтенләй үзгә вариантын кулланалар: «Без – татар чыгышлы беларусь, литва, поляк халкы». Бу үзгәрешнең сәбәбе бер – татарларны берләштерерлек уртак кыйммәтләр табылган, халыкка җиткерелгән, аңлатылган!

Күрәсең, бу кыйммәтләр – литва татарларының шанлы тарихы, куш йөрәкле гаярь бабаларының каһарманлыгы, яшәү рәвешен сакларга ярдәм иткән ислам дине, Нобель бүләге лауреаты Генрик Сенкевичларны, галимнәр М.И. Туган-Барановский, С.Я. Чаиньский, С.Крычыньский һ.б. биргән бай мәдәнияте… Аларны уртак китаблар, шуларга теркәлгән һәм бүген дә кешене туганда каршы ала, гомер буе саклап бара, бакыйлыкка кучкәч, җир куенына озата торган йола-гадәтләр дә, шул китабларны өйрәнеп, нәсел-ыруына җиткергән галимнәре дә берләштерә. Галимнәре булмаса, бәлки, башка кыйммәтләр дә тарих тузанына күмелмәс иде микән…

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

[4] Шляхта – морза.



*Г.Камал театрында «Казан утлары» журналына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов басманың баш мөхәррире Рөстәм Галиуллинга Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның редакциягә Рәхмәт хатын тапшыра. 25 апрель, 2022 ел.*



*Г.Камал театрында «Казан утлары» журналының 100 еллык юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичәдән зал күренеше. 25 апрель, 2022 ел.*







*Казандагы Татар китабы йортында «Казан утлары» журналының 100 еллыгы уңаеннан ачылган күргәзмәдәге ядкарьләр. Апрель-май, 2022 ел.*



*«Казан утлары» журналының 100 еллык юбилеена килгән кунаклар матбугат конференциясендә. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков Кыргыз Республикасы Язучылар берлегенең «Ала-Тоо» журналының баш мөхәррире Маркабай Ааматовка Рәхмәт хатын тапшыра. Сулда – Азәрбайҗан Республикасының «Интеллектуаль хокук үзәге» директоры Илгар Төркуглы, уңда – Саха (Якутия) Республикасының «Чолбон» журналы баш мөхәррире Гаврил Андросов. 25 апрель, 2022 ел.*




*Г.Тукайның туган көнендә Татарстан Язучылар, Театр әһелләре берлекләре әгъзалары, җәмәгатьчелек вәкилләре, «Казан утлары» журналының 100 еллык юбилей чараларына килгән кунаклар шагыйрьнең һәйкәле янында. 26 апрель, 2022 ел.*

# КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ИСЛАМ ДИНЕ

## Алтын Урта таркалу һәм татар ханлыклары оешу

Һәр империянең оешу, чәчәк ату һәм таркалу дәвере була. Кодрәтле Жучи Олысы да бу мәҗбүрияттән котыла алмый, билгеле.

Алтын Урта дәүләтенең таркалу механизмын хәрәкәткә китерүче төп көч итеп чыңгызлыларның тәхет өчен көрәштә бер-берсенең канын коюлары да, илдә башланган тирән сәяси кризис та күрсәтелә ала.

Үзбәк хан (1312-1342) тәхеткә утыргач, үзәк хакимиятне көчәйтү максатында яңа идарә системасы кертә: Жучи нәселе дәвамчылары кул астында булган күпсанлы биләмәләрне 70 төмән итеп зурайта, аларны җитәкчелектә хан билгеләгән бәкләр торган 10 өлкәгә – олыска берләштерә, реформа барышында 120 чыңгызлыны юк итә *(Почекаев Р.Ю. Золотая Орда. История в имперском контексте. СПб.: Наука, 2017. С. 67).* Үзбәкнең улы Җанибәк тәхеткә менгәндә, 2 ир туганын, аның нәсел дәвамчысы Бирдебәк барлык 12 туганын, хакимлеккә дәгъва итмәсеннәр дигән уйдан чыгып, һәлак итә. *(Почекаев Р.Ю. Күрс. хезмәт. С. 101).* Иң аянычлысы – Бирдебәктән соң тәхеткә утыртырга Бату нәселеннән килгән чыңгызлы калмый диярлек.

Үзбәк ханның хатыны, Бирдебәкнең әбисе Тайдула, оныгы үтерелгәннән соң хакимиятне үз кулында саклап калырга теләп, хан итеп Бату нәселеннән чыккан чыңгызлыны түгел, ә Жучиның башка балалары нәсел дәвамчыларын куярга исәпли. Жучиның алтынчы улы Тагут нәселеннән булган Нәүрүзне 1359 елда ак киездә күтәргәч, яңа ханга кияүгә чыга. Нәтиҗәдә Ак Урда тәхете өчен көрәшкә Күк Урдада яшәгән чыңгызлылар килеп кушыла, Нәүрүз хан һәм Тайдула үтерелә. Шул рәвешле, 1380 елга кадәр тәхеттә егермеләп чыңгызлы утырып ала һәм хакимият өчен көрәштә юк ителә (*Почекаев Р.Ю. Күрс. хезмәт. С. 101).*

Туктамыш (1380-1395) Күк Урда тәхетенә 1380 елда, Чагатай олысының хакиме Аксак Тимер әмир ярдәме белән ия була. Ул Ак һәм Күк Урданы берләштерә, 1382 елны Мәскәүне алып, 1374 елдан салым түләүдән туктаган рус кенәзләренә карата сюзерен һәм вассал мөнәсәбәтләрен кайтара. Ул да түгел, 1383 елда Харәземне Аксак Тимердән тартып алып, Алтын Урдага куша.

Үзенә уңыш һәрчак юлдаш була дип уйлаган Туктамыш 1380 нче елларда Монгол дәүләтен берләштерүче роленә әзерләнә башлый, хәтта «Туктамыш каан» (ханнарның ханы) исеме белән тәңкәләр суктыра. Дәүләтнең чикләрен киңәйтүне дәвам итеп, 1385 елда Чагатай олысы кулына күчкән Азәрбайҗанны кабат Алтын Урдага кайтара, 1386 елда Ширванны үзенә буйсындыра. Туктамыш 1387 елда, Аксак Тимернең Иранга һөҗүм итүеннән файдаланып, Чагатай олысы башкаласы Сәмәркандка барып җитә. Фәкать Аксак Тимер гаскәренең кире кайтуын ишетеп, башкалага һөҗүм итәргә базмый. Активлык күрсәтеп, Аксак Тимер 1388 елда Харәземне кабат үзенеке итә, шул ук елны гаскәре белән Мәвараэннәһергә килгән Туктамыш гаскәрен тар-мар китерә.

1391 елда Кондырча елгасы буендагы зур бәрелештә Тuктамыш кабат җиңелү ачысын татый. Аксак Тимер, Күк Урда белән идарә итүне Туктамыштан тартып алып, чыңгызлы Тимер-Котлыгъка һәм әмир Идегәйгә тапшыра. 1395 елда Аксак Тимер Терек елгасы буенда хәлиткеч бәрелештә Туктамыш ханның гаскәрен тар-мар итә һәм Ак Урданың Сарай, Азәк, Болгар, Хаҗитархан шәһәрләрен җимерә. Шәһәрләрне тәмам юкка чыгарудан 1396 елда башланган чума афәте генә коткарып кала *(Почекаев Р.Ю. Күрс. хезмәт. С. 118-119).* Нәтиҗәдә Ак Урдада Үзбәк хан төзегән үзәкләштерелгән идарә һәм салым җыю системасы тәмам таркала, төбәкләрдә хакимият җирле аксөякләр кулына күчә.

Туктамыш 1395-1406 елларда Идегәй әмир белән тәхетне кире кайтару өчен көрәш алып бара. Әтиләре үлгәч, бу көрәшне уллары дәвам итә.

Идегәй әмир, үзе билгеләп куйган марионет ханнарны файдаланып, Алтын Урда белән идарә итә, Ак һәм Күк Урдаларны берләштерә, күчмәннәр арасында ислам динен тарату буенча масштаблы кампания оештыра, ләкин 1420 елда Туктамышның улы Кадыйрбирде тарафыннан үтерелә.

Идегәй һәлак булганнан соң, Алтын Урда таркалуның соңгы этабы башлана. Әле 1410 нче елларда Көнбатыш Себердә Төмән йорты (XVI гасырлар Себер ханлыгы) оешкан була. Берничә дистә елда бер-бер артлы чыңгызлылар җитәкчелек иткән яңа дәүләтләр барлыкка килә: Олуг Урда (1441-1502), Кырым ханлыгы (1441-1783), Казан ханлыгы (1445-1552) һ.б. башка дәүләтләр һәм Нугай Урдасы (1480-1613).

## Казан ханлыгы сәяси тарихының төп этаплары

Бирдебәк хан үтерелгәннән соң, чыңгызлылар арасында Дәште Кыпчакта башланган тәхет өчен канкойгыч көрәш Урта Идел төбәгендәге үзәк хакимиятне нык йомшарта. 1361 елны Булат-Тимер Урта Идел буе шәһәрләрен үзенә буйсындыра һәм Болгарда хан исеменнән тәңкәләр дә суктыра. 1369 елны, Булат-Тимер үлеменнән соң ике ел узгач, төбәк белән Хәсән исемле хан идарә итә. Рус елъязмаларында һәм татар риваятьләрендә Болгар олысының түбәндәге идарәчеләре теркәлгән: Мөхәммәд Солтан (1370 нче еллар), Бәктут (якынча 1391 ел), Ентәк (1398/1399 еллар), Талыч (1410/1411 еллар), Гаязетдин (1421-1425 еллар) һәм Мәхмүт-хуҗа (1429 ел) *(Загидуллин И.К. К вопросу об образовании Казанского ханства // Средневековые тюрко-татарские государства. 2015. №7. С. 18-19).*

XIV гасыр ахырында Туктамыш һәм Аксак Тимер арасында сугыш, ушкуйниклар һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Болгар, Җүкәтау, Кирмәнчек, Казан, Кашан, Чаллы кебек шәһәрләр талана, төбәк икътисадына зур зыян салына. Әлбәттә, мондый канлы вакыйгалар төбәк элиталарының илбасарлар белән көрәшү өчен берләшүенә китергән.

XV гасыр башында Урта Идел төбәге Идегәй әмир һәм тәхеттән куылган Туктамышның уллары арасында көрәш мәйданына әверелә. Шулай итеп, тәхет өчен барган көрәш дулкыны, төгәлрәк әйтсәк, үзәк хакимияттәге тирән кризис төбәккә зур бәлаләр китерә.

Әйтергә кирәк, идарә структурасында да үзгәрешләр күзгә ташлана. XV гасырның беренче яртысында биредә Болгар, Җүкәтау һәм Казан олыслары булганлыгы билгеле *(Мустакимов И. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографичных источников (К вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве) // Гасырлар авазы – Эхо веков.2008. №1. С. 147; Гариф Н. Казан ханлыгы: Оешу тарихы, идарә системасы, административ бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 77 б.).*

Казан ханлыгы оешу XV гасырның 40 нчы елларында Алтын Урда тәхете өчен көрәшкә кушылган, Туктамышның нәсел дәвамчысы булган Җәләлетдиннең улы,

мәшһүр сәясәтче һәм оста хәрби җитәкче Олуг Мөхәммәд һәм, бигрәк тә, аның өлкән улы Мәхмүд шәхесләре белән бәйле.

Җәләлетдин Литва кенәзе ярдәмендә 1411 елда Алтын Урда тәхетенә утыра, 1412 елда Дмитрий Донскойның улы Бөек кенәз Василийны Сарайга чакыртып, яңадан еллык салым түләргә мәҗбүр итә. 1420 еллар ахырында тәхет аның улы Олуг Мөхәммәдкә күчә. Чынлыкта ханның исеме Мөхәммәд булып, «Олуг» сүзе шулай ук Алтын Урда тәхете өчен көрәшкән адашы (анысын аеру өчен «Кече Мөхәммәд» дип атыйлар) белән бутамас өчен өстәлә. 1431 елда Сарайга хакимлеккә рөхсәт сорап килгән Дмитрий Донскойның улы һәм оныгы арасындагы бәхәстә Олуг Мөхәммәд онык Василий Васильевич ягына баса.

1436 елда Идегәй уллары һөҗүменнән соң, Олуг Мөхәммәд тәхетен югалта, Кырымга күченә. Тәхеттә утырган Тимер Котлыгъның улы Кече Мөхәммәд хан аны җиңеп, Кырымнан бәреп чыгара *(Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 22-23)*. Дәште Кыпчактан куылгач, 1437 ел кышын Олуг Мөхәммәд үзенең 3 меңлек гаскәре белән Бөек Мәскәү кенәзлеге чигендәге Белев шәһәре янында уздырырга ниятли. 1437 елның 5 декабрендә Василий II-нең үзенә каршы җибәрелгән 40 мең яугирдән торган гаскәрен тар-мар иткәннән соң, Урта Идел төбәген буйсындыра һәм шуннан торып, Бөек Мәскәү дәүләте шәһәрләренә берничә тапкыр һөҗүм ясый.

1439 елның июлендә гаскәре белән Мәскәүне 10 көн чолгап торып, Олуг Мөхәммәд, кирмәннән кала Мәскәүнең бистә өлешен һәм тирә-як авылларны туздырып, Коломна кирмәнен яндырып, әсирләр һәм зур байлык белән әйләнеп кайта *(Мәрҗани Ш. Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 164 б.)*. Мәскәүгә каршы сәясәтен дәвам итеп, Түбән Новгород белән идарә итәргә ярлыкны Даниил Борисовичка бирә. Үзе 1444-1445 елларда ставкасын Түбән Новгород янында кора *(Горский А.А. Москва и Орда. М.: Наука, 2000. С. 143-144)*.

Василий II сугышка кузгалып, 1445 елның гыйнварында Муром янында Олуг Мөхәммәд гаскәренең алдынгы отрядын туздыра. Бу эш җавапсыз калмый: Олуг Мөхәммәд шул ук елның маенда Василий II гә каршы Мәхмүд һәм Якуб исемле улларын җибәрә. Алар 7 июль көнне Суздаль шәһәре янында Бөек кенәз гаскәрен тар-мар итеп, Василий II нең үзен әсир итәләр.

Курмышта вакытта, 1445 елның 1 октябрь көнне Олуг Мөхәммәд һәм Мәхмүд, Василий II дән ханга ел саен салым түләргә вәгъдә алып, аны Мәскәүгә кайтарып җибәрәләр. Шушы вакыйгадан соң Мәхмүд Казанда, җирле хакимиятне туздырып, идарә итә башлый. Ә Олуг Мөхәммәд, мөгаен, Алтын Урда тәхете өчен көрәшне дәвам иткән яки үлеп киткән. Аның исеме соңрак чыганакларда күренми.

Яңа оешкан Казан ханлыгының сәяси тарихы берничә этапка бүленә – дәүләтнең көчле, шанлы чагы (1445-1487 еллар), рус протектораты чоры (1487-1521 еллар), милли күтәрелеш заманы (1521-1550 еллар), Казан өчен көрәш (1550-1552 еллар).

Бу бүленешкә, ханлыктагы иҗтимагый һәм икътисади вакыйлардан тыш, күршедәге Алтын Урда кыйпылчыклары булып оешкан ханлыклар һәм Нугай Урдасы һәм, бигрәк тә, көчәеп килүче ут күрше – Бөек Мәскәү кенәзлеге/Мәскәү дәүләте белән мөнәсәбәтләр нык тәэсир итә, аерым очракларда соңгылары хәлиткеч роль уйный.

*Беренче этапта* тәхеттә Мәхмүд (1445-1461 елдан соң), аннары баласы булмаган өлкән улы Хәлил, ул үлгәч, энекәше Ибраһим (1467-1479) һәм хатыны Фатыйма белән никахыннан туган улы Илһам (Алихан) (1479-1487) утыра. Бу никахтан, тагын, Ходайкол һәм Мәлик Таһир исемле ике угыл һәм ике кыз булган. Фатыймадан туган балалар Казанда мөстәкыйль сәясәт алып барганнар һәм күбрәк нугайлар белән аралашканнар (*Алишев С.Х. Казан ханлыгы тарихыннан. Казан: «Раннур» нәшр., 2003. 37 б.)*.

Ибраһимның икенче хатыны – акыллы һәм сөйкемле Нурсолтан – гүр иясе булган абыйсы Хәлилнең тол калган хәләл җефете. Бу никахтан Мөхәммәд-Әмин һәм Габделлатыйф исемле угыллар туа. Нурсолтан, ире Ибраһим вафатыннан соң, 1480 елда Кырым ханы Миңле-Гәрәйгә тормышка чыга. Бер яктан, бу вакыйга ике ханлык арасында мөнәсәбәтләрнең тагын да якынаюына китерә. Әмма бу елларда Бөек Мәскәү кенәзлеге белән Кырым ханлыгы Олуг Урдага каршы юнәлтелгән ныклы союзда булалар. Нәтиҗәдә Нурсолтан балалары Мәскәү яклы сәясәттә катнаша.

1484 елны Бөек кенәз гаскәре Казанга килеп, Илһамны тәхетен Мөхәммәд-Әмингә тапшырырга мәҗбүр итә. Ләкин бер елдан Казан аксөякләре кабат тәхеткә Илһамны кайтаруга ирешәләр.

*Рус протектораты чоры.* 1487 елда Мәскәү гаскәренең Казанны алып, Илһам ханны, аның ир һәм кыз туганнарын һәм әнисе Фатыйманы әсир итеп, Вологдага җибәрүдән һәм Бөек кенәзнең ханлык тәхетенә Мәскәүдә тәрбияләнгән Мөхәммәд-Әминне (1487-1496) утыртудан башланып китә. Яңа сәяси халәт Казан хөкүмәте өчен, нигездә, өч кагыйдәне үтәүдә чагыла. 1) Мәскәүгә каршы сугыш ачмау. 2) Бөек кенәз рөхсәтеннән башка яңа хан сайламау. 3) Ханлыкта булган рус кешеләренең мәнфәгатьләрен кайгырту. *(Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 51).* Бу чорда Мәскәү хөкүмәтенең Казан илендә йогынтысы көчәя.

Казан аксөякләренең ханлык хокуклары кысылуына риза булмаган төркеме 1496 елда тәхеткә Себер ханы Мамукны чакыра, ләкин аның кырыс идарә ысулы белән килешмичә, кире кайтарып җибәрергә мәҗбүр була. Мәскәү хөкүмәте Казан тәхетенә Кырымда тәрбияләнеп, берничә ел гына Мәскәү кенәзлегендә яшәгән Гаделлатыйфны билгели, Казанда каршылыклар чыккач, аны кабат Мөхәммәд-Әмин хан (1502-1518) алыштыра. Көтмәгәндә, яңа хан милли мәнфәгатьләрне өстен куеп, мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый, Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне яңача кора. Ләкин балалары булмаган Гаделлатыйф һәм Мөхәммәд-Әмин үлгәч, Олуг Мөхәммәд нәселеннән тәхеткә утыртырлык чыңгызлы калмый. Бу вакытка Мәлик Таһир үлгән, аның уллары чукынган, төрмәдә утырган Ходайкол 1505 елда чукынып, Бөек кенәз Василий I-нең кыз туганы Евдокиягә өйләнгән, шул рәвешле хан булу хокукын югалткан була *(Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 47, 48).*

Мәскәү хөкүмәте бушап калган тәхеткә 1502 елда Кырым ханы, Олуг Урда тар-мар ителгәннән соң Мәскәүгә килеп сыенган һәм Касыйм ханлыгында көн күрүче Кече Мөхәммәд нәселеннән булган Әхмәд ханның туганнарыннан берсе – 13 яшьлек Шаһгалины җибәрә. Чынлыкта аның исеменнән Мәскәүдән килгән илче Карпов идарә итә. Аның эш алымнарына түзә алмыйча, Шаһгалины куып җибәргәч, казанлылар 1521 елда тәхеткә Кырымнан Сәхиб-Гәрәйне дәшәләр. 1502 елда Олуг Урда тар-мар ителгәч, Кырым ханлыгы үзен Алтын Урда мирасчысы итеп атый һәм Казан ханлыгына хокукы бар дигән фикердән чыгып эш итә.

Шул рәвешле, Казан ханлыгы тарихында яңа чор – *милли күтәрелеш этабы* башлана (1521-1550 еллар). Сәхиб-Гәрәй җитәкчелегендәге Казан һәм ярдәмгә килгән Кырым гаскәрләренең Мәскәүгә һөҗүме нәтиҗәсендә, Бөек кенәз Василий III ханлык өстеннән протекторатны юкка чыгара һәм Кырымга еллык салым түләү турында солыхка кул куярга мәҗбүр була. Сәхиб-Гәрәй, 1524 елда үз урынына 13 яшьлек Сафа-Гәрәйне (данлыклы Кырым ханы Миңле-Гәрәйнең улы Фатыйх-Гәрәйнең улы) калдырып, Истамбулга китеп бара һәм беркадәр вакыттан соң Кырым ханы булып таныла.

1531 елда Мәскәү хөкүмәте басымы белән Сафа-Гәрәй Казаннан куыла, аны Шаһгалинең энесе 15 яшьлек Җангали алыштыра. 1535 елны казанлылылар, Җангалине үтереп, кабат Сафа-Гәрәйне чакыралар. Ул Җангалинең тол калган хатыны, нугай морзасы Йосыфның кызы Сөембикәгә өйләнә. Яңа хан, Бөек кенәз Иван IV кечкенә булудан файдаланып, берничә тапкыр рус шәһәрләренә яу чаба. Мәскәү белән

килешүгә корылган мөнәсәбәт яклы Казан аксөякләре Сафа-Гәрәйне тәхеттән төшерү өчен заговор коралар. Ахыр чиктә, 1546 елның 13 июнендә аның урынына тәхеткә Шаһгалине утырталар. Бер ай үткәч, Әстерхан һәм нугай яугирләренә таянып, Сафа-Гәрәй тәхетен кире кайтара. (*Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 110-112*).

Сафа-Гәрәй хан 1549 елда кинәт үлеп китә. Хан итеп, Кырымнан аның улы Бүләк-Гәрәйне чакыру барып чыкмагач, тәхеткә Сафа-Гәрәйнең 2 яшьлек улы Үтәмеш-Гәрәй утыртыла, регентша итеп әнисе ханбикә Сөембикә билгеләнә. Хәрби көчләр белән Кырымнан килгән гаскәр башлыгы Кошчак углан идарә итә.

Мәскәү хөкүмәте 1545 елдан башлап, ханлык өстеннән кабат протекторат урнаштыру өчен, Казан кирмәненә уңышсыз һөҗүмнәр ясый (*Алишев С.Х. Казан ханлыгы тарихыннан. 105 б.)*. Яңача хәрәкәт итеп, 1551 елда ханлык башкаласыннан 30 чакрым ераклыкта Зөя кирмәнен кора; Түбән Иделгә хәрби отрядлар җибәреп, казанлыларның Кырым белән элемтәләрен өзә; Кошчак углан үтерелгәч, Сөембикә һәм Үтәмеш-Гәрәй хан Мәскәүгә озатыла. Казан тәхетенә кабат Шаһгали утыра. Казанлылар баш күтәргәч, Шаһгали тәхетне калдырып качып китәргә мәҗбүр була.

1552 елның көзендә казанлылар Әстерханнан чакыртылган 19 яшьлек Ядегәр-Мөхәммәд хан җитәкчелегендә башкаланы Иван IV гаскәрләреннән саклыйлар, рәхимсез канлы сугышта бәйсезлекләрен югалталар. Әмма Казанны алу әле ханлыкны буйсындыру дигәнне аңлатмый: «Казан сугышы» 1557 елга кадәр дәвам итә.

Ханлык халкы утрак тормыш алып барган элекке Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урданың Болгар олысы җирләрендә оеша. Язма чыганаклар буенча, аның Мәскәү дәүләте белән чикләре генә төгәл билгеле – алар көнбатышта Сура һәм Ветлуга елгалары бассейнына, көнчыгышта Агыйделгә, төньякта – Вятка һәм Чепца елгалары бассейнына, көньякта Иделнең Самара Лукасына җиткән (*Хисматуллин Б.Р. Политико-административное регулирование земельных правоотношений в Казанском ханстве: Автореф. дисс. ... канд. ист. наук. Казань, 2019. С. 8)*.

Ханлык салым җыюны күздә тоткан административ-территориаль берәмлекләргә – башларында дәүләт чиновниклары торган даругаларга бүленгән: Алат, Арча, Гәреч, Чуваш (Җөри), Нугай, Кырым (Буртас) даругалары *(Галлям Р. Административные даруги Казанского ханства: опыт реконструкции // Казанское ханство: актульные проблемы исследования. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани, 2002. С. 281, 296, 311)*.

Дәүләт белән идарә итүче хан каршында илкүләм мәсьәләләрне хәл итүдә мөһим роль уйнаган һәм Аргын, Барын, Ширин һәм Кыпчак ырулары вәкилләре булган карачыбәкләрдән торган киңәш органы – *диван* институты эшли *(Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства. Казань, Изд-во «Ихлас», Институт истории им. Ш. Марджани 2012. С. 222)*. Дәүләткүләм мәсьәләләрне тикшереп, җаваплы карарлар кабул итү һәм аны үтәтү өчен хан яки карачыбәкләр дәүләтнең төрле өлкәләреннән руханиларны, казак-огланнарны, бәкләрне, фин һәм мукшы халыклары җитәкчеләрен Корылтайга эндәшкәннәр. 1496-1551 еллар аралыгында булган шундый 15 Корылтайда ханны төшерү, яңа хан кандидатурасын билгеләү, аны чакыру, ак киезгә күтәрү, Мәскәү белән сөйләшүләр алып барырга рәсми вәкилләр сайлау, Рус протектораты елларында Бөек Мәскәү кенәзлеге белән хезмәттәшлек турында килешүгә тугрылык анты бирү кебек, ханлыкны борчыган гомуми мәсьәләләр тикшерелгән *(Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 192, 193)*.

Ханлыкның идарә системасында башка төбәкләрдән күченеп килгән аксөякләр өстенлек иткән. Аксөякләр килмешәк бәк һәм морзаларга һәм төбәк биләренә (мөселманнар) һәм мәҗүси халыкларның элиталарына бүленгән *(Гариф Н.Г. Күрс. хезмәт. 115-116 б.)*.

Өстенлекле катлам вәкилләренә руханилар, гаскәриләр, сәүдәгәрләр кергән, түбән катламны һөнәрчеләр, игенчеләр һәм кол-чуралар тәшкил иткән. Халык 700 дән артык авылда һәм Алат, Арча, Җөри, Чаллы, Кашан, Алабуга кебек шәһәрләрдә көн күргән.

Казан ханлыгын халкы ярты миллион чамасы булып, шуның 200 меңен мөселманнар, яки казанлылар тәшкил иткән *(Хамидуллин Б.Л. «...Окаянная дщерь Златой орды... »: очерки и историографические заметки по истории Золотой Орды и Казанского ханства.. Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. С. 285-286*). Дәүләттә – рус чыганакларында «казанлылар» исеме белән аталган, игенчелек белән шөгыльләнгән мөселман халкы, шулай ук башкортлар һәм мәҗүси диндәге марилар, удмуртлар, чувашлар, мукшылар яшәгән.

## Мөселман дәүләтенә хас билгеләр

Рус чыганакларында ханлыкта яшәгән җирле халык, «казанлылар», «казан халкы» дип исемләнүдән тыш, конфессиональ төшенчәле «басурманнар», «бесерменнәр» («мөселманнар»ның бозып әйтелеше) дип тә атала. Шуңа күрә тарихчылар казанлыларның милли үзаңнарында конфессиониум өстенлек иткән дип фаразлый (*Хамидуллин Б.Л. Күрс. хезмәт. С. 285)*. С.Герберштейн Алтын Урда җирләрендә яшәгән төрки-татарларның бигрәк тә «бесермен», ягъни мөселман дип эндәшкәнгә шатлануларына игътибар иткән (*Гербештейн С. Записки о Московии / Пер. с нем. А.И. Маминова и А.В. Назаренко. М.: Изд-во МГУ, 1988. С. 167*). Мондый гадәт һәм үз-үзеңне тотыш, һичшиксез, руханилар һәм суфиларның даими вәгазьләве нәтиҗәсендә формалашкан.

Гомумән алганда, Казан ханлыгының – мөселман дәүләте, анда ислам диненең дәүләт дине булуы түбәндәге дәлилләр белән раслана.

1. Казан тәхетенә фәкать ислам динен тотучы, әти-әнисе мөселман булган чыңгызлылар гына утыра алган.

2. Мөселман руханиларының башлыгы дәүләт хакимияте даирәсенә кергән. Дин әһелләре, өстенлекле һәм зыялы катлам вәкилләре буларак, дәүләт дәрәҗәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә зур роль уйнаганнар. Нәкъ менә мәдрәсәдә укыган яки өй шартларында белем туплаган мулла уллары һәм белемле башка шәхесләр хан һәм олыс җитәкчеләре канцелярияләрендә бахшилар һәм бетекчеләр булып хезмәт иткәннәр. Мәсәлән, Ибраһим хан ярлыгы «хаҗи Корбан-хафиз тарафыннан төзелде» дигән сүзләр белән тәмамлана *(Госманов М., Мөхәммәдьяров Ш., Степанов Р. Яңа ярлык // Казан утлары. 1965. №8. 148 б.).* Алар, шулай ук, дәүләтнең рәсми илчелекләре составына кертелеп, дипломатик сөйләшүләрне теркәп барганнар яки дәүләтара эшләрдә тулы вәкаләтле әгъза буларак катнашканнар. Бу хакта рус елъязмаларында мәгълүматлар очрап тора. Әйтик, 1518 елда Мөхәммәд-Әминнең үлеме турында хәбәр белән Казаннан Кол Дәрвиш илче итеп җибәрелә. 1534 елда Җангали хан бөек кенәз Василий III кә хат белән Чура мулла-задәне юллый. 1541 елда бояр улы Рудаков-Булатов белән Бөек кенәз исеменә хатны Гаммәт шәех китерә. (*Мухаммедьяров Ш.Ф. Күрс. хезмәт. С. 224*). 1533 елның июнендә Җангали хан белән нугай морзасы кызы Сөембикә арасында никахны килештерү өчен Мәскәүгә җибәрелгән Казан ханлыгы илчелеге составына оглан Аппак, кенәз Кадыш һәм бахши Әвтәк керә. 1534 елда Мәскәүгә Казан хөкүмәтеннән килгән илчелек составында бахши Хуҗа Әхмәт була. 1545 елның 13 июнендә Шаһгалинең тәхеткә утырганын хәбәр итү өчен Мәскәүгә оглан Аллаһбирде, кенәз Тәвәккәл һәм бахши – мулла улы Агиш составындагы депутация озатыла (*Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 97, 98, 110*).

Урта гасыр җәмгыятендә дини белем бирү һәм уку-язуга өйрәтү суфилар һәм руханилар кулында тупланып, еш кына мәктәпләрдә яисә гаиләләрдә тормышка

ашырыла. Аксөякләрнең һәм гади халыкның Коръән телен белмәүләре ислам дине тәгълиматын таратучы һәм аңлатучы руханиларның һәм суфиларның дәрәҗәләрен гаять югары күтәргән. Изге дини текстлар белән төрки мөселман җәмгыяте арасында тәрҗемәче, шәрехләүче һәм арадашчы вазифасын үтәүче руханилар һәм суфилар мөселман җәмгыятенең идеологлары булган дип әйтергә мөмкин.

Ислам дине ритуалларын үтәүче бу социаль һәм һөнәри төркем вәкилләре хан һәм олыс җитәкчеләре тарафыннан салымнар җыю һәм аларның вакытында керүен кәгазьгә төшерү, идарә итүгә кагылышлы рәсми күрсәтмәләр язу һәм аларны күчереп күбәйтү, мәхкәмә карарларын теркәп бару, васыятьнамәләр төзү һ.б. шундый гаять мөһим язу-сызу эшләре белән дә шөгыльләнгәннәр.

3. Ханнар рәсми карарларында сүзләренең хаклыгын раслау яки кылган гамәлләрен дәлилләү өчен «Аллаһ», «Мәхәммәд пәйгамбәр», шулай ук шәһадәт кәлимәсе сүзләрен («Лә иләһә иллә-л-Лаһ, Мөхәммәд расүлү-л-Лаһ») кулланганнар (*Алишев С.Х. Казан ханлыгы тарихыннан. Казан: «Раннур» нәшрияты, 2003. 71 б.).*

4. Казан ханнарының тамгаларында, мөһерләрдә дә шәһадәт кәлимәсе язылган (*Мустакимов И.А Еще раз о Казанском ярлыке хана Сахиб-Гирея // Средневековые тюрко-татарские государства. Сб. статей. Вып. 5: Вопросы источниковедения и историография истории средневековых тюрко-татарских государств. Казань, 2013. С. 43).*

5. Алтын Урдадагы кебек үк, тормышның аерым юнәлешләрендә шәригать кануннары өстенлек иткән. Казыйлар гражданлык хокукы өлкәсендә – гаилә мөнәсәбәтләрен көйләгәндә, мирас һәм милек бүлгәндә, шулай ук тормышның башка якларында килеп чыккан мәсьәләләрне шәригать күзлегеннән бәяләп, карар чыгарганнар. Бу эш үзәкләштерелгән булып, олысларда казыйлар эшләсә, Казанда баш казый торган *(Гариф Н.Г. Күрс хезмәт. 37 б.).* Баш казый апелляция институты вазифасын да үтәгән, ягъни иң югары дини мәхкәмә буларак, төбәк казыйларының карарлары белән риза булмаган мөрәҗәгатьләрне, шикаятьләрне тикшергән. Аерым очракларда ялгышлар кабатламасын өчен махсус фәтвалар чыгарган.

6. Ислам традициясе буенча, җомга көнне җәмигъ мәчетләрендә имам-хатыйб укый торган хотбәдә илнең сәяси җитәкчесе – Казан ханының исеме аталган. Сәхиб-Гәрәй, Бөек Мәскәү кенәзенең Сура елгасы буенда ике арадагы чиккә терәп үк, Васильсурск кирмәне төзеп, Казан ханлыгына һөҗүм куркынычы тудыргач, 1524 елда җавап йөзеннән, күрәсең, каршы якны куркыту максатын алга куеп, үзен Госманлы солтаны вассалы дип игълан итә. С.Алишев бу вакыйганың Казан ханлыгына чынлыкта кагылмавын күрсәтә *(Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV – XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. С. 64-65).* Чыннан да, Истамбул һәм Казан арасында яңа дәрәҗәдәге мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерер өчен ике яктан да бернинди адымнар ясалмый. Ш.Мәрҗани фикеренчә, Сәхиб-Гәрәй Казан дәүләте тәхетенә утыргач, үзенең сюзерены итеп, Госманлы дәүләтен тану сәбәпле, Казан дәүләте имам-хатыйблары хөтбәләрендә Төркия солтаннары макталып телгә алына башлый. Мәрҗани хәзрәтләре: «Шул сәбәптән булса кирәк, борынгы карчыклар кулында булган китаплардагы хөтбәләрдә Төркия солтаннары макталып телгә алына», дип фаразлый (*Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 168 б.*). Билгеле булганча, 1516 елның 24 августында Госманлы солтаны I ислам солтаны исемен кабул итә һәм Истамбул хәлифәтен нигезли (*Мухамедьяров Ш. Ислам в Казанском ханстве // Ислам на европейском Востоке: Энциклопедический словарь. Казань: Магариф, 2004. С. 125-127*). Безнең уебызча, Ш.Мәрҗани телгә алган текстлар Идел-Чулман төбәгендә 1552 елдан соң кулланыла башлаган булса кирәк.

Югарыда аталган тәртипләр Алтын Урда таркалгач барлыкка килгән һәм утрак тормыш алып барган барлык ханлыкларга да хас дип әйтергә була. Димәк, мәдәни берлекнең мөһим нигезен Алтын Урда заманында чыңгызлылар, карачыбәкләр, бәк,

әмир, оглан кебек аксөякләр арасында таралган һәм төрки-татар ханлыкларында куәт алган ислам дине тәгълиматы тәшкил иткән. Руханилар һәм суфилар арасында шәхси элемтәләр шактый тотрыклы булган, суфиларның бер төбәктән икенчесенә күчеп йөрүе дәвам иткән дип уйларга нигез бар.

Урта Азия белән даими бәйләнешләрнең ачык мисалы булып Казанда «таҗик сарае» (рус чыганакларында Урта Азия сәүдәгәрләре гадәттә шушы исем белән аталган. – И.З.) булуы һәм анда Көнчыгыштан китерелгән товарларның даими сатылуы күрсәтелә ала. 1552 елда Казанны алгач, калада яшәгән бохарлы сәүдәгәрләрнең шактый күп сандагы балалары һәм хатыннары әсир ителә *(Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства. Казань: Институт истории им.Ш.Марджани, 2012. С.194-195*).

Кайсыбер хакимнәр дә мәдәни бәйләнешләрны көчәйтүгә өлеш керткәннәр. Мәсәлән, Мөхәммәд-Әмин идарә иткән елларда, бигрәк тә, Урта Азия белән аралашу көчле булган. Мондый мөнәсәбәтләрнең даими төс алуының сәбәбе – Мөхәммәд-Әмин һәм үзбәк Мөхәммәд Шәйбани хан арасындагы дуслык. Күренекле тюрколог Зәки Вәлиди Казан ханының 1505 елда Бөек Мәскәү кенәзе гаскәрләрен җиңүенә багышлап Мөхәммәд Шәйбаниның шигырь язуын искәртә. Бабур исә үзенең истәлекләрендә Мөхәммәд Шәйбани ханның Мөхәммәд-Әмин сараена Голәм Шади исемле музыкантны җибәрүе турында хәбәр итә. В.П. Юдин бу шәхеснең Мөхәммәд Шәйбани хан биографиясен теркәгән һәм аның күренекле гамәлләрен мактаучы фарсы телендә язылган «Фатх-намә» авторы булу мөмкинлеген әйтә. Әдәбиятчылар да игътибар иткән – Казан ханлыгының күренекле шагыйрьләре Мөхәммәдьяр һәм Шәриф Хаҗи-Тархани иҗатына чагатай шагыйрьләре әсәрләренең йогынтысы, бәлки, шушы тыгыз элемтәләрнең чагылышы булырга мөмкин *(Мустакимов И.А Еще раз о Казанском ярлыке хана Сахиб-Гирея. С. 34).* Безнең уебызча, ике дәүләт арасындагы мәдәни бәйләнешләр күпкырлы булып, ислам гыйлеме, кулъязма китаплар һәм белем алуны, башка төрле һөнәр ияләрен алмашуны да читләтеп узмаган.

Күрше мөселман дәүләтләре һәм төбәкләре белән мәдәни бәйләнешләр дәвам итүнең тагын бер дәлиле булып, «Зафәрнамә-и вилайәт-и Казан» («Казан вилайәтенең җиңүе») исемле әсәрнең авторы – Шәриф Хаҗи-Тархани тәхәллүсен йөрткән шагыйрьнең – чыгышы белән Әстерхан ханлыгыннан булуы һәм аның өчен Казан иленең ватанына әверелү факты тора. «Шәриф Хаҗи-Тархани» тәхәллүсен Колшәриф сәедкә нисбәт итәләр. Шул рәвешле, сәедләр, чыңгызлылар кебек үк, Алтын Урда кыйпылчыгы булган татар дәүләтенең берсеннән икенчесенә күченеп йөргән.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

*Бари Рәхмәтнең тууына – 125 ел*

# МОГҖИЗА ТУДЫРГАН ӘДИП



Бу язмага күз салучылар арасында «Укыйсым килә», «Зәңгәр күл», «Ялкау, Иренчәк һәм Кире», «Сара мәктәпкә бара» кебек шигырь китапларын укып үсмәгән кеше юктыр. Булырга мөмкин дә түгел, чөнки яңа гасырга килеп кергәнче диярлек шушы китапларның авторы Бари Рәхмәт балалар арасында иң популяр шагыйрьләрнең берсе булды. Хәер, акыллы кеше әле хәзер дә баласына, оныгына аның китапларын алып кайта, чөнки шагыйрьнең шигырьләрендә бала күңеле белән генә сизеп була торган ниндидер бер могҗиза бар.

Татарстан язучылар берлеге сайтында урын алган мәкаләдән күренгәнчә, шагыйрь Бари Рәхмәт (Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин) 1897 елның 29 маенда Россиянең элекке Урал губернасы Гурьев өязе (хәзерге Казакъстан Республикасы биләмәсе) Жилая Коса дигән авылда мулла гаиләсендә туып-үсә. Башлангыч белемне бистәдәге татар мәдрәсәсендә ала.

1918 елда исеме таныла башлаган яшь шагыйрь гаскәри хезмәткә алына, шул елларда татар матбугаты белән хезмәттәшлек итә. Армиядән кайткач, туган ягында яши, әмма әдәбиятка булган мәхәббәт аны гел татар мәдәниятенең мәркәзенә тартып тора. 1932 елда ул гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Төзү трестларының берсендә озак еллар гади эшче, соңыннан хисапчы булып эшли. 1939 елдан башлап, көндәлек матбугатта лирик һәм сатирик шигырьләре белән аның исеме яңадан күренә башлый.

1942–1945 елларда Бари Рәхмәт фронтта була, Украина, Молдова, Болгария, Венгрия җирләрен азат итүдә катнаша, яралана. Фронт шартларында да ул шигырьләр язуын дәвам иттерә.


Илленче еллардан башлап, Б.Рәхмәт үзенең иҗатын яшь буынның рухи дөньясын баету һәм савыктыру эшенә, балалар поэзиясенә багышлый. 1950–1957 елларда аның балалар өчен язылган алты җыентыгы басылып, Б.Рәхмәт тиз арада татар балаларының иң яратып укый торган язучыларыннан берсенә әверелә. Шагыйрьнең үзе исән чагында нәниләргә атап язылган шигырьләре тупланган дистәдән артык исемдә китаплары басылып чыга.

Татарстан радиосы Бари Рәхмәтнең (1897–1957) тууына 125 ел тулу уңаеннан берничә тапшыру әзерләде. Шуларның берсе «Казан утлары» журналы сайтында да урын алды. Бу – журналист Дания Гайнетдинова тарафыннан әзерләнгән «Язучылар – балаларга» тапшыруы.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

*Әмир Мәхмүдовның тууына – 75 ел*

# РУХЫ БЕЛӘН УЛ КӨРӘШЧЕ ИДЕ



Шагыйрь, әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, җәмәгать эшлеклесе Әмир Гобәй улы Мәхмүдовның (1947–2018) тууына 75 ел.

Әдипнең гомер һәм иҗат юлына багышланган белешмәлекләрдә бәян ителгәнчә, ул 1947 елның 28 июнендә Башкортстанның Әлшәй районы Габдрәшит авылында дөньяга килә, урта мәктәпне тәмамлагач, Бөре дәүләт педагогия институтының рус филологиясе бүлегендә югары белем ала. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайта, 1970–1973 елларда Мәскәүдә Н.К. Крупская исемендәге педагогия институты каршындагы аспирантурада укый һәм, М.Җәлил иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләре турында фәнни хезмәт язып, диссертация яклый.

1974–1981 елларда Ә.Мәхмүдов СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1981 елның көзеннән ул – Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты.

Ә.Мәхмүдовның беренче шигырьләре 1963 елда район газетасында басылып чыга. Шуннан бирле шигъри әсәрләре белән Башкортстан һәм Татарстанның республика матбугатында, аннан соң русча тәрҗемәдә үзәктәге газета-журналларда даими катнашып килә.

1972 елдан башлап, Ә.Мәхмүдов әдәби тәнкыйть, әдәбият белеме өлкәсендә дә актив эшли. Аның М.Җәлил, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Камал, К.Насыйри кебек классик язучылар иҗатына багышланган аерым мәкаләләре, ана теленнән тыш, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә дә басылып чыга. «Матурлык тантанасы» (1983), «Мәңгелек моң» (1987) шигырь китаплары авторы.

Әмир Мәхмүдов халык хәтеренә туган телебезне саклау, милли аңыбызны уяту өчен янып йөргән җәмәгать эшлеклесе буларак та кереп калды.

Аның «Суверенитет» газетасында баш мөхәррир (1991–1995), бер үк вакытта Татарстанның «Суверенитет» комитеты координацион советы рәисе булып эшләгән елларында үз-үзен аямыйча башкарган фидакарь хезмәтен рәхмәт белән искә алырга тиешбез. Әмир Мәхмүдов киләчәккә зур өметләр баглап яшәде, шул өметләрнең җимерелү ачысы аның бәгырен теткәләде. Бу дөньядан иртәрәк китеп баруына, мөгаен, менә шул сәбәпче булгандыр да. Аның әле янып эшли, янып яза торган чаклары иде...

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган аудиоязмада сез Әмир Мәхмүдовның тавышын ишетерсез. Эдуард Мостафинның тууына 70 ел тулуга багышланган әлеге тапшыруда ул шагыйрь иҗатының үзенчәлекләрен, аның әдәбиятта тоткан урынын ачып бирә. Әдипнең якты рухын искә алып тыңлыйк.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimağí-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ОЛЫ БӘЙРӘМ

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы белән котлау юлладылар. Әлеге вакыйга уңаеннан Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты, «Russia Halal Expo» халыкара күргәзмәсе, Бөтенроссия татар дин әһелләре җыены, Җәмигъ мәчете төзелеше башлану хөрмәтенә истәлек ташы кую тантанасы, Болгар музей-тыюлыгында «Изге Болгар җыены», Коръән уку бәйгесе һ.б. чаралар үткәрелде.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов шагыйрьнең Казан үзәгендә Тукай скверындагы һәйкәленә чәчәк салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев, республикабызның җәмәгатьчелек вәкилләре, язучылар, галимнәр, мәдәният-сәнгать эшлеклеләре, башкалабыз кунаклары, студентлар, укучылар катнашты.

***

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Туган тел көненә һәм Г.Тукайның тууына 136 ел тулуга багышланган тантана булды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары – декоратив-гамәли сәнгать остасы Анатолий Егоровка һәм язучы Ләбиб Леронга диплом, күкрәк билгесе тапшырды. Аннары республикабыз сәнгать осталары концерты булды.

***

Габдулла Тукайның туган көнендә шагыйрьнең Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле янында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатларын игълан итте. Бәйрәмдә шагыйрьләр, шул исәптән «Казан утлары» журналының 100 еллык юбилее уңаеннан чакырылган кунаклар Маркабай Ааматов (Кыргыз Республикасы), Сәят Камшыгер (Казакъстан), Илгар Төркуглы (Азәрбайҗан), Әскәр Додуев (Кабарда-Балкар), җырчылар катнашты. Шигъри митингны Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ алып барды.

***

Г.Тукайның тууына 136 ел тулу уңаеннан бер төркем язучылар катнашында чаралар Арча һәм Балтач районнарында да үткәрелде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 100 ЕЛ

«Казан утлары»ның 100 еллыгын зурлап билгеләп үтәргә насыйп булды. Шушы күркәм вакыйга уңаеннан Г.Камал театрында әдәби-музыкаль кичә узды. Анда журналыбызны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов котлады. Ул редакциябезгә ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатларын тапшырды. Котлауларны журналыбызның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин кабул итеп алды. Аннары сәхнәне татар җыр һәм нәфис сүз сәнгате осталары тотты. Кич буена Рәсим Ильясов җитәкчелегендә «Казан нуры» оркестры уйнады. Бәйрәмне Идел Кыямов белән Айзилә Батырханова алып бардылар.

***

ТР Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигы, дәүләт эшлеклесе, «Казан утлары» журналын дөньяга чыгаруның башында торган Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулу уңаеннан фәнни-гамәли конференция узды. «Галимҗан Ибраһимов һәм XX-XXI гасырлар татар белеме» дип аталган бу чарада Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан мәмләкәтләреннән, Россиянең Мәскәү, Казан, Уфа, Ижевск, Якутск һ.б. шәһәрләреннән галимнәр, язучылар катнашты.

***

«Казан утлары»ның юбилее уңаеннан Казандагы Татар китабы йортында басмабызның 100 еллык тарихына багышланган «Ядкарьләрдә – рухи йөзебез» дигән күргәзмә дә ачылды. Анда, нигездә, ТР Милли музее фондында, «Казан утлары» редакциясендә сакланган экспонатлар

куелды. Витриналарда – журналның төрле илләрдәге төпләмәләре, татар әдипләренең, журнал хезмәткәрләренең тарихи фоторәсемнәре, хатлары, документлары, шәхси әйберләре.

«Казан утлары» журналының 100 еллыгы уңае белән үткәрелгән чараларда, шул исәптән юбилей хөрмәтенә үткәрелгән Ифтар ашында бәйрәмгә килгән бер төркем кунаклар – Кыргыз Республикасы Язучылар берлегенең «Ала-Тоо» журналы баш мөхәррире, Кыргыз Республикасының халык шагыйре Маркабай Ааматов, Казакъстан Республикасы «Алтын сака» нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Сәят Камшыгер, Азәрбайҗан Республикасының «Интеллектуаль хокук үзәге» директоры Илгар Төркуглы, Кабарда-Балкар Республикасы «Мәңге Тау» журналының баш мөхәррире, Карачай Республикасының халык шагыйре Әскәр Додуев, Саха (Якутия) Республикасы «Чолбон» журналының баш мөхәррире Гаврил Андросов, Башкортстан Республикасы «Шоңкар» журналының баш мөхәррире, язучы Айгиз Баймөхәммәтов һ.б. катнашты.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Казанның Татарстан урамындагы шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) яшәгән 7 нче йорт диварына истәлек тактасы куелды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фондының башкарма директоры Нурия Һашимова, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров, язучылар Ләбиб Лерон, Фәтхулла Абдуллин, шагыйрә Лилия Садриева, Мөслим районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Марина Бәдретдинова, әдипнең кызы Кадрия Хәлилова һ.б. чыгыш ясадылар. Тантананы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды. Шул ук көнне кич Г.Камал театрында шагыйрь Зөлфәтнең тууына 75 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

***

Казандагы К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә 60 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы Рәдиф Сәгъди, режиссёры Зөфәр Харисов) булып узды. Кичәдә юбилярны ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, бәйрәмдарның каләмдәш дусты Газинур Морат, сабакташлары, якташлары һ.б. котлады, Тинчурин театры артистлары әдипнең «Кыргын» хикәясенә нигезләнгән тарихи тамаша күрсәтте.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь, прозаик, драматург Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш, Ш.Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты Рафис Корбанга 65 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә бәйрәмдарның шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Р.Корбанны каләмдәшләре, Кыргыз, Казакъстан, Азәрбайҗан, Кабарда-Балкар, Саха (Якутия), Башкортстан республикаларыннан килгән язучылар, якташлары, дуслары котлады.

### БӘЙГЕ

Кукмара районы, Зур Сәрдек авылының Камил Шакиров исемендәге гимназиясендә якташлары, шагыйрь, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Газинур Моратның шигырьләрен сәнгатьле уку буенча укытучылар һәм укучылар арасында районкүләм бәйге уздырылды. Конкурста катнашучыларның чыгышына Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, журналист Габделбәр Ризванов, район мәгариф идарәсе башлыгы Илфат Әхмәдуллин һәм автор үзе бәя бирде. Чараны Зур Сәрдек гимназиясе директоры урынбасары Гөлсинә Зыятдинова алып барды.

### ШӘЛЕДӘ «ШӘЙ БУ-ШАЙБУ»

Язучы Камил Кәримов (пьеса авторы), Г.Кариев театрының баш режиссёры Ренат Әюпов (әсәрне сәхнәгә куючы) «Шәй бу-Шайбу» спектаклен Шәлегә алып кайтып, авылдашларын сөендерделәр. Тамаша алдыннан ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев, Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов чыгыш ясадылар.

### «КАЗАН УТЛАРЫ» ТУРЫНДА

«ТАТМЕДИА» АҖнең утырышлар залында «Казан утлары» журналы турында сөйләшү булды. Анда әдәбият галиме, язучы Тәлгат Галиуллин басманың соңгы өч елда чыккан саннарына күзәтү ясады. Сөйләшүне «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры Шамил Садыйков алып барды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести М.АМИРХАНОВА «Ататуш», Р.ШАГИЕВА «Аиша-Фатима», В.ГАЛИ «Последнее путешествие»; поэма Р.КУРБАН;*
*стихи Ф.ГИЛЯЗОВА, Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ, Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ, Г.САБИРОВОЙ.*
*Литературный конкурс «Майдан – для батыров»: рассказ З.ГИМАЕВА «Борец».*
*«Литература родственных народов»: отрывок из повести Н.ЛУГИНОВА «Хуннские повести» в переводе Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.*
*«Память»: статья Р.ЮСУПОВА к 85-летию Ф.Зиятдинова.*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 125-летию Б.Рахмата и 75-летию А.Махмудова.*
*Рубрику ведет Н.АКМАЛ.*
*Фотоархив журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: дом Ушковой со стороны садика Лобачевского. Фото И.Абрамовой.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: stories by M.AMIRKHANOV «Atatush», R.SHAGIEV «Aisha-Fatima», V.GALI «The Last Journey»; poem by R.KURBAN;*
*poems by F.GILYAZOV, E.SHARIFULLINA, S.ZIGANGIROVA, G.SABIROVA.*
*Literary contest «Maidan is for batyrs»: story by Z.GIMAYEV «Wrestler».*
*«Literature of kindred peoples»: excerpt from story by N.LUGINOV «The Hunnic Tales» translated by F.ZAMALETDINOVA.*
*«Memory»: article by R.YUSUPOV on the 85th anniversary of F.Ziyatdinov.*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Priceless voices»: articles for the 125th anniversary of B.Rakhmat and the 75th anniversary of A.Makhmudov.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Photo archive of the journal.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Ushkova house from the Lobachevsky garden. Photo by I.Abramova.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә: Ушкова йорты Лобачевский бакчасы ягыннан.*
*Ирина Абрамова фотосы.*